

# КАЗАН УТЛАРЫ

12.1987



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

12

1987

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

КАЗАН СТУДЕНТЛАРЫНЫҢ В. И. УЛЬЯНОВ-ЛЕНИН КАТНАШЫНДА УЗГАН СХОДКАСЫНА — 100 ЕЛ

Р. НИЗАМИЕВ. **1887 ел, 4 декабрь.** *Шигырь* . . . 3
Р. НӘФИКОВ. **Сходкага катнашучыларның язмышы** . . . 4
В. ЖУКОВ. **Кокушкинода, 27 август көнне** . . . 11

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

В. ШУГАЕВ. **Соңга калган яңгыр.** *Повесть* . . . 17
М. ХУҖИН. **Урак өсте болытлары.** *Повесть* . . . 40

ӘХСӘН БАЯНОВКА 60 ЯШЬ

Ә. БАЯНОВ. **Алтын кашбау.** *Шигъри трагедия* 84
А. ХӘСӘНОВ. **Кадерле көндәш.** *Хикәя* . . . 126

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

М. МУСИН. **Ике новелла** . . . 137
Р. ШӘРИПОВ. **«Оштарма» көе.** *Шигырьләр* . . . 141

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

А. Н. ХӘЙРУЛЛОВ. **Зөя буе йолдызлары** *(Апас районы)* . . . 143

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

Х. БӘДРЕТДИНОВ. **Төеннәрне чишкәндә** . . . 147
**Безгә ничек хезмәт күрсәтәләр?** . . . 154

МӨСӘГЫЙТ ХӘБИБУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. **Изге ният белән** . . . 157
М. НАСЫЙБУЛЛИН. **Дуслык көче** . . . 162

БИБЛИОГРАФИЯ

Ф. БӘШИРОВ. **Тарих үзе шаһит** . . . 165

*Баш редактор*

**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**

**ӘХӘТ ГАФФАР**

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**

**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**

**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**

**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**

**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*

**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**

**ФЛҮН МУСИН**

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*

**РӘФЫЙК НӘФЫЙКОВ**

**ҮУРИХАН ФӘТТАХ**

**РИЗВАН ХӘМИД**

**НИЛ ЮЗИЕВ**

**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,

*бүлекләр:*

проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

ОРЕНБУРГТА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

**А. ТИМЕРГАЛИНА. Риза Фәхретдиневкә мемориаль такта куелган йорт** . . . . . . . 168
**Җ. МИҢНУЛЛИН. Риза Фәхретдинев Оренбургта** . . . . . . . . . . . . . . . 169

**Күренекле әдип, галим һәм җәмәгать эшлеклесе** 170

ШИҺАП РАМАЗАНОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

**Г. ӘБҮБӘКЕРОВ. Мәгариф каһарманы** . . . . 179

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . . 183

**1987 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге** . . . . . . . . . 186

**Китаплар дөньясында** . . . . . . . . . . . 191

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

К 100-летию сходки Казанских студентов с участием В. И. Ульянова-Ленина: статьи Р. НАФИГОВА «Судьбы участников сходки», В. ЖУКОВА «27-го августа в Кокушкино», стихотворение Р. НИЗАМИЕВА «4 декабря 1887 года».

В рубрике «Дружба литератур — дружба народов»: повесть В. ШУГАЕВА «Запоздалая дождь».

М. ХУЗИН. «Облака страдной поры». Повесть. А. БАЯНОВ. «Золотой кашбау». Поэтическая трагедия. Рассказ А. ХАСАНОВА «Добрая соперница», новеллы М. МУСИНА, стихи Р. ШАРИПОВА.

«Татарстан — родной мой край»: выступление первого секретаря Апастовского райкома КПСС А. Н. ХАЙРУЛЛОВА.

«Литературный пост — АЭС»: очерк Х. БАДРУТДИНОВА.

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. «С добрыми намерениями» (литературный портрет М. Хабибуллина).

Статья М. НАСЫБУЛЛИНА о культурных взаимосвязях киргизского и татарского народов.

«Библиография»: рецензия на книгу А. ШАМОВА «Настоящие рассказы».

«Памятники культуры в Оренбурге»: Р. Фахретдинов в Оренбурге.

Слово о Галимзяне Ибрагимове: выступления Ю. И. СУРОВЦЕВА, М. М. КОЛОСОВА, В. Г. ГРИМИЧ, П. К. КАДЫРОВА, К. К. ТУРСУНКУЛОВА, А. М. МИРЗАГИТОВА и Т. А. МИННУЛЛИНА.

К 100-летию Ш. Рамазанова статья Г. АБУБАКИРОВА.

Содержание журнала «Казан утлары» за 1987 год.

На наших обложках: репродукция с картины Х. ЯКУПОВА «Пролог» и памятник студенту Володе Ульянову в Казани.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.*

Производствога бирелде 02.10.1987 ел. Басарга кул куелды 23.11.1987 ел. ПФ 05420. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 66849. Заказ М-436. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1987 ел.

*Казан студентларының В. И. Ульянов-Ленин катнашында узган сходкасына — 100 ел*

## Рашат Низамиев

### 1887 ел, 4 декабрь

Малайлыктан кырыс егетлеккә
Кереп кенә барган чаклары.
— Сходкага!
Шушы нәни бер сүз
Россияне салыр актарып...

Үзгәрергә уйламый да тормыш,
Баш орсаң да урам ташына.
Яшәп килгән иске тәртипләрне
Әйдә, долой, чүплек башына!

Йодрык булып йомарланды яшьлек:
Кемгә, нәрсә өчен сугарга?
Казан университеты шәкертләре
Җавап эзли бүген шуңарга.

Камчы кысып тоткан жандармның
Кулларына суык үрмәли...
Россиянең мондый бердәмлекне
Юктыр әле, юктыр күргәне,—

Яшь булса да, яшел түгел болар,
Йодрык чөеп сафка бастылар.
Ишек бикле... Залның ишекләрен
Төбенәчә каерып ачтылар!

Яңакларга кирәк искелекне,
Яңакларга — хурлау сүзләрен:
Инспектор Потаповның әнә
Сакалында — шуның эзләре...

Килер бер көн: илнең кырларында
Нәфрәт арты нәфрәт туачак.
Потаповка күтәрелгән йодрык
Тәхетләргә китереп сугачак!

Володяның күзләрендә — очкын,
Еллар аша дөрләр ул янып.
Зур көрәшләр уртасына таба
Кереп бара япь-яшь Ульянов.

«Сходкага!» Бу сүз яшен кебек.
«Сходкага!» Бу сүз — динамит...
Илне, җирне имин саклар өчен
Без дә шулай бердәм җыйналыйк!

**Рэфыйк Нэфиков,**
тарих фәннәре докторы, профессор

# СХОДКАГА КАТНАШУЧЫЛАРНЫҢ ЯЗМЫШЫ

Казан университетында 1887 елның 4(16) декабрендә булып узган сходкада катнашкан барлык студентларның да тормыш юллары әлегә кадәр ачыкланып җитмәгән. Бу юнәлештә алып барган эзләнүләребез (хәзер инде йөзләгән студентның биографиясе ачыкланды) сходкада катнашучыларның күпчелеге яшьлек идеалларына тугрылыклы калган, көрәшне дәвам иттергән дигән нәтиҗә ясарга нигез бирә. Аларның бер өлеше большевиклар партиясе сафларына баса. Бик күпләре озак еллар буе полиция күзәтүе астында яши. Еллар үтү белән, аларның балалары, үсеп җитеп, самодержавиегә каршы көрәшүчеләр рәтенә баса.

Сходкага катнашучыларның язмышларын ачыклау В. И. Ленинның студент елларындагы даирәсе турында төплерәк фикер йөртергә мөмкинлек бирә; дәверләрнең җанлы бәйләнешен, патриотизмның, халыклар дуслыгының тирән тамырларын ачыкларга, интернационалистлар тәрбияләргә ярдәм итә.

Мемуар әдәбиятта, «Каторга и ссылка», «Пути революции», «Пролетарская революция», «Красная летопись» һәм башка журналларда какшамас революционерлар турында бик күп мәгълүмат теркәлгән. Шулай ук «Россиядәге революцион хәрәкәт эшлеклеләре» исемле библиографик сүзлек өчен дә беренче социал-демократлар хакында төрле характердагы күпсанлы материал туплана.

Егерменче елларда Казанда 1887 елгы сходка тарихын өйрәнүне А. Аросев һәм М. Корбут кебек тикшеренүчеләр башлап җибәрә. Алар туплаган биографик мәгълүматлар бик үк тулы булмасалар да, бүгенгә кадәр үзләренең әһәмиятләрен югалтмаганнар. Кызганычка каршы, бу юнәлештә тикшерү, эзләнү эшләре бөтенләй үк тукталып тормаса да, озак еллар буе матбугат битләрендә киң чагылыш тапты дип әйтеп булмый.

Тикшеренүләрдә сыйфат ягыннан яңа этап КПССның XX съездыннан соң башланды. Журналист А. Старков публикацияләре игътибарга лаек. Ул, зур тырышлык куеп, 1887 елның 4(16) декабрендә Казан университетында булган сходкада катнашучы М. С. Дударь[1] һәм аның Зеленодольскида яшәүче улы турында архив чыганакларына нигезләнеп һәм башка тикшеренүчеләр булышлыгы белән бай фактик материал туплый («Огонек», 1968, № 5). А. Старков бертуган Николай һәм Иосиф Зегржда турында да дулкынландыргыч мөһим фактлар ачыклый, аларның Ленинградта яшәүче варисларын эзләп таба. Н. Зегржданың Октябрь революциясеннән соң В. И. Ленин белән очрашуы да билгеле булды. Авторның күп миллионлы укучыларга мөрәҗәгатенә һәм публикациясенә җавап рәвешендә матбугатта төрле язмалар күренә башлады. Чөнки журналда В. И. Ульянов-Ленин белән бергә университеттан чыгарылган 35 студентның фамилиясе аталган иде.

«Арохчапаутюн» исемле әрмән журналында А. Г. Закарьян сходкада катнашкан Ф. Фармановның тормыш юлын яктырткан мәкалә бастырды (1970, 2 сан.). Ф. Фарманов соңыннан большевиклар партиясе сафларына керә, Хезмәт батыры исеменә лаек була.

---

[1] Революционер Н. М. Дударьның кызы 1919 елда сугышларда яраланган В. И. Чуйковны дәвалап аякка бастыра («Правда», 1977, 21 апрель).

1944 елгача, ягъни тормышының соңгы көннәренәчә ул Н. Г. Чернышевскийның секретаре К. М. Федоров белән дуслык мөнәсәбәтләрен өзми (бездә аларның бергәләп төшкән фоторәсеме бар).

Монда тарихчылар өчен уйланырлык урын бар: казанлыларның бөек революцион демократ белән элемтәләре, һәм шулай ук В. И. Ленинның Чернышевский белән хәбәрләшергә тырышуы да бәлки Казан университетына кучкәнче Петербургта А. И. Ульянов белән бер бүлектә укыган, Н. Г. Чернышевский даирәсенә якын булган әстерханлы Ф. Фарманов аша баргандыр.

Казан дәүләт университетының КПСС тарихы кафедрасында Лениниананың, шул җөмләдән сходкада катнашучыларның биографияләрен өйрәнү эше егерме биш елдан артык системалы рәвештә алып барыла. «Казан университеты студентларының 1887 ел, 4 декабрь сходкасы тарихын өйрәнүгә карата» дигән мәкалә 1967 елда дөнья күргән иде[2]. Профессор Д. И. Фельдман редакциясендә рус телендә басылып чыккан «Ленин укыган факультет» (1970) исемле коллектив очерклар җыентыгы әнә шул эшнең дәвамы булып тора. Бу тема безнең тарафтан язылган «Революциягә беренче адым» (1970), «Революцион подполье серләре» (1981), «Һәм инанган марксист булды» (1985) исемле монографияләрдә һәм мәкаләләрдә дә чагылыш тапты.

Эзләнүләргә Уфадагы Галанов исемендәге мәктәп укытучылары һәм укучылары кушылды. Алар Уфа гимназиясен тәмамлап, Казан университетына кергән һәм сходкада катнашкан дистәләрчә студентның язмышын ачыкладылар.

Красноярскидан краевед И. Лалетин сходкада катнашкан һәм 1948 елда 80 яшендә вафат булган туфрак белгече, профессор А. А. Яриловның тормыш юлы турында «Правда» газетасы (1977, 2 март) битләрендә язып чыкты. Григорий Хаитның 1970 елда Красноярскида басылып чыккан «Эзләнү дәвам итә» исемле китабы 1933 елдан Коммунистлар партиясе члены, И. М. Губкин, А. Е. Ферсман, А. П. Карпинскийлар белән берлектә илебездәге җитештерүче көчләрне өйрәнгән шушы галимгә багышланган.

Пенза журналисты О. Савин сходкага катнашкан М. М. Корнильевның тормыш юлы турында документаль очерк бастырып чыгарды («Советская Татария», 1970, 7 октябрь). М. М. Корнильев соңрак Сызрань-Вязьма тимер юлы мастерскойлары, Сергеевның кәгазь фабрикасы һәм Крюгерның машина төзү заводы эшчеләре, шулай ук укучы яшьләр арасында социалистик пропаганда алып бара. Ул сүргендә вафат була. Октябрь революциясеннән соң аның хатынына В. И. Ленин күрсәтмәсе буенча пенсия билгеләнә. Революционерның балалары патриотлар булып үсәләр, илебездә социалистик җәмгыять төзүдә һәм Бөек Ватан сугышында актив катнашалар.

Иваново өлкәсе, Савиново район газетасы «Знамя»ның партия тормышы бүлеге мөдире Ю. М. Лапин 1972 елның 29 ноябрендә безгә сходкага катнашкан А. Н. Огородников турында хәбәр итте. Казан университетының элеккеге студенты 1902 елдан ук РСДРПның Владимир шәһәр комитеты белән бәйләнеш тота, Россиядәге беренче буржуаз-демократик революция чорында прокламацияләр тарата, 1905 елда Мәскәүдәге кораллы восстаниедә катнаша. Октябрь революциясе үзәк дәүләт архивының бүлек начальнигы Роговая кул куйган документта земство врачы булып эшләгән һәм полициянең яшерен күзәтүендә торган А. Н. Огородниковның В. И. Ленин белән элемтәдә булу мөмкинлеге дә фараз ителә.

Сходкага катнашкан тагын ике кешенең язмышы хакында без Ленинградтагы Хәрби медицина академиясендә нерв авырулары кафедрасы өлкән фәнни хезмәткәре булып эшләүче медицина фәннәре кандидаты А. Е. Архангельский хатыннан белдек. Бу кафедра академик В. М. Бехтеревның шәкерте һәм хезмәттәше, Хәрби медицина академиясендә нерв авырулары кафедрасына нигез салучы һәм аның беренче начальнигы, күренекле невропатолог, профессор Михаил Николаевич Жуковскийның (1868—1916) биографиясен өйрәнү белән шөгыльләнә. Оныгының әйтүенчә, М. Н. Жуковский 1887 елның декабрендәге студентлар чуалышында катнашкан һәм аның «В. И. Ленин белән таныш булуы да ихтимал».

Бу кафедра тарихы өчен икенче бер галим, сүргенгә җибәрелгән поляк егете, Бронислав Иванович Воротынский (1865—1925) исеме дә игътибарга лаек. 1890 елны ул Казанда, нерв һәм акылы зәгыйфьләнгән авырулар клиникасында ассистент итеп калдырыла; соңыннан приват-доцент дәрәҗәсенә ирешә, Томск һәм Одесса университетларында укыта. Совет власте елларында Б. И. Воротынский Симферополь медицина институтында ике кафедрага җитәкчелек итә.

[2] Вопросы историографии и источниковедения. Сб. 2. (Уч. записки КГПИ). Казань, 1967, 49—62 бб.

Бүгенгә без Ленинградтагы коллегаларыбызга М. Н. Жуковский һәм Б. И. Воротынскийларның студент елларында төшкән фоторәсемнәрен һәм аларның сходкада катнашуларын документлар нигезендә раслау белән генә ярдәм итә алдык. Бу мәсьәләдә әлегә чишелмәгән «төеннәр» дә калды. Мәсәлән, архив документларына караганда, сходкадан соң М. Н. Жуковский карцерда утыра...

1986 елда Ленинградта Г. А. Акимов һәм А. Е. Архангельскийның «Михаил Николаевич Жуковский» исемле брошюрасы дөнья күрде. Анда В. И. Ульянов-Ленинның беренче революцион чыгышлары буенча көрәштәше М. Н. Жуковскийның тормыш юлы бик тәфсилле яктыртылган. 1911 елның җәендә М. Н. Жуковскийның авыруларны дәвалау белән танышу йөзеннән Кырым һәм Кавказда, шулай ук Пятигорскида өч айлык махсус сәфәрдә булуы факты безнең игътибарны җәлеп итте. Пятигорскида аның Казан университетында бергә укыган һәм сходкада катнашкан врач Ф. Бочков белән очрашкан булуы бик мөмкин.

Сходкада катнашучылар турындагы мондый хезмәтләр киләчәктә бу юнәлештә эзләнүне тагын да тирәнәйтергә, әлегә кадәр билгесез кызыклы фактларны табарга ярдәм итә.

Сходкада очраклы кешеләр катнашмаган, әлбәттә. Алар чын дуслар, фикердәшләр. Еллар үтү белән, дуслык хисләре сүнмәгән дә, сүрелмәгән дә. Яшьлек идеалларына тугры калган хәлдә, алар самодержавиегә каршы көрәшне төрле юнәлешләрдә дәвам итәләр. Бу мәсьәләне өйрәнү шул чорны яхшырак аңларга, В. И. Ленинның даирәсен киң күзалларга, студент яшьләрнең көрәшен һәм тормыш шартларын тирәнрәк төшенергә мөкинлек бирә.

Эзләнүне дәвам иттерергә кирәклеге бәхәссез. Сходкада катнашучыларның варисларында бу күренекле вакыйгага кагылышлы документлар, кульъязмалар, хатлар, фоторәсемнәр саклануы, арада В. И. Ленинга бәйле мәгълүматлар да теркәлгән булуы ихтимал.

Алма-Ата тарихчысы В. З. Галиев «Сөргенгә җибәрелгән революционерларның Казахстанда медицина өлкәсендәге эшчәнлеге» (1982) исемле китабында XIX гасырның икенче яртысында врачларның казах далаларында алып барган фидакарь эшчәнлеге турында архив документларын укучылар хөкеменә тапшыра. Царизм тарафыннан милли төбәкләргә сөрелгән революционерларга һәм шулай ук мохтаҗларга ярдәм итү өчен үз теләкләре белән килгәннәргә коточкыч фәкыйрьлек, ачлык, ваба, тиф йоктыру куркынычы шартларында эшләргә туры килә. Алар барлык мохтаҗларны, авыруларны аякка бастыра алмасалар да, яңа туган балаларның бер өлешен булса да саклап калдылар. Һәм бу хезмәт иясе халкы өчен самодержавиегә каршы көрәшнең бер формасы иде. Шушы эшчәнлекләре белән врачлар массаларга царизмның череклеген, аның халыкка каршы характерын ачып салалар. Авырулар өчен үзен-үзе аямыйча алып барган бу тигезсез көрәштә булачак полководец, Гражданнар сугышы герое М. В. Фрунзеның әтисе В. М. Фрунзе һәлак була.

Китапның берничә сәхифәсе Казан университетын тәмамлаган врачларның Казахстандагы эшчәнлеген яктыртуга багышланган. Арада иҗтимагый эшчәнлекләрен В. И. Ульянов-Ленин белән бергә сходкада башлаганнары да бар: П. Ф. Матвеев, И. Лангор һ. б. М. В. Фрунзеның әтисе нәкъ менә П. Ф. Матвеев белән бергә эшләгән була. Врач П. В. Добровольский Н. Е. Федосеевның марксистик түгәрәге эшендә актив катнашкан.

Казан университетын тәмамлаган беренче казах врачларыннан М. Карабаев, Казандагы революцион подполье эшендә катнашкан, соңрак Харьковтагы эшчеләр түгәрәгенә җитәкчелек иткән Д. Д. Бекарюков та Казахстанда эшләгәннәр. В. З. Галиев монографиясендә игътибарга лаек башка мәсьәләләр дә куела. Аларны тикшерү, өйрәнү — киләчәк эше.

Кайчакта без тикшерә торган темага кагылышлы мәгълүматлар һич көтелмәгән җирләрдән, беренче карашка бу мәсьәләгә турыдан-туры бәйләнеше булмаган проблемаларны өйрәнгәндә дә табыла. Алма-Ата пионерлары һәм комсомолларының «Эзләнү» хәрби-патриотик клубы Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тормыш һәм сугышчан юлларын өйрәнә. Клуб членнары 19 яшендә акгвардиячеләргә каршы көрәштә һәлак булган Викторның — 1887 елгы сходкага катнашкан П. И. Станов улының язмышын ачыкладылар. Шуннан соң аның туганнары белән хат алышу башланды. П. И. Становның кызы — Ольга Павловна Станова-Екимова 43 ел производствода эшли, КПСС члены, хезмәт ветераны, Казан университетын тәмамлаган улы белән Алма-Атада яши. Икенче кызы Вера Павловна — шулай ук КПСС члены, хәзер Новосибирскида тора.

О. П. Екимова безгә әтисенең 1887 елда һәм һәлак булган ир туганының 1916 һәм 1918 елларда төшкән фоторәсемнәренең күчермәләрен җибәрде. Октябрь революциясенә кадәрге бөтен гомере буе диярлек П. И. Станов полициянең яшерен күзәтүе астында яши, аңа, хәтта, иптәшләре белән хат алышу да тыелган була. Полиция тарафыннан ышанычсыз дип саналган кешегә туган шәһәре Бийскида гына түгел, башка шәһәрләрдә дә (Ачинскида,

Усть-Каменогорскида, Семипалатинскида) эш табуы бик кыен була. Шуңа күрә вакытлыча күчереп язучы, конторщик ярдәмчесе, акциоз ведомствосында контролер булып эшләргә туры килә аңа. 1928 елда пенсиягә киткәнче, ул шәһәр финанс бүлегендә инспектор булып эшли һәм 1930 елның 13 ноябрендә вафат була. Гомере буе ул медицинага мәхәббәт саклый, дару үләннәре җыя, авыруларга кулыннан килгән кадәр ярдәм күрсәтә. Балаларына еш кына сходка турында истәлекләр сөйли, аларны социализм эшенә бирелгән ватандарлар итеп тәрбияли.

Сходкага катнашкан Н. А. Мотовилов биографиясе дә махсус очерк таләп итә. Ул җитәкләгән һәм жандармнар «үтә зарарлы» дип санаган түгәрәктә В. И. Ульянов-Ленинның катнашуы — билгеле факт. Н. А. Мотовилов Н. Е. Федосеев белән дустанә мөнәсәбәттә торган, Казаннан китәргә туры килгәч тә, аның белән хат алышкан. Соңыннан Н. А. Мотовилов Ростов-Дон шәһәрендәге эшчеләр түгәрәген җитәкли (бу турыда КПСС тарихының беренче томында искә алып үтелә), Харьковтагы эшчеләр түгәрәге белән бәйләнешкә керә, Казаннан куылгач Тарту университетына кергән студентлар белән элемтә урнаштыра[3]. Краснодарда һәм Новороссийскида марксистик түгәрәкләр барлыкка килүдә дә Н. А. Мотовиловның роле зур. Ул гомере буе самодержавиегә каршы көрәшә һәм Бөек Октябрь революциясен шатланып каршы ала. Сходкада, Н. А. Мотовилов белән янәшәдә А. Скворцов та була. Соңыннан ул большевиклар партиясе сафларына керә. Бөек Ватан сугышы алдыннан Урта Азиядә яши һәм эшли. Аның биографиясе әле тикшерүне сорый.

Сходкада катнашкан Д. Матвеев һәм М. Коников, 1888 елда чит илдә чакларында, Г. В. Плехановка якын революцион эшлеклеләр белән элемтәгә кереп, «Освобождение труда» группасы өчен средство җыю һәм Россиядән хатлар җибәрү хакында килешәләр[4]. Бу фактлар, кәләше А. Г. Соловьеваның Д. Матвеев белән язышуы аркасында, Н. Е. Федосеевка мәгълүм була. Шушы элемтәләр буенча чит илдән Казанга Г. В. Плеханов хезмәтләре һәм бер данә «Освобождение труда» группасы программасы җибәрелә.

Башка шәхесләрнең дә тормыш юллары өйрәнүне сорый. Әйтик, 1887 елда Казан университетында Г. М. Кржижановскийның бертуганы А. М. Кржижановскийның укуы кызыклы һәм мөһим факт түгелмени?! Авыру сәбәпле кышын отпуск алган һәм университетка 1888 елның башында гына әйләнеп кайткан А. М. Кржижановский 4(16) декабрьдәге сходка турында белмәгәндер дип әйтә алмыйбыз, әлбәттә. 1890/91 уку елында ул һәм аның бертуганы Борис сходкага катнашучылар (И. Курдов) белән бергә укыйлар, Н. Е. Федосеев эшен дәвам итүчеләр (Н. Сигорский һ. б.) белән аралашалар. А. Кржижановский А. Казаринов[5] белән дә аралаша, ә соңгысы, үз чиратында, Н. Бауман һәм В. Сущинскийлар белән таныш булган.

Ветеринария институты студенты Х. Акҗегетов һәм университетның ирекле тыңлаучысы И. В. Терегулов кебек шәхесләрнең биографиясен дә тирәннән өйрәнергә кирәк. Аларның сходкада катнашулары турында документлар юк, бәлки катнашмаганнардыр да. Ләкин ул вакыйгаларга мөнәсәбәтле булулары ихтимал.

1887 елгы сходканы һәм студентлар көрәшенең башка формаларын алдынгы яшьләр бик озак онытмый. Аның кайтавазы әле 1897 елның 7 ноябрендә дә яңгырый. Полиция департаментына җирле властьлардан алынган бер хатта мәсәлән, Казан университетында студентларга мөрәҗәгать-хатлар таралуы, анда реакцион инспектор һәм 1884 елгы устав тәнкыйтьләнүе хәбәр ителә. Иң мөһиме шул: аларда, сходка документларындагы кебек үк, Казан студентлары үзләренә тиешле хокукларны һәм өстенлекләрне яклауда бердәм булачаклар дигән фикер үткәрелә. Студентлар иптәшлек хисләренә һәм элеккеге революцион традицияләргә хыянәт итмиләр.

1935 елда Пятигорск шәһәрендә эшләгән Ф. Бочков һәм 1933 елда Харьков өлкәсенең Покатиловка авылында эшләгән ветеринария врачы И. де-Гейффье да университетта узган сходканы исләреннән чыгармыйлар. Туганнарына, хезмәттәшләренә алар бик күп кызыклы фактлар сөйләгәннәрдер, бәлки В. И. Ленин турында да истәлекләр белән уртаклашканнардыр. Бу юнәлештә эзләнү алып бару кызыклы табышларга китерергә мөмкин.

В. И. Ленин биографиясенә материаллар җыйган В. Д. Бонч-Бруевичның О. Португалов тарафыннан язылган «Казан университетында 1887 елдагы студентлар кузгалышы турындагы истәлекләр» кулъязмасын укуы — билгеле факт. Бу мемуар турында язган рецензиясендә ул, әгәр дә Португалов студентлар чуалышында В. И. Ульянов-Ленинның чыгышын тасвирла-

[3] Исаков С. Г. О первом марксистском кружке в Тарту — Уч. записки Тартуского университета. Вып. 261. Тарту, 1970, 17, 19 бб.
[4] ТАССР УДА. 199 ф., 1 тасв., 3726 эш, 39, 44, 45 бб.
[5] ТАССР УДА. 977 ф., Инсп. студ., 68 эш, 78 б.

ган һәм аның турында яңа мәгълүматлар биргән икән, аларны шуның өчен генә дә матбугатта чыгарырга кирәк дип саный[6].

Сходкага катнашучыларның язмышын өйрәнүне Россиядәге азатлык көрәшенең төрле юнәлешләре арасындагы бәйләнешләр тарихыннан башка күз алдына китереп булмый.

Мәсәлән, сходкада катнашкан дистәләрчә поляк студентларының биографияләрен өйрәнү дә яңа ачышларга китерер иде. Жандармерия мәгълүматларыннан күренгәнчә, алар арасында студент В. И. Ульянов-Ленин белән якын мөнәсәбәттә торганнары да бар. Шунысы да мөһим: аларның кайберләре, Казанга килгәнче, Петербург университетының А. И. Ульянов укыган физмат разряды студентлары булган.

Сходкачылар Н. С. Купревич һәм Б.-В. В. Пежарскийлар да элегрәк Петербург университетында укыганнар. Казан губерна жандармерия идарәсе начальнигының 1887 ел 19 октябрьдә Казан уку округы попечителенә хәбәр итүенә караганда, Н. С. Купревич «Пролетариат» исемле җәмгыять членнары белән элемтәдә торган[7].

Беренче революцион чыныгуны сходкада алган студентларның күпчелеге самодержавиегә каршы көрәшне дәвам иттерә. Н. Шемаев үзенең гимназист иптәшләре Н. Бауман һәм В. Сущинскийга дулкынланып сходка турында сөйли, В. И. Ульянов-Ленин исемен еш телгә ала. Сущинский белән дуслыгын ул соңыннан да өзми, аларның яшерен революцион эш алып барулары турында да хәбәрдар була. 1900 елның 4 февралендә Н. Шемаев Свияжскидан Казанга килә һәм квартира тотучы хатынга үзенең «бик мөһим эш буенча» тиз арада Б. Г. Сущинскийны күрергә тиешлеген әйтә[8].

Сходкага катнашучы Ф. Фарманов 1900 ел башларында марксистлар белән кулга-кул тотышып, актив рәвештә иҗтимагый-политик эш алып бара. Әстерханда яшәгәндә, ул социал-демократлар белән тыгыз элемтәгә керә һәм Казанда укучы әстерханлы студентлар өчен уздырылган кичәдә җыелган 200 сум акчаны Казанга җибәрә. Бу акчалар студентларның күренекле эшлекләләре, сходканы оештыручылар арасында бүленә[9]. Сумманың бер өлеше искрачы Н. Семашко, Б. Рюриков, З. Соловьев һәм башкалар белән бергә яшерен революцион эш алып барган студент Л. Мамаджановка бирелә[10]. Н. Е. Федосеевның күптәнге дусты, 1905—1907 еллардагы революциядә актив катнашкан Г. М. Волков, «Саратовский листок» газетасы редакциясе хезмәткәре К. Сараханов һәм үзе белән бергә сходкада катнашкан күп кенә башка студентлар белән хат алышып торган Г. Плетнев та марксистларның шушы төркемендә революцион эш алып барган[11].

Яшүсмер чагында ук Н. Г. Чернышевский белән танышкан һәм 1887 елгы сходкада катнашкан И. К. Курдов та революцион көрәш юлыннан тайпылмаган, шул эшчәнлеге өчен аны төрмәгә ябалар. Октябрь революциясеннән соң ул Урал өлкәсе сәламәтлек саклау бүлегенең дәвалау бүлеге мөдире булып эшли, соңыннан Свердловск медицина институтында социаль гигиена кафедрасын җитәкли («Советское здравоохранение», 1962, 2 сан, 73—76 бб.).

1887 елгы тарихи сходкага катнашкан, соңыннан большевик булган В. Перимов матбугат битләрендә Россиядә эшчеләрнең хәле турында мәкаләләр сериясе белән чыгыш ясый. «Эшчеләрне страховать итү турында яңа законнар» исемле корреспонденциясендә ул царизмның эшчеләргә каршы политикасын ачып сала («Камско-Волжская речь», 1912, № 289). В. Перимов В. В. Адоратский, А. И. Догадов һәм башка революционерлар белән дус була.

Жандармнарга күп кенә фактлар билгеле булмаган, ләкин алар хәтта XX гасыр башында да сходкага катнашучыларны үзләренең күз уңында тотканнар. И. М. Лангор, И. Есель, Г. Музыкантскийлар 1900 елда да охранкада исәптә торганнар. 1905—1907 елгы революция елларында чит илдә яшәгән Г. Музыкантский Россиягә кайтып, азатлык өчен көрәш сафына басарга җыена. 1905 елның 22 августында Женевадан Казанга җибәрелгән хатында ул түбәндәгеләрне яза: «Мин монда бик идеаль һәм укымышлы даирәдә аралашам. Россия социал-демократлар партиясенең барлык алдынгы вәкилләре... монда яши. Монда соңыннан практик эш өчен Россиягә җибәрелүче агитаторлар һәм пропагандистлар хәзерләү буенча университет дияргә була»[12].

---

6 Ленин исемендәге Үзәк дәүләт китапханәсенең кульязмалар бүлеге, 369 ф., 53 карт., 6 эш.
7 ТАССР УДА, 92 ф., 1 тасв., 17336 эш, 2 б.
8 ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 146 эш, 101 б.
9 ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 145 эш, 299 б.
10 Шунда ук, 240, 300 бб.
11 ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 124 эш, 16 б; 140 эш, 139 б; 248 эш, 280 б; 1 ф., 4 тасв., 1903 эш, 3, 85, 89 бб.
12 ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 736 эш, 4 б.

Сходкага катнашкан Я. В. Мартинкус, врачлар М. Н. Жуковский [13], Н. И. Шерстобитовларны [14] да полиция озак еллар буе яшерен күзәтүе астында тота. 1897—1898 елларда Н. Е. Федосеевның якын танышы А. П. Линькова да шундый күзәтүдән читтә калмаган [15]. Ул жандармнарга мәгълүм булмаган эшләр белән Әстерханга да баргалый. Шул ук елларда жандармнар 1887 елгы сходкада катнашкан Е. В. Барамзинны эзлиләр [16].

Властьларның сходкада катнашкан Н. П. Васильевскийны тынычлыкта калдырмаулары турында матбугатта сүз булган иде инде [17]. Соңгы вакытларда тагын яңа фактлар ачыкланды. 1889 елның 3 маенда Одесса жандармерия идарәсе начальнигы Казан губерна жандармериясе начальнигына, врач Н. П. Васильевский эшчәнлегенә аеруча игътибар итәргә кирәк, чөнки аның күптәннән политик яктан аеруча ышанычсыз кешеләр белән элемтәдә торуы мәгълүм, дип яза [18]. 1899 елның 16 маенда Казан полицмейстеры 1887 елгы сходкада катнашкан врач П. П. Сементовский турында да шуңа охшаш документ тутыра [19]. Алар икесе дә Сущинскийлар гаиләсе һәм сходканы оештыручы студентлар В. Адоратский, Н. Дамперов һәм башкалар белән таныш булалар. Бу елларда казанлылар белән элемтәдә торучылар арасында Киев, Чернигов губерналарында, башкалаларда һәм университетлы шәһәрләрдә, шулай ук Ригада тору хокукыннан мәхрүм ителгән М. И. Аккер да була [20]. Ул да Казан студентларының В. И. Ульянов-Ленин катнашында узган сходкасына катнашкан.

Байтак мөһим фактларны, революцион көрәш тарихының кайбер тирән катламнарын хәзергә кадәр ачыклап җиткергәнебез юк әле. 1900 ел башында Казан революционерлары В. Адоратский, Н. Дамперов, Б. Рюриков «үтә зарарлы юнәлештәге» түгәрәк члены Л. Богораз белән бәйләнешләрын дәвам иттерәләр. Витебскида яшәүче Л. Богоразга, В. Адоратский исеменнән, Двинадагы стачкада катнашучылар өчен Казанда җыелган акча җибәрәләр [21].

Нәсел җебе атаклы И. М. Симоновка барып тоташкан Васильевлар династиясе серләрен дә ачасы бар әле. Философия фәннәре кандидаты, доцент В. А. Бажанов мәгълүматларыннан күренгәнчә, философ Н. А. Васильевның бабасы В. П. Васильев Петербург фәннәр академиясе академигы, кытай халкы тарихы һәм этнографиясе буенча күренекле белгеч; әтисе А. В. Васильев — бөтен дөньяда атаклы Казан физика-математика җәмгыятенә нигез салучыларның берсе, күренекле математик; агасы Н. В. Васильев — профессиональ революционер, Г. В. Плехановның якын көрәштәше. Н. А. Васильев Казан университетында 1901 елгы сходкага һәм аннан соң урамда узган политик демонстрациягә катнашкан («Философские науки», 1986, 3 сан, 74—75 бб.). Н. А. Васильевның сходкада Н. А. Семашко, ә демонстрациядә Ленин «Искра»сы агенты О. И. Чачина белән бергә булганын да өстәп әйтергә кирәк.

Васильевлар фамилиясе жандармнарга яхшы таныш була, чөнки алар бу фамилия вәкилләрен озак еллар буе күзәтү астында тоталар. Н. А. Васильевның әтисе профессор А. В. Васильев Л. Н. Толстой белән хат алышкан. Архивта бөек язучының 1903 елның 2 октябрендә Ясная Поляннадан Казанга, профессор А. Васильевка җибәргән хатының агентлар тарафыннан алынган күчермәсе сакланып калган. Ул әдәбият белгечләренең, бәлкем политэкономия һәм философия тарихын өйрәнүчеләрнең дә игътибарын җәлеп итәр.

«Домашның китабын җибәргән... һәм җирне милекчелек хокукыннан азат итү кебек бөек эшкә (чираттагы практик эшләрнең беренчесенә) Сезнең теләктәшлегегезне күргән хат өчен рәхмәтемне белдерәм. Хөрмәтле Домаш әфәндегә... китап һәм андагы язу, шулай ук җирне национализацияләү лигасы членнарына конгресска чакырулары өчен рәхмәтемне тапшырсагыз, үземне Сезнең каршыда бурычлы дип санармын. «Национализация» сүзе мәсьәләне минем аңлавыма бик үк таңгәл килми. «Национализация» милләтнең милекчелек хокукын тануны аңлата, ә мин исә — җир кемнең дә булса милке булырга мөмкин диган ялгыш аңлауны юкка чыгару бурыч булып тора дип уйлыйм. Аерма бары тик аңлату ысулында гына булырга да бик мөмкин, ләкин алай булмаганда да, бар да, хосусый милекчелектән миллига күчү дә, идеалга якынлашу дигән сүз, шуңа күрә мин аларның эшчәнлегенә теләктәшлек итәм» [22].

---

[13] ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 105 эш, 578 б.
[14] Шунда ук, 123 эш, 358 б.
[15] Федосеев Н. Статьи и письма. М., 1958, 58 б.
[16] ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 105 эш, 14 б.
[17] Нафигов Р., Литвин А. Они были первыми. Казань, 1963, 7 б.
[18] ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв. 123 эш, 211 б.
[19] Шунда ук, 215 б.
[20] ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 131 эш, 70 б. 1935 елда профессор М. И. Аккер Ленин ордены белән бүләкләнә.
[21] ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 248 эш, 20, 22, 23 бб.; 335 эш, 164 б.
[22] ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 441 эш, 167 б.

Профессор А. В. Васильев улларының революцион хәрәкәттә катнашулары турында жандармерия тулы мәгълүматлар җыя алмаган, әмма, шуңа да карамастан, аларның «политик яктан бик зарарлы юнәлештә» булулары хакында агентлардан берничә тапкыр хәбәр керүе мәгълүм. Профессорның үзе турында исә ачык һәм катгый рәвештә, ул «революцион пропаганда эшенә һәм студентлар хәрәкәтенә» тулысынча теләктәшлек күрсәтә, дип язылган. Казан губерна жандармерия идарәсендә профессор А. В. Васильевның узган гасырның 80 елларында Казандагы революцион төркемнәр белән элемтәдә торуы хакында да мәгълүматлар сакланган [23].

Шулай итеп, Казан революцион подпольесының 80 еллардан, Н. Е. Федосеевлардан килгән күпьеллык элемтәләре ачыклана. Н. Е. Федосеев Васильевлар аша Лондондагы революцион эмиграция белән бәйләнештә торган. Бу элемтә, жандармнар никадәр тырышса да, өзелми.

Революцион көрәш дәвамында буыннар алышынуы һәм алар арасындагы бәйләныш мәсьәләсе махсус өйрәнүне таләп итә.

Казан революцион подпольесы бөек рус язучылары белән элемтәсен Россиядәге азатлык көрәшенең өченче — пролетар этабында да югалтмый. Мәсәлән, бертуган Васильевларның, В. Адоратский һәм Н. Семашконың дусты, студентларның революцион подпольесы җитәкчеләреннән берсе Н. Дамперов, узган гасырның 90 нчы еллар азагында Л. Н. Толстой белән хат алышкан. 1901 елгы тентү вакытында алынган кәгазьләр арасында Л. Н. Толстойның 1899 ел 10 январьда язган җавап хаты табыла [24].

Казандагы Югары хатын-кызлар курслары тыңлаучысы Глядкова Александра Константиновна 1909 елда РСДРП члены була [25]. Ул — В. И. Ленинның Сембер гимназиясендә укыган чактагы иптәше, 1887 елгы тарихи сходкага катнашучы К. Глядковның кызы.

Казан университетында «чит тыңлаучылар» дип йөртелгән даирә һәм университет каршындагы Повивальный институтта укучылар тарихы да әлегә кадәр тикшерелмәгән килеш кала бирә. Купчелеге, кагыйдә буларак, гимназия тәмамлый алмаган разночинецлар. Аларны университетка кабул итүгә властьлар төрле киртәләр куеп килә. Студентлар хәрәкәтендә алар да катнашканнар. 1887/88 уку елында, ягъни В. И. Ульянов-Ленин университетта укыган вакытта, исемлектә барысы 42 «чит тыңлаучы» һәм Повивальный институтта укучы 45 кеше теркәлгән. Алар арасында бик таныш фамилия — студентларның дусты, А. М. Пешковның өлкән иптәше А. С. Деренковның бертуган сеңлесе Деренкова Мария Степановна да бар. Аның янәшәсендә Ф. Г. Беркович һәм А. П. Сементовская — Н. Е. Федосеевның үзәк революцион түгәрәге членнары.

1887 елгы сходкада катнашкан Л. М. Троицкийның бертуган сеңлесе, Сембер гимназиясен тәмамлаган А. М. Троицкая һәм шулай ук Сембер гимназиясен тәмамлаган В. Н. Алексеева да алар белән бергә була. Казан революцион подпольесы эшендә бу кызлар сизелерлек роль уйнаганнар. Алар үзләренең дуслары, иптәшләре, гимназисткалар арасында эш алып барганнар, агымдагы политик мәсьәләләр тикшерелгән студент кичәләрендә катнашканнар. Бу кызлар А. С. Деренковның А. М. Горький эшләгән пекарнясы, лавкасы һәм Н. Е. Федосеев белән элемтә тотуда студентларга ярдәм иткәннәр.

Архив документларыннан күренгәнчә, «чит тыңлаучы» Яблочков та 1887 елгы сходкада катнаша. Ул иптәшләренә теләктәшлек күрсәтеп, үзен университетта тыңлаучы булудан азат итүләрен сорап гариза яза һәм билетын калдырып китә.

Күренгәнчә, мондый «чит тыңлаучылар» да университетта булган мөһим вакыйгалардан читтә тормаганнар.

Сходкада катнашучыларның бер өлеше (безнең исәпләүләр буенча, алар егермедән дә ким түгел) большевиклар партиясе сафларына баса; зур өлеше социал-демократик оешмаларга теләктәшлек күрсәтә һәм хәлләреннән килгәнчә ярдәм итәләр. Кайберләре соңыннан күренекле галимнәр, врачлар һәм башка профессия ияләре булып китсәләр дә, иҗтимагый проблемалардан читтә калмаганнар.

Россиядәге азатлык хәрәкәтенең пролетар этабына кадәр үк көрәш мәйданына чыккан эшлеклеләр тарихта яңа эз калдырып киткәннәр.

---

[23] ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 441 эш, 181 б.
[24] ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 3565 эш, 120 б.
[25] ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 3565 эш, 120 б.

# КОКУШКИНОДА, 27 АВГУСТ КӨННЕ

Владимир Ильич Ленинның шахмат уйнарга яратуы һәм бик оста уйнавы турында мәгълүматлар байтак. Ульяновлар гаиләсендә, гомумән, бөтенесе дә шахмат белән дус булганнар. Ленин шахматка эш итеп түгел, уен итеп карый, ләкин ихтыяр һәм игътибар тәрбияли торган, логик фикерләүне, каршы якның йөрешен алдан күрү осталыгын үстерә торган, ягъни политик эшлеклегә дә бик кирәкле сыйфатлар тәрбияләргә сәләтле уен итеп карый.

Ленинның бу мавыгуы турындагы һәр яңа факт игътибарга лаек дип уйлыйбыз, чөнки алар юлбашчы образын тагын да тулырак итеп күз алдына бастырырга мөмкинлек бирә.

Мәсәлән, «Пулемет» дигән сатирик журналны чыгарган Н. Г. Шебуевның иҗатын өйрәнү Володя Ульяновның тормышындагы тагын бер сәхифәне ача, «Ленин һәм шахмат» темасына яңа мәгълүматлар өсти.

В. И. Ленин исемендәге СССР Дәүләт китапханәсендә журналистның «Җиде җидеелльк. Н. Шебуев тормышыннан мозаика 1881—1887» дигән басылып чыкмаган истәлекләре саклана. Анда Н. Г. Шебуев 1887 елның 27 августында (яңа стиль белән) патшага һөҗүм ясаган өчен җәзалап үтерелгән Сембер егете Ульяновның энесе белән очрашуын искә ала. (Кульязмалар бүлеге, 384 ф., 11 эш, 32 б.) В. И. Ленинның Биографик хроникасында бу көн турында мәгълүматлар юк, шунлыктан ул көнне Владимир Ильичны күргән кешенең язганнары игътибарга лаек.

Заманында танылган язучы һәм журналист Николай Георгиевич Шебуев турында белүчеләр хәзер күп түгелдер. Революцион 1905 елда ул гадәти булмаганча «Пулемет» дип аталган мәшһүр сатирик журнал чыгара башлый. Пулемет ул вакытта яңа һәм дәһшәтле корал санала. Рус-япон сугышы аның өстенлекләрен ачык күрсәтә. Сугыш башланганда Япониянең 147 пулеметы була, ул бу яклап Россиянең Ерак Көнчыгыштагы көчләреннән күпкә узып китә.

Н. Г. Шебуев (1874—1937) Казанда туган. Ул 1 нче император гимназиясендә укый, аннары Казан университетының юридик факультетын тәмамлый. Ул яшьтән үк журналистикага тартыла, газеталарда көндәлек фельетончы, театр һәм сәнгать тәнкыйтьчесе булып эшли, берничә газета-журналга редакторлык итә.

Университетны тәмамлагач, Шебуев Мәскәү Суд палатасына эшкә керә, аннары адвокатурага присяжный поверенный ярдәмчесе булып күчә. Ләкин нигездә әдәби эш белән шөгыльләнә, хәер, иҗатында да суд эшләренә якын тора.

Революция алдыннан, 1905—1907 елларда Н. Г. Шебуев «Негативлар» дип аталган берничә җыентык чыгара, аларда ул төрле вакытта «Новости Дня», «Русское Слово» һәм «Русь» журналларында басылган сайланма фельетоннарын урнаштыра. Фельетоннарында автор капиталистик шәһәрнең чирләрен тәнкыйтьли, киң политик гомумиләштерүләргә кадәр күтәрелмәсә дә, социаль гаделсезлекнең хосусый күренешләренә каршы хәл кадәренчә көрәшергә тырыша.

Ул самодержавиенең зур һәм тутыгып беткән механизмының вак-төяк түрәләрен генә тәнкыйтьләп калмый, зур дин башлыкларына, Синодның обер-прокуроры К. П. Победоносцевка, юстиция министры С. С. Макухинга да үрелә, аларны да фаш итә, шуның өчен 28 тапкыр суд әзәрлекләвенә тартыла. Судлар һәммәсе дә Шебуев файдасына тәмамлана. Беренчедән, ул фаш иткәндә документлар белән расланган фактларга таяна, икенчедән, аны оста адвокатлар, А. И. Ульяновны яклаган И. П. Каляев һәм башкалар яклый. Газета-журнал битләрендә урын алган җәмәгатьчелек фикере дә аның ягында була, журналист һәм публицист буларак сиземләве, тәҗрибәсе, юридик хәзерлеккә ия булуы да файда итә.

Шул рәвешле, 1905 ел җиткәндә Н. Г. Шебуев тәмам формалашкан, танылган, тәҗрибәле журналист, берничә шигырь һәм проза китабы авторы була, чит илдә корреспондент булып та эшләп ала. Болар һәммәсе дә аңа профессиональ тәҗрибә генә түгел, социаль тәҗрибә дә бирә. Ул чын политик сатира белән шөгыльләнергә, югарыдарак утыручыларны фаш итәргә хыяллана. Сугышчан журнал турында хыяллана.

Кыю һәм демократик фикерле журналист Шебуев яңа революцион шартларда читтә калырга мөмкин түгеллеген, язучыларга эшкә тотынырга, һөҗүмгә ташланырга кирәклегенә ышана. «Ротация машинасы пулемет кебек атарга тиеш», ди ул (Шебуев Н. Дело об его рабочем величестве пролетарии российском. М., 1931. 12—13 бб.). Әнә шулай итеп көтелмәгән һәм усал исем туа, аның артыннан журнал үзе дә озак көттерми. Ул революциянең иң югары күтәрелеш чорында, пролетариат һәм крестьяннарның массакүләм сугышчан хәрәкәтләре нәтиҗәсендә патша матбугат иреге бирергә мәҗбүр булгач, барлыкка килә.

Пулеметның самодержавиегә төзәп җибәргән беренче пулялары туры тия. Николай II нең үзенең дә ачуын чыгара. Журналда «Яз турында» әкият басылып, анда 17 октябрь конституциясе аллегорик формада яз итеп сурәтләнә. Ләкин чын түгел, ясалма, өтек яз, «хәрби хәл дә, еврей погромнары да, юньсез казаклары да, карагруһлары да булган яз. Һәм бөтен җирдә ыңгырашу-сыкрау башланды» («Пулемет». СПб., 1905, 13 ноябрь, № 1. 3 б.). Социал-демократлар бу әкиятне башка пропаганда әдәбияты белән бергә тарата, аны Англия, Франция, Германия һәм Польша газеталары да күчереп баса.

Беренче санның тышлыгында кулын сузып «Долой!» дип кычкырып торучы студент-оратор рәсеме ясалган була, ә соңгы биттә — «самодержавие конституциясенә» үтергеч сатира — 17 октябрь Манифестының тексты, аның астына «Бу кәгазьгә император галиҗәнапләре свитасының генерал-майоры Трепов кул куйды» дип язылган һәм текст өстенә канлы кул эзе басылган. Шебуев үзе ясаган бу рәсем-прокламация манифестта мул итеп бирелгән вәгъдәләрне һәм аларны революцион хәрәкәт палачының ничек итеп тормышка ашыруын гәүдәләндерә. Ул бөтен Европада таныла, безнең аңыбызга ул Беренче рус революциясе вакытындагы царизмның график символы булып бик хаклы рәвештә кереп калды.

Үзенең журналын чыгарган өчен Н. Г. Шебуев кулга алына һәм төрмәгә ябыла, шулай итеп ул патша манифесты биргән «матбугат ирегенең» беренче корбаны була. «Пулемет» исә беренче саныннан ук 1905—1907 елларда чәчәк аткан актуаль политик сатираның иң югары казанышларыннан берсе булып әверелә («Пулемет»ның беренче санын В. И. Ленин Үзәк музеенда, Мәскәү һәм Ленинградтагы башка тарихи-революцион музейларда күрергә була, ул башка шәһәрләрдәге музейларда да бар. Аны 1905 — 1907 еллар революциясе турындагы һәр китапта диярлек күрергә мөмкин). «Пулемет»ның аягы җиңел була, революция елларында Россиядәге 34 шәһәрдә мең ярымлап исемдәге журналның гомуми тиражы 40 миллионлап булган 2,5 меңнән артык саны чыга.

Н. Г. Шебуев Октябрьдән соң совет басмаларында хезмәттәшлек итә, СССР Язучылар союзы төзелгәннән алып аның члены була. Рус совет журналисты, язучы, рәссам Николай Георгиевич Шебуев Мәскәүдә, Новодевичий зиратында күмелгән. Аның каберенә «1905 ел сугышчысы» дип язылган.

Язучының әтисе Георгий Николаевич Шебуев (1850 — 1900) Казан реаль училищесында математика һәм физика укытучысы, Казан университетының математик физика кафедрасында приват-доцент була. Ул һәр җәйне гаиләсе белән Казаннан 27 чакрымдагы кечерәк кенә Шигали имениесендә уткәрә. Ул кышын гадәттә темасын, белешмә материалларын табып куя, ә җәй көне имениесендә мәкаләләре өстендә эшли. Аңа җәйләрен генә шулай иркенләп укырга, фәнни хезмәт белән шөгыльләнергә мөмкинлек туа. Ул аналитик механика, математик физика, теоретик оптика, физик география һәм җир магнетизмы буенча ике дистәдән артык хезмәт язып калдырган.

Айның егермеләрендә барлык чиновниклар да жалованье ала, Георгий Николаевич та Шигалидән Казанга барып йөри. Чираттагы баруында, 1887 елның 20 августында, реаль училищедагы хезмәттәше, рус теле тарихын укытучы П. С. Кукуранов аны имениесенә чакыра. Кукурановның Кокушкино тирәсендәге имениесе Шигалидән 15 чакрым ераклыкта була.

Казаннан кайткач, Шебуев хатынына бу чакыру хакында әйтә һәм Казан университеты ректоры, Рим хокукы профессоры Н. А. Кремлевтан сәлам тапшыра. Шебуев белән яхшы мөнәсәбәттәге Кремлев бер үк вакытта асылзат кызлар институтының инспекторы да була, ә ул институтка Георгий Николаевичның туганы З. Н. Урусова җитәкчелек итә.

Г. Н. Шебуев сүзләренә караганда, Кремлев «бик аптырашта калган» була, чөнки «быел университетка керергә теләүче яшь кешеләр арасында патшага һөҗүм ясаган революционерның энесе дә бар икән.

«— Кремлевка нәрсә уйлап торырга! Мин шунда ук кире кагар идем,— ди хатыны өзеп.

— Кремлев та... баш тартыр иде. Эш бик гади булып тоелса да, алай түгел шул. Дурново үзе (ул чагында полиция департаменты директоры — В. Ж.) Ульяновның әнисенә улы провинциаль университетларның теләсә кайсысына кабул ителер, дип вәгъдә иткән... Ә шуның өстенә Кремлев Сембер гимназиясе директоры Керенскийдан (Вакытлы хөкүмәтнең булачак башлыгы А. Ф. Керенскийның этисе — В. Ж.) яшь Ульяновның искиткеч сәләтле булуы турында хат алган. Алтын медальгә тәмамлаган. Тәртибе телтеш тидерерлек түгел. Андыйны кабул итмичә мөмкин түгел» (Н. Г. Шебуев мемуарлары, 2-3 битләр).

Мемуарларның авторы, ул вакытта яндурт яшьлек гимназист, «Кремлевның кәефен бозган шул яшь кеше анда булуын ишеткәч», этисеннән үзен дә Кокушкинога, Кукурановларга алып баруын үтенә.

«— Эти, Кокушкинога мине дә алып бар әле!

— Башыңнан чыгарып ташла шул Кокушкиноны! Студентка синең белән... икенче ел утыручы белән кызык булыр дип уйлыйсыңмы әллә!.. Урядник әнә ул укый яисә шахмат уйный дип сөйли...

— ...Мин аңа күз генә салыр идем... бик күрәсем килә...— һәм без киттек» (Шунда ук, 5, 7, 8 битләр).

Н. Г. Шебуев үзенең балачакта В. И. Ульянов белән очрашудан калган тәэсирләрен болай тасвирлый: «...скамьяга атланып җитен курткалы бер бик яшь егет утырган иде... Минем йөрәгем дерт итеп китте:— Юк, моның ул булуы мөмкин түгел! Геройга охшаган бер нәрсәсе юк. Ә каешы нәкъ минеке кебек... гимназист каешы. Курткасы да гимназист вакытыннан калган кебек. Мин озын буйлы, мәһабәт, кояшта янган каратутлы, «бөркеттәй профильле кеше» күрермен дип көткән идем. Безнең гимназиядәге икенче ел утыручы Пронин белән Бутягин моңа караганда күпкә гайрәтлерәк һәм, минем уемча, герой-террористка ныграк охшаганнар... Ә минем алдымда шомарткан булса да бөдрәрәк чәчле («әле генә су коенгандыр», дип уйладым) блондин басып тора. Шахмат тактасына иелгән дә, кыен йөрешен уйлый.

Кукуранов безне шатланып каршылады.

— Ә менә минем күршем Владимир Ильич, аның турында сөйләгән идем бит... Студент...

...Эти дә минем кебек егетнең артык яшь булуына аптырабрак калды ахры.

— Сезгә ничә яшь соң?.. Сез, һичшиксез, бөтен университетта иң яшь студент буласыз.

— Унҗиде тулып үтте инде!— дип елмаеп җавап бирде егет һәм фигурасын күчерде:— Петр Сергеевич, сезнең йөреш...» (Шунда ук, 8, 9 битләр).

Тактадагы хәлне тиз генә бәяләп ала да, П. С. Кукуранов бирелә. Гомуми исәпләре — ике ничья һәм Кукуранов тарафыннан сигез оттырыш.

— ...Кайчан ачуын кайтарырсыз соң?— дип сорый В. Ульянов.— Чөнки берсекөнгә мин Казанга китәм... университетка... бөтенләйгә.

— Сезгә минем белән уйнауның кызыгы юк,— дип җавап бирә Кукуранов.— Георгий Николаевич белән уйнагыз... Аның да комбинацияләре профессорларча... (Шунда ук, 9 б.).

Шебуевның этисе белән Владимир Ильичның партиясе чиксез озын була. Уенчыларның икесе дә һәр йөрешен бик җентекләп уйлый.

«Ниһаять В. И. Ленин бөтен уенга беренче тапкырмы икән, партнерына карады:

— Ничьямы?

— Ничья!»— дип җавап бирә тегесе (Шунда ук, 10, 11 битләр).

Бөтенесен дә төшке ашка чакыралар. Ульянов рәхмәт әйтеп баш тарта, үз өендәгеләрнең аннан башка ашарга утырмаячагын әйтә. «Һәм, хушлашып тормыйча, бер җитез малай кебек, капкага таба йөгерде».

Өстәл артында П. С. Кукурановның хатыны Георгий Николаевичтан сорап куя:

— Ничек соң, күршебез сезгә ошадымы?..

— Бик тә, бик тә кызыклы кеше,— дип җавап бирә Г. Н. Шебуев җанланып.— Без аның белән бик әйбәт сөйләштек...

— Кайчан сөйләшергә өлгердегез әле?— дип көлә Петр Сергеевич.— Киресенчә, сез аның белән ике авыз сүз сөйләшергә дә өлгермәдегез.

— Булмас!.. Беләсезме... Кайчакта кеше белән бер әйбәт шахмат партия-

се уйныйсың да, аның белән һәммәсе хакында да сөйләшкән кебек буласың... Минә бу егет белән уйнадым да, гүя ул үзе турында бөтенесен сөйләп бирде... Әйбәт итеп... акыллы... эчтәлекле итеп.

— Нәрсә сөйләде соң ул сезгә үзе турында?

— Үзенең инде җитлеккән акыл булуын сөйләде... Максатына ирешә торган... сыгылмалы... Комбинацияләрне ничек анализлый!.. Нинди ачыклык, кыюлык, кискенлек... Мин ышанам, ул математика факультетының бизәге булыр!

— Сез инде артыгын мавыгып киттегез, Георгий Николаевич! Ул беркайчан да математика факультетының бизәге булмас, чөнки өченче көн юридик факультетка алынды... (Шунда ук, 11, 12 битләр).

Булачак студент белән университет галиме шулай очрашалар. Мемуарчы Н. Г. Шебуев болай яза: «Минем әтиемнең бик күренекле математиклар— Пороцкий, Дубяго, Громеко, Гольдгаммер, Васильев, Бугаев, Некрасов, Жуковский, Чаплыгин белән уйнаганы бар иде һәм ул яшь Ульянов бу профессорларның күбесеннән көчлерәк уйный дип тапты» (Шунда ук, 32 бит).

Казанда туып-үскән кеше буларак, Н. Г. Шебуев «Ленин Казанда» дигән китап язарга хыяллана һәм материаллар да туплый башлый. Бу китап шулай да язылмыйча кала. Ләкин аның истәлекләре В. И. Ленинның шахмат уенын яратуы турында тагын бер дәлил булып тора.

Н. Г. Шебуевның югарыда өзекләр китерелгән истәлекләре 1933 елдан да иртәрәк язылмаган булса кирәк. Мондый сорау куйыйк: мемуарчының хәтере ялгышмыймы, чөнки вакыйгалар булып үткәнгә ярты гасыр чамасы, ә язган чакта Н. Г. Шебуевның яше алтмышка якын булган бит. Һәм, гомумән, тасвирланган очракның булуы мөмкинме?

Беренче сорауга болай җавап бирергә кирәк: юк, ялгышмаган. Психологларның күптән инде ачыклавынча, олы яшьтәге кешеләр яңарак кына булып үткән түгел, ә нәкъ менә күптәнге вакыйгаларны хәтердә яхшырак саклыйлар һәм яңарта алалар. А. Ф. Кони кебек танылган юристның кешеләр белән күп еллар эшләү практикасы да шуны раслый, ул болай дип яза: «картлар хәтере яңарак булган вакыйгаларга карата йомшара һәм яшьлегендәге, хәтта балачактагы бик күптәнге истәлекләрне ачык итеп саклый. Күп кенә картлар кичә яки берничә көн элек кайда булганнарын, кемне кайда күргәннәрен бик кыенлык белән генә искә төшерәләр, ә дистәләрчә ел элек нәрсә күргәннәрен һәм кичергәннәрен бик тәфсилләп сөйләп бирә алалар» (Кони А. Ф. Сайланма әсәрләр, 2 томда, I т., М., 1959, 157 б.).

Шунысын ачыклау мөһимрәк: В. Ульянов 1887 елның 27 августында Кокушкинода була һәм Г. Н. Шебуев белән очраша алганмы? Алгандыр, диясе килә. Моны раслау өчен В. И. Ленинның Биохроникасына мөрәҗәгать итик. Анда В. Ульяновның 1887 елның 10 августына кадәр (биредә һәм алга таба барлык даталар яңа стиль белән алынды) Кокушкинодан университетка керү өчен Казанга килүе әйтелә. 10 августта ул Казан университеты ректоры Н. А. Кремлевка үзен юридик факультетның беренче курсына алу хакында үтенеч язуы бирә, 25 августта студентлыкка кабул ителә. 25 августтан 6 сентябрьгә кадәр арада керү билеты ала һәм шул хакта кул куя. 31 августта Ульянов Казан университетының адреслар китабына үзенең адресын язып куя: Беренче Тау урамы, Ростова йорты.

Н. Г. Шебуев В. Ульянов Кокушкинодан Казанга ике тапкыр килгән дип раслый. 10 августта — үтенеч язуы бирү өчен һәм 25 августта — кәгазьләр алу өчен. 1887 елның 30 августында ул Казанга бөтенләйгә күчкән һәм Беренче Тау урамындагы Ростова йортында бүлмә алган. Аталы-уллы Шебуевлар Кокушкинога 27 августта барганнар (Шебуев истәлекләре, 31, 32 битләр).

Минем уемча, ике тексттагы мәгълүматлар бер-берсенә каршы килми. Биохроникада, әлбәттә, Владимир Ильичның 10 августтан соң Кокушкинога кайту-кайтмавы турында ачык әйтелмәгән. Ләкин «кайтмый» дигән сүз дә юк. 25 августта ул студентлыкка алынган, ә керү билеты өчен 25 август белән 6 сентябрь арасында кул куйган. Монда В. Ульянов керү билетын шул көнне үк (25 августта) яисә икенче көнне (26 августта) кул куеп алган, ә аннары Кокушкинога кайткан һәм 27 августта Г. Н. Шебуев белән очрашкан, аннары, 30 ы көнне, Казанга бөтенләйгә киткән дип уйларга мөмкинлек бар. Ульянов керү билетын 30 ыннан соң да кул куеп алган булырга мөмкин. Биохроникада 25 августтан 6 сентябрьгә кадәр арада ала, диелгән бит.

Н. Г. Шебуев П. С. Кукурановның этисенә Ульянов «өченче көн юридик факультетка алынды» дип әйткәнен искә төшерә, ягъни 25 августта була. Монда каршы килү юк.

В. И. Ленин тормышындагы фактларны аның фәнни Биографиясеннән карап дөресләргә мөмкин бит әле. Аның 5—7 басмаларыннан мондый юлларны укыйбыз: «1887 елның июнь ахырында Ульяновлар гаиләсе Сембердән китә. Ул бер ай Кокушкино авылында яши, аннары Казанга барып урнаша» (I том, 11 бит). 1918 елның 14 февраленә григориан календаре кертелгәнгә кадәр Россиядә булган барлык фактлар Биографиядә иске стиль белән бирелгән. Яңа стильгә күчергәндә, Ульяновлар гаиләсе Сембердән июльнең беренче декадасында киткән була, ә бер айдан, ягъни августның 10 сы тирәсендә алар Казанга килеп урнаша.

Шулай укыганда даталар Биохроникада күрсәтелгәнгә туры килер (10 августта «үтенеч язуы бирә»). Ә мәгънәсе ягыннан караганда дөреслә охшамый: чыннан да, дәресләр башланырга бер ай кала диярлек (В. Ульянов университетта 6 сентябрьдә укый башлый) яшь егет, авылда өйләре була торып, тузанлы шәһәрдә нишләп ятсын? Владимир Ильич, 10 августтан бирле Казанда яшәгән булса, кайда торган? Биографияне болай аңлату Ленинның якыннарының истәлекләре белән дә расланмый. Шуларга мөрәҗәгать итик.

А. И. Ульянова-Елизарова болай дип искә ала: «Казанда 1887 елның август ахырында Беренче Тауда, Ростова йортында квартира алынган иде» (Ленин турында истәлекләр, 3 басма, I том, 29 б.). Шунысын әйтик, Анна Ильиничнаның кайсы стильне күздә тотуына карамастан, квартира алу факты август ахырына туры килә. Чыннан да, Биохроникада әйтелгәнчә, Ульянов университеттагы адреслар китабында үзенең адресын 19 (31) августта язган. Истәлекләр гади сөйләм телендә язылган, гади телдә бу даталарның икесе дә август ахыры дигәнгә туры киләчәк.

Владимир Ильич апасының бу мәгълүматларын туганнан туган энесе Н. И. Веретенников та раслый, ул Н. Г. Шебуев кебек үк Казандагы беренче гимназиядә укыган, ике класска арттарак кына. Веретенниковның әнисе Казанда стенографистка булып эшли һәм һәр җәйне улы белән Кокушкинода үткәрә. Веретенников болай дип искә ала: «Уку елы башында Маша апа (М. А. Ульянова — Владимир Ильичның әнисе һәм Веретенниковның тутасы.— В. Ж.) гаиләсе белән Кокушкинодан Казанга күчеп килде. Володя Казан университетының юридик факультетына язылды» (Веретенников Н. И. Володя Ульянов. В. И. Ленинның Кокушкинодагы балалык һәм яшьлек еллары турында истәлекләр. Горький, 1969, 30 б.).

Безнең уебызча, В. И. Ленинның апасы һәм туганнан туган энесенең истәлекләрендә Ульяновларның авылдан нәкъ менә август ахырында китүе ышандырырлык итеп әйтелгән. Н. Г. Шебуев та Владимир Ильичка карата шуны ук раслый. («30 ында... ул Казанга бөтенләйгә күчеп китте»), һәм бу Биохроникага каршы килми (31 августта «үзенең адресын язып куя»).

Ләкин, Биографиядә күрсәтелгәнчә, Ульяновларны Кокушкинода бер ай тора дип югарыда әйтелгәнгә туры килми. Юлбашчы Биографиясенең беренче дүрт басмасын ачып карыйк һәм бөтенесе үз урынын алыр: «1887 елның июнь ахырында Ульяновлар гаиләсе Сембердән китә. Ул августка кадәр Кокушкино авылында яши... ә августтан Казанга күчә» (В. И. Ленин. Биография.1 басма, 10 б.; 2 һәм 3 басма, 9, 10 б.; 4 басма, М. 1970, 12 б.). Мондый контекст әлеге фразаны болай дип аңларга мөмкинлек бирә: Кокушкинода ике айлап яшәгәч, Ульяновлар 18 августта (иске стиль белән) Казанга күчеп киткәннәр.

В. Ульянов 1887 елның 25 августыннан 31 августка кадәр арада (яңа стиль белән) Кокушкинога кайткан, 27 августта анда булган һәм Г. Н. Шебуев белән очрашкан булырга мөмкин дигәнне нигезләү өчен мондый барып кайтуның мөмкинме икәнлеген күз алдына китерергә кирәк. А. И. Ульянова-Елизарова Кокушкиноның Казаннан 40 чакрымда булуын яза, башка чыганаклар да шуны раслый. Н. И. Веретенников югарыда телгә алынган истәлекләрдә болай яза: «Хәтта Казаннан начар грунт юл буйлап кырык километр барырга кирәк булуы да безгә ошый иде».

Җәй көне бу юлны ат белән үтүнең әллә ни кыенлыгы булмый һәм ул, О. И. Ульянованың язуынча, өч сәгать ярымга сузыла. Илья Николаевич исән чакта «хезмәте буенча Кокушкинода ике-өч көнгә Казанга китеп торгалый» (Н. И. Веретенников истәлекләре, 6 б.). Яшь кеше өчен исә бу тагын

да җиңелрәк эш, һәм В. Ульяновка 1887 елны августның соңгы көннәрендә җәйнең калган өлешен үткәрү өчен Кокушкинога кайтырга берни дә комачауламаган.

Ниһаять, шул ук Николай Иванович Веретенников истәлекләрендә Н. Г. Шебуев тасвирлаган фактның дөреслеген куәтләгән төп дәлилне табабыз: «Әле дә хәтеремдә, ул җәйне (1887 елда.— В. Ж.) Кокушкинога Казан университетында математика буенча лекцияләр укучы Г. Н. Шебуев килгән иде. Ул Володя белән озак, бик озаклап бакча буйлап йөрде һәм сөйләште. Сүзләре ни хакта булгандыр, анысын белмим, ләкин соңыннан Шебуевның Владимир Ильичка һичшиксез математика факультетына керергә кирәк, аңарда «шөбһәсез математик акыл» дип кабат-кабат бик мавыгып әйткәнен хәтерлим» (Шунда ук, 44 б.).

Бу юлларга караганда, галим Кокушкинодагы йортта яшәүчеләр белән таныш булгандыр, анда бер генә бармагандыр. Ике имениенең арасы бик ерак булмавын (15 чакрымлап) һәм Георгий Николаевичның инде ун елга якын һәр җәйне Шигали пүчинкәсендә үткәрүен исәпкә алганда, болай дип раслау нигезсез түгел.

Баштарак куелган сорауга әйләнеп кайтсак, ягъни В. И. Ульяновның Шебуев белән очрашу факты булырга мөмкинме, дисәк, бу сорауга уңай җавап бирергә бөтен нигезләр бар. Гәрчә Георгий Николаевичның фамилиясе В. И. Ленинның Биографиясендә дә, Биохроникасында да очрамаса да, яшь Ленин турында соңгы елларда чыккан хезмәтләрдә бу очрашу турында берни дә әйтелмәсә дә. Чөнки бит әле В. И. Ленинның Биохроникасы 1887 елның 27 августында Кокушкинода шундый очрашу булырга мөмкинлеген юкка чыгармый, ә Н. И. Веретенников истәлекләре мондый мөмкинлекне ышандырырлык итеп раслый.

Шул рәвешле, Владимир Ильичның туганнан туган энесенең 50 нче еллар ахырыннан бирле ун тапкырдан артык басылып чыккан истәлекләренә таянып, мемуарчы Н. Г. Шебуев тасвирлаган шахмат партиясен җитәрлек кадәр дөрес факт дип, журналистның истәлекләрен исә В. И. Ульяновның Казан приват-доценты белән очрашуы кебек Ленинианада мәгълүм булган фактның детальләрен, срогын дөресли торган чыганак итеп танырга мөмкин.

**Вадим ЖУКОВ,**
Ленинград төзүче инженерлар
институтының КПСС тарихы
кафедрасы укытучысы

**Вячеслав Шугаев**

# СОҢГА КАЛГАН ЯҢГЫР

**ПОВЕСТЬ**



Хатын-кыздан читләшеп, куркып яшәде ул. Үсмер чагыннан ук хәтерендә калган: поляр киңлекләрне гизеп, диңгезләрдә йөзеп, дөньяны шактый күргән абыйсы, җирән чәчләрен тузгытып, йодрыкларын төя-төя, өстәлгә капланып елады. Тозакка эләккән җанвардай, ыңгырашып, әле шыңшып, әле ярсып, агарынып-каралып үкседе. Абыйсының чибәр хатыны башка берәүгә ияреп киткәч, аның диңгезләр кичеп тапкан акчасына кооператив квартира салдырган иде.

Ә аннан соң шулай булды: тупас итеп, әмма үзенчә генә бер якынлык белән шаярта, көлә белгән абыйсы йомылып, үз эченә бикләнеп калды. Хыянәт ачысын, югалтуның зурлыгын һәм авырлыгын хәмер белән басарга тырышты. Тимофей аны сырахәнә ишеге төбендә көтеп ала, кайтырга кирәклеген аңлатып, өйгә таба сөйри иде. Шундый чакларда абыйсы аның ябык җилкәсен чытырдатып кыса да җан ачысын, әрнү-газабын теш арасыннан кысып чыгара:

— Читләп үт, энекәш... Урман ерсаң — ер, сазга керсәң — кер, әмма хатын-кызны йөз чакрымнан урап үт...

Хәер, абыйсының бу үгет-нәсихәт сүзләрен Тимофей соңыннан гына исенә төшерде. Ә аңынчы бу мәңгелек нәсихәтне үсмер чакның шик-шөбһәсез, гөнаһсыз, җәрәхәтсез көннәре, һәрчак аяз күге, гел кояшлы иртәләре томалап торды. Менә Тимофей солдат хезмәтенә алынырга йөри, ә куен кесәсендәге рәсемнән аңа Наташа исемле бер матурның ягымлы күзләре елмая. Кыйгачланып киткән кара кашлар, карашлардагы серле бәрхет томан, хәтта төссез фоторәсемдә дә алланып торган бит алмалары, кызарып-чияләнеп күренгән иреннәр — аларның кайнарлыгын, алардагы сулышның көчен, алардагы татлы тоз тәмен Тимофей бер генә минутка да исеннән чыгармады. Нәкъ шулай, җырдагыча иде: кичен ятса да, иртән уянса да — яшь солдатның уенда, күз алдында әнә шул татлы иреннәр, кыйгач кашлар, калын толымнар булды. Ул хәтта төннәрен дә Наташаның иреннәрен күреп саташты. Ә ул иреннәр, күңелне кузгатып, кайчандыр ишетелгән серле сүзләрне

---

ШУГАЕВ ВЯЧЕСЛАВ МАКСИМОВИЧ *(1938) — Татарстанның Минзәлә шәһәрендә туган рус әдибе, «Җәй уртасындагы мәхәббәт», «Аерылышу», «Сукмакта» һәм башка проза китаплары авторы. Бөтенсоюз Ленин комсомолы премиясе лауреаты. Мәскәү язучылары оешмасы секретаре. Мәскәүдә яши.*

пышылдый иде: «Төшләнгәннән теш үсми, җүләр!..» Бу сүзләрнең мәгънәсен аңламый калды Тимофей. Шуны аңлатуын үтенеп, Наташага хат та язды. «Нәрсәсен аңлатасың инде аның?! — дип җавап бирде кызыкай.— Йөрәк йөрәккә таба ашкына — менә шул. Шундый сагынам мин сине, шундый көтәм. Рәсемеңне каршыма куям да сәгатьләр буе карап утырам, күзләреңнән үбәм — төшкә керүләрең, мине төштә күрүләрең дә әнә шуннан. Миңа бер күрше әби әйтте: төштә күреп сагыну кешенең аерылып торуны бик авыр кичерүеннән, аерылышуга нәләшә, күнегә алмавыннан икән. Ә артык авыр кичерү бик зыянлы. Син минем рәсемемне югалтмадыңмы? Карыйсыңмы аңа шулай? Шундый сагынам, көтәм мин сине. Әле менә хәзер дә рәсемең каршымда, күз алдымда тора. Зарыгып көтәм. Күз яшьләрем яңгыр булып тама...»

Әйе, Тимофей да сагына, Тимофей да көтә иде кавышу көнен. Солдаттан кайтты да Наташаның иреннәренә үрелде. Хәле беткәнче, суларлык сулышы җиткәнче үпте — туймады. Ә Наташа, ут янган иреннәрен учы белән җилләтеп суыта-суыта, шаяртты:

— Их син, Тима, Тимоха!.. Һич кенә дә кызганмыйсың, сакламыйсың мине. Әле бит туйда да күпме үбешәсебез бар. Аннан соң да кирәк булачак әле ул иреннәр!

— Ә без сакланып кына... Сак кына...— дип пышылдады Тимофей, үзе һаман кызның иреннәренә үрелде.

Туй көне капка төбенә килеп җиткән иде инде. Әнә шул шаукымлы, шатлыклы, мәшәкатьле һәм буталчык көннәрнең берсендә Наташаның ахирәт дусты — Тимофей ул кызның исемен телгә алырга да теләми — үзенең күптәнге серен ачып салды:

— Күрше авылда Наташаның кызы үсеп килә, Тимофей. Туйга кадәр барып, күреп килер идең. Югыйсә, соң булып куюы бар. Җәллим мин сезнең икегезне дә. Алдан белеп торсаң яхшырак...

Күк күкрәде, әмма яңгыр яумый калды.

— Кем үсә?!

— Оля. Наташаның кызы.

— Кайсы авылда?

— Күрше авылда дим ич, Наташаның әбисендә. Өйләрен дә яхшы беләсең, солдатка китәр алдыннан Наташа белән бергәләп баргансыз. Наташа сөйләгән иде миңа, печәнлектә йоклау рәхәт дип... Кызына ел да бер ай хәзер.

— Син нигә дип тыгыласың?! Ахирәт дусты булып йөрисең тагын. Гайбәт мичкәсе син, беләсең килсә!

— Ә син миңа кычкырма, кәләшеңә кычкыр. Их, Тимофей, Тимофей. Синең аркада менә шушы дөреслекне ачканга, Наташа белән дә арам өзелә хәзер. Аңлыйсыңмы? Ә син мине гайбәтче дип атыйсың...

Тимофей дәшмәде. Күкрәгендә, кайдадыр йөрәк турысында ниндидер бер тешле тәгәрмәч шыгырдап куйганын тойды. Әйе-әйе, бу тәгәрмәч шыгырдап-шыгырдап әйләнә; моңарчы күңелдә йөргән матурлыкны, өмет-ышанычны, сафлык-чисталыкны ваклап-тураклап әйләнә иде. Ә тагын да эчтәрәк, тирәндәрәк кинәт кенә берьюлы ике тойгы баш калкытты: кычкырып, шыңшып елыйсы килүме, әллә акырып, шыркылдап көләсе килә идеме бу — монысын Тимофей үзе дә сизми калды. Һәрхәлдә, ул елый да, көлә дә алмады — шул ике тойгы эчендә бәргәләнеп, күрше авылга юл тотты, Наташаның кызын барып күрде.

Бөтерчек хәтле генә кызчык бөтен өй эчен ниндидер ягымлы җылылык белән тутырган иде. Әле әбисенең итәгенә килеп сарыла да, үзалдына нидер сөйләнеп, Тимофейның тезләренә килеп кагыла. Ниһаять, болай тиктомалга йөгереп йөрү аны алҗытты булса кирәк, күгәрчен кебек гөрләвеннән туктады да Тимофейның аякларына килеп елышты, ничектер тынып, боегып калды. Аның нәкъ курчакныкыдай ап-ак, йомшак кулларын, нәни бармакларын чалбар балагыннан ычкындырып та булмас кебек иде. Тимофей каушап, югалып калды. Ә әби кеше, егетне монда,

һичшиксез, Наташа җибәргән дип уйлап, һаман бер үк сүзләрне кабатлады:

— Күрсәнә, синң ничек тиз иялəште! Беренче күрүдә үк үз итте. Ә бүтәннәр керсә, читләшә, кача бит, балакаем. Ят кешене якын да җибәрми.

Тимофей, дөп-дөп типкән йөрәген басарга тырышып, гаепле кеше сыман ничектер сәерсенеп кенә, кызчыкны кулына алды, аның йомшак тәнен иреннәре белән, мыек очлары белән кытыклады. Аннан соң, үзе дә аңламас-белешмәс бер талпыну белән, кызны өскә чөйде:

— Кем бу шулай биеккә оча?! Кем бу шулай түшәмгә тия?!

Өй эчен көлү, кеткелдәү тавышы яңгыратты. Кызчык яңадан очынды, яңадан сөенде, яңадан җанланды. Тимофей аны идәнгә төшерде, «Исән-сау торыгыз»,— дип, әбигә баш какты. Инде чыгып китмәкче иде, карчык туктатты. Ничектер бик якын кешеләрчә кочаклап, иккә ияген тигерде: «Ярый, балакай, күрешкәнгә кадәр... Сиңа да исәнлек-саулык бирсен»,— диде.

— Нәрсә шулай өзгәләнәсең? — дип битәрләде әнисе Тимофейны.— Бик хәтәр эш килеп чыккан, имеш. Житкән кыз бәби алып кайткан. Шуны ишеткән дә, имеш, аңа инде дөнья беткән. Син бит инде малай-шалай түгел! Йөрәгеңнән чыгарып ташла да оныт. Балавыз сыгып йөрмә! Йә, нишләвең инде бу? Кая җыенуың бу синең?

— Күзем кая караса — шунда! — Тимофей инде үзен дә, үзенең үрсәләнгән йөрәген дә тәмам ышандырып өлгергән иде: югалтуны кире кайтарып булмаячак; хыянәт зур, гафу итү, кичерү мөмкин түгел. Үртәлеп, әрнеп, ярсынып өзгәләнгән йөрәкне хәзер бары тик юл, бетмәс-төкәнмәс, очсыз-кырыйсыз юл гына бераз тынычландырырга мөмкин.— Юк, кала алмыйм мин монда, әни! Наташаның күзләрен, йөзен күрәсем килми. Ә үзе ничек шаярткан, көлгән булды бит әле. Бармакларына балдаклар үлчәп йөргән булды. Әйтү юк, сиздерү юк — бер гөнаһсыз фәрештә диярсең!..

Тимофей үзенең абыйсын — кайчандыр нәкъ менә шушы бүлмәдә өстәлгә капланып елаган диңгезче абыйсын, аның үгет-нәсихәт сүзләрен нәкъ менә шул чакта исенә төшерде. Һәм кинәт үзенең дә күңелендә ниндидер кыргый бер теләк — башны бәрә-бәрә елыйсы килү теләге туды.

— Җибемә, улым, җебемә...— дип көрсенде әнисе.— Яратасың икән, шундый килеш кабул ит Наташаны, аңларга тырыш. Ә инде кичерә алмыйсың икән — уеңнан, күңелеңнән сызып ташла. Наташа гөнаһлы, тик бу гөнаһ аның үзенә дә әллә ни зур шатлык түгелдер...

— Әһә! Аның гөнаһы аңа шатлык түгел. Ә миңа соң, миңа шатлыкмы? Теләмим! Андый сөйрәлчекнең гөнаһын да, хатасын да аңларга теләмим! Ишетәсем дә, күрәсем дә килми! Йөрәкне изде, талады — мәңге гафу итәсем юк!

— Шулай, улым, шулай,— әнисе янә көрсенде.— Йөреп кайт, дөнья күреп кайт, балакай. Башыңда бераз җил уйнап алсын. Тормышны өйрәнә төшкәч, кешедән гел гаеп кенә эзләүдән арынырсың, бәлки.

— Нинди гаеп эзләү?! Эш монда гаеп эзләүдәмени?! Монда бит сүз хыянәт турында бара!

— Бар, бала, йөреп-әйләнеп кайт. Күп нәрсәләрне аңлап кайтырсың...

Соңрак, инде шактый вакытлар узгач, дөньяның ачысын-төчесен татып өлгергән Тимофей аңлады: Наташаның кызын, кечкенә Оляның алтынсу чәчләрен, баш очында зәңгәр күбәләк кебек җилпенеп торган бантикларын, нидер аңлатырга теләгәндәй үзалдына сөйләнеп йөрүен, мендәр кебек күпереп торган йомшак бит очларын ул әле һаман да исендә тота, һаман да оныта алмый икән. Нәни Оляның ничек итеп аның аякларына, тезләренә сыенуын, башын күкрәгенә куеп тынып калуын исенә төшереп, Тимофей кинәт кенә калтыранып куя; «Юкка баш

тарттым мин аннан,— дип уйлый.— Кулыма күтәреп чөйдем — шатланган-сөенгән иде. Ничек итеп көлгән-кеткелдәгән иде. Читме ул миңа, ятмы — аңа бит барыбер. Аның монда бер эше дә, бер кайгысы да юк иде. Ул бит беркемнең гөнаһын да белми һәм белергә дә теләми. Ул мине үз итте, якын итте. Ә бит барысы да минем үземнән генә тора иде, барысын да үзем хәл итә ала идем...» Наташа турында да тыныч кына, әрнү-рәнҗүсез уйларга тырышты Тимофей: «Ә бәлки бары тик ул гына минем хатыным була алгандыр? Ә мин, җүләр, язмышны төзәтергә ашыктым. Имеш, үз язмышыма үзем үпкәләдем. Олядан баш тартмый калып була иде бит, була иде!..»

Әмма вакытлыча гына туган бу йомшаклык кабаттан калкып чыккан әрнүле һәм аек уйларга урын бирә иде: «Ике ел, бары тик ике генә ел көтәсе иде ләбаса. Хәтта алай ук та түгел; ялга да кайтып килде бит әле ул чакта Тимофей. Хатларны еш яза, бик еш яза иде. Кайчан, ничек башы әйләнеп өлгергән Наташаның — аңлап та, аңлатып та булмый». Әнә шулай уйлап, Тимофей тагын рәнҗүләренә кайта, үткән көннәрдәге әрнүләре белән яши башлый. Болай яшәү кыен икәнен ул үзе дә бик яхшы аңлый һәм, шуңа күрә, үткән көн белән бүгенге көн арасына ныклы бер киртә куярга, газаплы уйларын тирән бер чүлмәккә салып, әлеге хәтер чүлмәгенең авызын ныклап бикләргә ашыга иде.

Үз эченә бикләнеп, йөрәгенең һәр талпынуын тыеп, монах тормышына охшаш буйдаклык белән яшәгән көннәре арта торды. Ул инде хәзер хатын-кызларга карамый, аларның һәр шаян сүзендә, һәр елмаюында кычкырып торган ялган һәм бозыклык күрә иде. Кая гына барып чыкмасын, кайда гына эшләмәсен — бары тик ирләр белән генә аралашты, алар белән генә сөйләшергә тырышты. Аның хезмәттәшләре, дуслары-иптәшләре салчылар, геологлар, урман кисүчеләр булды. Әлбәттә, мондый эшләрдә дә хатын-кыз заты булмый калмады. Әмма алар, үз ирләренең авыр хезмәтен бүлешүче хатыннар, яшькә дә шактый өлкән булып, сүзгә дә, күзгә дә илтифатсыз булалар һәм Тимофей күңелендә яман шик тудырудан ерак торалар иде. Кайчак шулай, озакка сузылган явымнар киткәндә, йә булмаса кечке учак тирәсенә җыелган вакытта, ару-талуларын оныткан әлеге хатыннар үзләренең өс-башын, йөз-кыяфәтен карыйлар, ничектер яшәреп, үзгәреп китәләр, күркәмрәк булып тоелалар; өйгә кайту юлын каплаган яңгыр пәрдәсен, төн карасын ярып яктырган учак сыман, ирләрнең карашын үзләренә тарталар. Әнә шундый чакта Тимофейның бар кирелеге, үҗәтлеге уяна. Нинди дә булса Маша түтәйнең ирләр карашын сизүдән яктырып киткән йөзен, каш уйнатып алуларын эчке бер ризасызлык белән күзәтә һәм үзенчә фикер йөртә: «Ни кыланганын бер дә сизми микәнни соң бу түтәй? Һәр елмаюы, һәр хәрәкәте ялган белән, ясалмалык белән тулган лабаса. Инде тәмам бөрешкән, бетерешкән үзе, ирләр күңелен алдарлык рәте дә калмаган — барыбер тырыша, кемнеңдер башын әйләндерү ягын чамалый. Шунсыз яши алмый, күрәсең: картаеп беткәч тә, кәфенгә төренгәч тә шуңа тырышачак, шуңа омтылачак. Юк, карыйсы да, күрәсе дә килми мондый оятсызлыкны!» Тимофей, кашын җыерып читкә борыла, учак яныннан ераккарак китү ягын карый. Йә булмаса палаткасына кереп ята. Динамолы кесә фонареның сабын алсыз-ялсыз кыса-кыса, ут яктысында Сергей Тимофеевич Аксаковның «Балык тоту турында язмалар»ын укый башлый.

Бервакыт ул Ангара еласының уң ярында, Невон тирәсендә күмер ятмалары эзләүче геологларга барып кушылды. Көрәк һәм кәйлә белән җир казыды, шартлаткыч матдәләр салынган авыр-авыр тартмаларны җилкәсендә йөртте. Аның буыннары шактый ныгыган, җилкәләре калынайган, ә үзе чын-чынлап ир-ат кыяфәтенә кергән, йөк аты сыман пар бөркеп эшләргә күнеккән иде. Башкалар тәмәке тарткан арада ул инде үзе казыган чокырга бил тиңеннән төшеп өлгергән була. Аның кулларында көнгә өч пар брезент бияләй туза. Ә ул куллар балтадан

да, көрәк һәм кәйләдән дә — бернәрсәдән дә ялыкмый, ару-талуны белми. Эш никадәр ныграк карышса, Тимофей да үҗәтләнә бара, үзенең шул үҗәтлегеннән ләззәт таба. Аның бар ялкыны, көче-кодрәте маңгаендагы кайнар тир булып чыга. Эштән ул бик озак суына; әйтерсең кулларына — бияләй, беләкләренә эш җитми кала, тагын нидер эзли, нәрсәгәдер барып тотынасы, каерасы-кузгатасы килә. Үзе эшләгәндә яңгыраган балта тавышын, кәйлә-көрәк авазын ишетеп, төшләрендә елмая иде Тимофей.

Аның шулай эшкә аеруча ихлас булуын табордагы берданбер хатын-кыз — аз һәм тупас сүзле, төссез һәм гамьсез күзле, шәлперәйгән иякле Неля да күреп алды. Әлеге хатынның кычкырмыйча, җикеренмичә сөйләшкән чагын, мөгаен, монда бер генә кеше дә күрмәгәндер. Чыннан да, Неля һәрвакыт ачуланып сөйләшә, хәтта аш бүлгәндә дә: «Ашаудан башка бер генә юньле эшегез дә юк! Бу якларга сез кеше күзеннән качып тыгыныр өчен генә килгәнсез! Ярты хезмәт хакын тамакка тыгып барасыз!» — дип җикерә. Табакка ботка салганда да Неляның тавышы кашык-чүмеч чыңлавы белән бергә кушыла: «Мәгез, тыгыныгыз, ач бүреләр!» Әмма, шуңа да карамастан, ә бәлки нәкъ менә шуның өчендер, Неляның ашын һәркем яратып, тәмләп ашый, аның сукрану сүзләре бары колакны иркәләп, аппетит өстәп тора сыман иде. Ирләр инде аның тупас сүзләренә тәмам ияләшкән, күнегеп беткән. «Менә егетләр, Неля түтәгез кыздыра бүген! Бил мәсьәләсе шулай усаллан дыра аны, бил мәсьәләсе!» — дип көлешә-көлешә, пешекче хатынның тулып, күпереп торган ярымшарларына һәм юанаеп барган гәүдәсенә ишарә ясыйлар.

Август башлары иде. Җомга көннең җылы матур бер кичендә Тимофей эштән соңлабрак кайтты. Елга ярында көймәләр булмавын күреп, гаҗәпләнеп, таборга күтәрелде — Неля бер ялгызы гына аш-су әзерләп йөри иде. Хатындагы ниндидер бер үзгәрешне Тимофей шунда ук шәйләп алды: Неля иркен, киң нейлон халат кигән, әлеге халатының түшенә кызыл тасмалар бәйләгән. Юеш чәчләре күпереп, әле генә мунча кереп чыкканнан соң, йөзе, яңаклары алсуланып, яшәреп киткән. Күзләреннән кайнар бер яктылык сирпелә. Тимофей тагын шуны искәрде: Неляның гел сукранырга, сүгенергә яраткан иреннәре елмая да белә һәм ул иреннәр шикәрдәй ап-ак тешләрне яшереп торган икән бит. Ул башта аптырап, исе китеп карап торды. Аннан соң гына:

— Ә көймәләр кайда? — дип сорады.

— Ирләр Невонга китте.

— Ничек инде? Нәрсәгә?

— Күптән җыенып йөриләр иде бит. Бүген кибеткә әйбер күп кайткан анда. Сельпо көймәләре янәшәдән генә үтте.

— Һы. Ә миңа әйтү юк. Миңа, алайса, бармак суырып ятарга гына кала. Әйбәт инде, булдырганнар, рәхмәт.

— Сиңа да әйткән булырлар иде, тик мин бутадым аларны. Сине аучылар белән китте дидем. Шулай тоелган иде.

— Кайчан әле син минем аучылар белән киткәнемне күрдең?

— Катерда сиңа охшаган бер кеше бар иде. Шакмаклы күлмәктән. Берәр нәрсә кирәк булгандыр да ашыккансыңдыр дип уйладым.

— Минем кайчан эш ташлап ашыкканым бар?! Аңа шулай тоелган имеш.

— Шул шакмаклы күлмәгең аркасында инде.

— Һе, шакмаклы күлмәк күргән имеш, күзе үткенләнгән берәүнең!

Неляның йөзе яңадан төссезләнеп, тупасланып калды.

— Әйдә, утыр да аша,— диде ул һәм сап-сары итеп юылган өстәл тактасына корымланып беткән табаны китереп куйды.— Артык күп сөйләшә башладың.

Әнис һәм суган турап, тәмләткечләр салып кыздырылган яшь бәрәңгедән кайнар пар бөркелә, тәмле ис борыннарны кытыклый иде.

Неля майда кыздырылган балык һәм сарымсак белән казылык та китереп куйгач, табынга бөтенләй бәйрәм төсе керде.

— Ярар, сөйләшмим, әсир партизан кебек, бер сүз дә дәшмим,— Тимофей җайлабрак утырды, күлмәк изүләрен ычкындырды — алда бик тә җаваплы һәм зур эш, тәмләп тамак ялгау эше тора иде.— Әгәр мине болай сыйлый торган булсалар, гомер буена сөйләшмәскә дә риза.

Неляның йөзе кабат яктырды, аның көмештәй тешләре яңадан күренде:

— Шулай диген аны. Аша, әйдә, тәмләп аша.

Яр буенда ял итеп, дулкынга таш ыргытып йөрде Тимофей. Үзе һаман елганың сул як ярына, Невонның йортлары күренгән якка күз салгалады. Анда инде тиздән утлар кабыначак, җемелдәп-җемелдәп үзенә дәшә башлаячак иде. «Ә безнекеләр хәзер клубка җыелгандыр,— дип уйлады Тимофей. Үзе, ирексездән, рюкзакларын, кием-салым, азык-төлек тутырган иптәшләренең авыл клубына шау-гөр килеп кереп тулуларын күз алдына китерде. Шулай ук, клубның калын, сап-сары нарат бүрәнәләрен күзаллап куйды, фуражкасын кыек салып йөргән гармунчы Гошаның иләсрәк тавышын ишеткәндәй булды: «Ә-һәй, ярдагылар! Колакларыгызны шомрайтыгыз, күзләрегезне ныграк ачыгыз! Сезнең игътибарга — күмәк бию!..» Гоша шулай дип кычкыра да берьялгызы биеп китә. Кыстатып-нитеп тормый, кирәк икән — җырлап та җибәрә. Оркестрларың бер читтә торсын. Биергә керүчеләр парлашып өлгергән арада кино башланыр вакыт та җитә. Хәзер инде Гоша киномеханик булып әверелә. Әмма аның җорлыгы, шуклыгы, исәрлеге һич тә үзгәрми кала. Кайчак ул, аппаратны көйләп-кабызып җибәрә дә сиздерми-нитми генә залга кереп утыра. Әллә ни озак көтми: кинәт утны кабыза. Җүләргә кызык — кемнең кем белән ничек кочаклашуын күреп, шуннан рәхәт табып көлә. Кызлар оялышып кычкырыша, егетләр куеныннан читкәрәк елыша. Ә егетләре исә, тыйнак бер оялчанлык белән генә, йодрыкка йөткереп куйган була. Арада берәрсе, Гошаның муен тамырын кашып алырга теләп, урыныннан кузгала. Әмма өлгерә алмый: тегесе инде, утны сүндереп, чыгып йөгергән була.

Тимофей, Невон клубының бөркү һавасын, андагы өметле караш-ларны тойгандай булып, үзалдына елмаеп куйды. Әмма монда, яр буенда, барыбер рәхәтрәк иде: салкынча булып барган төн һавасы чебен-черкине куа, үзенең җиләслеге белән күңелне иркәли, яшәүнең тәмен, ләззәтен искәртә.

Өстән, табор ягыннан, калак, пычак, чәнечке һәм савыт-саба тавышлары яңгырап ишетелә. Неля әле эшен тәмамлап өлгермәгән — юа, җыештыра. Савыт-саба шалтыраган тавышка аның үз сукранулары да килеп кушыла: «Тапкан ял итеп утырыр урын, гомер буена су күрмәгән диярсең. Ашыйлар-ашыйлар да ата мәче кебек, яр буена олагалар». Тимофей Неляның сүзләрен тыңлап-тыңлап торды да шуны аңлады: сүгенеп-сукранып алу бу хатын өчен бер җырлап алу кебек үк зарури нәрсә икән бит. Аерма бары тик шунда гына — Неляның көе дә, сүзләре дә гел бер төсле генә. Әнә бит, учак янындагы шаман сыман, мырлап-мыгырданып ала, үзенчә нидер укына. Кем белә, бәлки аның сүзләре фәрештәләр колагына барып ирешәдер дә, Неляның аш-суы тәмле булып чыгадыр. Карыйсың — барысы да тәртиптә, барысының да тамагы тук, барысының да кәефе күтәренке, барысы да канәгать.

Тимофей яр өстендәге маякка, сигнал баганасы янына күтәрелде. Бу багананы алар үзләре томанлы, яңгырлы көннәрнең берсендә куйганнар иде: бер тапкыр шулай, Невоннан кайтышлый, таборны шактый узып китеп тукталганнар. Багананы шуннан соң утырттылар. Тимофей, маякның тәрәзәсен ачып, пыяласын сөртте, лампасына ягулык өстәде.

Неляның тавышы тынды. Мөгаен, үзенең палаткасына кереп киткәндер. Якындагы урманнанниндидер кошның ялкау һәм тоник тавышы ишетелә. Күрәсең, ул да көне буена эшләп, кычкырып арган. Тимофей

тагын бер кат елганың аргы ярына күз салды. Невонның йортлары печән чүмәләләре кебек булып кына күренә иде. Авыл, әле утлар, йолдызлар кабынып өлгергәнче, тонык караңгылыкка һәм сүрән тынлыкка чумган.

Елга өстендә алтынсу-зәңгәр төсләр биешә. Әлеге төсләрнең кайдан килүен аңлау да кыен. Көн инде соңгы болытлар артында югалып бара, ә йолдызлар әле кабынып өлгермәгән иде.

Тимофей татлы һаваны иркен итеп сулады да таборга таба борылды. Хәзер ул үз палаткасына, үз почмагына кереп түнәчәк тә кесә фонаре яктысында балык тоту серләрен өйрәнәчәк. Һәм бүгенге озын көн бәхетле тыныч халәттә тәмамланачак.

Палаткасының читен ачуга, бер мәлгә каушап, артка чигенеп куйды Тимофей. Анда иң түрдә, кызыл тасмалы нейлон халатының изүләрен киң ачып, түгәрәк тез башларын ялтыратып, Неля утыра иде.

— Син нәрсә? — Тимофей, үзе дә сизмәстән, як-ягына күз салды.— Палатканы бутадыммы әллә мин?

Юк, палатканы бутамавын, нәкъ менә үз урынына, үз почмагына кереп баруын Тимофей яхшы белә иде. Шуңа күрә дә, Неляның монда ачыктан-ачык басып керүеннән куркып, тәмам коелып калды.

— Сине көтәм,— Неля кисәк кенә алга үрелде дә Тимофейны, кулыннан эләктереп, әчкәрәк тартты.— Аучылар турында алдап кына әйттем мин сиңа. Ирләрне дә Невонга юри алдап җибәрдем. Синнән башка гына китсеннәр дип.

— Ә соң син миннән сорадыңмы?— Тимофей кулын тартып алмакчы булды. Әмма Неля аны шактый нык эләктергән иде.

— Ярар, җитәр лә инде! — дип пышылдады ул һәм, Тимофейны үзенәрәк тартып, кочаклап алды. Нейлон халаттан очкыннар чәчрәп, Тимофейны ниндидер яшен сугып үткәндәй булды.

— Сулыш алырга ирек бир ичмасам!..

— Ярар, инде, кыланма шулай... Нәрсәгә дип киреләнәсең?.. Кил якынрак... Менә шулай. Җитмәсә үзең геолог булып йөрисең тагы...

Озак та үтмәде, геологлар яныннан бөтенләйгә китеп барды Тимофей. Елганың сул ярындагы бер карьерга тракторчы булып урнашты. Неляның талымсыз иркәләүләре, хисләрендәге комсызлыгы, теләкләрендәге әрсезлеге куркытты аны. Кыскасы, гөнаһтан ераграк качарга тырышты ул. Китүен китте, әмма үзендә ниндидер үзгәреш тә сизеп йөри башлады: Неляның калын, киң җилкәсе, әрсез-талымсыз таләпләре хатын-кызга карата булган нәфрәтен, ышанмау, якын җибәрмәү хисен каплый язган икән бит. Хәзер инде Тимофейда хатын-кызларга карата түземлерәк караш, үзара тыныч яши алу мөмкинлеге барлыкка килде. Алар белән ара-тирә булса да аралашырга, күзгә бәрелеп торган хәйләләренә кайчак күз йомарга, кычкырып торган җилбәзәк тавышларын ишетми калырга мөмкин икән. Әмма мондый риза-бәхиллек вакытлыча гына бер хәл булып, бары тик атнаның ял көннәрендә мунчага барып кайту кебек кенә бер күренеш иде.

Әле моннан тыш, йөрәгенең мең төрле икеләнүләренә, әрнүләренә, ай-ваена карамастан, Тимофей хыялында тагын бер нәрсә — үзенә бик тә якын булырга, кайчан да булса бер очрарга тиеш хатын-кызның әле ачыкланып та бетмәгән төсмерләре, буй-сыны, йөз-кыяфәте яши иде.

Әйе-әйе, Наташаның хыянәте һәм ялганы белән беррәттән, Неляның артык беркатлы һәм дуамал гадәтләреннән тыш, тормышындагы ачы сабакларга да карамастан, үзен гел сиздереп-сиздереп куйган якты хис — бердәнбереңне табу хисе Тимофей йөрәгендә тамыр җәеп өлгергән иде инде. Әнә шул хыялда гына йөргән бердәнбер ярны җәйнең иң җылы җилләре иркәли. Аның зифа буена килешеп торган зәңгәр күлмәге офыкларга барып тоташа. Кинәт ачылып-ачылып киткән зур, якты күзләре елмаеп та, моңаеп та карый, үзенә дәшә. Ә иреннәре ниндидер ягымлы, җылы сүзләрне кабатлый. Һәм бу сүзләр, һичшиксез, Тимофей турында әйтеләләр. Тимофей ул сүзләрне тыңлап, ишетеп туя алмый:

куллары белән дә, йөрәге белән дә, жаны-тәне белән дә әнә шул хыялындагы ярга — бердәнберенә тартыла. Сак кына, курыкмыйча гына, тупаслык күрсәтмичә генә назларга, иркәләргә тели. Юк-юк, Тимофейның бердәнбере хәтта хыялда да гел буйсынучан, өй мәшәкатьләре белән генә яшәүчән кеше түгел. Алар, һичшиксез, үзара килешеп, бергә-бергә эшләп көн итәчәкләр, балалар үстерәчәкләр. Тимофей күз алдына китерә: алар икәү, ишек катындагы болдырга утырып, ерак-ерак илләр, чит-ят җирләр турында, бу фани дөньяны урап алган мажаралар турында сөйләшәчәкләр. Ә сүзләрендә бернинди гаеп, бернинди гайбәт, бернинди шик-шөбһә булмаячак.

Үзе күрергә теләгән йөз-кыяфәтне, үзе табарга теләгән карашны очратты Тимофей: зәңгәрсу күзләр, якты, киң маңгай, сәламәтлек һәм йөз яктысы бөркеп торган алсу яңаклар. Фоторәсеме астында кызның һөнәре дә язылган иде. Тегүче. Тормышта көн итәр өчен менә дигән: иренең дә, балаларының да өс-башы бөтен булачак. Тегүче кызга шундый хат язып салды Тимофей: «Хөрмәтле Зина, мин үзем Ангара ярындагы бер төзелештә эшлим. Тракторчы. Солдатта чакта берничә һөнәр үзләштердем. Сезнең белән танышырга телим. «Работница» журналында чыккан рәсемегез миңа бик ошады. Йөз-кыяфәтегезнең мөлаемлыгы, яктылыгы тартты. Каршы килмәсәгез, мин дә сезгә үз рәсемемне җибәрә алам. Сез ул рәсемдә җирән чәчле, мәрхәмәтле һәм хөр күңелле кешене күрерсез. Кыяфәтем ошаса, күрешә дә алыр идек. Үзегезне күреп, тормыш турында ныклап сөйләшү турында өметләнәм. Кайда, ничек очрашасын гына килешербез дип уйлыйм. Еракта гы якын дустыгыз Тимофей Неженатов. Урынсыз шаяруым өчен гафу үтенәм. Чын фамилиям — Воробьев. Монысы да, шулай ук, көлкерәк фамилия. Сау булыгыз, хөрмәтле Зина. Сездән җавап көтәм.»

Тегүчедән җавап озак көттермәде: «Исәнмесез, Тимофей Воробьев! Хатыгызны алдым. Хат-хәбәр өчен чын күңелдән рәхмәт. Ангара кебек матур елга ярында яшәвегезне белгәч, үзем дә, ирем дә бик нык соклаunion, сезнең өчен шатланып куйдык. Хатыгызны укыганда, бездә тагын бер кеше — якын дустым Алла бар иде. Ул безнең комбинатта эшли. Шулай ук, алдынгы тегүче исеменә лаек булды. Хатыгыз аңа бик ошады. Ул кыз Себер белән дә, андагы казылма байлыкларны үзләштерү белән дә күптәннән кызыксына икән. Истәлек өчен бергәләп төшкән фоторәсемебезне җибәрәбез. Иремнең сул ягында — дустым Алла. Ул тулай торакта яши. Анда килгән хатлар кайчак юкка да чыккалый. Шуңа күрә, Аллага язган хатыгызны безнең адреска җибәрегез. Без аңа, һичшиксез, тапшырырбыз. Рәсемегезне, хатыгызны көтәбез. Сезгә Себер кебек озын гомер, ныклы сәламәтлек теләп калабыз».

Тимофей рәсемгә текәлде: калын иякле, юан гәүдәле бер прапорщик, колачларын җәеп, ике хатын-кызны кочаклап төшкән иде.

Кап-кара күзләрен кысыбрак, нәрсәнедер төбәлеп күзәткәндәй карап тора. «Амбар күсесенә охшаган» — дип, башта ук өнәп бетермичә карады Тимофей прапорщикка.— Кара әле син аны, күзләрен ничек итеп кыскан. Бер-бер затлы мал эләкмәсме, дип тырышуыдыр. Эләктереп киткәнен көт тә тор...»

Алдынгы тегүче Алла үзенең ихлас күзләрен зуррак ачарга тырышкан. Болай да зур борыны ап-ак булып, аерылып тора. Фотога төшкәндә, ашыга торгач, пудраны күбрәк ягып ташлагандыр. Тимофей шулай дип фараз кылды. Алла аңа ягымлы, беркатлы, тырыш һәм тыйнак кыз булып күренде. Мөгаен, мондый кыз белән тормыш корып җибәрү дә мөмкин булыр иде. Әмма Тимофейның күңелендә үҗәтлек баш калкытты: «Беләм мин ул ахирәт дусларны,— дип уйлады ул һәм, тегеләрнең уен белергә теләгәндәй, рәсемне читкәрәк этәреп карады.— Нинди дә булса мөгез чыгаруны иң якын дусларыннан көт. Ә бу прапорщик нишләп әле кулын Алланың иңенә салган? Кем әле аңа Алла шулкадәр — сеңлесеме, әллә балдызымы? Юк инде, кызыкайлар, гафу ите-

гез, әмма мин адресыгызны онытыбрак торырмын. Гаепләп калмагыз, дус һәм тату яшәгез». Тимофей тегеләрне үртәп көлде дә хат белән рәсемне агач тартмага шудырып төшерде. Абыйсы бүләк иткән шушы тартмада Тимофей үзенең уңмаган язмышы истәлекләрен саклый иде. Кайчак ул шушы тартмадан Наташаның хатларын эзләп таба һәм үзенең ваемсыз, гамьсез солдат чакларын тоташ бер рәсем, тулы бер күренеш итеп күз алдына китерә. Даладагы хәрби гарнизон. Офыкка кадәр сузылган зәңгәр киңлек, соры сопкалар. Наташаның чираттагы хаты. Тимофей, гөлҗимеш куагы астына яшеренеп, хат укый... Аның күз алдында сентябрьнең пәрәвезле көне калкып чыга, җанын шул чактагы хатларның ялкыны җылыта, шул чактагы ышаныч-өмет күңелен иркәли башлый. Һәм Тимофей, әнә шул өметне җуймас, югалтмас өчен, Наташаның хыянәтен дә онытып торырга, бөтенләй истән чыгарырга тырыша. Шуны оныта да, үзалдына калтыранып, түземсезләнеп, чын күңеленнән хыялланырга керешә: нинди матур өй салырлар иде алар; кунакчыл булыр, якты булыр иде ул өй... Менә ул, үзенең улларын ияртеп, урманга таба китеп бара. Яңа ел бәйрәменә чыршы алып кайтырга бара алар. Тимофей бу урман юлын ничек үтүләрен, чыршыны ничек кисеп, ничек алып кайтуларын, өй эчендәге бәйрәм-шатлыкның нинди булуын кабат-кабат кайтып, тәфсилләп тә, гаепләп тә күзаллый иде.

Абыйсы бүләк иткән бу тартмада җилемнән ясалган уенчык алтын балык та саклана иде. Наташаның кызы барлыгын ишеткәч, күрше авылга барганда сатып алган иде бу балыкны Тимофей. «Әгәр ул кыз чынлап та бар икән, әйдә, бәхетсез абыйсыннан бер кияү бүләге булсын!» — шулай дип, үртәлеп-үрсәләнеп алган иде. Әмма беркемнең дә бәхетсезлеген санга сукмаган, бернинди югалту белән дә исәпләшмәгән, бары тик үз дөньясына бирелеп, балкып, уйнап-көлеп йөргән шул тере җанны күргәч, аңа дип алынган алтын балык тәмам исеннән чыккан. Әйтерсең, әнә шулай еллар үткәч, бер сагынып карасын дип, язмыш бу бүләкне Тимофейның үзенә юри кире тоттырып җибәргән. Һәм менә, чынлап та, Тимофей әлеге балыкны кулына ала, аның йомшак саңакларыннан сыйпый, җиңел генә кысып, сызгыртып карый. Үзендә ниндидер бер баш җитмәс теләк барлыгын — Оляны күрергә теләвен тоеп, көрсенеп куя. Бәлки хәтердә шундый нәни, шундый йомшак зат булып калгангадыр, Оляның үсмер йөрәге нидәндер, нәрсәдәндер бик нык куркынган, яклауга, ярдәмгә мохтаҗ булып тоела Тимофейга. Агач тартмада Неляны искә төшерердәй бер генә истәлек тә, хат-фәлән дә, хәтта бер саргайган яфрак кисәге дә сакланмаган иде. Неля, күрәсең, үзенең тыеп та тыелмас хисләре, шул тупас хисләренең талымсызлыгы, ялкыны һәм көче белән генә хәтергә кереп калырга уйлагандыр. Әмма Тимофей күңеленә айлы төннәр белән дә, көзге сукмаклар, сагынып-саргаеп язылган хатлар белән дә бәйләнмәгән Неляның хисләре җавапсыз калды. Хәер, үткәндәге хатирәләр коесына Тимофей сирәк бакты, хәтта карамаска, күз салмаска тырышты кебек. Ә чынлыкта исә ул нәкъ әнә шул коеларның суын эчә, сусавын шул коелар аша баса иде.

Аның буйдаклык белән төссезләнгән, ягымлы караш тоймаудан томаланган холкы тора-бара тагын да сәеррәк булып китте: ул инде тирәюньдәге хатын-кызларны бөтенләй диярлек күрми башлады, аларның мәгънәле карашларын, чакыру авазларын сизмәде-тоймады. Ир җилкәсенә, ышанычлы һәм нык кулларга сусаган ялгыз хатыннар төркеме уртасыннан кичереп булмаслык бер салкын канлылык белән үтә бирде. Төрле кәгазь эшләрен башкарып яшәүче оешмалардагы чибәр-чибәр туташлар һәм ханымнар аның артыннан эчке бер рәнҗү, өмет һәм сагыш, ярату катыш каргыш җыеп калды. Әмма Тимофей борылып та карамады, назга сусаганга — наз, өметкә сусаганга өмет бирмәде.

Ә үзе ул һаман өметләнде. Хыялында йөрткән бердәнбер, үзенә генә дигәне, ягымлысы һәм якты йөзлесе, эзләп-эзләп тә табылмаган кешесе турында уйлады. Тимофейга кайчак шулай да тоелды: ул ярны

табу өчен башта әле, әкияттәге баһадир кебек, урман-суларны кичәргә, җиде башлы Дию пәриенең җиде башын да чабып өзәргә, читлеккә ябылган таң былбылын эзләп табып, аның нурлы йөзләренә багарга кирәк. Аны тизрәк табу өчен алтын яллы аргамак булып чабарга, күк күгәрчен булып, зәңгәр күкләрне гизәргә кирәк. Шулкадәр бирелеп, онытылып хыяллана Тимофей — күгәрчен булып очуын гына күзаллап калмый, үзенең канат каккан тавышларын да ишеткәндәй була. Шул бердәнберенә илтер юлны эзләү аның яшәү мәгънәсенә әверелә, көннәр белән төннәр бер-беренә бары тик шул хакка гына ялгана.

Ни генә кылса да, нәрсә генә эшләсә дә, аның уенда әнә шул бердәнбере, тиңе, яратканы була. Балта тотса да, йорт нигезе салса да — бары тик аның өчен. Тимер юлда шпаллар тезсә, борылып-борылып карап куя: күзәтеп тормый микән, күрми микән? Янәшәдән генә үтеп баруы түгел микән? Йә булмаса, бүтәнчәрәк уйлана: күрде микән ул Тимофейның ничек эшләвен? Аның беләкләрендәге көчкә, йөрәгендәге дәрманга игътибар итте микән?

Шулай түземсезләнү, шулай ашкыну кайчак көлке хәлгә, кыен хәлгә дә калдыра Тимофейны. Әйтик, йөк төяп килгән баржа, ярга җитә алмыйча, төпкә утырып калган. Бозлы суны билдән ерып йөк ташу өчен үзе теләгәннәр генә бара, андый чакта Тимофей иң беренчеләрдән була. Соңгы капчыкны бушатканчы, соңгы тартманы ярга аударганчы тырыша, бозлы судан чыкмый, җилкәсен турайтмый. Кат-кат әйтелгән рәхмәт сүзләре дә, шул ук рәхмәт йөзеннән сузылган кружка да кирәкми аңа. Әлбәттә, кружканы алыр, җиңен иснәп, пошкырып та куяр. Әмма күзе ярда булыр, башында уй йөрер: «Карап тормады микән? Күрмәде микән?..»

Кайнар мунчага кереп, тәнен җылытыр. Аннан соң, киемнәрен алыштырыр да, Невон мәктәбенең элекке завучы — күптиражлы газета редакторы янына чабар.

— Әй, корреспондент, ишеттеңме әле: болынлык янында баржа утырган иде?

Редактор, яшь кенә булса да, шактый коры егет:

— Ишетмәдем, күрдем,— дип җавап бирә.

— Ярдәмгә килүчеләр шактый иде.

— Син нәрсә, санап тордыңмы әллә?

— Санадым.

— Газетага мәкалә язып бир, санаган булсаң.

— Юк, мин бит корреспондент түгел. Мин анда үзем эшләдем.

— Без барыбыз да эшлибез.

— Карале, мин сиңа сөйләп торыйм, ә син яза бар!

— Нәрсә турында? Синең баржа коткаруың, герой булуың турындамы?

— Герой итү кирәкми. Ничек булсам, шулай итеп яз.

— Мактанчык адәм икәнсең. Калкавыч кебек, гел өскә калкырга тырышасың.

— Минме? Мин калкавычмы? Кармакны алай кисәк тартма син, туган: балык атылып чыгар да койрыгы белән маңгаеңа бәрер.

— Янасам, үзем турында яздыра алырмын дип уйлыйсың инде син.

— Туктале, нишләп яныйм ди мин?! Син минем турыда язасың, ә мин сиңа хөрмәт күрсәтәм. Кызмыйча гына, акыл белән генә уйла.

— Әһә, димәк, акыл һәм хәйлә белән генә эш итәсең. Макталасың килә. Ялагайлык күрсәтәсең.

— Юк, ялагайлык белән түгел, яхшылык белән. Күреп торасың бит: син миңа начар сүзләр әйтәсең, ә мин гел яхшылык белән җавап бирәм. Менә бит мин нинди кеше!

— Ярар, әйтеп тор алайса. Нәрсәләр язарга синең хакта?

— Юләр сатма! Әйтеп тор, имеш...

— Үзе сорап килүчеләр турында беренче тапкыр язуым лабаса.

— Соң, үзең тап инде сүзләрен. Баржаның төпкә утыруы турында яз. Минем шунда ук ярдәмгә ашыгуымны, бозлы суга сикерүемне әйт. Мине беркем дә кумады, мәҗбүр итмәде. Үзем теләп кердем суга. Соңгы капчыкны да үзем чыгардым. Түздем, чыдадым!

— Ах, мәнә нинди каһарманнар белән яшибез икән без! Белмәгән идек...

— Яки бүтәнчәрәк башла. Ничектер, күңел сизенгән минем. Елга буена барасы иттем. Әйдә, мин әйтәм, яр буенда йөрим әле бераз. Килсәм, баржа янтаеп калган.

— Карале, бәлки гадирәк итеп язаргадыр, ә? Мәсәлән, болайрак: фәлән-фәлән иптәш, дан-шөһрәт яулар һәм чиратсыз гына квартира алу өчен, сайга утырган баржадан йөк бушаткан. Ничек?

— Яшь күренсәң дә, тешләрең калмаган. Тешләшәсең, тешләшәсең — киемне дә ерта алмыйсың. Нәрсәгә дип миңа бәйләнәсең инде, я? Ник котырасың?

— Әрсезлегең котырта.

— Нинди әрсезлек тагын?

— Фәкыйрьләр әрсезлеге. Ник кирәк сиңа газетада чыгу? Кул сузып, башың белән тыгылып керәсең. Шул буламыни инде тыйнаклык?

— Соң, анда бит ялган нәрсә юк. Барысы да дөрес кенә була.

— Үзеңне күреп алуларын теләсәң — читкәрәк кит, күзгә кермә!

— Һе! Аттың, әмма тигерә генә алмадың. Минем хакка газетада бер яхшы сүзен җәлли. Вәйт кеше!

— Үзеңне күр син! Макталган бер тиен үзен өч таңкә дип хис итә башлый икән.

— Миңа макталу кирәкми. Миңа үземне күреп алулары кирәк.

— Әрсезләр авылында иң беренче егет буласың икән.

— Аңла син, ниһаять, аңла, ә?! Яхшы кешеләр күп, бик күп бу дөньяда. Барысын да күреп, аерып бетерү мөмкин түгел. Мәнә мин дә шулай: намус белән эшлим, иптәшләрне кыен хәлгә куймыйм, озын берлек артыннан чапмыйм. Бер генә теләгем бар: күрсеннәр мине, ничек эшләвемне күрсеннәр. Акча сорамыйм, бүләк сорамыйм, бары тик билгеләп үтүне генә сорыйм. Күп түгел лә инде бу.

— Алай бик аз да түгел.

— Көннәр үтә, еллар үтә, аңлыйсыңмы? Ул көннәрдән бер генә эз дә калмый. Ә мин үземнең гомерне кәгазьдә генә булса да язып калдырырга телим. Балалар укыр, оныкларым укыр дип.

— Язып калдырмасаң, сүзгә генә ышанмаслар дип уйлыйсыңмы?

— Сүзгә дә ышанырлар ышануын. Тик мин үзем кәгазьгә төшкәнне ышанычлырак күрәм.

— Тезләнеп ялварырга уйламыйсыңмы соң?

— Ташла шул гадәтеңне... Нинди булсам, шулай итеп яз. Кая синең теге тутыкмас каләмең? Утыр да эшкә тотын әйдә, минем тормышны, язмышны сурәтлә!

Әлеге мәкалә «Тимофей һәм баржа» дигән исем белән басылып чыкты. Иптәшләре, тулай торактагы бүлмәдәшләре шактый вакыт шаяртып йөрде: «Мәнә кем белән яшибез икән ләбаса!» — дип. Тимофейның җилкәсеннән кактылар. Ә ул үзе газетаны ачып та карамады. Әллә ничек кыен һәм күңелсез булып китте аңа. Юкка үгетләде хәбәрчене, юкка җиңеп маташты аның кирелеген. Мәгънәсез эш килеп чыкты. Кем күреп алсын Тимофейны шул мәкаләгә карап? Кемгә кирәк ул бу тормышта? Шунда ник йөз мәкалә язып карамыйсың — беркем күрмәячәк, беркем борылып карамаячак.

Мәнә шулай мең үкенү, мең икеләнү белән яшәде Тимофей. Үзенең тормышын ничек тә үзгәртергә, тирәнәеп килгән гадәти эздән чыгарырга, язмышын бүтән юлга җибәрергә тырышты. Кайчак, кабаланып, ашыгып, көлке хәлдән — гонаһка, гонаһтан көлкегә килеп юлыкты. Әнә шулай икеләнүле уйлар өермәсен, газаплар буранын ерып атлаган

чакта кинәт кенә тукталып калып: «Нишләргә соң? Нәрсә кирәк, кем кирәк миңа? Кемне эзлим, кайлардан эзлим?» — дип, үз-үзенә сорау биргән чаклары да булды. Мондый чакта маңгаеннан кайнар тир бәреп чыга, йөрәге сыкрый, әмма ул көткән җавап табылмый кала иде. Май башында, яңгыр катыш кар яуган көннәрнең берсендә, нәкъ әнә шундый уйлар, шундый газаплар белән эштән кайтты Тимофей. Тулай торакның ул яшәгән бүлмәсеннән, ярым ачык тәрәзә аша шаркылдап көлешкән тавышлар ишетелә иде. Бүлмәгә атылып, очып диярлек килеп керде: дусты Костя Родионов чираттагы ялдан кайткан икән. Шактый озын ялын Костя файдалы үткәргән — Балтик буе республикаларының тормышы, көнкүреше белән танышкан. Күчтәнәчләр белән, үзе әйтмешли, милли тәм-томнарның әчесен дә, төчесен дә шактый төяп кайткан. Әлеге күчтәнәчләр, әлеге тәм-томнар, күз явын алып, кызыктырып, ялтыравык кәгазьләре белән балкып, тулай торакның сынык аяклы өстәлендә — табын уртасында торалар иде. Костя тәрәзә төбенә менеп кунаклаган. Бүлмәдәгеләрне үзе алып кайткан «Танышулар газетасы» белән таныштыра.

Тимофей, ишек төбендә тукталып, чираттагы көлү тавышлары тынганын көтте.

— Исән-сау әйләнеп кайттыңмы, Костя?

— Әһә! Менә тагын бер кияү табылды! — Костяның артык күп көлүдән яңгыравыкланып калган тавышы һаман да суынып бетмәгән иде әле. Һәм бу тавыш чатнап ярылыр да кисәкләре идәнгә сибелер кебек иде.— Әйдә, түргә уз, дускай! Без монда барыбыз да кияү булырга җыена идек әле. Син соңгарак калдың, үпкәләмә. Әһә! Менә сиңа да бер кәләш бар: «Ягымлы, зифа буйлы, мөлаем табигатьле, иреннән аерылган хатын, буе 166 сантиметр, ярата һәм яратуны аңлый белә торган 30—40 яшьләрдәге тормыш юлдашы табарга өметләнә». Йә, Тимофей дус, җавап бир! Ярата беләсеңме син?! — бүлмәне шаркылдап көлгән тавышлар яңгыратты.— Ә бәлки яратуны аңлый белмисеңдер, ә?

Тимофей Костяга йодрыгын селкеде.

— Аңлашыла, — дип сузды Костя.— Димәк, син яратуның кадерен белмисең. Ә бәлки ышанычлы дус була беләсеңдер? Ул чакта рәхим ит. «Мәрхәмәтле, начар гадәтләргә ия булмаган шат күңелле югары техник белеме булган ышанычлы дус эзлим. Үзем турында шуларны әйтә алам: миңа 32 яшь, буй-сыным күркәм, кыяфәтем сөйкемле, холыкфигылем сабыр, өйдә эшләргә яратам». Юк, Тимофей дус, монысына өметләнеп тә маташма, үзең болай яхшы гына кеше булсаң да, югары техник белемең юк. Шулай да, борын салындырырга ашыкма, техник белемне шәхси тормыштан өстен куймаган хатыннар да була дөньяда!

Костя тәрәзә төбеннән җиңел генә шуып төште дә, кызыксынуны тагын да арттырырга теләп, кулындагы газетасын селкеп алды.— Ул ялгыз һәм ятим хатыннарның барысын да Тимофей дуска бүләк итик әле! Беренчедән, ул бераз соңгарак калды һәм күп гәпләребезне ишетеп өлгәрмәде. Икенчедән, Тимофей — төпле кеше, нинди дә булса бер асыл кошны эләктереп куюы да мөмкин...

Костя, кулын күкрәгенә — йөрәк турысына куеп, Тимофейга баш иде дә газетаны аңа тоттырды:

— Рәхим итегез, хөрмәтле кияү! Игътибар белән укып чыгыгыз.

— Укырмын, җентекләп карармын,— дип вәгъдә бирде Тимофей һәм бу сүзләрен чынлап әйтте. Чөнки ул вәгъдәне уйнап-шаяртып бирә белми һәм уйнап сөйләшүне өнәп тә бетерми иде. Әмма аның нәкъ менә шул җитди сүзләре бүлмәдәгеләрне дәррәү көлеп җибәрергә мәҗбүр итте. Мондагыларның күбесе Тимофейның, бик сирәк булса да, кайчак шактый оста шаярта белүенә ышанып куйды.

Башкалар үзара гәпләшеп, тәмәке тартып торган арада Тимофей «газета»ны өйрәнеп, карап та чыкты. Башта, кулына карандаш алып, үзенә якын дус эзләүчеләрне исемлектән сызды. Үзенең яшен, буен, төс-

битен һәм башка тышкы камиллекләрен белдергән хатын-кызларга да якты чырай күрсәтмәде. Ул аларның һәркайсын аерым-аерым күзалларга тырышты. Әмма алар, үч иткән шикелле, барысы да бер рәткә тезелеп, бер үк кыяфәттә пәйда булалар иде.

Аннан соң, нииндидер аңлашылмас бер куркыныч белән янаган хәбәрләрдән баш тартты Тимофей. Әйтик, «ярата белгән һәм яратуны аңлый белгән» дигән сүз нәрсәне аңлата? Юк, артык томанлы, артык күп мәгънәле сүз иде бу — шуңа күрә дә мондый нәрсәне читкә этәрү ягын карарга кирәк иде. «Торак ягы хәл ителгән»— монысы инде бер карауда ук аңлашылып тора: кармак очына эленгән җим бу. Менә сиңа — сөйгән яр, менә сиңа баш очына түбә, ягъни мәсәлән. Юк, танышырга теләгән очракта да мондый игъланга җавап яза алмас иде Тимофей.

Ниһаять, газета битендә кире кагылмаган, сызып ташланмаган бер генә язу калды. Монысын инде Костя да укып үткән иде. Алтынсу чәчле егерме сигез яшьлек бер хатын хыяллана һәм үз теләгенә ирешә белә торган ир эзли. «Һе, нәрсә әйтергә тели ул бу сүзе белән?»— дип кашын җыерды Тимофей.— Киләчәк турында уйлый белүне күздә тотамы? Әллә Марста кеше яшиме, юкмы дип хыялланууны әйтәме? Хыяллана белә торган кеше... Кызык бу. Үз теләгенә ирешә белүче дигәне — анысы инде аңлашыла. Монысына баш ватып торасы юк. Нәрсә эшләргә теләдең — шуңа ирештең дигән сүз, бетте-китте, вәссәлам! Ә хыяллана белү нәрсәгә кирәк бу хатынга! Нишләргә уйлый ул хыялый кеше белән?»

Әлбәттә, бик еракта — Тихов дигән бер шәһәрдә яшәүче бу хатынга Тимофей хат кына язып җибәрә алыр иде. Әлеге дә баягы «хыяллана белү» турында да шулай ук хат аша гына сорап булыр иде. Әмма хатның юлда югалып калуы бар, кайдадыр гасыр буена юл көтеп ятуы бар. Җавап көтә-көтә көтек булып бетәрсең аннан.

Шулай уйлады да, чираттагы ял бирүләрен сорап, гариза язды Тимофей. Костромага хәтле билет та сатып алды. Ә аннан соң инде пароходта барасы икән. Үзе юлга җыенды, ә үзе һаман үз-үзен тиргәп йөрде: «Кем инде газетадагы игълан буенча җир читенә китеп бара? Синең кебек «хыялыйлар» булай да күп килеп киткәндер инде. Бар, әйдә, бар — сине генә көтеп торалар ди анда». Тимофей үзен шулай дип тиргәде, ә кесәдә йөргән самолет билеты, шыгырдап-шыгырдап куеп, күңелне кузгатып, тәмам түземсезләп торды. «Ярый, килеп төшәрмен мин ул Тиховка. Әйтерләр: синең кебек җирән чәчлеләр үзебездә дә бик җитәрлек иде, диярләр...»

Үзен күпме генә битәрләсә дә, күпме генә сукранса да, хәзер инде кире борылмаячагын, тукталып калмаячагын яхшы белә Тимофей. «Ярар, бер һава сулап, дөнья күреп, җилләнеп кайтырмын ичмасам,— дип юатты ул үзен. Икеләнүләрдән арынырга, күңелен дәртләндерергә тырышты.— Теләгемә ирешергә барам».

Шулай дип кат-кат кабатлады Тимофей. Әмма иптәшләренә бүтәнчәрәк, алдашыбрак әйтте: имеш, башта Мәскәүгә, аннан соң Кавказга оча; билгеле, күптән өйрәнелгән маршрут. Тиховка баруын әйтсә, күзен дә ачырмыйча көләрләр, тузга язмаган киңәш-табышлары белән теңкәгә тиярләр дип курыкты.

Хәер, Костя Родионов Мәскәвенә дә, Кавказына да ышанмады.

— Сизәм, боргалыйсың син, туганкай!— дип серле генә елмайды ул.— Беләсең килсә, май аенда алмалар әле өлгермәгән, кызлар тәне кояш күрмәгән була. Алдашасын, туган, алдашасын, шуңа күрә башыңны читкә борасың, шуңа күрә кызарынасың. Их, Тимофей, Тимофей, юкка мине үзең белән ячы итеп алып бармыйсың. Ә бит теге газетаны синең өчен махсус алып кайткан идем! Ярар, дәшмә әйдә, дәшмә. Юлың уңса, мине дә искә алырсың, уңмаса, миңа үпкәләмәссең, бигайбә!

Костяга тегүче кыз Зина белән булган хәлне сөйләгәнен онытккан булган икән шул Тимофей. Ә менә Костя исендә тоткан. Тимофейның язмы-

шы анә шул журналларда чыккан рәсемнәргә, газетадагы игъланнарга барып терәлгәнен аңлаган. Кемдер үз язмышын үзе эзләп таба, кемгәдер аны туганнары тергезеп бирә, ә кемдер, язмышын күтәп, бөтен гомерен үткәрә. Тимофей да язмышының дәшкән авазын ишетте. Хәзер инде аны беркем дә туктата алмый һәм ул үзе дә тукталып кала алмый иде.

Әле буяу исен дә җуеп өлгермәгән ап-ак пароход Тимофейны Тихов шәһәрендә калдырып китте. Яшь-яшь әрекмәннәр, кычытканнар урап алган причал тирәсендә каравыл йорты, агач киоск, өсте ябулы сәүдә мәйданчыгы тезелеп киткән иде. Нәкъ менә шул мәйданчык янында өч карчык көнбагыш сатып тора. Көнбагышлар шактый эре, буй-буй сызыклы, авызга кермәм, тешкә эләгәм дип атлыгып торалар. Әйтерсең, өч карчыкның өч капчыгындагы көнбагышлар барысы да бер орлыктан, бер үк басудан — кайсын сайлап алырга аптырарсың. Тимофей белә: көнбагыш озын юлны кыскарта, кечке эңгер-меңгерне ямьләп тора, эшсез, уй-фикерсез чакны күмеп, югалтып тора.

Карчыклар каршысына килеп басты да юл сумкасының авызын ачты Тимофей:

— Йә, әбекәйләр! Берегезне дә рәнҗетмим, өчегез дә тутырыгыз көнбагышны! Тик артыгын гына кыланмагыз — сумканы ябарлык булсын.

Карчыклар аның сумкасын бик тиз тутырды. Тимофей хәтта кесәләренә дә салдыртты: Тиховтагы кирәкле йортны эзләп тапканчы, әлеге йортка керү һәм, әлбәттә, чыгу юлларын өйрәнгәнчегә тикле, әле шактый чиртергә туры киләчәк бу көнбагышны.

Елга ярыннан башланган тугайны узды да куе, яшь каенлыкка кереп югалды. Аннан соң, әле күптән түгел генә сөрелгән, күпереп торган басу кырына килеп чыкты. Басуның шушы күркәм күренеше, иркенлеге һәм орлык көтеп зарыккан булуы аны ашыгып атлавыннан туктатты. «Шушы туфракны ипигә як та каерып-каерып аша!»— дип сокланды ул, хәтта көнбагыш чиртүеннән дә туктап. Шундый чиста басуны чүпләү килешә торган эш түгел иде. Әлбәттә, үзенең бер кесәсе тишек булуын һәм юл читенә көнбагыш коелып баруын ул белмәде дә, сизмәде дә. Басуның хозурлыгына тагын бер кат сокланырга дип артына борылгач, үткән сукмагы буйлап көнбагыш үсентеләре калкып чыкканын, аларның сабаклары күзгә күренеп ныгый барганын күрде. «Чүлмәктәге хикмәт бит бу! Ышансаң — ышан, ышанмасаң — ышанма!»— дип гаҗәпләнде ул һәм, шәһәр капкасы булырга тиеш иске кирпеч баганалар арасыннан үтеп, Тихов урамнарына кереп китте. Койма аша үрелеп үскән канәферләрнең хуш ис бөркегән чәчәкләренә кагылып, тар гына тротуарлардан үтте, шәһәр үзәгенә якынлашты. Калкулыкта ап-ак булып утырган, манарасы киселгән изге бинага «Культура йорты» дип язылган иде.

Тимофей, шәһәр урамын күзәтеп, утыргычта утырып торды: түбәндәрәк — базар мәйданы, таштан коелган юллар, таштан салынган сәүдә рәтләре; мәйдан артында — стадион, дөресрәге, спорт кыры. Аны ГТО нормаларын ничек тапшыру турында аңлаткан фанер стендлар урап алган. Йөгереш сукмагы буйлап шәһәрнең яшь хатыннары, яшь киленнәре әкрен генә атлап йөри: төрле төстәге бәби арбаларында аларның нәни уллары һәм кызлары йокымсырый. Тимофей шәһәрнең шактый борынгы булуын, шушы борынгы күренешнең җанга аңлашылмас бер рәхәтлек, ихласлык, табигыйлек бирүен тойды. Тып-тын аланнары, күләгәле сукмаклары белән аерылып торган карт бакча да шәһәрнең үзенә, үз йөзенә туры килеп тора иде. Тимофей стадионда бала тирбәтеп торган яшь хатыннар турында гаҗәпләнеп уйлап куйды: «Нишләп соң әле алар менә шушы бакчада йөрмиләр? Нишләп стадион буйлап йөриләр? Әллә соң бу хатыннар элек спорт белән шөгыльләнгәннәрме? Юктыр, мөгаен, артык юан, артык таза гәүдәләләр бит. Алай дисәң... ядрә этү буенча шөгыльләнгән булулары мөмкин».

Ниһаять, Яр буе урамын эзләп тапты. Мондагы өйләр, иннәрен җыерып, нәрсәгәдер бик гаҗәпләнгән сыман торалар иде. «Чокырга

төшеп китүдән куркалар кебек,— дип уйлады Тимофей һәм үзенең шундый чагыштыру табуына сөенеп куйды.— Ярга кадәр йөгереп килгәннәр дә, куркып, кире чабарга маташалар. Ә безгә куркып калу ярамый. Шулай ук кире чигенү юлы да юк — яр астына тәгәрәвеңне көт тә тор».

Ниһаять, ул эзләгән Яр буе урамындагы унсигезенче йорт күренде. Капкадагы чылбырны тартып шалтыратты да ишегалдыннан эт-мазар чыкмасын дип көтеп торды. Күрәсең, этләре юк иде — бары тик тынлык кына җавап кайтарды. Шуннан соң ул капканы әкрен генә ачты да кирпеч ватыкларыннан салынган сукмак буйлап болдырга таба атлады.

— Әй, алла бәндәсе, кемне эзлисең анда?— кинәт ишетелгән шушы йөгерек, җырлап торган тавыш каяндыр куак арасыннан күтәрелде. Бакчада, күкрәп үскән канәфер куагы төбендә, өстәл куелган һәм шул өстәл өстендә кайнар пар бөркегән самавыр тора иде.

Өй артындагы бакчада, күкрәп-күпереп чәчәк аткан куак төбендә, җәйге өстәлдә табын әзерләнгән, уртага куелган самавырдан җиңелчә генә пар бөркелә. Берничә бал корты варенье салынган ташаяк тирәсендә бөтерелә. Аларның шулай усал безелдәшеп очуы зур, сары мәченең тынычлыгын боза иде: ул, ал аякларын өстәл читенә куеп, муенын суза төшеп, тын калып, бал кортларын күзәтә һәм аның бары тик мыеклары, колак очлары гына кайчак селкенеп куя иде. Канәфер ботагы ычкынып, күтәрелеп китте, һәм Тимофей өстәлнең икенче ягында утырган хатын-кызны күреп алды. Аның өскә таба матурлап таралган алтынсу чәчләре ак маңгаен аерып, киңәйтеп күрсәтә, шул ап-ак маңгайны ассызыклап торган кашлар гаҗәпләнеп, нечкә җеп булып сузылган; сәламәтлек бөркеп торган алсу бит алмалары кабынып, янып китәр сыман; күпереп, алланып-кызарып торган иреннәр дә, талгынлык һәм сабырлык белән төбәлгән зәңгәрсу күзләр дә — барысы да шушы бакчаның бер яме сыман тоелды Тимофейга. Хатын аклы-кызыллы таҗлар белән бизәлгән кыска җиңле кофта кигән, тулып торган ап-ак беләкләре куак арасыннан яктырып тора. Аның шул ак, йомшак кулы өскә күтәрелгән ботакны җибәрмәскә, ычкындырмаска тырыша. Икенче кулына— шулай ук йомшак, шулай ук ап-ак бармакларына бизәкле чынаяк тоткан. «Минем сезне кайдадыр күргәнем бар бит!»— Тимофей шулай дип әйтергә теләде. Әмма әйтми калды. «Күрмәгән-сөйләшмәгән — ә инде танышлыкка дәгъва кыласың»,— дип битәрләде ул үзен. Һәм ул, яттан белсә дә, кесәсеннән «Танышулар газетасы»н тартып чыгарды: шунсыз телен әйләндереп сүз әйтә алмас кебек иде. Күзен газетадан алмаган хәлдә йөткереп куйды.

— Саблецова Глафира Даниловна сез буласызмы?

— Мин булам. Ә кем булсын тагын? Ә, менә бит кунакныңниндие килгән икән!— хатын, ниһаять, Тимофейның әлеге газетаны ни өчен укып маташуын аңлап алды. Әмма югалып калмады, кыенсынмады, әз генә күтәрелә төшеп, баш кагып куйды.

— Табынга рәхим итегез. Самавырым кайнап тора.— Ул өстәл тирәсеннән мәчене куып җибәрде.— Менә монда утырыгыз. Ә Вася — шушы мәче — бүген иртәдән бирле битен юды, кунак чакырды. Күрәзәче булса да булыр икән!

Тимофей сумкасын киереп ачты да аэропортта сатып алган бер тартма конфетны, ал аяклары белән кедр күркәсен кочып торган сувенир тиенне өстәлгә чыгарып куйды. Аннан соң, бераз уйлап торгач, сумкадагы көнбагышларны да бушатты, самавыр алдына ук өеп куйды. Күчтәнәчләрен алганда, сумкасына нелгән арада кызарынып, бүртенеп, ачуы килеп уйлап куйды: «Табынга рәхим итегез, имеш... Самавырым кайнап тора... Кайнап торыр шул, төркем-төркем булып кияүләр килеп йөргәч. Өйрәнеп беткән, рәхим итегез, имеш... Ярар, әллә ни озак утырмам мин монда. Озаклап аңлашыр нәрсә юк, барысы да беленеп тора».

— Ә көнбагыш безнең Тиховныкы бит?— дип елмайды хатын һәм аның күзләре яктырып китте, ике битендә ике түгәрәк чокыр пәйда

булды.— Мондый көнбагыш бүтән беркайда да юк. Пристаньнан алдыгызмы, әллә базарданмы?

— Пристаньнан.

— Мөгаен, ерактан килгәнсездер?

— Себердән.

— Ой, бездә дә тиеннәр бар бит!

— Нинди тиеннәр?

Хатын өстәлдәге сувенир тиенгә ымлады.

— Менә шундый. Чүпрәктән ясалган. Беркөн кибеттә күргән идем.

— Монысы минем белән бергә очып килде,— дип кырт кисте Тимофей.

— Чынлапмы? Сәяхәтче тиен икән алайса. Рәхмәт инде. Безнең кибеттәгеләргә караганда матуррак та, йомшаграк та бугай. Әйдәгез инде, эчегез чәегезне. Ерак юлдан соң бер самавыр чәй эчеп бетерсәң дә аз. Исемегез ничек соң? Әйтмәдегез дә...

— Тимофей Иванович.

— Бик тартынып кына сыйланасыз, Тимофей Иванович. Әллә мин юньләп кыстый белмим шунда. Хәзер мин сезгә кайнар бәрәңге белән тозлы кыяр алып киләм.

— Кирәкми, Глафира Даниловна. Соңыннан өлгерермен. Менә килдем мин... ягъни, килүем... Сезнең газетадагы сүзегез, Глафира Даниловна, бик җитди нәрсә. Һәрхәлдә миңа шулай тоела. Сез ничек уйлыйсыздыр...

— Мин бит гел берьялгызым, Тимофей Иванович. Бөтен дөньям бушап калды. Һәм менә — газетадагы шул игълан...

— Җир йөзендә ялгыз кешеләр шактый. Менә мин дә... Ничектер җыена алмый йөрдем. Гафу итегез, Глафира Даниловна. Мин соңгарак калмадыммы?

— Сез ныклап игътибар итмәгәнсез ахры, Тимофей Иванович. Газета узган елныкы бит. Декабрь аеныкы.

— Миңа ул очраклы рәвештә генә килеп эләкте. Төрле хәл була, мин әйтәм... Димәк, мин инде соңардым?

— Юк-юк!— Глафира Даниловна ничектер үзгәреп китте. Күңелсезләнеп, башын түбән иде, йөзеннән алсулык югалды, бармак очлары агарып чыкты.— Үзең бер дә белмәгән кеше янына соңга калу мөмкинмени? Сез бит мине бөтенләй белмисез, ә инде ничектер ачуланырга да өлгердегез бугай.

— Нәрсәгә ачуланыйм! Соңга калганмындыр дип кенә уйлап куйдым.

— Юкка алай уйлагансыз, Тимофей Иванович.— Глафира Даниловна бөтенләй күңелсезләнеп куйды. Тавышы да әкренәйде, йомшарды.— Хат та язучылар булды миңа. Үлчәп-сынап карарга дип, ике сәүдәгәр дә килеп китте. Барыбер шушы самавыр янында бер ялгызым утырып калдым. Мөгаен, үтми торган товар булганмындыр инде мин, Тимофей Иванович.

— Алайса мин инде өченче сәүдәгәр булып чыгам. Өченче — артык диләр. Яки өченче тапкыр атуда тигерми калу ярамыймы? Ялгызлык бик нык сулыктырган сезне, Глафира Даниловна. Килешми сезгә болай ялгыз яшәү.

— Ә кемгә килешә ул? Мин тыныч кына, ашыкмыйча гына, елмаеп кына сөйләшүне яратам. Үз өемне яратам, балалар үстерергә телим. Ә тормыш миңа никтер гел кырын карый. Янәшәдән читләп үтә. Бераз рәнҗим тормышка, Тимофей Иванович... Ярый, туктыйм зарлануымнан,— Глафира Даниловнаның йөзе яңадан яктырып китте, ап-ак беләкләре өстәл буенча йөреп, вареньены, күмәчне, барлык тәм-томны бер урыннан икенче урынга күчерде. Тимофейны ниндидер бер өй җылысы, табын җылысы, күңел җылысы урап алды, аңлап-тоеп бетермәслек бер ләззәткә күмде.

— Сезгә килгән хатларда ни язалар иде соң, Глафира Даниловна?

— Үз гадәтләре турында язалар, гаиләгә карата мөнәсәбәтләрен белдерәләр иде. Күбрәк фоторәсемемне сорадылар. Мин инде үзебезнең фотографның теңкәсенә тиеп беттем.

«Фоторәсем» сүзе Тимофейның күңелен көйдереп үткәндәй булды. Ирексездән, Наташаның ягымлы, хәйләкәр күзләрен исенә төшерде. Баш очында куерган бу болытны Тимофей көч-хәл белән куып җибәрде.

— Җавап хатлары тулы альбом булып җыелдымы?

— Бер генә җавап та килмәде.— Глафира Даниловна янә күңелсезләнә башлаган иде, әмма үз-үзен бик тиз кулга алып, кулын селтәп көлеп җибәрде.— Мин бит фоторәсемдә бик мәгънәсез кыяфәттә күренәм. Күзләрем шар булып ачылган, иреннәрем турсайган, кот-ямь калмаган була. Җүләр дисәң — җүләр. Кем җавап язсын шундый хатын-кызга?

— Фоторәсемдә ничектер — анысын белмим, күргәнем юк. Ә менә тормышта сез бик күркәм, Глафира Даниловна. Ягъни, бик ягымлы һәм кызык кеше. Ялгышсам, гафу итегез, билгеле.

— Рәхмәт, Тимофей Иванович. Миңа әле болай дип беркемнең дә әйткәне юк иде.

— Менә сиңа, мә! Ә теге, үзегез телгә алган сәүдәгәрләр? Алар авызларына су кабып утырмаганнардыр бит?! Килсеннәр дә, имеш, берни дә сөйләшми, күрми китсеннәр.

— Әллә ни күргән кебек тә тоелмадылар шул. Берсе бөтенләй сәер адәм булып чыкты. Бер атна буена шахмат уйнап ятты. Я үзе белән үзе уйный, я мине өйрәтергә тотына. Өйрәтә-өйрәтә дә кычкыра башлый: «Ат алай йөрми, болай йөри!— ди.— Шуны да аңламаска мөмкинмени?!»— дип тузына. Ә минем башым авырта, күзләремә яшь килә башлый. Атның ничек йөрергә тиешлеген тәки аңлый алмый калдым. Ә тормыш турында сөйләшергә дә өлгермәдек.

— Атна буена менә шушында яшәп яттымы?— Тимофей, аңлый алмыйча һәм өнәмичә, башын чайкап куйды.— Фатирга керткәнсез инде алайса?

— Танышырга кирәк иде бит, Тимофей Иванович. Кияү булып килгән ич, куып чыгарып булмый. Сез дә яшәп карагыз, Тимофей Иванович.

— Ә икенчесе?

— Анысы хәйләкәр. Кубань казагы. Каяндыр шул яктан инде, тикшереп тормадым. Сүзгә оста,— сайрап кына тора. Әмма бар сөйләгәне ялган иде бугай. Әйдә, безнең якка күчеп китик, ди. Анда, имеш, аның өе бар, фәлән сутый бакчасы бар! Акчасы күп, тавык та чүпләми, имеш. Тик менә кышын болдыры белән өй түбәсе генә янган икән. Бергәләп төзербез, шунда яшәрбез ди. Өеңне сат та Кубаньга киттек ди. Аңладым мин аның уен. Тиховтан беркая да китмим дидем.

— Монысы да бер атна яшәдеме?

— Өч кенә көн. Бик ашыга иде. Бәлки мунча ягып җибәрергәдер, Тимофей Иванович? Шундый ерак юл үтеп килгәч инде...

— Шахматчы белән теге бакчачы да мунчада парланып киттеме?

— Юк, мунча керә алмадылар. Берсенең йөрәге начар, икенчесе эссене күтәрә алмый икән. Алар инде бөтенләй онытылды, күрмәгән дә кебек. Шулай булгач, нигә искә төшереп торырга?

— Хәзер мунчада парланып алудан да яхшырак нәрсә юк инде ул югын! Тик мунча ягу мәшәкатьле эш шул.

— Нәрсәсе мәшәкать? Кое — ишегалдында. Утыны өелеп тора. Хәзер ягып та җибәрәбез аны.

Глафира Даниловна — эре сөякле, димәк, әкренрәк кыймылдарга тиешле хатын булып тоелса да, урыныннан җитез кузгалды. «Буй-сыны бик килешле,— дип уйлап алды Тимофей.— Эшне тиз тота торган кешегә охшый».

— Тагын бер сорау бар икән әле, Глафира Даниловна. Анда, газета-

да, шундый таләп куелган... «Ул хыяллана һәм үз теләгенә ирешә белсен диелгән». Мәсәлән, миндә андый сыйфатлар бармы, юкмы икән?

— Юкка баш ватмагыз, Тимофей Иванович. Үзем дә кайнарлык белән генә язып ташлаганмын ул игъланны. Әзрәк зарланып алырга, юк нәрсәләр уйлап чыгарырга яратам ахры. Игъланга да артыграгын өстәп җибәргәнмендер. Болдыр баскычында бергәләп сөйләшеп, бергәләп хыялланыр берәр кеше табылып куяр, бәлки, дип уйлаган булганмындыр инде. Уйлаганмын да күз алдыма китереп очынганмындыр — менә шуннан киткән инде ул сүз.

— Кая соң әле ул болдыр баскычы? Бәлки шунда утырып торырбыз бераз? Алай утырып хыялланганым юк иде, карап карарга кирәк.

Әмма Глафира Даниловна баскыч янына алып бармады аны. Каты куыра бу егет дип хафаланды сыман. Тимофей юкка ашыкты, юкка сүз кузгатты баскычта сөйләшеп утыру турында: артыграгын ычкындырып җибәрде. Әллә нәрсә уйлавы бар Глафира Даниловнаның. Аның бик җитди кеше икәнлеген белми бит әле ул.

— Тимофей Иванович, ә-нә теге яктагы имәнлекне күрәсезме?— Глафира Даниловна яшел болын ягына күрсәтте.— Ә имәннәр янында ялгыз иске бер өй тора. Күрәсезме?— Ул, яшел болынны да, имәнлекне дә, әлеге ялгыз иске йортның үзен дә сыйпагандай, кулын талгын гына болгап алды.— Ә-нә ул өй. Игътибар беләнрәк карагыз.

Тимофей игътибар белән карады. Өй тирәсендә ниндидер түмгәкләр калыккан. Котырып үскән кычытканнар, ялкаулыктан әлсерәп утырган әрекмәннәр аланлыктагы өйне кымәргә тора сыман. «Күчеп киткән авыл урыны», дип аңлап алды Тимофей.

— Авылның исеме ничек иде?

— Имәнлек! Хәзер дә шулай атала. Хәзер менә шул авыл турында уйлап карагыз да, башыгызга ни килсә, шуны әйтегез, Тимофей Иванович.

— Хыялланып күрсәт, Тимофей Иванович, дигән сыман инде бу.

— Ничек булса, шулай инде.

Тимофей, күзләрен кысып, имәнлеккә төбәлеп карап торды, элеккеге авыл урамындагы түмгәкләрне күзәтте.

— Матур авыл булган — урманы салкын җилдән саклаган, тәрәзәләр көньякка — җылы якка караган. Уртадагы аланлык та бит матур. Кичләрен бөтен авыл шунда җыела торган булгандыр. Биегәндер, җырлагандыр, көнбагыш чирткәндер. Бу урында берәр ял йорты ачарга яки кешеләргә бакча урыны бүлеп бирергә кирәк.

— Дөрес! Нәкъ менә шундый иде бу авыл, Тимофей Иванович! Әлбәттә, бакчалар да үстереп була анда. Ял йорты да төзергә мөмкин. Тик миңа әле аның хәзерге көне турында уйлау кызыклырак. Шул хакта гына хыялланам. Элеккесен инде кире кайтарып булмый. Киләчәктә ничек булыр — анысын белмим. Ә менә бүгенгесен болай да, тегеләй дә үзгәртеп корырга була. Уйлыйсың, исәплисең — барысы да синнән генә тора кебек.

Глафира Даниловнаның йомшак, талгын тавышы киерелеп, куерып, дулкынланып китте, күзләрендә ялкынланып-ялкынланып алган очкын чагылды. «Карале, ничек кабынып китте!— дип уйлап куйды Тимофей.— Яңаклары яна, күзләре яна — ачык күңелле, ялгансыз, хәйләсез хатын булса кирәк».

— Имәнлекне хәзер, минемчә, берничек тә үзгәртеп булмый инде.

— Ә мин беләм!— Глафира Даниловна, Имәнлекне яхшырак күрү өчен, болдыр баскычына күтәрелде.— Әнә шул бердәнбер өйне яңартып төзергә кирәк. Анда ике карчык яшәп ята. Тол калгач, бергә тора башлаганнар. Коеларын чистартып, буралап кую да начар булмас иде. Юкса, алар бик интегеп ала суны коедан. Имән төпләрен йомшартып, чүпчарны яндырып, тирәсенә ком сибеп чыгу кирәк. Аннан соң, сукмак яннарына утыргычлар ясап куярга була. Әле анда тагын бер салкын

чишмә бар — анысын да ап-ак ташлар белән әйләндереп аласы. Шуннан соң, бу урын бөтенләй яшәреп китәчәк!— Глафира Даниловна дулкынланудан күзләрен йомды — Иманлекнең яшәргән көнен тагын бер кат күз алдына китерде ахры. Бер мәлгә тавышы югалып торды һәм, әнә шул тавышын табарга теләгәндәй, бармак очлары белән муенына кагылып алды.— Ә аланлыкта атынгычлар, таганнар ясап куярга була. Биек иттереп, ерактан ук күренерлек итеп. Элек язларын Тиховта һәрбер урамда таганнар була иде. Берәр кызны утырталар да, әй, чөяләр таганда, әй, чөяләр — егете кем икәнне әйттергәнче туктатмыйлар!

— Хәтерлим. Бездә дә бар иде таганнар,— Тимофей үзе дә дулкынланып китте. Глафира Даниловна болдырга менеп, Иманлек турында сөйли башлаганнан бирле, аннан күзен алмады ул. Хатынның шулкадәр ышанып сөйләгән тавышы, мондагы күренешләрне чын күңеленнән бирелеп тасвирлавы Тимофейны да кузгатып җибәрде.— Элек аркан-баулар белән ясыйлар иде. Хәзер инде башкачарак... Гафу итегез. Мин монысын болай гына, кирәкмәстән генә әйттем бугай. Бәлки, Глафира Даниловна, барысын да бүген үк хәл итәрбез, ә? Газетадагы игълан турында әйтәм. Бәлки, үз теләгенә ирешә белгән кешене бүтән эзләү кирәкмәстер дим? Гафу итегез, билгеле...

— Мин моңа риза, Тимофей Иванович,— хатын, кулын сузып, кунакның иңенә таянып, болдырдан төште.

Тиздән мунча да өлгерде. Аның бүрәнәләре, эссегә түзә алмыйча, шартлап-шыгырдап торды. Ләүкәнең ап-ак, коры башы уттай кызган, киптерелгән мәтрүшкә һәм әрем куеп бәйләнгән каен, имән себеркеләрдән җәйге болын исе аңкый. Мунчаның алгы ягындагы тезмәгә йомшак тастымаллар эленгән, әле генә кар базыннан чыккан куас парланып киткән иде.

Капкадан күрше Андрей карт башын тыкканда, әлеге хуш исле себеркеләр Глафира Даниловна белән Тимофейны мунчаның беренче уртак парына куып керткән, әмма тәннәрен дә җебетеп өлгермәгән иде әле. Карт инде тәмам бетерешкән, тәбәнәкләнеп калган һәм оныгының солдат гимнастеркасы аның үкчәсенә кадәр диярлек төшеп тора иде. Күршеләре белән элек тә тату яшәгән Андрей карт, Глафира Даниловнаның әтисе-әнисе дөнья куйгач та, аңа гел ярдәм итеп килде: утынын кисте, бакчасын сөрде, коесын чистартып торды. Хәзер инде үзе дә көчхәл белән генә йөри башлагач, эшсез-йомышсыз гына, сәбәп-сылтаусыз гына керә иде. Керә дә: «Тиздән, кызым, атаң-анаң белән күрешергә китәм. Ниләр тапшырырга икәнен әйт»,— дип сүз башлый. Шулай хәлахвәл сорашып өчен генә кергәндә дә купкан койманы кадаклап, аркылы ятканны буйга салып чыга иде үзе.

Андрей карт бакчага күз салды, өйне, ишегалдын әйләнеп чыкты — Глафира Даниловнаны тапмады. Болдырга утырып, тәмәке кабызды. «Кәтим бераз. Бүген шимбә — Глафираның эш көне түгел, күренми, кайтмый калмас». Шунда ул мунча ягыннан килгән тавышны ишетеп алды. «Әһә! Менә эш нәрсәдә икән! Тагын кемдер кияү булып килгән. Кара син аларны бер беренә ничек дәшәләр: Иваныч та Даниловна. Шәрә калсалар калалар — сөйләшүләрендә әдәп саклыйлар, имансызлар! Мунчада түгел, казна йортында күрешкәннәр диярсең». Андрей карт тәмәкесен яңадан кабызды. Шулай ук оныгы бүләк иткән фуражкасын салып, янәшә куйды. Фуражкасыз әйбәтрәк ишетелә кебек тоелды картка. Чыннан да, болай ачыграк ишетелә иде. Һәм ул «Тишенька... Глашенька»... дигән сүзләрне ишетеп кеткелдәп куйды: «Менә монысы икенче эш! Парны шәп салганнар болар. Һәйбәт чабыналар!..

Андрей карт урыныннан кузгалды да, аптырап, авызын ачып калды: әллә күзаллары томаланып китте, әллә миенә кан йөгерде инде шунда — мунчаның түбәсе күтәрелеп, стеналары селкенеп куйгандай булып күренде картка. «Чынлап селкенүе дә бар,— дип уйлады ул.— Җыеп-җыелып килгән көч ләбаса. Ләүкәсе дә тар була андый чакта. Ярар, мондый

сүзләрне тыңлап тору килешми карт кешегә. Аллага шөкер, парның кайнарын тапканга охшый болар...»

Мунчаның ләззәтен татыганнан соң, алгы якта гамьсез бер иркенлек белән хәл җыеп яту үзе бер рәхәт.

— Аһ, Тимоша, без икебез дә бер авылдан икән бит! Икебезнең дә тәндә җирән төкләр...

— Ничек инде?!— Тимофей, кулына куас савыты тоткан килеш, гаҗәпләнеп, тукталып калды.

— Ә берничек тә түгел! Рәхәтлектә йөзәм мин, шуңа күрә башка җыен җуләр уй кылә.

— Куас эчәсеңме?

— Таган атынганда тагын шундый җыр җырлыйлар иде бездә: «Яратам дип кердем янган утларга...»

Таң аткач, Тимофей Имәнлеккә китте. Бердәнбер ялгыз йортта яшәгән карчыклар инде аяк өстендә иде. Тимофейны бик гаҗәпләнеп, таякка таянып каршыладылар.

— Имәнлек халкына кайнар сәлам!— төнне бөтенләй йокысыз диярлек уздырган, Глафира Даниловнаның назлавына иркәләнеп, иртәтаннан уянган, кулы эшкә кычыткан Тимофей биленә кадәр бөгелеп исәнләште. Соры шәл бөркәнгән, аягына иске итек кигән чандыр гәүдәле карчык Тимофейның билендәге балтасына шикләнеп кенә карап куйды да күршесенә төртте:

— Шура, бу башкисәр нишләп йөри икән монда? Безнең башны чабарга килгәнме әллә?

Юкарып, тәмам чаларып калган Шура карчык бик белдекле кыяфәттә әйтеп салды:

— Безнең ояны туздырырга килгән. Әйтте диярсең...

Тимофей хәтта үпкәләп куйды:

— Нәрсә сөйлисез сез, әбекәйләр! Мин сезгә чын күңелдән булышырга килдем, ә сез миңа башкисәр исемен тагасыз.

— Әйдә, әйдә, килгәнсең икән, уз,— диде карчыкларның Шура исемлесе. Һәм алар, каш астыннан гына карап, Тимофейның ни кылануын күзәтә башладылар. Ир-егет имән төпләрендәге чүп-чарны, тимер-томыр кисәкләрен, кирпеч ватыкларын — җирне ямьсезләп торган һәрнәрсәне себереп түкте. Кулга ярардай әйберләрне эшкә җигә барды: кирпечләрне чишмә төбенә тезде, такта калдыкларыннан утын сарае кебек нәрсә әмәлләп куйды.

Иске нигезләр буйлап әйләнеп чыкты. Буяу һәм әлиф салынган банкалар, бидоннар тапты. Каяндыр тәмам каралып беткән җиз самавыр да килеп чыкты.

Әллә ни күп вакыт та үтмәде, Тимофей чистарткан кое суы салынган җиз самавыр (егет анысын да ком белән ыклап ялтыратты), бал корты сыман тигез генә безелдәп, шаулап утыра иде инде. Самавырны карчыклар янына, болдырга китереп куйды.

— Бик җилләнмә, сине сыйларга чәй дә, шикәр дә юк. Әнә, кайнаган су эчәрсең,— дип сукранып алды карчыкларның Шура исемлесе.

— Ярар, кайгы юк, ашарлык эшләмәдем әле.

Тимофей инде бердәнбер йортның нигезен, почмакларын да төзәтергә керешкәч, карчыкларның карашы бөтенләй үзгәрде, сукрануларын риза-бәхиллек алыштырды. Тимофей түбәгә дә менде, тишек-тошыкларны калай белән ямаштырды. Түбәне, тәрәзә яңакларын буяп чыкты.

— Сине кем җибәрде соң монда?— карчыкларның кызыксынуы бермә-бер арткан иде.

— Глафира Даниловна.

— Анысы кем була тагын?

— Тиховта иң зур кеше.

— Нәчәлник-мазардыр?

— Аннан да зуррак.

— Алла исәнлек-саулык бирсен үзенә. Син самавырыңны алып китәсеңме, калдырасыңмы?

— Авыл самавыры бит ул, шәһәрдә нишләсен?

— Алайса, әйдә, өрдереп җибәр самавырыңны, чәй эчәбез.

Чәйне варенье белән, кайнар сумсалар белән эчтеләр. Карчыклар, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, үз тормышларын, зар-кайгыларын, көнкүрешләрен сөйләделәр.

Күп тә үтмәде, Тиховта бульдозерчылар янына эшкә урнашты Тимофей. Иманлектәге чокыр-чакырларны тигезләде, авылдан Тиховка кадәр килгән юлны ачты. Аннан соң, Иманлеккә елга комы алып килде. Таратты. Иман төпләренә утыргычлар ясап куйды. Аланлыкта атынгычлар, таганнар үсеп чыкты.

Иманлеккә илтә торган юлда иң беренче булып яшь аналар — сабыйларын җитәкләгән, бәбиләрен арбага утырткан хатыннар пәйда булды. Ә Иманлектәге карчыклар, тешсез авызларын ерып, монда килүчеләрнең һәркайсын шатланып каршыладылар.

Яшь аналар, яшьлеккә кайтып төшкәндәй, чыр-чу килеп, таганнарны килеп сарды, аларның көлү-шаяру тавышларын ирләре дә ишетте: алары да Иманлек ягына агылды.

— Күрәсеңме, Тиша?! Шәп булды бит, ә?— Глафира Даниловна шатланып бетә алмады.— Ә кышын шугалак ясап куярбыз, ә?

— Ясарбыз,— диде Тимофей.

— Ә беләсеңме?..— Глафира Даниловна Тимофейның кулын әләктерде дә, бу кулларның күпме авырлыкны күтәрә алуын, көчен ачыкларга теләгәндәй, селкеп-үлчәп торды.— Тиховтагы барлык ялганчыларны куып таратасы иде.

— Кемне, кемне?!

— Соң, ялганчыларны инде... Бер төрле сөйләп, икенче төрле эшләп йөрүчеләрне.

— Ә... андыйларны куып-таратып булмый. Сазлыктагы куык кебек бит алар.

— Бик күп түгел алар. Тиховта шул, күп булса, егермеләп булыр.

— Начальникләрмени?

— Барысы да түгел.

— Ул чакта күп түгел бу.

— Тик алар — иң куркынычлары. Берсе, газетага яза, икенчесе лекция укый, өченчесе радиодан сөйли, Тиховтагы тормышның матурлыгын мактый: безнең шәһәр — борынгы шәһәр, горурланып сөйләргә мөмкин, билгеле. Әмма боларның сөйләвен тыңласаң — барысы да ал да гөл имеш. Тыңлыйсың да күңел болгана башлый.

— Нервларың бозылган, күрәсең.

— Дөрес әйтәсең. Ялган тыңлап, чиргә сабышырга да мөмкин. Үзләре Тиховта яшәмичә, читтән торып кына алдашып ятсалар, түзәр идең әле. Үзләре дә монда яши бит. Кибетләрдә юньле ризык юк. Кем ничек җай таба — шулай маташа. Шундый яхшы, кара туфраклы җирдә яшибез юкса. Гореф-гадәтләре дә үчеп бара. Ә боларны тыңласаң — чәчәк атабыз, яхшы яшибез. Көчемнән килсә, кул төбенә ташлар идем шул ялганчыларны. Тиша, бәгырькәем, әйдә куып җибәрик шуларны Тиховтан, ә?

— Ничек?!

— Кул-аякларын бәйләп, капчыкка салыйк та, кырга чыгарып ташлыйк. Буп-буш бер урынга.

— Син нәрсә, мине кире Себергә җибәрергә телисеңме?

— Тиша! Юләр сүз сөйләмә инде!

— Берсен илтеп ташларсың. Ә аның урынына икенчесе килеп утырыр.

— Юк! Тиховта алай түгел. Бүтән җирдә, бәлки, шулайдыр. Әмма Тиховта котылып була алардан. Ныклап тотынучы гына кирәк.

— Мышьяк белән агулап чыксаң гына инде?

— Башта берсеннән башларга кирәк. Глафира Даниловнаның күзләре очкынланып китте.— Степан Васютинны акылга утыртырга иде.

— Нәрсә, сиңа бәйләнеп йөрдеме әллә?

— Юк. Эш анда түгел, Тиша. Дөреслек булсын дип әйтәм,— Глафира Даниловнаның күзләре дымланып китте.— Галяның ире ул. Дус кызымның ире. Теңкәсенә тиде Галяның.

— Ә, кичә елап килгән хатынмы? Тукмыймыни соң ул аны?

— Куралмый аны Галя. Ялганнарына түзә алмый. Тәмам чиргә сапты. Шундый шат күңелле кыз иде бит үзе. Бетерде, таптады шул кызны теге ташбугаз.

— Кем, кем дидең? Ташбугазмы?

— Безнеңчә, ашап симергән, шомарган ата мәче була инде.

— Нишләп куып кына чыгармый соң ул аны?

— Алай җиңел генә булмый шул. Ике балалары бар. Йорт-җир бар. Түзеп яшәве дә кыен. Туганда ук алдакчы булып тумаган ла инде ул, тора-бара өйрәнгән.

— Аңлый алмыйм, ни дип алдаша соң ул?

— Мәсәлән, авылларны шул туздырды. И сөйләде, и сөйләде инде: үзәккә күчәсез дә балда-майда гына йөзәсез, якташлар, дип йөрде. Иманлек кебек авыллар әнә шул чакта бетте. Кемдер Тиховка күчте, кемдер бөтенләй читкә чыгып китте. Соңыннан тагын сөйләнде: бераз ялгыш киткән, якташлар, зыян юк, эшләмәгән кеше генә ялгышмый, имеш.

— Бер алдашасың, ике алдашасың — аннан соң инде дөреслек кирәк тә түгел сыман.

— Шулай шул. Китапханәләрне дә шул үзәкләштерде. Авыллардагы бөтен китапны Тиховка ташытты. Череп тик ята хәзер китаплар. Алар өчен махсус бүлмәләр юк бит. Ә ул һаман үз сүзен сөйли: «Рухи азыкны бер йодрыкка тупладык»,— ди. Их, Тиша, хатынын гына түгел, тагын бер хатынны алдап йөри ул.

— Синеме әллә?

— Юк ла инде. Миндәмени эш! Галя шуның бер сөяркәсе белән очрашкан. Тегесе барысын да сөйләп биргән. Ә ире нишләгән дисең шуннан? Тезләнеп елаган. Юк, оятыннан еламаган ул. «Мин,— дип әйтә ди,— ул хатынга чын йөрәктән гашыйк булдым, ялгыштым, хәзер шул яраларым әрнетә. Син, Галя, миңа ярдәм итәргә, яраларымның сыкравын басарга тиеш»,— дип әйтә ди.

— Галяның йөрәге ярылмады микән соң?

— И, Тиша, ул бәндәнең нотык сөйләүләрен күрсәң иде.

— Кирәге бар иде!

— Ә син тыңлап кара. Чынлап!

— Сүз тыңлап, багана башына үрмәләмәс идем әле.

— Алай димә, Тиша, син аны тыңлап кара башта. Барып кайт шул Степан Васютин янына. Менә хәзер үк.

— Ничек инде хәзер үк «барып кайт»? Көнозын сөйләп тормыйдыр ла ул?

— Һәркөн күнегүләр үткәрә: нотык сөйләргә өйрәнә. Үзләренең мунча артында.

— Нәрсә, микрофоннары да бармы әллә?

— Барып кайт, үзең күрерсең.

Тимофей, кичке чык төшкәч, чирәм-үләннәрне ерып, Васютинның мунчасына барды. Матур, тигез, ышанычлы тавышны ул ерактан ук ишетеп алды. Мунча янындагы чирәмлектә урта яшьләрдәге бер ир әрле-бирле йөренә, кулларын болгап-болгап, нидер сөйләнә, каршыдагы каеннарга, усакларга карап, нотык тота иде.

— Хөрмәтле якташлар! Бүген мин бик үк күңелле булмаган нәрсәләр турында сөйләячәкмен. Күптән түгел мин районыбыз экономикасында булган торгынлык турында сүз алып барган идем. Хәзер инде бу

авыруның озакка сузылачагы ачыкланды: кул көче житенкерәми, планнар үтәлми, кайбер хужалыкларның яшәве — мәгънәсез бер көрәнеш. Әмма, кадерле якташлар, узган юлы мин мәсьәләне тулысынча ачып бетермәдем, кайбер четерекле якларга кагылмый калдым. Бер-беребездән дөреслекне, ачы хакыйкатьне яшереп сөйләшү заманнары үтте. Хәзер инде һәммәбезгә дә ныклап үзгәрергә, эш алымнарыбызны үзгәртеп корырга кирәк. Ни өчен мин бу хакта узган юлы әйтми калдым? Чөнки, иптәшләр, минем үземдә дә дәшми калу дигән шайтан фигыле яшәп килә. Сезнең белән очрашуга килгәндә, әнә шул шайтан фигыле баш калкыта башлый. Менә монысын сөйлә, ә монысын сөйләмә дип котырта.

«Бәйләп ташларга кирәк,— дип уйлады Тимофей.— Өч минут кына тыңлап тордым — төтен эчендә утырган кебек булдым. Сәгатьләр буена тыңлаучылар нишләр?» Кире кайтты да Глафира Даниловнага әйтте:

— Йә, нишләтәбез Васютиныңны?

— Нәрсә, бәйләп ташлыйбызмы, Тиша?! Менә рәхмәт! Галя да, бөтен кеше дә рәхмәт әйтәчәк сиңа!

Сандугачлар тавышы яңгырап торган бер матур кичтә Тимофей йоклап яткан Васютин янына килде. Иркенләп, изрәп йоклаган бу кеше тиз генә уяныр сыман түгел иде. Тимофей аны брезент җәймәгә төреп, җилкәсенә салды, урамга алып чыкты.

— Бик авыр түгелме, Тиша?— дип каршы алды аны Глафира Даниловна.

— Түзәрлек.

Күперне тавышсыз-тынсыз гына үттеләр дә урманга кереп киттеләр. Аяк астында сазлык тирбәлә башлагач кына Глафира Даниловна сүз катты:

— Минем эздән генә атла, Тиша. Як-якта упкын.

— Ә син соң, син ничек барасың?

— Мин бу сукмакны беләм. Андрей бабай өйрәтте.

Сазлык буйлап шактый озак бардылар. Утрау кебегрәк бер җиргә килеп чыктылар. Тимофей Васютинны җиргә яткырды, кул-аякларын чиште. Ә Глафира Даниловна үзе белән алып килгән азык-төлекне — он, ярма, тоз кебек әйберләрне урнаштырды.

— Кышка кадәр җитәргә тиеш болар...

— Берәрсе килеп, алып чыкмасмы икән соң аны моннан?

— Юк. Андрей бабай белән миннән башка бу сукмакны белүче юк.

Тиховка иртәнге якта гына кайтып төштеләр. Мунча ягып җибәрделәр. Рәхәтләнеп, туйганчы парландылар, чабындылар.

— Минем сине кайдадыр күргәнем бар икән бит!— Тимофей Глафира Даниловнаның буй-сынына сокланып карап торды.

— Их, Тиша, мин әле һаман Яр буе урамы турында уйлыйм. Балчык та ләм генә бит ул урам. Чәчәкләр, агачлар утыртасы иде бит шунда. Ничек матур булыр иде, ә?!

— Берүзең генә тотынып булмый андый эшкә. Иптәшләр кирәк.

— Иптәшләр булачак, Тиша. Булачак.

Тиздән ул ике игезәк малай тапты. Тагын бер елдан — ике игезәк кыз. Берзаман китте шулай эшләр уңайга: игезәк арты игезәк!

Яр буе урамын үз малайлары, үз кызлары белән чистартты, түзекләндерде Тимофей. Кичләрен бөтен гаилә бергә җыела. Җәй көне — бакчада, кышын иркен олы бүлмәдә. Һәркем бер-берсен аңлап, белеп, тыңлап сөйләшә — чөнки сүз аларның үзләре, туган шәһәрләре, шул шәһәрне тагын да матуррак итү турында бара. Тимофейның төпчеге — түгәрәк йөзле, зәңгәр күзле Оля — китап укырга ярата. Аның тавышы яңгырап-яңгырап ишетелә. Кызын тыңлый да үзе узган юллар, үзе яшәгән җирләр турында уйлый Тимофей. Уйлый да, рәхәтлек тоеп, күзләрен йома: Ә тирә-якта яңгыр ява, җып-җылы ләйсән яңгыр ява сыман аңа.

Русчадан **Нияз АКМАЛОВ** тәрҗемәсе

## Мәгъсум Хуҗин

# УРАК ӨСТЕ БОЛЫТЛАРЫ

ПОВЕСТЬ

8

**1984 ел, көз уртасы.**

Сәгать сигезләрдә Каюмның өенә партия райкомының беренче секретаре шалтыратты. Гадәтенчә, колхоз хәлләрен тәфсилләп сорашты, тик бу юлы әңгәмә уңаеннан киңәшләрен бирә бармады. Сәеррәк иде монысы. Һәм ахырдан Каюмны:

— Иртәгә сезгә өлкә комитетына барырга кирәк. Туры беренче секретарьга керегез. Сәгать унга,— дип аптырашта калдырды.

Каюм ни өчен көтмәгәндә чакырылуының сәбәбен сорамады, кирәге булса, моны райком секретаре үзе үк әйткән булыр иде, хәер. Ярый әле бүген куен дәфтәренә яңа мәгълүматларны теркәп куйган иде. Хәтергә генә ышанып бетеп булмый, өлкә комитетына әңгәмәгә чакыргач, колхоз хәлләрен сораштырмыйча калмаслар.

Юл хәстәрен хәзердән үк күрергә кирәк, иртәгесен кабаланырга туры килмәсен. Поездның иртән алтыда ук китә торганы бар, шунысына чыгасы булыр. Машина куу җай түгел, өлкә үзәгенә илле чакрым гына булса да, юлның элә-танагы юк. Ярый ла, туңдырып, бераз кар яткач, дала буйлатып кая телисең, шунда чабасың, машинаң асфальт дип талымламый. Бөтен дөньяны быкыр итте, тәмамысы, өченче тәүлеккә китте карлы-бозлы яңгыр ява башлавына. Көйләп тә күрсәтте табигать дигән абзаң! Далада аның холкы бигрәк тә үзгә. Табигатьне буйсындырабыз, дип мактанабыз, далада авыллар, шәһәрләр төзедек, дибез, әмма дала үз холкынча кала бирә. Даладан миһербан көтеп булмый, иң башлап илле мөнәсәбәт кирәк аңа...

Нәрсәгә чакыра икән беренче? Туры үзенә керергә кушкан. Төпле уйлаучан, тәҗрибәле, кешене аңлый торган җитәкче өлкә комитетының беренче секретаре, үзе далада үскән, шуңа күрәдерме, дала халкын аңлый белә. Шулай да бер очракта кешеләрне аралап карый торган гадәте бар. Каюм аны күп белми белүен. Киңәшмә-җыелышларда кыска вакытлы күрешүләрне санамасаң, өлкә комитеты секретаре аның колхозында ике, юк, өч тапкыр гына булды, берсендә башка колхозга барышлый тукталып кына узды. Әмма кешеләрне аралавы турында нәтиҗә ясау өчен, аның Каюм белән еш очрашуы төп шарт түгел бит, кылган эшләрен белү дә җитә. Ә өлкә җитәкчесенең аралау гадәте менә нәрсәдән гыйбарәт: куелган постына карап кешедән эш таләп итә, әгәр дәрәҗәлерәк эштәге кеше ялгышса яки хилафлык кылса, аңа каты-

Ахыры. Башы 11 нче санда.

рак җәза күрүгә ирешә, чөнки житәкченең ялгышы зуррак зыян китерә. Райком секретарен гына түгел, бәлки колхоз механизаторын да үзенә чакырып, яки килеп, сабак укыткалый ул. Каюмга нинди сабак укытырга җыена икән беренче? Нинди гаебе бар икән Каюм Фәсәхиевнең?

...Каюм, поезд тәрәзәсе янагына кул аркасын терәгән дә, учына башын куеп, уйланып бара. Өлкә үзәгеннән кайтышы. Беренче секретарь белән әңгәмәдән соң. Тәрәзә пыяласына җепшек кар күсәмәсе белән бәрелә, чәчрәми, шуып аска төшә. Карлы-бозлы янгыр туктарга исәп итми. Бик житкән кәнә. Шөкер, урасын вакытында урып, җыясын җыеп бетерделәр, терлекләрне, җәйләүдән кайтасыларын кайтарып, җылы абзарларга ябарга өлгерделәр. Кышка әзерлекле килә колхоз. Хәер, колхозның нинди хәлдә булуы, бер уйласаң, Каюм Фәсәхиевкә хәзер нигә кирәк инде? Шулай да... Шулай да колхозны яңа кешегә тапшырырга туры килүе ихтимал бит, әлегә бу мәсьәлә хәл ителеп бетмәсә дә, өлкә комитеты секретаренең сүзен кире кагучы булмас та, бәлкем. Шулай да колхозны төзек хәлендә тапшыру әйбәт, күңел пакьлеге дигән нәрсә дә бар бит әле. Үз хезмәтеңне үзең бәяли белү кирәк. Дөрес итеп бәяли белү. Моньсы бүтәннәр хезмәтен бәяләүдән кыенрак, үсеш юлын үзең табарга тиешсең, бу очракта сиңа юнәлеш биреп торучы юк. Яңа председательгә авылдагы хуҗалыкны гына түгел, ә ерактагы җәйләүләрне дә күрсәтәсе булыр. Аны үсеш юлына житәкләп кертү булмас бу, таныштыру өчен генә, калганын үзе уйлар. Ә бәлки, колхозның яңа башлыгы үзебезнең авылдан ук булыр. Бу мәсьәләдә Каюм секретарьга тәгәл тәкъдимен әйтә алмады. Председатель сайлау аңа гына бәйле түгел, район житәкчелеге бар бит әле. Ахыр килеп, председательне колхозчылар сайлый.

Шулай уйланып барганда, Каюм өлкә комитетында сөйләшүнең ахырыннан әңгәмәнең башына кайтты. Хәл-әхвәл белешкәч:

— Туган якларга кайтып килгәнсез икән,— дип, сүз ара гына әйтеп куйды партия өлкә комитетының беренче секретаре Сергеев Егор Степанович.

Ни булды бу: гаепләүме, әллә соң булса да Каюмның туган якларын искә төшерүен хуплаумы? Моны секретарьның нинди төсмер белән әйтүен Каюм абайламады.

Әйе, кайтты Әлгый Фәсәхетдиненең малае Каюм Кылыкка. Бу хакта райком секретарена әйтте ул. Өендә дә белделәр, белделәр генә түгел, кайтуының сәбәбе әнисе Тәүфирә кушуын тыңлау иде. Ә авылда аның кемлеген берәү дә белмәде. Кайтышлый юлда очраган Рәсиха исемле ханымга үзенең кемлеген — колхоз председателе булуын — турыдан әйтсә дә, чыгышын һәм кайту максатын тәфсилләмәде. Авылда бүтән берәү белән дә, исәнләшеп узудан тыш, сүз алышмады ул. Өч озын урамны да йөреп чыкты, әнисе өйрәтүе буенча үз йорт-җирләре урынын эзләп тапты. Буш иде бу урын, кемдер бәрәңге утырткан, инеш башыннан аны казый да башлаган. Киртәләп алганнар пуҗымны. Йорт салган булсалар соң шушында, бик тә кулай урын бит. Елгага да, инешкә дә якын, болыны да күз алдында җәйрәп ята. Ошатмаганнар, димәк, Әглый Фәсәхетдиннәре урынын. Янык, дигәннәрдер. Янып көлгә әйләнгән йорт урынына яңасын салырга яратмый крестьян агай, борынгыдан килгән ырымга ышана: тагын янгын чыгуы мөмкин, имеш. Менә бит ул тормыш дигәнең. Бу нигездә иң соңгы туган кеше — Каюм. Әгәр... әгәр Каюм шушында яңа нигез корса? Һәм аның нәселен дәвам итәсе төпчеге шушында туса? Соңрак шул. Бик соң. Илләне узды Каюм абзаң. Оныгы бар кешегә бала тудыру турында уйлау — акылсызлык. Димәк, Әлгый Фәсәхетдиненең төп нигезендә Каюм мәңгегә соңгы бала булып калыр. Шул нигезне, үзе тапи басканчы гына яшәргә өлгергән нигезне кайтып күрде ул. Күрде дип, караңгыда күрүе дә чамалы иде, дөресе — булды ул анда. Илле бишенче яшенә чыккач. Хәзер шушы гаеп саналамы? Нәрсәгә ишарәләде икән беренче секретарь?

— Ай чамасы элек кайтып килдем шул,— диде Каюм, беренче секретарьның сүзләреннән сискәнеп утыргач.— Әмма мин анда бернинди дә хилафлык эшләмәдем. Колхоз председателе хатыны машинасына утыртып алып кайтты. Шул гына. Башта утырырга да теләмәгән идем.

— Начар.

Нәрсәсе начар иде — Каюм тагын төшенеп җитмәде. Ләкин ул шөбһәсен көчәйтергә өлгермәде, Егор Степанович, урыныннан кузгалып, тәрәзәдән урамга карап уйланып торды да кире утырды һәм кызуланып сөйләп китте:

— Начар! Ерак сәфәр кылып, хуҗалыгың өчен бернәрсә дә алып кайтмау начар. Чыгышыгыз өчен куркып яшәргә кирәкмәс хәзер. Сезнең Ватан кешесе икәнлегегезгә мин ышанам, мәсәлән. Үзегез дә Ватанга үч тотмавыгызны тоясыз. Һәм үч тотмавыгызга ышанып җитәргә тиешсез. Мин әйткән өчен генә түгел. Үзегез уйланып. Беләсезме, Каюм Фәсәхиевич,— дип көлемсерәде беренче секретарь,— малай чакта, әле монда далада килеп яши башлагач, минем сәер гадәтем бар иде. Бер ноктага турылап карый идем дә хәлдән таеп егылганчы далага йөгерә идем. Хәл җыйгач, кире кайтырга кирәклеге искә төшә. Ерак кителгән, авыл күренми. Кайтырга кирәк. Далада ялгызың яшәп булмый. Әллә ниткән үлән урманнарын, сазлыкларны узып киткәнмен. Барыр уңайда мин боларга игътибар да итмәгән идем. Ә хәзер ничек үтәргә? Ярдәмгә кеше чакыра алмыйсың, далада сине кем ишетсен. Мондый сәфәрләрдән кайту әмәлен тапканмын бит менә, алдыгызда утырам, сазлыкта йотылып калмаганмын, елан чакмаган.

Егор Степанович тагын урыныннан кузгалды, ишекне ачып, чәй сорады.

— Ул чакта мин кереремнән элек чыгарымны уйламаганмын,— дип дәвам итте аннары секретарь.— Һәм максатымны анык белмәгәнмен. Әлбәттә, бу йөгерүләр мине физик яктан күпмедер чыныктырган. Бәлки көрәшү ысулларын, дала белән көрәшү ысулларын өйрәнгәнмендер. Сезнең авылыгызга кайтуыгыздан олы отышыгыз булмаган. Бу юлы. Югыйсә нинди дә булса яңалык алып кайтыр идегез. Туган авылыгызга. Һәм торган авылыгызга. Мин, мәсәлән, туган җиремә ел саен кайтам һәм, мактану булмасын, күкрәк киереп йөрим. Нәрсәдер өйрәнеп киләм. Шулай ук мактану булмасын, нәрсәгәдер якташларымны да өйрәтәм.

— Сезнең сәбәпләр башка...

— Хак әйтәсез. Сәбәпләр башка. Мин утыз җиденче елгылардан. Соң, Каюм Фәсәхиевич, бу далада, мондагы төп халыкка өстәлеп, кемнәр яши, дисез? Биш төркем, дөресрәге, биш буын алар даланың бүгенге кешеләре: даланың үз кешеләре, колхозлашу елларында кулак булырак сөрелүчеләр, утыз җиденче ел корбаннары, сугышта әсир төшүчеләр һәм бишенчесе — үзләре теләп чирәм җирләрне үзләштерергә килүчеләр. Үз кирәгенә даланы кочарга, төгәлрәк әйткәндә, даланы башкаларга сиздермичә кочып алырга теләүчеләр дә күренгәли башлады соңгы вакытта. Андыйларны даланың биш төркем кешеләре арасыннан да очратып була.— Егор Степанович чәй эчәргә ымлап чакырды һәм, зур тәтәй чокырны кулына алып, чәен озаклап болгатты.— Менә шул бармаклары үзләренә генә кәкре... сез, татарлар, шулай дисез кебек, бармаклары үзләренә кәкре кешеләрне алтынчы төркемгә теркикме? Ертмачлыкка юл куйсаң, монысы инде төркем генә булып калмаячак, азын теләмәс, без бетергән изүче сыйныфка әйләнүне максат итәр, хосусый милекчелеккә бер ябышып алса ягъни. Кайчагында кирәгеннән артык миһербанлыгыбыз аңдыйларны шуңа өметләндерүе мөмкин. Әмма искегә кайту юлын социализм бөтенләйгә томалады. Һәм бу сезгә үз гаиләгез мисалында ачыграк да аңлашыла булыр. Алда — әнә, коммунизм. Авыл хуҗалыгы да аңа бары тик күмәк төстә генә бара ала. Дала авылы да, һичшиксез, коммунизм юлына төште. Тик бу юл сәрхүшне һәм аек килеш тә алпан-тилпән йөрүчене яратмый. Һәм

андыйларны үзенә кертми. Әйе, чуар безнең дала,— дип, чәен йотымлады Егор Степанович.— Шушы гаиләдә яхшыларыбыз да, яманнарыбыз да бар. Әмма Ватанга каршы кешеләрне белмим мин. Әйтмим, бардыр да бик нык яшеренүче дошманнар. Бардыр, бәлки. Ләкин алга алып баручы көч безнең кулда. Һәм үсештә дала кешеләре башкалар сызган эздән генә барырга тиешме? Дөрес юл алгач, без дә алга чыгыйк. Бер үк кешене гел алдан бару ардырырга да мөмкин. Кирегә кайту ихтималлыгы юклыгын социализм һәркемгә төшендереп аңлатты. Дөрес, дала кешеләре арасында моны соңлабрак төшенүчеләр булды. Сезнең авылда ничә милләт кешесе яши әле?— дип, кинәт әңгәмәне борып җибәрде секретарь.

— Удмурт.

— Удмурт. Санарга кул бармаклары җитми. Удмурт милләт кешесенең бер гаилә булып яшәве — рухиятне баетырга ныклы нигез. Минем сезнең авылда сабан туенда булганым бар, хәтерлисездер. Бик ошады бу бәйрәм. Көрәше бигрәк тә. Монысы, бәлки, миңа беркайчан да бил тотышырга туры килмәгәнгәдер.— Егор Степанович, җилкәләрен сикертеп һәм кечкенә кулларын селкетеп, ябык гәүдәсенә ишарәләде.— Көрәш буенча мин белгеч түгел, әмма, абайлавымча, татарча көрәш кешенең көченә нигезләнә, ә казахча көрәштә татарча көрәштә тыелган алымнар бар, анда җәһәтлекнең көчне җиңүе, ягъни көчлене хәйләләве дә мөмкин.

Секретарь чәен йотымлап эчеп бетергәч кенә сүзен дәвам итте. Аның тел төбе нәрсәгә баруын Каюм һаман чамаламады. Һәрхәлдә, чакыруы авылга кайту өчен кинаяләү түгел кебек иде.

— Каюм Фәсахиевич, удмурт милләт халкының матур гореф-гадәтләрен авылыгыз тормышында уртак итү турында уйлансак, ә?

— Без сабан туйлары уздырабыз. Туй йоласы да яшь кияү белән яшь килен теләгәнчә, ягъни төрле милләт кешеләре теләгәнчә үтәлә.

— Боларын беләм. Болары әйбәт. Туганлашу мәсьәләсендә алгарак китеп уйланыр нәрсәләр тагын һәм тагын юкмы икән, дим. Бәлки, әйтик, шул ук сабан туеның эчтәлеге сезнең туган якта хәзер үзгәрәктер. Сабан туйлары Татарстанда ничек уза икән? Авылыгыздагы һәм башка милләт халыкларының туган җирләрендәге бәйрәмнәре кай ягы белән матурайды икән?

— Белмим бит.

— Беләсе иде шул. Менә мин — рус кешесе. Милләтче түгел мин. Һәр халык, үзенең үсеше өчен, ягъни милләтен үстерү өчен башка халыктагы матурлыкны үзенә алырга тиеш. Һәм, бу мәсьәлә, дөресе, проблема, безнең төрле милләт кешеләрен бергә җыйган далада башлап тормыш чагылышын табарга тиеш, дип саныйм мин.

— Әмма һәр кеше беренче тәрбияне үз гаиләсендә ала бит. Димәк...

— Милләтчелек аның канына сеңгән, дисезме?

— Алай ук кистереп әйтмим. Шулай да. Мин, мәсәлән, үз халкымны яратырга тиешлегемне белеп үстем.

— Һәм бик әйбәт!

— Әни укытучы булды, колхозның беренче председателе иде, ә әти колхозга гомере буена кермәде. Ирле-хатынлы яшәделәр. Әнинең гәрчә күмәк хуҗалык оештыручы булса да, хәзер дә гаҗәп фикерләр әйтеп куюу гадәте бар.

— Сез, Каюм Фәсахиевич, сыйнфый мәсьәләгә күчеп барасыз,— дип бүлдерде Каюмны Егор Степанович.— Башта без милли мәсьәлә буенча әңгәмәбезгә нокта куйыйк. Сез һәр милләтнең матурлыгын барлык халык өчен уртак итеп алуга каршы түгелме?

— Түгел, әлбәттә!

— Сыйнфый мәсьәләгә килсәк исә, болайрак уйлап карыйк. Хәзерге эшче, станогын зырылдату белән бергә, дачасында җиләк-җимешен дә үстерә белә, урып-җыюда да игенчегә ярдәм итә. Крестьян да, иген үс-

терүенә өстәп, гайка ачкычы тотарга өйрәнде, кышларын зур заводларга барып, кадровый эшче белән рәттән басып эшли. Интеллигенция вәкилләре «шабаш»та осталык күрсәтәләр. Культура дәрәҗәләрендә дә аерма кими. Димәк, тупасрак чагыштыру булса да, тормыш марксизм өйрәткәнчә бара. Димәк, безнең тормышны фәнгә нигезләп алып баруның хаҗәте хәзер аерата көчәйде. Димәк, һәр мәсьәләне безгә кечкенә генә дә ялгышусыз хәл итү мәҗбүрияте туды. Димәк... Димәк, шулай.

— Шулай да сезнең мине чакыруыгыз сәбәбен төшенмим. Гаебем бармы? Юк дип беләм. Туган авылыма кайтып килү генә гаеп саналмас, дип беләм. Мин бу хакта райком секретарена алдан белгерттем.

— Бу очракта гаебегез шундыйрак: сез туган авылыгызга буш кул белән кайттыгыз һәм далага да кул селтәп кайтып кердегез. Икесе дә кайту.

— Далага кайтуым буш кул белән үк түгел,— диде Каюм, җиңеллек сизеп.— Туган як агачларының яфракларын алып кайттым,— дип көлемсерәде ул.

— Анысы әйбәт булган,— дип, чынлап нәтиҗә ясады партия өлкә комитеты секретаре.— Ә әти-әниегез турында әйтмәсәгез дә беләм мин. Яшермәвегез — шулай ук әйбәт. Сезне чакыргач, мин сезнең хакта вакылыкларына хәтле алдан белергә дә тиеш бит. Әтиегезнең колхозга кермәвен дә беләм. Әмма ул сугышта кулларын күтәреп дошман ягына качмаган. Ил азатлыгы өчен аяусыз көрәштә яралар алган. Димәк, Ватанын таныган. Әниегезне мин районда эшләгән чагымнан беләм. Әйе, бар аның читкә чыгып уйланулары, гаярь хатын әниегез. Көчле кеше.

— Сәламәтлеге какшады.

— Анысы бездән рөхсәт сорап тормый. Сәлам әйтерсез аңа, сәламәтлек телим. Ана алдында без һәрчак бурычлы, диләр. Хак сүз. Ә менә әтиегез колхозга ни өчен кермәде икән?

— Авылда колхозга бер мәртәбә кереп чыккан булган ул. Хәтта, уңышлардан баш әйләнгәндә, колхозны таратырга тырышучыларның берсе булган.

— Димәк, монда колхозга керсә, сүзендә тормау була иде, дисезме?

— Бәлки. Холкы үзе белән иде. Әмма мин аны гаепләмим.

— Аннары. Колхозга керү ирекле. Димәк, ул шушы мөмкинлектән файдаланган. Гомеренең соңгы елларында алмаган да булырлар иде, бәлки. Менә сез хәзер колхозыгызга яңа членнарны ничек аласыз?

— Энә күзеннән үткәреп.

— Теләүчеләр бармы?

— Бар! Шушы арада гына шәһәрдә яшәүчеләрдән өч гариза керде. Шартлар һәркем өчен бер үк төрле. Гаиләсендә колхозда эшләрлек ике кешесе булсын, башта, колхоз члены булмыйча гына, алты ай эшләп күрсәтсен. Шушы сынауны узса, ул безнең кеше, үзенә хәтта йорт та салып бирәбез.

Каюм бу сүзләрен йодрыгы белән тезләренә суккалап әйтте. Онытылуы түгел, үз иманына ышануның үзгәрмәслеген раславы иде аның мондый хәрәкәте.

— Яхшы. Мин сезне гаепләмим бит,— диде секретарь, тагын урыныннан кузгалып. Аның тыныч кына утыра алмавында эңгәмәгә катнашы булмаган сәбәп бар иде бугай.— Яхшы. Йодрык төймәсәгез дә,— дип, кашларын сикертеп төрттерде ул,— мин сезнең олы идеалга ышануыгызны беләм. Шуны белмичә, шуңа аз гына булса да шигем калса, мин сезне чакыртмаган да булыр идем. Сезнең кемлегегезне хәзерге эңгәмәдә генә белергә тырышсам, бу, кем әйтмешли, олы эшкә җиңен сызганмыйча һәм кулларын төкрекләмичә тотынган хөрәсән кыланмышы гына булыр иде. Яхшы, Фәсәхиев иптәш, Каюм туган.

Һәм партия өлкә комитетының беренче секретаре дала колхозы председателе Каюмны ни өчен чакыртуы сәбәбен турыдан һәм кыска

итеп әйтте. Шулай да аларның әңгәмәсе шактый озак дәвам итте әле.
...Тәрәзәгә җепшек кар сылана. Аны яңгыр шудырып төшерә.
Поезд акрынлап туктады. Таныш йортлар күренде — Каюмның станциясе икән ич, уйланып барып, кайтып җитүен дә абайламаган ул.
Машина белән каршыларга кушмаган иде Каюм, станциядән дә колхоз идарәсенә шалтыратмады. Ара ике чакрымлап кына булса да, җәяүли торгач, җеп-бөртексез чыланды, юлның асфальт булуы гына пычранудан коткармый икән. Җиңелчә һәм көяз киенү иртән машина белән озатканда гына яраган икән.
— Нигә машина дәштермәдең?— дип каршылады аны әнисе.
— Чакырмаган идем шул.
Каюм пычрак туфли-оекбашларын өйалдында ук салды. Әнисе биргән җылы башмакларны кигәч, эшләпәсен һәм көзге пальтосын верандадагы түгәрәк өстәлгә куйды. Әнисе:
— Киптерергә мунчага эләрбез,— диде.
— Шунда да кибәр әле. Эше юк.
— Кипкән ди, лычма су булган! Иштиен китергәнсең инде син моның.
— Яңасы булыр.
— Шәһәргә барган саен өр-яңадан киенә башласаң, каккан казыгың да калмас! Әнә, мич авызында кайнаган чәй, баллап эч. Үпкәңә салкын алуың да ерак китмәс, болай егетләнеп йөрсәң, яшь чагың түгел.
Тәүфирәнең малаен өлкәгә ни өчен чакыруларын беләсе килә. Әмма моны турыдан сорамый, Каюмның үзе әйтүен көтә. Горурлыгы кушмый аңа, далада яшн башлагач, хәер, Кылыкта чакта да, беркайчан да үтенеч-сорау белән беркемгә дә мөрәҗәгать иткәне булмады Тәүфирәнең. Таләп итәргә, кушарга гына күнеккән иде ул. Каюмның юеш киемнәрен мунчага илтеп элеп кергәч тә, Тәүфирә, бәйләмен кулына алып, диванда дәшмичә утырды. Каюм әнисенә барыбер әйтмичә булдыра алмаячагын белә чөнки.
Алар өйдә икәү генә иде. Каюмның хатыны мәктәптә, озайтылган көн группасында эшли. Кызы — олы баласы — район үзәгендә кияүдә, мәктәптә укыта, иртәгә шимбә, гадәтләренчә, кияү белән парлашып кичке җиделәр тирәсендә кайтырлар, бәлки: мондый пычракта кайтып та йөрмәүләре мөмкин. Малае колхоз мастерскоенда, токарь, өйләнергә җыенып йөри, киемнәрен дә алыштырмыйча, кәләше янына фермага йөгергәндер.
— Секретарь туган җиргә тагын кайтып килергә кушты.
Тәүфирә Каюмга кырын күзен генә төшереп алды. Шаяртмый малае.
— Нигә?
— Кылыкта сабан туйларын ничек уздыруларын белү өчен генә түгел инде. Колхозлар башлап төзелгән җирдә, тормышның үзәгендә нәрсә икән, ди. Үзе ул моны шәп төшенәдер, туган авылымда ел саен булам ди. Дәһадагы тормыш белән борынгы нигездәге тормыш арасында аерма бармы? Булса — нинди һәм нигә? Анда да, монда да, кешеләрнең иманы бер ләбаса... Гомумән, кайтып килергә кушуының сәбәбенә төшенеп җитмәдем әлегә.
— Кайтасыңмы соң?
— Кайтам. Бөтенләйгә дә кайтыр идем, сез араны бөтенләйгә өзгәнсез. Кылык ошады миңа. Йә, кем инде үз йорт-җирен яндырып китә?
— Мин! Әтиең белән мин! Ни өчен без Хәкимҗан Газизҗаныны бөтен байлыгыбызны калдырырга тиеш идек ди?!
— Ни өчен бер аңа? Колхозга калдырырга иде.
— Син, беренче секретарь катында булуыңа таянып, әтиең белән мине гаепләмәкчеме әллә?
— Һич юк. Гәрчә акламыйм да мин сезне. Газизҗаннар сезнең, безнең ягъни, өйләргә калмаган булган икән. Элек нинди булгандыр, ә хәзер төзек Кылык авылы. Минем туган авыл.

— Ышанам. Кылыктан безнең даладагы авылыбыз кайтыш түгел-дер, дим.
— Шулай да аерма сизелә. Кылыкның тынычлыгы үзгә. Төн буе нигезебездә утырдым бит. Кылыкның йокысы да тәмле. Кызганычка каршы, туган авылымның эш вакытын күрә алмадым. Күркәм авыл. Кешеләренең матур эшли белүенә дәлил бу матурлык.
— Мәчетләре юк, дисең бит. Ә безнең менә дала авылында да мәчетебез бар. Әтиең салдырды. Таш мәчет. Далада ташын табуы да ансат түгел аның.
Каюм чәй савытларын җыештырды. Алгы бүлмәдәге телефоннан колхоз канцеляриясенә шалтыратып, хәлләрне белеште. Аннары әнисе янына утырды.
— Әни, гаҗәпкә калам мин кайчак: әти, бисмилласын ялгышып әйтсә дә, мәчет салдырган, син, ике класслы гына булса да, мәктәп төзеткәнсең. Үз акчагызга.
— Начармыни?
— Түгел. Әмма сез бу изгелекләрегезне, диик, халыкны үз кулыгызда тотар өчен генә эшләмәдегезме соң?
Тәүфирә бәйли торган оекбашын тезенә куйды да улына табарак борылды. Каюм ут кабызды. Лампочка яктысы әнисенең ярты йөзенә генә төшкәндәй булды, йөзенең сул ягы кара кебек иде.
— Дөрес әйтәсең,— диде Тәүфирә. Аның җыерчыкланган йөзендә, зәңгәрләгән җуйган күзендә сөенү чаткысы яктырып узды.— Дөрес аңлагансың. Шуңа иртәрәк төшенгән булсаң, бәлки, син мине коммунист итә алган булыр идең. Тик хәзер соң инде. Миңа янадан туарга соң. Мин үзем булып калам. Советка каршы түгел әниең. Әмма мин тормышны яңартуны кемнәрнедер талап эшләү ягында түгел идем. Хәзер дә шулай уйлыйм. Тигез тормыш төзергә алынгач, авырлыгын тигез төшерергә иде аның.
— Алай була алмый, әни! Беркайчан да! Буржуазияне бәреп төшергәч... бәреп төшергәч,— дип кабатлады Каюм,— крестьянны үзебезнең яклы итәргә тиешбез, дигән Ленин. Ә мондый олы үзгәрешләр күрәшсез генә була алмый. Тигезләү ысулы бармый монда, бармый! Ни өчен элек тигез булмаган алайса, бер ишләр бай булган да күпчелек ярлылыкта интеккән? Заман килеп, кинәт кенә тигезләп бүләргәме аннары?.. Яңалык юл ярганда, кыюлыкка дорфалык өстәлүе мөмкиндер.
— Әгитләргә соң мине, Каюм улым... Далага күчеп килеп алачыкта яшәгәндә салкын тимәгән булса, синең сыңарың — Котдусым бүген дә исән булыр иде...Тигез тормышка баруда шул нарасыйның тормышы өзелүе мәҗбүрият идеме соң? Игезәкләр идегез сез. Икегезгә дә гөрләшеп кенә яшисе иде канә. Тигезлекме соң бу? Нигә эндәшмисең? Шулай ул, тормыш дигәнендә замана дигәнең дә бар. Сез игезәкләрдән соң балабыз булмады. Әтиең сугыш башланганчы кайта-китә йөрде, анысын инде үзең дә беләсең. Олыгаеп та киттек.
Тәүфирә бәйләвен алды, башлаган энәсен чыгарып бетерде.
— Дөрес әйттең. Мәчет һәм мәктәп салдырып, халыкны, син әйткәнчә, крестьянны, үз ягыбызда тотарга тырыштык. Әмма заман агышы безне үзенә бөтереп алды. Далада да күмәкләшү таләп ителде. Колхозны без соңлап, җирләрнең колхозларга мәңгегә бирелүеннән соң гына оештырдык. Һәм мин бу эшнең башында тордым. Башкача мөмкин түгел иде. Карышуның файдасы тимәячәген белдем. Ни әйтсәң дә, әниең гимназиядә сабак алган синең, фикерен үстерү җаен тиз таба. Тик без төзегән колхозның да үсешен заман билгеләде, мин түгел.
— Партия билгеләде бу юлны, әни, һәм шул юлдан туры алып барды.
— Синеңчә. Ә минемчә, партиягез кешесе булмасам да, колхозның бүгенгесендә минем дә өлешем бар. Әле ничек кенә бар! Әниең сугыш вакытында да колхоз председателе булды! Керфек тә какмаган төннәре

аз идеме әниеннең! Җиңү өчен! Сталин өчен! Безне авылдан сөрдерткән Сталин өчен!

— Халык өчен, Ватан өчен.

— Сугыш буенда гына түгел, далада да Ватанны саклау иде максатыбыз. Сыңарың Котдусны онытма син.

— Әле узган атнада гына каберен карап уздым.

— Безнең дала авылында синең сыңарың Котдус зират башлады.

— Әтинең чардуганы кыйшайган иде.

— Онытма.

— Онытмыйм ич.

— Хәкимҗан Газизҗаны кудыртмаса, сабыем Котдус хәзер дә исән булыр иде.

— Безне авылдан сөрүгә нигә бер генә кеше гаепле булсын инде? Син аңлы кеше бит, әни.

— Хәкимҗан Газизҗаны калдыра ала иде. Безне Кылыкта яшәтеп тә үзенә буйсындыра ала иде ул. Бу кешенең хыялында аждаһа көче, беләгендә арыслан куәте иде. Мөгаен, хәзер дә шулайдыр.

— Бәлки, ул күптән вафаттыр.

— Исән!

— Каян беләсең?

Тәүфирә җавап бирмәде.

— Авыл белән хәбәрләшмибез. Мин дә аның турында сорашмадым. Йөз кат әйттем ич инде: Кылык колхозының председателе хатыны белән генә сөйләштем мин.

— Әнә, «Социалистик Татарстан» газитендә язганнар, колхоз төзегән ил карты, имеш! Әйтерсең, бер Газизҗан гына төзегән колхозны!

— Кырыслыгың белән кайчак сугышта каны каткан кешегә охшап куясың син, әни! Син бит минем әни, миһербанлы, йомшак күңелле бул! Оныкларың да бар өстәвенә. Бүгенгесе көнебездә бәхетсез түгел бит без.

— Син мине бүген кирәкмәс хатирәләргә алып кердең, улым. Синә, коммунист кешегә,— мин синең партийный булуыңа каршы төшмәдем, әтиең дә ризалыгын бирде, моны да онытма,— әйе, коммунист кешегә шулай ук миһербанлы булу кирәк. Минем кырыслануыма, бәлки кайбер хатын-кыз сыйфатларымны югалтуыма сәбәпләр күп. Санаймк Котдус... Даладагы тормышны кору әниең җилкәсенә төште... Әтиең белән әниең үз йортларын гына яндырсалар, туган җирләренә качып кайтып, колхоз милкен яндыручылар да булгандыр, бәлки. Җинаятьләре ярылып яткан кешеләрдән оештырды әниең колхозны, хатын-кызга җиңел булмагандыр бу... Сугыш... Хәзерге тормыштан канәгать мин. Тик... Бирде дөнья кирәкне...

Алар шактый сүзсез утырдылар.

— Туган теленне оныттырмадым мин сиңа, улым!..

Тәүфирә карчыкның күзенә яшь килде.

— Мин сиңа барысы өчен дә гомерем буена бурычлы, әни.

— Рәхмәт шул сүзеңә. Миңа хәзер булганнарыннан бүтән берни дә кирәкми. Калган көннәремдә генә яңадан туган кебек була алмыйм. Синең әйбәт яшәреңә мин ышанам.

Тәүфирә карчык яшьле күзләрен алъяпкыч кесәсеннән бәләкәй кульяулык алып сөртте.

— Әни, тагын бер нәрсә турында сорыйм әле. Күңелдә төен калмасын. Әти Кылыкка яшерен кайтып йөрмәдеме? Сез, мин малай чакта әле, безнең туган якларда колхозлашу елларында һәм соңрак булган янгыннар турында сөйләшә идегез. Татарстаннан алдырган газеталардан укый идегез булса кирәк.

— Юк, Кылыкка мин дә кайтмадым. Читтә эшләп йөргәндә, әтиең дә кайтмагандыр дип беләм, кайтса — яшермәс иде. Янгыннарда безнең катнаш юк. Хәтерлим укыганымны. Кылыкның Түбә куагындагы ындырда кибәннәр һәм атлар янган. Волостьтагы больница янган, монысы

алдарак та. Әтиең авыл советының беренче секретаре чагында күршедәге боярның каралтыларына ут төрткән булганнар. Әмма анда да әтиеңнең катнашы юк. Байлар котыртуы буенча ут төрткән кешене хөкем аклаган. Әтиең шулай дип сөйли иде. Мин ул чакта килен булып төшмәгән идем әле.

Карчык, иреннәрен дерелдәтеп, нәрсә турындадыр, әйтергәмени юкмы, дигәндәй икеләнеп торды. Каюм үзе сорамады.

— Бер тапкыр мылтык тотты әтиең. Хәкимҗан Газизҗанына төнлә урманда атты. Аның волостьтан кайтуын чыршы төбенә яшеренеп көттек. Әйе, икәүләп көттек. Ботаклары җиргә салынып төшкән чыршы төбендә көттек. Әтиең Кияү Газизҗанга төбәп тә тормады. Һавага атты. Куркыту өчен генә атты.

— Һе, шәп куркыту!

— Хәкимҗан Газизҗаны әтиең атканны сизенгән. Шулай да хөкемгә тарттырмады.

— Әни...

— Нәрсә аны, карт башың белән, иркә сабый кебек, сузып кына әйтәсең? Урак өстендә котырынып чыккан кара болыттан, яумый узчы, дип ялваргандай мескенләнәсең? Әниең кара болыт түгел, борчылма. Шулай ук урак өстенең тирән аяз күге дә түгел.

— Әни, безгә моннан китәргә туры килмәгәе.

— Китәргә? Безгәме?! Ике аягымның берсен дә атламыйм! Котдусым монда, Фәсәхетдинем монда! Миңа дала мазарлыгында урын иркен. Китәргә дип ашкынып тора ди анда берәү, әмма ул Тәуфирә түгел, ди. Себергә үк җибәрергә мәллә? Миңа шушы даласы да җитеп ашкан.

— Әллә кайларга барып ирешмәче, әни. Мине үзебезнең партия райкомына беренче секретарь итмәкчеләр.

Көтелмәгән бу хәбәрдән Тәуфирә карчык аптыраушта калды. Сөенергә дә белмәде, кайгырырга да уйламады.

— Дөрес булыр. Каршылыгым юк. Ләкин мин моннан район үзәгенә күчмим. Китегез әнә, килен белән икегез. Онытым өйләнсә дә, һәркайсы болын хәтле дүрт бүлмәле ике катлы шушы йортта миңа урын табылыр, шәт.

...Каюм, өлкә комитеты секретаре мондый тәкъдимне әйткәч, бик аптырауга калган иде. Ул алга иелде дә өстәлгә бармакларын ышкып озак утырды. Секретарь аны җавабы белән ашыктырмады, алгы бүлмәгә дә чыгып керде бугай, ишек ачып ябылган кебек булды. Каюм башын күтәреп караганда, секретарь кулындагы стаканыннан чәй йотымлый иде. Һәм, җавабын әйтәсе урында, ул: «Нигә тынгысыз хәрәкәтләнә икән соң безнең секретаребез»,— дип уйлады. Бик тыныч кеше итеп белә иде ич аны Каюм.

— Безнең хәзерге секретаребез әйбәт эшли, аны нигә алыштырырга икән?— дип сорагандай итеп башлады Каюм.

— Мин дә аны, начар эшли, димәдем. Аны өлкә комитетының икенче секретаре итеп сайламакчы булабыз.— Егор Степанович буш стаканын почмактагы тәбәнәк өстәлгә куйды.— Үсәрен истә тотып.

— Ышанычыгызга рәхмәт, билгеле. Ләкин минем яшь шактый бит. Пенсиягә таба юл тоту. Тагын биш ел чамасыннан.

— Район партия конференциясе ике елдан ике елга үткәрелә. Начар эшләсәгез, Каюм Фәсәхиевич, биш ел утырырга туры килмәс. Әмма сез булдыра алачаксыз. Даланың үз кадры. Тормышның матур якларын бергә туплау өчен, димәк, байлыгыбызны — һәм матди, һәм рухи байлыгыбызны — арттыру өчен тәҗрибәле һәм фикерләүчән кеше кирәк район җитәкчесе булырга, ягъни сез кирәк, Каюм туган. Әтиегез исеме белән дә эндәшмәгәнгә ачуланмыйсыздыр, татарлар исем белән генә эндәшүне хуп күрәләр. Ялгышмыйм, шулаймы?

Каюм баш кагып ризалашты.

— Сезнең кандидатураны секретарегыз тәкъдим итте. Белә, димәк.

Мин яклыйм менә. Ышанам сезгә. Ә картаю турында кимендә биш ел уйламыйча торыгыз. Биш елда әйбәт житәкче тауларны күчереп куя. Менә мин сездән яшьрәк тә, ә хәтәррәк итеп сиздергән башка нәрсә бар. Сәламәтлек...

Егор Степанович Каюмны алгы бүлмәгә озата чыкты. Кул кысышып саубуллашкач, жилкәсенә кагып алды һәм елмаеп кына:

— Шулай да Татарстанны күрергә туры килер сезгә, Каюм туган,— диде.— Әмма бөтенләйгә китү турында уйлап та карамагыз, дала жибәрми сезне! Уңышлар телим сезгә, Каюм туган!

Каюм чыгып китәргә ашыкмады.

— Барысы өчен дә мин җавап бирәчәкмен була,— диде ул, коридор ишеге төбендә кире борылып.

— Әлбәттә. Һәм беренче чиратта кешеләргә матурлык бирү өчен җаваплысыз. Сезнең моны аңлавыгызны белгәнгә күрә, мин бу хакта сүз кузгатмадым.

— Фәлән фермада сөтнең аз савылуы өчен дә райком секретаре гаепле булачак.

— Ә сезгә эшне бүтәнчә корырга беркем дә комачауламый. Һәм эшне аргта сөйрәлмәслек итеп оештырыгыз.

— Шыплап тутырылган аппараты белән авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы райком секретаре канаты астында ышыкланып йөри бирсен. Йөзен җил чеметмәсен, башын яңгыр чылатмасын аның. Урак өстендә болытлы күккә сокланырга әвәс кешеләр шактый шул авыл хуҗалыгына җитәкчелек итүчеләр арасында. Беләсе иде: колхозлар элегрәк төзелгән якларда авыл хуҗалыгына җитәкчелек ничек камилләшә икән? Анда да теге яки бу колхозның алга китүе район идарәсенә бик чамалы бәйләме икән? Андагы идарә безнең дала идарәсеннән аерыламы икән?

— Сезне секретарьлыкка тәкъдим итеп ялгышмыйбыз, димәк. Хәзердән үк уйлана башладыгыз. Туган ягыгызда сабан туеннан башкасын да белешергә кирәк, димәк. Каюм туган, менә сезгә бер мәсьәлә алайса. Авылда, җир эшендә ягъни, күмәк хуҗалык формасы үзен аклады. Ә гомумән, авыл хуҗалыгына җитәкчелек итү ничек тора бездә? Район идарәсендә чебен куу белгече генә җитмидер хәзер. Колхоз формасын үзгәртеп булмый. Киләчәктә, бәлки, үзгәртү дә таләп итәләр итеп түгел. Район идарәсендәге белгечләр колхозларга хезмәт күрсәтүче станцияләрдә, оешмаларда эшләргә тиеш түгелме? Колхоз төзелешенең, авыл хуҗалыгын үстерүнең, сезнең сүзне кабатлап әйткәндә, урак өсте җиттеме? Авыл хуҗалыгына җитәкчелектә, гәрчә игенчелеккә бәйле тармак булса да, ел саен чәчеп тә, урып та булмый. Уйланыгыз.— Егор Степанович җилет кесәсеннән сәгатен алып карады.— Миңа ашыгырга туры килүе бар. Әңгәмәне дәвам итә калсак дим. Ә ашыгырга сәламәтлек дигәнең ирек бирми...— һәм ул кием шкафына таба борылды.— Машина белән килдегезме?

— Поезд белән.

— Озатып куйсыннармы?

— Кирәкми. Минем әле күчтәнәчләр аласым бар. Чит җирдән күчтәнәчсез кайтуны әни өнәми.

— Нишлисең, бу очракта хаклык аның ягында.

Секретарь киенде. Һәм алар урамга бергә чыктылар. Егор Степанович машинасына утырды да китеп барды. Каюм, өлкә комитеты каршындагы мәйданны турыга чыгып, олы урамга керде.

## 9

### 1985 ел, хикәяләү башланган көн, өйлә узгач.

Гаян Сәйфулов Кылыктан кайтканда, ак тавык үзенең барлыгын сиздермәгән иде. Илтә чыккач, тәмам шашынды, каһәр. Әле алгы утыр-

гыч аркасына сикереп куна, әле арткы кечкенә тәрәзәгә оча да, машина тентына бәрелеп, аралыкка мәтәлеп төшә. Гаян, машинасын туктатып, аны карарга мәҗбүр.

— Җан тәслим кылдың мәллә, мөртәт! Тавык мие эчкән нәрсә!— Сәйфулов аннары үзен әрләп куя.— Тавык тавык мие эчә диме инде, тиле!

Исән икән тавык, шайтан да булмаган, хәйләләп кенә яткан. Машина туктауга, арткы утыргычка менеп, кытаклый башлады. Тавышы имансызның, машина гөрелтесен дә басып китә. Дөнья яра, инкубатор калдыгы! Машина эчен хәзинәсенә буяп бетергән, тизәк корсак!

Идарә начальнигы ачуы белән газга баса да машина дуылдап кузгала. Ак тавык тагын алгы утыргыч аркасына очып менә.

Ниһаять, Газизҗан картлар капка төбенә житте Сәйфулов. Ул үз ягы ишекне ачуга, ак тавык, аның битенә канатын бәреп, чыгып очты. Җиргә төшкәч, җилпенеп кагынды. Кукыраюын күр син аның, ике аяклы имгәкнең! Һәм тавык капка астындагы тишектән ишегалдына кереп качты.

Гаян китәргә машинасын борганда, йортның ачык тәрәзәсеннән, тартылган пәрдәне күтәреп, Газизҗан туктарга ишарәләде. Сәйфулов машинасын тәрәзә турысына китерде, иелеп, каршы ишекне ачты, уң якка күчеп, йорт хуҗасына эндәште. Карт ишетеп житкермәгәч, ачкычын борып машинасын сүндерде һәм:

— Газизҗан абзый, тавыгыгызны китердем,— дип кычкырыбрак кабатлады.— Малаегыз тыңлаусыз икән.

— Минем малаймы? Кайсысы? Икәү бит алар минем,— дип сизенмәгәнгә сабышты Газизҗан.

— Председателе инде, мин бүтәнен белмим.

— Бар анысының кире гадәтләре. Кайчак мине дә тыңламый. Мин нәрсә, малае Җиһангир сүзен дә колагына элмәгән чаклары була... Теге хатка җавап яздым. Шуны кабат карап утырам. Кызык хат. Кермисеңме соң?

— Юк. Минем эшем житәрлек.

— Бардыр анысы эшең. Шулай да нишләгән соң әле минем председатель малай?

— Тавыгыгызны килеп алырга машина җибәрергә кушкан идем, киресенә бетте.

Газизҗан, тәрәзә төбенә күкрәге белән терәлеп, идарә начальнигына чеметтереп карады.

— Син тыңлаусыз бу очракта, начальник. Әйттем ич мин сиңа, машина ишегеңне ябып куй, дидем. Ирендең. Хезмәтче кирәк ахры сиңа. Син итәгеңне җыеп йөрмәгән өчен, минем малай сиңа хезмәт итәргә, тавыкны барып алырга тиешме? Колхоз машинасын тәккә кусынмы? Көне буена тырай тибеп йөрисең ахры син бүген, иптәш начальник! Район үзәге белән Кылык арасындагы юлны ашлап. Күчереп булмый олы юлны. Басу юлын гына күчерә идек элек. Ат җигеп кыр эшенә йөргәндә, юл тиресләнгәндә, дим.

Сәйфулов аскы иренен каты итеп тешләде. Ачуы моның белән генә басылмады, шытырдатып машинасын кабызды да дуамалланып китеп барды. Хәтта саубуллашмады.

— Тәрбиясез...— дип ачуланды Газизҗан идарә начальнигы артыннан. Һәм, кәефе кырылудан, җавап хатын төзәткәләүне дәвам итә алмады.

Күпергә кергәнче, Сәйфулов инешләр тамакларындагы уентыкларны тагын күзеннән кичерде. Мондагы кире халыкны тыңлатуы ансат булмастыр, дип уйлады ул. Тиз генә сөрергә ризалашмаслар кебек. Ис киткән, ди, барыбер сукалаттырабыз! Район идарәсе начальнигы куша, ягъни бөтен житәкчелек куша!

Гаҗәп, Сул инеш тамагында карга хәзер дә бар иде. Әллә шул

иртәнгесе үк тагын. Бигрәк иләмсез. Иртәнгесе, кугач, каркылдап, тал очына менеп кунган иде, туган урыны шул ахрысы. Монысын да куаргамы әллә? Ара еragrak, ташны алай еракка үк ата алмас Гаян. Малай чакта ташны ыргытып төз чүки иде ул үзе.

— Әллә акылдан шаштыра башлады инде бу тавык белән карга,— дип үзен әрләде Гаян.— Начальник башың белән карга куып йөрү генә житмәгән, ди... кукуруз басуыннан, диләрме әле,— дип жыр сүзләрен кабатлады. Аннары:— Инеш тамагыннан,— дип төзәтте. Әмма үзгәртүнең көй агышына ятышмавын сизде.

Иртәнге якта аның итәген чәйнәргә ябышкан каралы-аклы бозау Гаянның машинасына карый кебек иде. Үткән-сүткәнне күзәткәләп кенә торадыр бу ала бозау. Ашауда гаме юк ахрысы мәхлукның. Уентыкның үләне тәмсезме әллә, бозау да ашамый. Бу уентыкларны файдага жигәргә кирәк. Шунысы шиксез!..

— Исәнме, энем,— дип, посып кына дигәндәй килеп керде Кәшшафетдин бертуган энесе Әмиржан янына.

Туганлык хисе көчле булуы өстенә, яшь аралары ерак булганга күрә, Әмиргә ул һәрчак кече итеп эндәшә иде. Үзе егет яшенә житкәч туган энесен, гәүдәгә үзенә караганда зур булуына карамастан, һаман кечкенә итеп күрә, үз тормышы өчен хафаланудан бигрәк, Әмиржан хакында ныграк борчыла иде Кәшшафетдин.

— Минем хәлләр әйбәт, абый,— дип, Әмир дәү учын Кәшшафның жилкәсенә салды һәм телевизор янәшәсендәге тәбәнәк йомшак кәнәфигә китереп утыртты.

— Бер-бер күңелсезлек бармы әллә, энем?— диде Кәшшаф, кәнәфинең алгы читенә шуышып күчеп.— Чакырдың. Кул изәдең, дим. Тәрәзәдән. Әле ярый күреп алдым, сугылмыйча узар да китәр идем.

Монысы абыйсының Фәрах мәсьәләсендә сүз кузгатмаска иплэп кенә алдан сиздереп куюы булды. Шулай, үз хәсрәтен энесенә бикләргә тырыша Кәшшафетдин, гадәте шундый. Сизгер һәм тиз яралана торган, әмма үтә чыдам күңелле ул. Бу яктан энисе Сәхәриягә бик тә охшаган. Бәлки, әтисе Газизжан, колхоз оештырып, колхоз өчен көнен-төнен кызганмыйча йөреп, өй тирәсендә аз кайнашканга, ягъни малай энисе янында күбрәк булганга, энисе гадәтләрен үзенә тулаем алып үсте Кәшшафетдин.

— Барысы да иплe, абый. Чакырдым шул. Югыйсә, сирәк күрешәбез бит.

— Эшнең күп чагы хәзер, энем. Ике-өч көннән комбайнны ремонтлап бетерәм. Бая, машина утарына кергәч, минем янга үзең килмәдең. Мин дә бармадым инде. Эш күп. Сабан туе да житә. Бәйрәм мәшәкатьләре тагын, безнең халыкка әзерләнмичә ярамый.

Бәйрәмне башлагансың да инде син, дип әйтеп жибәрә язды Әмир. Ярый ла тыелды, югыйсә абыйсының күңел ярасын тирәнәйтеп кенә жибәрер иде. Аракыга хирыс кеше түгел Кәшшафетдин абыйсы. Фәрахетдиненең авыл белән шәһәр арасында очынып йөрүенә эчтән сыза. Шулай да мондый чакта хәмер киңәшче була алмый. Ачуланып әйтмәсәң дә, шуны сиздерергә кирәк үзенә. Хәер, бу мәсьәләдә абыйсы аның киңәшенә' калмаган калуын, әллә нидә бер тотып куя. Ләкин колхоз председателенең абыйсы да кеше күз алдында, абыеңны бел, дип төртеп кенә күрсәтерләр. Сабан туе алдыннан, Кылык авылы төрле яклардан кайткан кунаклар белән тулгач, кайтучылар арасыннан шәбәебрәк сыйланучылар да була. Була гынамы соң, атна буена айный алмый кайберсе. Эчүчелеккә каршы карар чыккач, шешәгә табынучылар күзгә күренеп кимеде, быелгы сабан туен бөтенләй хәмерсез уздырырга жыенабыз. Һәм дөрес. Югыйсә, сабан туе мәйданына төшкәнче үк авыз чылатып алалар да — диңгез тубыктан аннары! Әйе, авызга аракының бер йотым керүе генә кирәк, аннары шул бер йотымы да үзенекен итә. Әйе, эти

әйткәндәй, аракы каршында һәркем бертигез, дәрәҗәң белән дә, сәламәтлегең белән дә санашып тормый хәмер, эчүгә сабышкан бәндәне тәмуг дигәннәренә бөгәрләп кенә сала. Шулай булгач, Кәшшафетдин абый, хәмергә сәлам биреп дөрес эшләмисең. Минем үгет-нәсихәтемә мохтаҗ түгелсең. Юк, мохтаҗ икәнсең, эш вакытында «көч борын»га оешырлык хәлгә төшкәч, бик тә мохтаҗ икәнсең!

— Абый...— дип ачуланып үгетен башламакчы гына иде Әмир, рөхсәт тә сорап тормыйча, ишекне каты ачып, тирләп төшкән Шәриф атлы шофер килеп керде.

— Әмир абый!— диде ул һәм тыны кысылып тукталды.

— Ни булды?— дип куркынып урыныннан сикереп торды председатель.

— Әмир абый! Машина...— Тагын тыны кысылып туктады Шәриф һәм буылып йөткерде.

— Нишләттең машинаңны? Авария ясадыңмы? Кеше таптаттыңмы? Нинди бәла чагардың? Әйт тизрәк!

Председатель, үзе дә сизмәстән, кулларын йодрыклады, әмма баскан урыныннан кузгалмады, шулай да бөтен тәне белән калтыранды. Абыйсы Кәшшафетдиннең янына килеп басуын да абайламады, күзләрен акайтып басып калды.

— Әмир абый!..

— Әмир абыең инде! Корт чаккыры!

— Машина кирәк...

— Уф-ф!— дип иркен сулады Әмир.— Котны алдың. Нинди хәл булган икән, дип торам.— Әмир урынына барып утырды да маңгаена бәреп чыккан тирләрен ашыкмыйча гына сөртте.— Сиңа машина кирәк, ә?— дип мыскыллавын яшермәде ул.— Машинаң бар ич синең.

— Җиңел машина кирәк. «Волга»ны биреп тор, ә. Хатынны район больницасына илтергә кирәк. Бәбәй таба алмыйча азаплана. Үзебезнең хатын-кыз врачын агитаторлар семинарына җибәргәннәр диме шунда,— дип, көч-хәлгә тезеп чыкты ата буласы кеше Шәриф шофер.

Председатель урыныннан тагын сикереп торды.

— Соң, җебегән җан, адәм рәтле итеп әйтергә ярамыймы сиңа шуны! Мә, гаражны ача тор! Тукта! Бир ачкычны! Хатының янына төш! Врачны монда чакыртырбыз! Шул хәлендә юлга алып чыгалар диме?!

— Операция ясап алырга кирәк, диләр, баланы.

— Район больницасыннан ким түгел безнең больницабыз! Нәрсә терәлеп каттың? Йөгер больницага, дим бит! Операциясенә әзерләнә торсыннар. Врачны хәзер чакыртам. Машинаны да җибәрәм, үз врачыбызны да семинардан туздырып алып кайтырлар! Бәбәй табар вакыты җиткәч кенә хатын кайгысы төшкән син акыллы башка, моңарчы хатыныңны кыерсытмыйча яшәргә иде аны. Синең кимсетүләрең нәтиҗәсе бу, бел, хөрмәттә яшәгән хатын бәбәен дә җиңел таба... Карале, терәлеп катты, әй, йөгер, дим бит!— Шәриф ишеккә бәрелеп чыгып йөгерде.— Алло! Больницамы? Хәкимов бу, Кылыктан.— Әмир районның баш врачына мәсьәләне тиз генә аңлатып бирде.— Ашыгыч!— һәм, үтенечен көчәйтмәкче булып:— Алдынгы савымчыбыз!— дип өстәде.— Ире дә менә дигән шофер! Нигә köләсез?! Ашыгыч, дим!..

Трубкасын куйгач кына баш врачның көлеп куюы мәгънәсенә төшенде Әмир. Соң, кешегә ашыгыч ярдәм кирәк булганда, аның кем булуы мәҗбүримени инде...

Кәшшафетдин Әмирнең беләгенә кагылды.

— Сиңа врач та булырга туры килә шул, энем. Мин китим. Син үзең хәл итәрсең. Хаклыктан чигенмәсеңне беләм, энем,— дип, Кәшшафетдин салмак атлап чыгып китте.

— Ярар,— дип аңышмыйча әйтеп калды Әмир.

Туктагыз, нәрсәне хәл итәргә тиеш соң әле ул? Фәрах мәсьәләсенме? Фәрах...

Председатель селекторны кушты.

— Теге... Фәрах дигән философ кайсыгыз янында анда? — дип карлыккан тавыш белән кычкырды председатель.— Тиз керсен монда!

Әмир абыйсы үзе чакырып алуына Фәрахның авызы ерылган иде.

— Икенче раунд сөйләшүләр туганнарча дуслык шартларында башлана,— дип җил-җил килде ул. Әмма председательнең:

— Шоферлык таныклыгың мондамы?— дигән кискен сүзләре аның шаяртуын томалады.

— Үзем белән, Әмир абый,— дип чалбарының арткы кесәсенә сукты Фәрах.— Киң профильле механизатор булу правам да кесәмдә.

— Әйдә!— диде Әмир, боерып, һәм, гараж ачкычын кулында кош тоткандай итеп, ишеккә таба ашыгып атлады.— Тиз!

Фәрах, берни аңламаса да, председатель абыйсына карусыз буйсынып атлады.

«Волга» пыр тузып кузгалып киткәч, Әмир гараж күләгәсендәге чирәмгә утырды. Аякларын алга сузды, учларын аяк очларына куеп, гимнастик хәрәкәтләр ясады. Күзәтеп торучы булса, безнең председатель җиңеләя башлаган, дип уйлавы да бар иде. Шөкер, гаражның арткы ягы — басу ягы, моннан узучы күренми.

Хатыннарны иркәли белмибез шул, дип уйлады Әмир. Ачуланырга, кимсетергә оста без — ирләр. Хатыны бәбәй табар вакыт житкәч, исенә төшкән, өенә исереп кайтып җәнҗал куптаруларын оныткан Шәрифен. Хатынның кадерле җан икәнлеген хәзер генә аңлаган, әй. Аңлаган булса. Аңлаганга охшый үзе. Тормыш бу, җанкисәгем Шәрифҗан. Хатын безгә, хатын булып кына түгел, тормышта хөрмәткә лаеклы җан булганы өчен дә кирәк, агайниш. Кирәк, кирәк... Адәм баласына барысы да кирәк. Ә колхозда бүген комбайннарга запчасть кирәк. Идарә начальнигы аларны үзебезгә юнәтергә куша. Табарбыз соң. Урак өстендә кырга чыкмыйча калган бер генә комбайн да булмады моңарчы. Менә кешенең яраланган күңеленә запчастьне каян табарга икән... Кәшшафетдин абый күңеленә. Фәрахетдин күңеленә. Аның кәләше... Фәрах мең тапкыр кабатлады, әй, онытканмын, әллә инде күңелгә алмаганмын. Ә-ә, Фәрзанә ич!.. Фәрахетдиннең кәләше Фәрзанә күңеленә... Шофер. Шәрифҗанның кимсетүенә дә чыдам, хәзер бәбәй табу газабы кичерүче тыныч холыклы Заһирә күңеленә... Дөньяга Кеше бүләк итү өчен пычак астына керүдән дә курыкмаучы Ана күңеленә... Комбайнга запчастьне каян алырга икәнен әйтә алмадың, иптәш начальник, бәлки, кешеләр күңеленә ачкыч табарга булышырсың. Ай-һай ла...

Тор, иптәш Хәкимов, синең бүгенгә диелгән тагын бер эшең бар лабаса. Гимнаст, имеш. Колхозның картлар йортына барып, Мөсәвир картны күрергә тиешсең син. Кичәдән бүгенгә калдырган идең бу йомышыңны, инде иртәгә күчермә. Вакыт күпме соң әле? Өченче ярты булып бара. Алай...

Кылыкта картлар йорты оештыруны тормыш таләп итте. Тормышның да тамак ягы түгел, бәлки күп кенә картлар-карчыкларның ялгызлык хәсрәтен җиңеләйтү өчен эшләде моны Әмир Хәкимов. Әйе, нәкъ менә председательнең башлап йөрүе, кайберәүләрнең үгетләве, ә икенчеләренең дәлилләренә үзенең кире беткәнлеген каршы куюы белән ачылды картлар йорты. Бу мәсьәләдә этисе Газизҗан да:

— Син әниең белән мине дә шул йортка илтеп ташламакчымы әллә?— дип каршы төшеп караган иде, ләкин Әмир сүзне коры тотты.

— Минем дә, киленең Рәсиханың да сезне ташламаячагыбызны белеп торасың, эти!— дип кырт кисте ул.— Шулай да кирегә сөрмичә түзмәдең! Син булып син түзмәдең. Юк инде, оештырабыз картлар йортын! Хаклы булуыма барыбер барыгызны да ышандырам. Һәм төзелеш кирәк-яраклары, бүтән әйбер-сәйбер генә колхоздан булачак, картлар йортын өмә белән салабыз, барлык эш өмә белән башкарылачак! Шөкер, һөнәр ияләре эзләп, авылдан чыгып йөгерәсе юк. Кылык

үзе үстергән кешеләр арасында проект сызарлык инженерлар да, хәтта күз нурыңны алырлык итеп бизәүче рәссамнар да бар. Үзең төзегән колхоз үстергән кешеләр алар, эти. Шуңа сөен. Һәм тирәнтенрәк уйлап кара, эти,— дип тавышын йомшартты малае.— Туган нигез турында, җир турында, шуларга өстәп, киләчәк буыннарны тәрбияләү турында сүз бара лабаса.

Әтисе озак кына эндәшмичә торды да:

— Белмим шул, улым,— диде,— яхшылап уйлап бетердеңме икән менә. Минем фикер белән хәзер ерак китеп булмас, анысы бар. Ләкин җирнең киләчәге хакында уйларыңда адәмгә яхшы булып күренү максатын тотма, колачлы яхшылык эшләүне алга чыгар. Минем исәпләвемчә, хәзерге көндә Кылыкта бөтенләй ятим ике генә карт бар. Аларны...

— Әти, тукта, югыйсә ямьсез сүз әйтәсең,— дип бүлдерде Әмирҗан.

— Әйтүем дә мөмкин. Ләкин гаепләнерлек эш түгел. Чөнки картлар йортлары тәрбиячесез калган кешеләр өчен хөкүмәт карары нигезендә ачылды. Ә караучысыз калган кешеләр, минем санавымча һәм әйткәнемчә, бездә икәү генә. Нишләмәк кирәк, аларны туган авылдан аеруда берәүне дә битәрләп булмый.

Әмирнең бер гадәте бар, ул үз фикерен тәфсилләп аңлатырга яратмый. Фикеренең нигезле булуына бүтәннәр үзләре уйланып төшенергә тиешләр дип исәпли ул. Нәкъ менә уйланып төшенергә тиешләр. Югыйсә, «ә»гә «җә» дип торучыларны тирәсеннән тиз арада тайдыра иде председатель. Кайберәүләр моны көчләп буйсындыру дип санасалар да, Әмирнең үзе өчен бу кагыйдә изге иде. Ахыр чиктә кешеләр аңа түгел, ә бәлки төпле фикергә, шул фикерне һәр яктан бәяләп буйсыналар, алай гына да түгел, синең фикереңне үстереп тә җибәрәләр ләбаса. Үзең уйлану хәер. Әмма әтисенә, картлар йорты ачу фикеренә ышандыру өчен, кайбер дәлилләрен әйтмичә булдыра алмады. Чөнки бу яңа эш һәм күп яктан калыпка сыймый торган эш иде.

— Авылда пуҗумнар ишәя, эти.

— Моның өчен мин синнән ныграк пошынам, улым. Нишләмәк кирәк, авылларны шәһәр йота. Гомеремнең сиксән елын шушы Кылыкта уздырган кеше мин. Армия елларын исәпләмәгәндә дә сиксән... Авыл уртасына таш пулатлар салып кую белән генәмени, крестьян нигезләрен бетерә баргач...

— Әгәр без моңа чик куйсак?

— Ничек итеп? Ике картка яңа нигез салып бирепме? Һәм шуның хисабына аларның ике нигезен корытыпмы?

— Корытмыйбыз нигезләрен, эти. Аларныкын да, башкаларныкын да. Теләгән чакларында үз өйләрендә торырлар. Әмма аларның ялгыз түгеллеккә ышанычлары булсын. Аннары, йорт-җирләрен сатып-сүтеп шәһәргә балаларына киткән карт-карчыклар авылга кайта башлаячаклар. Һәм без аларны картлар йортына ачык чырай белән каршылап урнаштырырбыз. Аларның моңа олы хакы бар, үзең белән бергә эшләгән кешеләр.

— Белмим шул, кайтырлармы икән. Бер кискән икмәк кире ябышмый.

— Туган җирнең күңеле киң, эти. Адашып йөргән кешене башлап туган җире чакырып алыр.

Газизҗан карт малаеның фикере дөреслегенә ышана башлады.

— Анысы, йортларын бетерүчеләрнең үкенүчеләре дә бар инде. Җәйне туган-тумачаларында уздыручылар шактый. Кышка шәһәргә киткәндә, күңелләре сыкрыйдыр. Картлар йортына кайтып торырга риза да булырлар алар, улым. Син дөрес фикерлисең сыман. Туган җир бит... Мин мәсьәләнең бу ягы өстен икәнлеген искәрмәгәнмен. Үз башыма төшмәгәч. Хәер, синең дә башыңа төшмәгән инде бу. Шулай да дөрес хәл кыласыңдыр. Әмма алардан колхозга файда өметләнергә кирәкми.

— Аларның кайтулары ук колхозга бәһасез файда булачак. Хәзер олыгаеп баручылар һәм яшьләр, һәм авылның барлык кешесе киләчәктә колхозның үзләрен ялгыз калдырмаячагына үзе, үзе күреп ышаначак. Бәлки, авылга кайтып йорт-җир коручылар да булыр? Колхозыбызга яңа әгъзалар ала башларбыз, бәлки? Эшләр шулайга китсә, начар булмас иде. Сугыш башланганда, авылда өч йөз дә өч хуҗалык бар иде дисең бит син. Бу дәрәҗәгә сугыш бетеп кырык ел узгач кына җиттек.

— Революция булганда, унсигезенче ел башына, безнең Кылыкта өч йөз сиксән өч ихата иде,— дип хәтерләде Газизҗан.— Тормышны яңача корганда, үсәргә тиеш чакта ягъни, без авылны кечерәйттек. Минем дә гаеп бар монда.

— Бөтен ил белән кылынган ялгышлык.

— Шулай, бөтен ил белән. Әмма гаепле кешесен атап эзләсәк, бу гаеп Кылык авылы өчен минем өскә дә төшә, барысы өчен дә Сталинны гына гаепләмик. Әле дә ярый авылны бөтенләй бетермәдек, нигезне сакладык. Авылыбыз һаман бер колхоз булды.— Газизҗан уйланып торды, фикерен очлау җаен тиз генә таба алмады.— Син хаклы кебек, Әмирҗан улым,— дип килеште ул бераздан.— Ләкин бу уеңның барып чыгарына шикләнеп тә куям. Син теләгәнчә үк барып чыгарына...

«Революция» колхозының картлар йортын Арыслан тавы итәгендә Әрәмәлек буена салдылар. Аны, Әрәмәлекне дә кертеп, койма белән әйләндереп алдылар. Бу эшне башлаганда, уен итеп караучылар да булды. Әмма өмәләрдә эшнең сыйфатына беренчел әһәмият бирелүен күргәч, колхозчылар картлар йорты оештыруның кирәге турында үзләре үк уйлана башладылар. Һәм колхоз председателе Әмир Хәкимовның фикере җиңеп тормышка ашты. Шунысы да бар, хәзер Кылыкта картлар йортына олы бер хуҗалык итеп карарга күнектеләр. Монда өлкән авылдашларының хәлен белергә килүчеләр күп, алар белән кунак йөрешү гадәткә әверелде.

Өмәләр уздырып картлар йорты салу хәбәре авылдан читтә яшәүчеләргә дә тиз барып иреште. Аларны үгетләргә кирәк булмады, колхоз идарәсеннән кайтырга рөхсәтне баш иеп килеп сорадылар. Көчләрендә булганнары йортны салуда үзләре дә булыштылар, акча бирергә тәкъдим иттеләр.

Тик Әмир Хәкимов, инде башлангычының тамыр җибәрүенә ышангач, әлбәттә, бу очракта да бер кирелеген, үзенчә фикерләвен күрсәтмичә кала алмады. Колхоз идарәсе читкә китеп яшәүчеләрнең акчасыннан баш тартмады, бу акчаларны аерым исәпкә салып бардылар, йорт төзелешенә тотмадылар. Кайтучыларның улларына-кызларына колхоз идарәсе мондый таләп куйды: алар, эти-әниләре өчен, өмәдә катнашырга тиеш. Шушы мәсьәлә буенча низаглар да кузгалып алды. Кайберәүләр, эти-әниебез безгә артык түгел, без аларның кайтып китүенә ризалашмыйбыз, авыл белән алыш-бирешебез юк, ни өчен без кайтып эшләргә тиеш әле, дип каршы төштеләр. Ләкин эти-әниләренең кайту теләге белән килешергә, колхоз идарәсенең өмәләрдә катнашу мәҗбүри саналган карарын үтәргә туры килде.

Хәзер һәркем канәгать. Картлар йортында яшәүчеләр теләгән чакта улларында-кызларында озаклап кунак булалар, аларның үзләренә кунаклар кайта.

Тагын бер киң күңеллелек күрсәтте колхоз. Быел, Җиңүнең кырык еллыгы уңаеннан, картлар йорты салганда җыелган акча Тынычлык фондына тулаем тапшырылды. Картлар йортында яшәүчеләр май ае, Җиңү ае пенсиясен шулай ук Тынычлык фондына бирделәр. Моны, әйтүләренә караганда, Кылыкта малай чагыннан ук өмәләрдә йөреп тәгәрәп үскән Мөсәвир карт оештырды.

Колхозда картлар йорты ачылуына көзгә дүрт ел тула. Өмәче Мөсәвир аның беренче көненнән шунда. Йортын да сүтмәделәр, төзек тота аны колхоз.

Әмир Хәкимовның Мөсәвиргә йомышы төште, авылның өлкән агае катына барышы председательнең.

Мөсәвир ихата түрендәге яшелчә түтәлләре арасында йөри иде. Әмир олы капкадан әйләнмәде, Әрәмәлеккә һәм Мишәгә чыгу өчен соңыннан ясалган ян капкадан керде.

— Әссәламегаләйкем, Мөсәвир бабай!

— Вәгаләйкемәссәлам!— дип Мөсәвир чирәмлектәге терәкле эскәмиягә таба агач аягы белән кайшалып атлады.— Үзеңнең дә эшләрең көйле икән, күзләреңдә хафа юк. Шөкер шунысына. Гел дә борчусыз гына яши алмассың анысы. Башлык кеше бит син. Әмма картлардан теләк сиңа шул: озын гомереңә сәламәтлек бирсен үзеңә. Игелекле бул. Гомерең буе кешеләргә мәрхәмәтле бул.

— Рәхмәт, Мөсәвир бабай. Шатлык зур бит әле безнең, Мөсәвир бабай: колхоз бу бишьеллыкта терлекчелек продуктлары җитештерү планнарын үтәде. Ә бишьеллык бетәргә ярты елдан артык вакыт бар югыйсә. Беләсеңме, Мөсәвир бабай, колхоз бу бишьеллыкта сөтне, беренче бишьеллыктагы күләмнән, бер йөз егерме сигез тапкыр артык җитештерде. Шәп бит, Мөсәвир бабай!

— Кичә бу хәбәрне колхоз радиосыннан ишетеп сөендек, Әмирҗан энем. Сабан туена күңелле хәбәр бу. Ризык табынга куелгач та бәрәкәтле булсын, әйе, бәрәкәте булсын ризыкның.— Карт энҗеләр белән чигелгән йомшак күн түбәтәен салып, читләрен төзәткәләп киде.— Бу хәбәрне монда килеп ирештерүеңә дә шатмын. Тик хәзер син мәсьәләгә яннан килеп керергә җыенасың түгелме? Син — холкың белән турыдан яручы егет. Хәзер дә турыдан әйт, читләтеп йөрмә. Бүтән йомышың бар сыман сизәм, Әмирҗан энем.

— Йомыш дип, зур йомыш түгел. Арысланбәк байдан калган түгәрәк йорт бар бит әле...

— Сүттермәкче буласыңмы?— дип бүлдереп сорады Мөсәвир.

— Искергән бит, авылның ямен алып тора.

— Ямен аламы?

— Беләсең ич, элек колхоз идарәсе һәм авыл советы урнашкан ихатада түгәрәк йорт. Байның йортларын күптән үзгәртеп салдык, хәзер анда агроном яши. Ә түгәрәк йорт тора да тора. Агроном да: «Урыны да әрәм»,— ди.

— Болын тикле урын җитми икән агрономга, хикмәт кенәсе. Әтиең ни киңәш итте соң?

— Синең белән сөйләшергә кушты. Өмә ясап сүтәсегез булгач, син Мөсәвир бабаңны чакыр, ди. Аның тәпи басканнан бирле бер генә өмәдән дә калганы юк, ди. Дәшмәсәң, үпкәләр, ди. Сабан туена чаклы сүтеп куйсак, дигән идем. Быел безнең сабан туена олы кунаклар да килмәкче.

— Кунакның барысы да олы. Алтмыш яшьлеге дә, алты яшьлеге дә. Түрәләр килә дисәң инде. Бездә түрәләр юк, җитәкчеләр генә бар, дисең син үзең.

— Җитәкчеләрнең дә олылары була.

— Аларның иске йорт күрүләреннән куркасың икән син, менә хикмәт кенәсе нәрсәдә икән! Соңыннан сүзе була калса, җавабың да хәзердән әзер икән. Борынгыдан калган йортны мир белән сүттек, янәсе, Мөсәвир аксак та катнашты, дип акланмакчы!

— Алай дип уйламадым. Сине хөрмәтләп өмәгә чакыруым, эшләтер исәптән түгел.

— Өмәгә килгән кеше биленә таянып тормый, энем. Анда балачага да йомычка булса да җыеша.

— Сүтмәскә дисеңмени, Мөсәвир бабай. Түгәрәк өй шулай сураеп торсынмыни?

— Сураеп? Сураеп дигәч, нык-таза икән бит түгәрәк өй!

Әңгәмә киселде. Әмир белән Мөсәвир арасында әрепләшү куба ал

мый, монысын икесе дә беләләр. Әмма болай ,ипле сөйләшеп тә, берсе дә үзенең хаклы икәнлеген исбат итә алмады. Хәер, мәсьәләне хәл итүдә Әмиргә киңәш тә кирәк түгел иде, бульдозер китерттең дә иштең җибәрдең өйне. Ике малаен ияртеп, авылдан җәяүләп чыгып киткән бай хатыны Фәрзия калдырган өйне. Колхозның әйберләр келәте булып тора бирде түгәрәк өй. Хәзер дә колхоз милке булып санала, тик бәясе күптән бетте инде аның. Гамәлдән сыздың ташладың һәм вәссәлам! Тик бүтән чакта тәвәккәл Әмир Хәкимов бу очракта өлкәннәр белән киңәшәсе итте. Өлкәннәр агрономның теләгенә һәм аның үз фикеренә каршы килмәсләр дип уйлаган иде ул. Алай түгел икән шул. Башта этисе чатнатып фикерен әйтмәде, инде Мөсәвир карт хупламый. Картлыклары, ягъни Кылыкта шушы түгәрәк өйне малай чактан күреп үсеп, яшьлекләрен сагынулары гына да сәбәп түгелдер моңа. Тарихны үзләренчә сакларга омтылуларымы әллә? Белмәссең. Әмма этисе Газизҗан — искелекне тамырыннан күп йолкыган этисе Газизҗан белән Мөсәвир — һәр өмәне бәйрәм итеп көтүче Мөсәвир — байның түгәрәк өен сүтәргә каршы. Тарихны онытмау кебек олы мәсьәләгә кереп китмәсәк тә, аларның картаймыш көннәрендә яшьлекләрен күз алдына китерергә бер әйбер икән түгәрәк йорт, чыннан да, сүтмәскә дә кирәктер бәлки аны. Өлкәннәр тарих өчен үзләрен сакламакчы булалар. Ләкин моның өчен байдан калган түгәрәк өйнең сураеп, чөләеп торуы мәҗбүриме икәнни? Барыбер кайчан да булса череп, тузанга әйләнәчәк ләбаса ул, инде күп гомере калмагандыр...

— Туза,— диде Мөсәвир, агач аягына ымлап.

Картның түгәрәк өй мәсьәләсеннән читкә тайпылуына председатель әзер түгел иде. Җайсыз сүз башлады Мөсәвир бабай, ни хуплап, ни кире кагып булмый, телсез итте, әй, Әмирне. Бер сүзе белән бит. Председатель эскәмиягә утырган җиреннән үрелеп сарут сабагы өзде, аны орлыклана башлаган очыннан төбенә хәтле бармаклары араларыннан шудырып чыкты, аннары төбеннән аска тартты. Сабак, иң очыннан чеметеп тоткач, турыга асылынып калды. Әмир аны ычкындырды, әмма сабак өзелгән төбе белән җиргә кереп кадалмады. Гомере иртә өзелгән сарут сабагын председатель кулына кире алды.

— Монысы да туза,— дип беравыктан кабатлады Мөсәвир.— Күп ясадым инде мин аларны. Аяксыз калганга алтмыш елдан ашып китте бит, гражданнар сугышыннан, чалбарның бер балагын җилфердәтеп, култык таякларына таянып кайттым бит мин. Син белмисең инде моны, син юк та юк, этиең дә өйләнмәгән чак бит әле. Этиең Газизҗан белә. Гражданнар сугышыннан этиең исән-сау кайтты. Бәхете булган икән. Һәм аның имгәнмичә кайтуында безнең дә бәхет булган икән. Нигәме? Чөнки колхоз төзегәндә, аның сәламәтлеге дә булышты.

Мөсәвир тагын тукталып торды. Агач аягының башындагы ялтырап торган тимер боҗрага таягы белән төртте.

— Очы тиз туза. Боҗраны өскәрәк күчерә алмыйсың, аяк кыскара да йөрүең исерек йөрешенә тарта аннары. Ә агач аякның бу өске ягы ярылгалый. Кадак кагып, ярыгын тарттырсаң, чын аякка кадак каккан кебек була. Ярылуына күрә дә еш алыштыргаладым агач аякны. Шөкер, үзем агач эшен беләм, аяк ясатырга кешегә йөрмәдем. Шулай. Менә шул агач аякларны саклыйм бит, Әмирҗан энем! Барысын да! Мичкә яга алмадым шуларны. Җаннары бар кебек! Аннары, әбиең, минем карчыгым инде, моның белән генә мич җылынмый, истәлеккә сакла шуларны, титаклап булса да сине йөрткән бит алар, дия иде. Мин үлгәч, яныма тезәрсез искергән агач аякларны. Чөнки алар — минекеләр.

Өмәче Мөсәвирне Арысланбәк байның түгәрәк өен сүтешергә, дөресе, карап кына торырга олылап чакырмакчы булган иде колхоз председателе. Һәм карт моңа каршы төшмәс дип уйлаган иде ул. Ләкин Мөсәвир Әмирнең фикерен хупламады. Карашын читкә төбәгән, Әмиргә борылмый. Синең сүзеңә килешкәндә, ул күзләреңә тутырып карый,

сөенә. Күңеленә тиярдәй сүз әйтсәң,— ачуы кубуын карашын яшереп сиздермәскә тырыша, әмма телгә астыртын зәһәрлеге көчәя.

— Әмирҗан, хак сүзме шул: сине, янәсе, Арыслан тавы өсләтеп шәһәр урамы салдырмакчы дигән булалар. Шуңа күрә картлар йортын шул урамның башына — тау итәгенә салдырган, димешләр.

— Яңа урамны мин ялгызым гына төзи алмам, Мөсәвир бабай, әмма авылның өч янәшә урамына дүртенчесен сузсак, килешеп торыр, дигән уй бар. Монысы — киләчәк эше, хәзергә Кылыкның пужумнарын бетерергә кирәк.

— Пужумнарның күзеңә кылчык булып керүе әйбәт. Башлап алар синең күзеңне тырнамаса, фәтва чыкмавы ихтимал.

— Бер миңа гына тәрәлеп калса икән эш,— дип аклану ягын каерды Әмир.— Тылсым таягын бер селтәп җибәреп, Кылыкны бер селтәнүдә гөлбакча итәр идем! Бөтен җир йөзен хәтта!

— Булмас. Чөнки тылсым таягын кулыңа кемдер китереп тоттыруын көтеп йөрисең икән. Мин бирмим сиңа ул таякны. Үземә кирәк. Син үзең эзлә аны. Картлар йорты салдырганда, тылсым таягы кулыңда кебек иде. Хан сарайларын күрергә соңлабрак туганмын, нинди булуларын белмим. Әмма безнең бу йортка теләсә кайсы хан чатыр чабып килер иде. Валлаһи! Сезнеңчәрәк әйтсәң, киләчәктә музей булырлык.

— Бу йортны бөтен авыл белән салдык. Һәм бүтән каралтыларын. Өмә белән.

— Тылсымлы фикерең аңлаешлы иде ул чакта. Синең сүзеңә авыл халкы шуңа күрә күнде. Безнең борынгыдан калган матурлыкларыбыз бар, Әмирҗан энем. Бу матурлык сулмасын өчен, шул матурлыкның халык матурлыгының чишмәләре бәреп торырга тиеш. Ә чишмәнең улак тулып агуы өчен, аның башы көчле булуы шарт.

Мөсәвир аркасын эскәмия артына терәде, карашын Әмиргә бора башлаган кебек булды. Ләкин шул мәлдә үк, башын дерелдәткәләп, туктalып калды. Арыслан тавына карап утыра бирде.

— Ишеттеңме,— дип дәвам итеп китте карт.— Туксанга җитеп килсәм дә, беләсеңдер, мин әтиеңнән ике яшькә өлкәнрәк, күперенке сүзләрне бер җепкә тезүдә сездән калышмыйм. Вакыт күп безнең, колхоз карт-карчыкларының. Үзебез уйланып баш җитмәгәненә радиосы-телевизоры өйрәтеп кенә тора.

— Сөйләү осталыгы юк ла инде миндә, Мөсәвир бабай.

— Шулай булгач, уйлану осталыгыңны шомарта төш. Сүз уйлап сөйләгәнне ярата. Менә син мине йорт сүтү өмәсенә дәшә килгәнсең. Олы башыңны кече итеп, дияр иде бүтән берәү. Мин бармыйм синең өмәңә. Бармыйм! Ә син минем каршы төшәчәгем турында уйламагансың, шуңа күрә ык-мык утырасың. Дәлилләреңне алдан табып куйган булсаң, тәненнән ите качкан картны оста сөйләвең белән өреп кенә очырткандай итәр идең. Ай-һай, уйлансаң да, дәлил таба алыр идең микән, әле анысы да бар. Өмәче, дигән даны чыккач, Мөсәвир карт Арысланбәк байның революциядән соң да ничә еллар торган түгәрәк йортын җимерешергә сүзсез килешәчәк, янәсе. Әйтәм ич, трактор белән төрттер дә аудар, балта чабуны ташлаган картның өйрәтеп торуы кирәкми җимерергә.

— Бүген син чынлап торып бик оста сөйлисең, Мөсәвир бабай. Хәзер үк авыл җыенына чыгар да бастыр.

— Остамы?! Чөнки мин бу хакта күп уйланган. Менәтерәк! Нигә чыкмаска ди авыл җыенына?! Син, кирәңә беткән җан, сүземне тыңламасаң, авыл җыенында нотык тоту гына түгел, шул җыенны үзем җыя алам!

— Мин синең нинди сүзеңне тыңларга тиеш соң, Мөсәвир бабай? Өмәгә бармыйм дидең. Барма соң. Үгетләмим.

— Менә болай, синең үз чүлмәгеңдә сөт әчи башлагач, турыдан әйтмичә булмый икән. Баярак мин чишмәгә ишарәләп куйган идем.

Мәгънәле сүз әйттем кебек. Хәзер чишмәнең үзебезнең авылдагысына кайтыйк. Синең әниеңнәр нигезенең бакча башында чишмә бар. Өске чишмә, дибез аны. Арыслан тавының түбәсе нәкъ шул турыда. Син салдырачак шәһәрчә урам ул түбәне узып та китәр шәт.

— Мөсәвир бабай, мине мыскыл ук итә башладың түгелме соң син?

— Тыңлап бетер элгәре. Мин сине мыскыллаunion, Газизҗан Әмирҗаны. Синең кодрәтеңнән килә торган эш әйтәм. Сер итеп кенә.— Мөсәвир төрттермичә барыбер уза алмады.— Кем киңәш итте, дип сорасалар... үзем уйлап таптым, диярсең. Түгәрәк өйне син, Әмирҗан энем, Арыслан тавының нәкъ түбәсенә күчертеп салдыр.

— Ничек?! Ни хаҗәте бар аның анда? Аннары...

— Байдан калган йортка мөкиббән булган, диярләрме? Әйтмәсләр. Кайбер шәһәрләрдә борынгылык төсләрен бер төшкәрәк оештырып салалар икән хәзер. Телевизор карамыйсың ахрысы син. Бүлмәндә бай кәләшнең бирнә сандыгына тиңләшерлек телевизор тора лабаса.

«Бүген икенче капкыр телгә керде телевизор,— дип уйлап алды председатель.— Бүген үк котылам шул инвентарьдан. Тик кая куярга? Клубта бар, больницада бар, мәктәптә икәү, терлекчеләр йортлары саен төслеләре куелган, Мөсәвир бабай картлар йортында телевизор каравы белән мактанып җибәрә».

— Түгәрәк өй байдан калган, анысы хак. Әмма халыкның борынгыдан — тирмәләр исталеге булып килгән байлыгы ул. Безнең нәсел, белгәнеңчә, бай сыйныфтан түгел. Үзем дә колхоз оешыр елда гына атка тиештем, балта тотарга һөнәрем булса да. Ә матурлыкны аңламый торган синең агрономыңның хәзерге ихатасындагы түгәрәк өйне минем бабай белән әти салган. Нәп чыккач, Арысланбәк бай аны миннән өр-яңадан диярлек төзәттерде. Хатыны Фәрзия бикә мине эшләгәндә гел тәмле ризыклар белән сыйлаган иде. Ашыкма, чыдамлы булсын, дип кисәтә тордылар. Түгәрәк йортның тышлык тактасын килештереп сугуы ансат түгел. Нишлисең, балаларыбыз юк, кайбер һөнәрләр үзем белән китә. Син киләчәктә түгәрәк өйләр дә салдырырсың әле. Бу эшне кемгә кушарсың соң? Монда өмә белән генә эш барып чыкмас. Арада осталар булмагач, дим. Ә-ә, әйе, Арысланбәк бай өйнең нигез бүйләрын яшелгә үзе буяган иде. Фәрзия бикәнең — җиңне бүтән төсле ситсы белән әдепләү кебек инде, дип каршы төшүенә дә карамады. Ямау булып күренмәде бу әдеп. Карале, Арысланбәкнең бер малае сурәт ясаучы икән, дип сөйләгәннәр иде. Хакмы икән шул? Хәер, нигә булмасын икән. Колхозчы — электәге ярлы балаларыннан сурәт төшерүчеләр үсеп чыкты. Безнең картлар йортын бик тә матур итеп бизәделәр. Үзебезнең Кылык малайлары, зур укымаган кешеләр малайлары. Ә Арысланбәк бай электән китап укыган, малайларын да түгәрәк өйдәге китапларны мәҗбүри укыттыра иде. Әйе, аларның түгәрәк өендә китап-газит күп иде. Әтиең Газизҗан хәтерлидер, Фәрзия бикә, китапларын да колхозга калдырды, утка якмаган.

— Искә дә кереп карамаган нәрсәләр куштың әле син миңа, Мөсәвир бабай,— дип, урыныннан акрын гына торды Әмир.— Бәлки, син хаклыдыр. Арыслан тавы башында колхоз музее салдыртмакчы икән син. Табигать музее да кирәк диярләр аннары башкалар. Шүрәле сазлыгын, Аждаһа купкан төшне шунда күчерергә кушарлар. Алпамша чабатасын каккач калган Помры тау шунда менеп утырачак. Түбә куак дигәне дә Арыслан тавына күчәчәк... Бәлки Мишәне дә Арыслан тавы сыртыннан агызырбыз... Һе, телевизор карап кына хәл ителсә икән болар...

— Менә, менә, Әмирҗан энем, сөйләргә бик остара башладың бит! Уйлыйсың чөнки! Кылыкның син әйткән урыннары Арыслан тавы түбәсенә ничек бар шулай күчерелмәсә дә, колхоз укыткан осталар аларны шуларга охшатып ясарга булдыра.— Мөсәвир бу сүзләрен Әмирнең каршына басып, инде аның күзләренә туры карап әйтте.— Арыслан

тавы өстеннән яңа урам корырга ният иткәндә, син боларны уйда тотмыйча калмагансыңдыр, хәер. Акыл чүлмәгең игелектән тулып тора лабаса синең! Әрәмәлекне онытма, Торналар күле дә исеңә төшәр, шәт.

Әмир бу төрттереп мактаудан башын чайкалдырып көлеп җибәрде.

— Шулай да хәтсез телдең син мине бүген, Мөсәвир бабай.

— Балта йөзен чыгарасы урында, телеңне кайрагансың, дисеңме. Тел чарлау да кирәк, Әмирҗан энем. Үзеңне иркендә очратасым килеп йөри иде. Мин, пенсионер булып та, вакыт җиткерә алмыйм, ахры үзең эзләп таптың.

— Шәп үткенләгәнсең фикерләреңне, Мөсәвир бабай, әйтерем юк.

Алар ян капкага таба атладылар. Әмир, артка калып, ике яктан чирәмгә төренгән сукмакка Мөсәвир картны алдан төшерде.

— Карале, Әмирҗан энем,— дип, ян капканың келәсен ычкындырды Мөсәвир, һәм читкә тайпылып, рәшәткә капканы ачты да Әмирне уздырды,— этиеңә әйтмәссеңме икән, минем катка сугылып узсын иде. Бу арада күренмәде. Исәнлектә сөйләшеп каласы кайбер нәрсәләр бар. Әллә бар гомер дигәнең, әллә юк. Озаграк яшәлде.

— Бар әле, бар, Мөсәвир бабай! Яңа урам сала башлагач кына башыңа яман уйлар кертмә. Әтигә әйтермен. Йорт сакчысы иттегез дип, кайткан саен әрли. Әни өйдә юк иде, аның кайтуын өйдән чыкмыйча көтә, ә үзе безне гаепли. Әни кайткандыр да инде.

— Тагын бер нәрсәне искәртим әле,— дип, рәшәткә тактасы башына учын куйды Мөсәвир. Аның кулының эре сөякләрен тире генә таркатмыйча тотадыр кебек тоелды. Үзеннән ничәмә-ничә тапкырлар зур эш кылган кул бит бу...— Өмәче инде мин. Кушаматым шундый. Минем үземә ошый ул. Бу кушаматта мәсхәрәләү юк. Әйе, авылда бер өмәдән дә калмадым. Үзем монда булганда. Авырып та калмадым. Ә сырхап ятмадым. Беркайчан да. Аяк сызлаштыруы исәпкә керми. Аңа алмашка агачын уйлап тапканнар борынгылар. Шуңа күрә дә сакладым агач аякларымны. Әйе.— Мөсәвир карашын Әмиргә күтәрде. Офыкка юл тоткан кояш аның күзен чагылдырды, ул кулын маңгаена куйды.— Әйе, өмәче мин. Ләкин ки мин беркайчан да сугу өмәсендә катнашмадым. Төзү-кору өмәләрен генә беләм мин. Картлык көнемдә үз кыйблама хилафлык кыла алмыйм. Түгәрәк өйне суттеру өмәңне күрәсем юк! Сугу, җимерү,— йөз кеше катнашса да,— чын өмә түгел, Әмирҗан энем. Сугышта меңәрләгән кешеләр катнаша. Ләкин ки үтереш беркайчан да өмә була алмый. Сугыш дигәннәр аны борынгылар. Әйе. Бигәйбә!..

Председатель, яр өсләтеп кенә сабан туе булачак мәйданны да күзәтеп, Мишә күперенә таба менгәч тә, уемга сокланып торды. Сабан туе быел шәбрәк тә узар, мөгаен. Чөнки хәмерсез үтәчәк. Урын шәп монда. Нәкъ сабан туе өчен, җыен өчен аталып эшләнгән кебек. Шуны сукалату өчен күпме әмерләр бирелде, әмма Кылык халкы боларны үтәмәде. Хәзер болыннарның кадерен белүчеләр күбәйде, тик сөреп хур булдылар шул кайбер авылларда, күпчелек авылларда. Ярый әле бу уентыкларны сөрмәделәр, югыйсә, Арыслан тавы түбәсенә шушы уентыкларны да ясатырга мәҗбүр булыр идең. Үлән куерып үсә. Мал-туар да, каз-үрдәк тә кертми халык, саклый. Бала-чагага да бер шөгыль булды. Бүген Җәүһәрия сакларга тиеш иде. Хәер, безнең чират төшкә чаклы ук иде бит. Хәзер, әнә, күрше малае чыбыгын болгап әрле-бирле чаба.

Әмир, машина тавышы ишетеп, Урта урамга борылып карады. «Волга» аның янына якынлашып килә иде инде. Фәрах, машинаны сүндереп, кабинадан атылып чыкты.

— Тәртип, иптәш председатель!— диде ул, командирына рапорт бирүче солдатка охшатып кулын чигәсенә куйды.—«Революция» колхозында бүгенгесе көндә өч егет артты!

— Ничек — өч егет?!

— Кылыкның җил җиткермәс шоферы Шәриф белән уңган терлек-

чесе Зәһирәнең игезәк малайлары больницада әле күптән түгел генә дөньяга сәлам биреп кычкырдылар.

— Әнисенең кәефе ничек? Врач тиз килдеме? Операция ясадылармы?

Фәрах саргылт чылбырлы ачкычны бармагында әйләндереп алды, җавап кайтармыйча торды.

— Кәефе ничек, дим мин сиңа!

— Әйбәт, диделәр. Нечкәлекләрен каян белим ди инде мин! Игезләр табасына гына башта хәле авыр булган. Син, Әмир абый, миннән врач ясамакчы мәллә? Кулыннан килсә, чындыр, хатын-кыз врачы итәр иде мине, әй!

— Җафа!

— Кем җафа? Минме? Син... син үзең җафа чиктерәсең мине, иптәш председатель! Колхозда бүген арткан егетләрнең өченчесе кем дип сора, ичмасам.

— Кем?

— Мин!

— Салып җибәрсәң, күпер култыксасына очып барып кунарсың да, башың әйләнеп, суга мәтәлүең бар инде...

— Югары дәрәҗәдә сөйләшүләрнең өченче раундында колхоз председателе Әмир Хәкимов оста куллы һәм киң профильле механизатор Фәрах Хәкимовның дәлилләрен кире кагарлык көч тапмады. Урта урам тузанына сырты белән үзе сыланды. Шулай итеп, аның уңган егетне күпер култыксасына кунаклату хакындагы явыз нияте барып чыкмады.

— Нигә теләңә салынасың син? Минем эшем сине көйләү түгел ләбаса!

— Сез, иптәш председатель, миңа, хөрмәтле колхозчыгызга, тавышыгызны күтәрмәгез. Аңлашыламы?

— Син — колхозчымы?!

— Мин, әлбәттә.

— Колхоз керәп-чыгып йөри торган хуҗалык түгел дип аңлаттым түгелме соң мин сиңа?

— Кем әйтмешли, бәрәкалла! Соң алайса, миңа колхозның шушы кыйммәтле машинасын нигә тоттырып җибәрдең? Әмир абый, йәле, әйтеп бир. Ваткан булсам, кем җавап бирер иде?

— Ябышкак...

Фәрах машинаның түбәсеннән сөеп куйды, утыргыч астыннан чиста чүпрәк алып, алгы тәрәзәне сөртергә кереште. Әмир, күзләрен кысарак төшеп, туганнан туган энесенең эшен күзәтте, машинага утырырга да, утырмаска да белмәде, башыннан күп төрле уйлар агылып узды. Комбайннарга запчасть кирәк; ак тавык идарә начальнигы машинасына кереп кунаклаган; Арыслан тавы түбәсендә түгәрәк өй ераклардан маяк булып күренеп тора; Кәшшафетдин абыйсы шушы очкалак Фәрах өчен кайгыра; әнисе нигәдер кайтып җитми; Арысланбәк байның бичәсе колхозга китапларын калдырган, әтисе дә әйткән иде аңа бу хакта; бүлмәсендә төсле телевизор сораеп утыра; авылда пуҗумнарны бетереп кенә түгел, ә аны зурайтырга хәбәр салып, игезәкләр туды бүген, әйе, алар, һичшиксез, яңа урам кешеләре инде; Мөсәвир бабай агач аякларын саклый икән; Рәсиха исән-имин йөредеме икән; Җәүһәрия белән Җиһангир йоклап киткәнче, өйгә кайтып өлгерәсе иде... Тагын... тагын...

Машина кабынгач, уйларыннан сискәнеп бүленде Әмир.

— Сүндер машинаңны!

— Сүндердем. Рульгә үзең утырасыңмы әллә? Туганнарча әйткәндә, Әмир абый, син каты тәнкыйтькә бик лаеклы. Машинаны үзем йөртәм, миңа хезмәтче кирәкми, дигәнең күкрәк сугу гына булып калмагае. Карамыйсың машинаны. «Газиг»ың да шушындый хәлдә булса, шәп шелтә чәпәргә кирәк үзеңә. Тормозларын ныклап карыйсы бар,

зажиганиесен көйләдем. Тыңла әле, менә ничек рәхәтләнеп эшли машина! — Фәрах машинаны тагын кабызып сүндерде.— Җанын кыясың икән машинаның. Ярамый болай, иптәш председатель, колхоз милке, күмәк милек бу.

— Житкәндер сиңа, Фәрах-Фейербах...

Әңгәмәдә өстенлек егет ягына авышып бара иде.

— Әмма мин кире кагылмаслык фактны әйтәм, Әмир абый. Утыр, әйдә, кая илтим?

Әмир машинага кереп утырды, ләкин Фәрахка кузгалмаска кушты. Машина тагын сүнде.

— Белмәдеңме, әни кайтты микән?

— Рәсиха җиңги семинардан кайтышлый кереп алган аны. Әле дә ярый «Жигули»егызны җиңги карап йөртә.

— Рәсиха да өйдәме?

— Семинарга барган врачны больницада калдырды да әбине кайтара китте.

— Тәк, иптәш философ, колагыңны торгызып тыңла.

— Тыңлыйм, иптәш председатель! — дип, кулын тагын чигәсенә терәде Фәрах. Ләкин Әмир аның кулын тартып төшерде.

— Солдатта булмаганың әллә каян күренеп тора, юньләп честь бирә дә белмисең. Өйләнә, имеш! Өйләнерсең, анысына остарды яшьләр. Әмма хатыныңны олылау кирәклеген хатыныңны бәбәй тулгагы тоткач кына исеңә төшерсәң...

— Безнең нәселдә хатын кыерсыту гадәткә кермәгән, Әмир абый. Үзең дә Рәсиха җиңгине кадерләп кенә йөртәсең.

— Синең бердәнбер җиңгәң бит, шуның өчен генә инде,— дип шаяртуга күчеп алды Әмир.— Менә шул сөекле җиңгәңә әйт, колхоз канцеляриясенә менсен.

— Ничек дип әйтим: председатель чакыра димме, әллә ирең дәшә димме?

— Икесен дә әйт.

— Алай була алмый,— дип, Әмирне сүздә каптырды Фәрах.— Син дә хатыныңны хөрмәт итәргә тиешсең. Председатель ирең чакыра, дип әйтү Рәсиха җиңгине пычракка күмү булыр иде, әйтерсең, аның председатель булмаган ире бар...

— Кыен ашыйсың килеп, телеңне чәпелдәтәсең, иптәш...

— Иптәш колхозчы. Аңлашылды. Тагын ни боерасыз?

— Тагын этигә әйт, Мөсәвир бабайның аны күрәсе килә. Бүген үк картлар йортыннан әйләнергә тырышсын.

— Ә сине кая илтим?

— Мин больницада тукталам әле. Аннары канцеляриядә булам. Миңа машина кирәкми. Тәк. Тагын болай ит. Минем бүлмәдәге телевизор дигән инвентарьны картлар йортына төшер. Багажникка куегыз, өстенә палас каплагыз, тырнак эзе дә төшмәсен, акрын йөр. Һәм бухгалтериядә әйт, минем өстән имгәк инвентарьны сызсыннар. Алганлыкка картлар йорты мөдиреннән кул куйдыр. Аннары...— Әмир сүзеннән тукталып торды.— Шулай да син минем ышанычны акламадың бит, Фәрахетдин туган.

— Ничек?

— Колхозның партоешма секретаре, беләсең, читтән торып укып институт бетереп, аспирантурага керәчәк, ә урынбасары өч ай инде авырып ята, инвалидлык бирергә тиешләр аңа. Миңа бит бер уңайдан партоешма секретаре вазифасын да башкару килешмәс, килешмәс кенә түгел, ике эшкә берьюлы җигелә алмыйм мин. Сине партоешма секретаре итеп тәкъдим итмәкче идем. Син очкалак булып йөри башлаганчы шундый уйда идем. Ялгышканмын, димәк.

— Мин риза булмас идем бит, Әмир абый.

— Нигә?

— Нигәме? Чөнки сез, житәкчеләр, һәм район житәкчеләре дә, кадрлар мәсьәләсенә кайчак бик тә формаль карыйсыз бит. Терлекчене яисә механизаторны житәкче эшкә этә-төртә күчерәләр дә гади халыкны үстерәбез дип мактанып йөриләр аннары. Буразнада туфракны каерып салган тракторчы, авыл советында председатель урындыгына көчләп утырткач, каләм дә күтәрә алмый башлый, чөнки ул аның эше түгел! Аңа син басуларны буразналар белән сырларга ирек бир, эше шул аның. Шулай, Әмир абый, партоешма секретареннан башка колхозны алып баруы сиңа кыен икәнен беләм, әмма мин бу зур эшкә алынмас идем. Чынлап торып уйлаганда, кемне сайларга икән соң партоешма секретаре итеп? Кемне?

— Мин, мәсәлән, сине сайламакчы идем, ләкин син җиргә берегеп житмәгән булып чыктың.

— Бу мәсьәләдә, Әмир абый, жир кешесе булу гына житмидер дә, рухияттән үтә бай булу кирәктер.

— Күп беләсең!

— Беләмдер дә, белер өчен институтта читтән торып укып йөрим ләбаса. Философияне дә, партия тарихын да өйрәтәләр безгә анда...

Председатель, Фәрахның җилкәсенә кагып, машинадан чыкты һәм Уң Тамак урамындагы ике янәшә пужум итәгенә, моннан өч кенә ел элек салынган больницага таба китте.

Ир уртасы булып житкән Әмир абыйсы тыкрыкны олы гәүдәсе белән тутырып бара кебек тоелды Фәрахка. Һәр яктан тарткалауга-йолыккалауга түзәр өчен, хәзерге заманда колхоз председателе булу өчен, Әмир абый кебек әзмәвер булу кирәктер шул, дип уйлады егет. Һәм машинаны борып салганда, хәзерге колхозның житәкчесе дәрәҗәсенә күтәрелергә теләсәң, Әмир абый кебек киң күңелле булырга тиешсең, дип фикерен дөресләде. Хәер, берәүгә дә күтәреп йөри торган йөк түгел бу сыйфат... Ә... ә Фәрахның үзеннән колхоз председателе чыгар идеме икән? «Суга сәнәк белән язып булмаган кебек, миннән дә председатель чыкмас, колхоз партоешмасы секретаре шулай ук чыкмас, Әмир абый»,— дип нәтиҗә ясады Фәрах. Бер Фәрзанәне авылга кайтырга күндерә алмаганны...

Машина Урта урамнан югарыга таба җилдертте. Авыл уртасындагы киң тыкрыкка житкәч, Сул Тамак урамы ягына шома гына борылып, төз каралтылар артына яшеренде кебек, тавышы ишетелмәс булды.

## 10

**1985 ел, хикәяләү башланган көн, кичке уңай һәм төн кергәч.**

Моннан ике ел элгәре өйдәге кичке әңгәмә вакытында Рәсиха «Жигули» машинасы алырга кызыгуы турында сүз кузгаткач, аның теләгенә ире Әмир каршы төшкән иде. Әткәсе Газизҗан хуплау яки кире кагу фикерен әйтмәде. Әнкәсе Сәхәрия генә килененең бу теләген күтәреп алды.

— Бик дөрес уйлагансың, Рәсиха килен,— дигән иде каенана.— Электә хуҗалыкның күрке ат булса, хәзер машина инде. Акчабыз житәр, өйдәге алты җанның дүртесенә акча килеп тора, шөкер. Акчаны аны тозлыйсы юк. Авылда һәр ихатада машина-мотоцикл гөрелдәп торганда, нигә без генә читтә калырга тиеш ди. Әйтәм ич, электә ихатада ат булуы бәхет иде, хәзер машина...

— Бәхет машинага гына терәлеп калса, ни боргаласаң да, ерак китә алмыйсың, әни,— дип, үзенчә үтемле итеп әйтте Әмир.— Бик беләсең килсә, элек хуҗалыклар аерым булганнар, хәзер күмәк хуҗалыкта яшибез.

— Бик беләсем килә шул менә, шул күмәк хуҗалык кешеләренә тигезлек булмавын беләсем килә!

— Нишләп тигезлек булмасын ди бездә?!

— Юк шул! Менә синең хатының колхозда барлык культурный эшләр-

не алып барамы? Бара шул! Шушы дәү авылның бер басуыннан икенчесенә җәяүләп чабамы? Район үзәгенә барасы булса, машина туктатырга күпер төбенә чыгып басамы? Ә син аны машина белән илттермисең, безнең председатель хатынын машинада гына йөртә, дип әйтүләреннән куркасың.

— Әй-й, алыгызсана!

— Алабыз шул! «Жигули»ен алабыз! Мотоцикл түгел! Рәсиха килен шул матайга утырып чапмас бит инде.

— Машинасын алыгыз, дим бит! Әмма мин машинагызны караячак түгел!

— Йөртеренә-карарына да өйрәнер Рәсиха. Син генә түгел машина рулен боргалаучы, Кәшшафетдин улым белән Фәрахетдин оныгымнан да осталар юк авылда,— дип йомгаклап бетергәндә, картына да тел тидереп аласы итте Сәхәрия карчык: — Син нигә дәшмисең? Шушы кире беткән малаеңның сүзен тотмакчы буласыңмы әллә, ходаем?

Ләкин Газизҗан эндәшмәде. Фикерен ул соңрак, Фәрахетдин оныгы яшел «Жигули»не капка төбенә алып кайтып җиткергәч кенә, кире кагылмаслык итеп әйтте.

— Әйбәт машина. Әмма ки аны ишегалдына кертмәбез,— диде йорт башы Газизҗан.

Аның бу сүзләренә машина алуга баштан каршы төшкән улы Әмир дә аптырап калды. Ләкин әтисенең сүзендә торачагын белә иде ул. Ачулы түгел әтисе, димәк, машина алуга каршы булмаган икән. Тик машиналы да булып, аны ишегалдына кертмәү мәсьәләсен ничек хәл итәр икән соң әтисе?

— Машинаны әйтәм, ишегалдына бер кергәч, гел шул гадәтен кумагае,— дип елмайды инде Газизҗан карт.— Ат ишегалдын бозмый иде, машина канау ерып бетерәчәк. Шуңа күрә тыкрыктан борылып, бер торык киртәне төшерик тә абзар артына оялатыйк без аны. Гаражны да шунда салырбыз.

Бу гаиләдә мәсьәләне кайчакта тузга язмаганча очлау очраклары булгалый инде. Баксаң, моның өстенлегє кукраеп тормаса да, ахыр чиктә үзенчә кызыгы була икән. Анысы да кирәк, хәер.

— Күпләр әнә, урам капкасы янына гараж капкасы тишteләр. Машина — зур байлык, чәлеп китүләреннән шүрлиләр. Машинаны күз алдына куялар, янәсе,— дип аңлатты соңыннан Газизҗан «мөгез чыгару»ын.— Нигә без кешеләргә ышанмаска тиеш ди? Ышанабыз.

Һәм гаражны абзар артына кирпечтән өйделәр. Былтыр абзар-кураларны яңарткач, гараж дигәнең югалып калды.

...Рәсиха, Сәхәрияне урам капкасы янында төшергәч, машинасын әнә шул гаражга кертеп куйды. Өйгә кергә:

— Әткәй, балалар өйдә юкмыни? — дип сорады ул.

Газизҗан, гайрәт чәчеп торган самавырны күтәргән килеш, әле Сәхәриягә, әле Рәсихага карап торды. Самавырны өстәлгә утырткач кына карчыгына атап эндәште.

— Әйттем түгелме мин сиңа, каравылчы иттегез мине, дип. Берсе каршында өй иминлеге өчен җавап тот, икенчесенә почык борыннарының авылның кай төшендә йөгерешеп йөрүләрен әйтеп бир.

Газизҗан чәйнеккә пешерергә чәй салды.

— Кайсыгыз юды иданнәрне шушылай ялтыратып? — дип картының ачуын йомарга тырышты Сәхәрия. Әмма Газизҗан тагын кырт кисте:

— Мин!

— Синдер, синдер,— дип, бу юлы да карты җаена төшүне тиеш тапты Сәхәрия.

— Утырыгыз, кулларыгызны юыгыз табынга утырганчы. Чәй ясыйм. Өй турында кайгылары бетте. Барысының да. Хезмәтче итеп Газизҗан картны куйгач. Әмирҗаны җитмәсә карлыганнарны күтәрмичә чыгып качкан.

— Карт, дим, ачуланып ясагач, чәең тәмле булыр микән соң?
— Самавырын белеп кайнаткач, чәен белеп пешергәч, ничек ясарга кирәген генә белербез. Сез сәяхәтчеләрдән кайтыш ясамам. Сәяхәттә йөреп, инде бик остарып китмәгән булсагыз.
Сәхәрия Рәсихага ым какты да, алар юынырга чыктылар. Карчыгы белән килене алдына мөлдерәмә тулы чокырларны куйгач, Газизҗан үзенә дә чәй ясады.
— Ачуың чынлап купмаган икән лә, эткәй,— диде Рәсиха, чәйдән авыз итеп.— Чәең бик тәмле.
— Тырышабыз инде... Ватан хакына.
— Шулай инде ул менә, картым, шулай шул,— дип әйләнгечтән башлады Сәхәрия.— Кеше көтүләре бик яман шул. Гомерем буена сине көтеп яшәдем мин, кайчан кайтыр икән, нигә озаклады икән дип. Исән кайтып күземә күренсен генә, ачуланып бер генә дә сүз әйтмәс идем, дия идем.
— Мин эш белән йөри идем лә.
— Әмирҗан да, Рәсиха да уйнап йөрмиләр. Мин дә туганнар хәлен белергә бардым. Картлар өчен монысы да зур эш аның. Әле иртәгә генә кайтырга тиеш идем ич бөтенләй дә. Рәсиха хәл белешә кергәч, аңардан калмадым инде.
«Волга» килеп туктап, капка ачылганы да сизелмәгән икән — ишектән, җилтерәп, Фәрах керде.
— Бабай, исәнме! — диде ул һәм ишек катында катып калды.
— Имин, Фәрахетдин улым. Әмма нигә миңа гына сәлам бирүең соң әле? Әллә син дә, заманның кайбер әтрәкләре кебек, йомышың төшкән кешегә генә сәлам бирә башладыңмы?
— Ә-ә, әби белән җиңгине күргән идем инде мин. Хәзер Әмир абый йомышын үти килдем.
— Бу ниткән гадәт китте соң әле? Туганнар кайдадыр читтә очрашалар, ә төп нигезгә җыйналып, рәхәтләнеп сөйләшергә ярамыймы? Нәселдә өлкәне Газизҗан картны барыгыз берләшеп санга сукмый башладымы? Бүген кичкә барыгызны да җыям!
Фәрах эндәшмичә басып торды, каккан казыктай селкенмәде дә ул. Бабасының чынлап торып ачуы кабара башлавында үзен гаепле санады онысы, чөнки ул кергәндә, өйдәгеләр, бәлки, гөрләшеп тә түгелдер, һәрхәлдә бер өстәл артында чәйләп утыралар иде.
— Фәрахетдин улым,— дип, кискенлеккә җәя җебе булып тартылырга ирек бирмәде Сәхәрия,— ризык янына утыр әле.
— Бабай, әби һәм җиңги,— дип кулларын күкрәгенә кушырды Фәрах,— зур рәхмәт, ямегез. Эшләрем ашыгыч. Әмир абый миңа күп йомышлар кушты бит әле.
— Нинди йомышлар? Сине колхозга алуга каршы иде ич әле ул,— дип сүзгә кушылды Рәсиха.
— Бүген мин колхоз председателенең ярдәмчесе булып эшлим, җиңги. Ә иртәгә... иртәгә комбайн ремонтына тотыначакмын. Урак өстенә ерак калмый, комбайнны урак өстендә тик яткыра алмассың. Әйтәм ич, урак өстенең яңгырлы болытлары да була аның.
— Чыннан әйтәсеңме соң син, Фәрахетдин улым? Абыең хактан да эш куштымы? — дип сорады Сәхәрия.
— Чынын сөйләгәнгә охшый,— дип, Фәрах өчен әйтте Газизҗан.
— Бабай, Әмир абый мондый йомыш кушты, сине хәзер үк Мөсәвир бабайның хәлен белсен әле, диде.
— Соң, мин аның янына үзем дә төшәргә торам лабаса. Йортҗирне ялгыз калдырып булмады ич, шуңа төшмәгән идем кичәлебүгенле.
— Бабай, мин колхоз канцеляриясеннән генә әйләнеп киләм, машинага утыртып төшерермен, яме.
— Мин атлый торам, улым. Син куып җиткәнче Мөсәвир бабаң янында утырырмын инде мин, шат.

— Ә сиңа, җиңги, Әмир абый хәзер үк колхоз канцеляриясенә менәргә кушты.

— Миңа?

— Төп нигезен кәнсәләргә күчермәкчеме әллә абыең? — дип, әңгәмәдән читтә торып каласы килмәде Сәхариянең. Әллә киленне рәнҗетергә җыенамы икән Әмирҗан, дип уйлады ул. Үз кызыдай якын күргән килененә өйдә тел-теш тидертмәячәк Сәхария.— Нигә хатынын кәнсәләргә чакырта ул? — дип ачуланып кабатлады Сәхария.

— Председательнең ярдәмчесе буларак әйтә алам,— дип кулларын болгап алды Фәрах.— Әмир абый печтик кенә ялгышты бугай. Чөнки ул җиңгине китапханәгә чакырырга тиеш иде. Чөнки нинди дер китаплар турында сөйләшмәкче бугай ул. Чөнки минем белән бүген өченче раунд сөйләшүләр вакытында, әңгәмәгә бөтенләй катнашсыз рәвештә, иске китаплар... иске китаплар, дип кабатлаштырды. Синең, җиңги, аның янына баруың бик тә кирәк. Чөнки Әмир абыйның бүгенгә билгеләнгән эшләре муеныннан. Чөнки Әмир абый белән бүген бер генә кешенең дә юньләп сөйләшкәне юк. Чөнки Әмир абыйга көн буена хет бер кеше елмаеп карарга тиештер. Әмир абый да кеше ләбаса! Һәм шәп кеше...

Фәрахның шаяртып әйткән сүзләре һәркайсын уйга калдырды.

— Шул Әмирҗанымны авылда иң юаш, иң мәлҗерәгән кеше ителәр,— дип, чынаякларын җыештыра башлады Сәхария.— Бөтенесе өчен ул җаваплы, рәхәтләнеп утырып ял да иткәне юк бит аның. Гап-гади тракторчы да хәзер председательдән күбрәк акча эшли, нигә кирәк иде аңа председательлек, йә, нигә кирәк?

— Монысында ялгыштың, әнисе,— дип каршы төште Газизҗан.— Авыл өчен, колхоз өчен кирәк аның җитәкче булуы.

— Беткән ди Кылыкта председатель булырлык кеше! Китерсеннәр соң читтән, сиңа да малаеңа гына димәгәндер! Гомерләрегез буена җик чигәргә!

Бу сөйләшүдән читтәрәк торган Рәсиха кайтып керүгә әйткән сүзләрен кабатлады. Шушы соравы белән әңгәмәнең артык тирәнгә керүен туктатырга теләде ул.

— Әткәй, балалар кайда икән соң?

— Аларның эш көйләнгән, борчылма син, килен. Күптән түгел генә берәр телем ипине шапылдатып сугып, су буена төшеп киттеләр. Инеш буена. Сәяхәткә. Йөрсеннәр. Борчылма син. Җәүһәрия дежурын торды. Дәфтәренә, ручка башын кимерә-кимерә, нәрсәләрдер язып маташты аннары. Әмирҗанны күреп кайт әле син. Башта. Анысының балага әйләнә торган чаклары булгалый. Иске китаплáр хакында исенә төшергәч, димәк, нинди дер ярдәм кирәктер үзенә. Синең ярдәм кирәк, Фәрахетдин дөрес әйтә. Уйлап җиткермичәрәк бер фикергә килсә, аннары Әмирҗанны үз киресеннән кайтаруы кыен булыр. Беләсең, халкын егәрлеккә әйләндерсәң — Алпамша көченә тиң. Артыбрак та китмәсә әле. Кайчандыр колхоз инвентарена кергән китаплар турында әйтә булыр Әмирҗан. Кичен, барыбыз да бергә җыйналгач, китапларны колхоз милкенә алган заманнарга кайтып сөйләшер сәбәп тә бар әле. Сез югында, миңа атап хат килде.

— Бабай, кич белән әтиләр дә төшсеннәрме? — дип сорады Фәрах.

— Төшсеннәр. Һәм син дә. Мин Мөсәвир картны алып менәрмен. Юк, болай итик, Фәрахетдин улым, Мөсәвир бабаңны алырга «Волга» белән төшәрсең. Әмирҗан абыеңны кисәтеп куй. Ә син, әнисе, мулрак итеп табын әзерлә. Ачуланышып яшәргә ярамый. Ачуланышыр заманнар узды.

Таралыштылар. Башта Фәрах чыгып очты. Аннары Рәсиха, шкафтан яшел тышлы калын китап алып, аның урта төшен ачып карады да, сумкасына салып, китапханәгә ашыкты. Соңыннан Газизҗан җыенды. Өйдәге барлык эш тагын Сәхария җилкәсенә өелеп калды.

* * *

Әмир больницадан менешли китапханәгә тукталды. Әмма китапханә ишеге бикле иде. Председатель ишекне, ачык түгеллеген белсә дә, тартып куйды. Аннары, башын күтәреп, икенче катның дәү тәрәзәләренә карады. Хәер, монысы эчке сизем белән шулай эшләнә инде, әйтерсең, ишек бикле булгач, тәрәзәдән керә аласың.

— Хәзер ачам, ишекне ватасың ич,— дип эндәште аңа тыкрык буеннан килеп житмәстән үк Рәсиха.

— Ә-ә, сине көтәм,— дип хатынына каршы атлады Әмир.

— Үзең мине канцеляриягә чакырткансың, нигә монда йөрисең соң әле син? — дип, Рәсиха иренең беләгенә кагылды.— Менә бу яңа алган китапларны гына куйыйм да синең янга менермен дигән идем.

Әмир Рәсиха кулыннан сумкасын алды, аны кулыннан кулына күчереп кузгалмыйча торды. Сау-сәламәт, акылын һичкайчан җуймас әзмәвер иренең сабый хәлендә калуына гаҗәпләнмәде Рәсиха. Мондый вакытта иренең җаеннан торып бер генә җылы сүз әйтү дә житүен белә ул. Көче югалып торганда, хатыны терәгенә аеруча мохтаҗ Әмир. Иренең хәзер шундый хәлдә икәнлегенә Рәсиха күрүгә үк ышанды. Бая Фәрах үзен канцеляриягә чакыруы турында әйткәч тә шикләнгән иде. Әмир Рәсиханың күзләренә текәлеп озак карады.

— Яхшы кеше син, Рәсиха, име,— диде ул, ниһаять.

— Сагынгансың ич мине, картым! — дип сузып әйтте Рәсиха.

— Валлаһи, фәрештәдер син! Миңа бит сине сагынуымны синең кычкырып әйтүең кирәк иде! Бер сүзең кирәк иде!

— Әй-й, Әмир, фәрештә дип үк мактама ла. Кеше булу миңа бик житкән.

— Чын әгәр! Ничек очраттым икән мин сине?! Бәхеткә инде.

Рәсиха ишекне ачты. Алар, беренче каттагы клуб фойесы белән тыш стена арасында калдырылган аралыктан барып, икенче каттагы китапханәгә менделәр. Рәсиха үзенең эш өстәленә яңа алып кайткан китапларын өйде, яшел тышлы китапны читкә куйды.

— Очратмыйча ди, безнең район үзәге шәһәр түгел бит әле дә,— дип сөйләнде ул.— Зур авыл гына. Безнең өй Кылыкка чыга торган очта, җәяүләп иртән идарәгә килә идең, кичен кайтып китә идең. Башыңны гел күккә чөеп йөрсәң дә, каршыңа очраган кешене күрмичә мөмкин түгел. Иртән мин чишмәдән су алып менгәндә очрый идең бит. Әмма синең авылдан килүеңә каршы чыгуым түгел иде.

— Мин дә сине очратыр өчен көн саен бер үк вакытта йөрмәгәнмендер. Шулай да...

Әмир Рәсиха урынына утырды. Өйләнешергә вәгъдәләшкән төнне хәтереннән уздырды ул.

...Алар саубуллашканда төн уртасы житә иде инде. Авылдан чыккан юл уртасына төшеп, тирә-юньне онытып атлый торгач, артына борылып карады Әмир. Капка төбендә Рәсиханың ак күлмәктән басып торуын караңгыда да аерып була иде. Әмир кирегә торып йөгерде. Төнне ярып:

— Мин сине хәзер үк алып кайтам! — дип кычкырды.

Әмма ул килеп житәрдә кечкенә капка келәсе йомшак тавыш чыгарып бикләнде. Әмир, капка төбендә бераз басып торды да, кулларын артка куеп, кайтырга чыкты.

Әнә урман. Дөнья моңының сихри серләре шушында гынадыр. Зур оркестр булып акрын гына төнге җырын көйли урман. Кошлар сайрамый, ә шулай да урман җырлый кебек.

Таң беленә, урман өстендә. Әмирнең кайтыр юлы каршысында, сыек яктылык сизелә башлады. Кинәт күке яңгыратып кычкырды: Әмир, үзе дә сизмәстән, аңа җавап бирде:

— Күк-күү! Күк-күү!..

Күке артыннан башка кошлар таңга сайрап сәлам бирделәр. Сөйгәне

белән вәгъдәләшкән авыл егете аларга ияреп җырламыйча ничек түзсен ди инде?! Йә!

Иделләре, Иделләре,
Иделләре, күлләре.
Мин — синеке, син — минеке,
Ник димәдең элгәре?!

Аннары Әмир, инде туган авылына җиткәндә, үр итәгеннән үк чыклы болынга керде...

Рәсиха иренең уйлануын читтә басып күзәтте. Ул да вәгъдәләшү төнен хәтерләде.

...Әмир кирегә йөгереп килә башлагач, Рәсиха, бүгенге матурлыкны бозу куркынычыннан сискәнеп:

— Килмә! — дип эндәште.

Әмма бу кисәтүен каты кычкырып әйтә алмады ул. Шуңа күрә аның сүзен Әмир ишетмәде, әгәр ишеткән булса, кызның әмеренә буйсынып, туктальп та калган булыр иде.

Рәсиха капкадан ялт кереп китте. Ишекне аңа әнисе ачты. Кыз әнисенең җилкәсенә башын салды, әнисе аны аркасыннан сөйде. Караңгы. Ләкин шатлыкны күзләргә карашмыйча да бүлешәләр алар. Моңсулыкны да тойдылар. Әнисе куенына Рәсиханың гөнаһсыз сабыйдай соңгы сыенуы иде бу.

— Әни, мин кияүгә чыгам...

Ана кызын күкрәгенә ныграк кысты: рәхәт тә соң син, ана куены!

Алар бергә яттылар. Бу төнне күзләргә йокы кермәде. Әтисенә яңа хәбәрне әнисе иртән генә әйтте...

Яшьлеккә ара-тирә кайтып килү кирәк шул. Тик бу бик тә авыр сәфәр, монда ялгызың гына юлга чыгуы хәвефле. Тугры юлдашсыз булмый. Ә Әмирнең андый юлдашы бар, Рәсиханың да ышанычлы Әмире бар. Бәхетле алар. Яшьлекләренә парлап кайталар, тормышларын тагын шул вәгъдәләшүдән башлап җибәргән кебек булалар.

— Элгәре эш турында сөйләшеп бетермәсәк,— диде Әмир, ерак уйларыннан арынып,— син фәрештә янында шөгылемне онытуым да ихтимал.

Рәсиха урындык тартып иренең каршысына утырды.

— Иске китаплар белән кызыксынгансың икән,— диде ул һәм урыныннан җәһәт торды да стеллажлар арасыннан почмактагы саклау бүлмәсенә таба атлады.— Төреп куйган килеш монда торалар алар. Гарәп әлифбасы белән язылганнар, мин укый белмим.

Төргәкнең берсе күләмле, икенчесе уртача китаплар зурлыгында иде. Әмир зур төргәкнең бавын, чишә алмагач, кесәсеннән пәке алып кисте.

— Журналлар ич болар! — диде Әмир, бер төпләмәне актарып.— Их, укып булса икән! Туктале, Рәсиха, «Яшь ленинчы» газетасында мәнә бу тышлыкны күчереп бирделәр түгелме соң?

— Әй, менә елы да күрсәтелгән ич! Совет чорында чыккан китап... журнал алайса бу. Муса Җәлил юбилее уңаеннан биргән иде ич моны газета, Җәүһәриянең әнидән хәрефләрен сорап утырганы искә төште. «Кечкенә иптәшләр» журналы икән болар.

— Һе, томаналарда инде без синең белән,— диде Әмир һәм журнал төпләмәсен читкә куйды.— Чеп-чи наданнар. Без Җәүһәрияне өйрәтәсе урында, ул безне өйрәтә башлаячак. Алып кайт әле монысын, этиләрдән укытыйк.

Икенче төргәктәгеләр журналга охшамаганнар. Болары төрле калынлыктагы китаплар иде. Һәм алар элеккерәк китаплар булырга тиеш, битләре нык саргайган, әмма таушалмаганнар иде. Күрәсең, түгәрәк өй хуҗалары аларны катыргыга үзләре төпләгәннәрдер.

— Шулай, бүгенгә ашарга икмәк булса, башкасы хакында хәтта

уйларга да онытабыз без.— Әмир Рәсиха өйгә алып кайтасы журнал төпләмәсе өстенә, сайламыйча гына, бер иске китап та куйды.— Ленин бабай кисәтеп өйрәткән, югыйсә, кешелек байлыгына сак булыгыз, дигән. Байдан калган хәзинә, янәсе. Шуңа күрә актарып карарга да куркабыз. Соң, ул хәзинә җиребез биргән хәзинә ләбаса! Һәм бу байлыкның ни начарлыгы бар? Китап ич болар! Китап!

— Мин гаепле,— дип бүлдерде ирен Рәсиха.— Бу китапларны күптән академиягә илтеп бирәсе калган, әллә кайчан тикшергән булырлар иде.

— Син гаепле? Ай-һай!

— Нигәдер авылның байлыгын читкә җибәрүдән жәлләдем.

— Дөрес иткәнсең. Сакланган әйбер кыйммәтен югалтмый. Гомумән, синнән дә әйбәт кеше юк, карчык,— дип, күкрәгенә кысты Рәсиханы Әмир.

— Миннән әйбәт кеше бер син генә,— дип, шаяртуны элеп алды Рәсиха.

— Мин чынлап әйтәм! Валлаһи!

— Мин дә.

— Шулай да мин хаклырак,— диде Әмир.— Беләсеңме, менә көн кичкә авышып килә, әле мин көнозынга җылы сүзләрне беренче тапкыр синнән ишеттем. Көн буена гел начарлык хакында ишетеп, житмәүчелек хакында кайгыртып карау дигәнең дә бар икән... Комбайннарга запчасть табарга кирәк. Арыслан тавына күмеп куймадылармы икән аларны...

Рәсиха иренең җиткән чәчләрен үрелеп сыйпады.

— Сабан туе җитә, Әмир, тузгыган чәчләр Рәсиханың ирендә генә, диярләр...

— Әллә аклары бармы?! Ак төшкәннәре булса, төптән кырдырып алдырам. Рәсиханың иренең чәчләре чаларган, дип гомер әйттерәсем юк! — дип сәгатенә карады Әмир.— Тик чәч алдырырга бүген өлгермәмдер инде.

— Күрдеңме, бер мин генә әрләмәде дигән идең... Юк, агармый чәчләрең, түзәләр әлегә. Башыңның түбәсе яктырып кына килә тик...

— Хәйләкәр фәрештә син, әй! — дип, Әмир чыгып китәргә җыенды. Әмма Рәсиха:

— Кая ашыгасың? Сүзем бетмәде ич әле,— дип туктатты.

— Әллә син дә чынлап торып ачуланырга җыенасың инде мин юашны?

— Әмир, хәтерлисеңме, былтыр көз минем машинага таныш түгел бер абый утырып кайтканны әйткән идем бит сиңа. Ул миңа юка яфрагы бүләк иткәнен дә әйткән идем. Менә ул юка яфрагы.

Рәсиха, өйдә шкафтан алган китапны актарып, яфракны тапты. Аны кыска сабагын бармаклары арасына кысып бөтерде дә иренең зур учына салды.

— Күрче, кипкәч тә матур була икән юка яфрагы! — дип шаккатты Әмир.— Игътибар ителмәгәнме, әллә онытылганмы шунда. Әмма, фәрештәкәй, мине барыбер көнләштерә алмыйсың,— дип, яфракны кире бирде ул.

— Мин синең белән чынлап сөйләшәм ич, шаярып түгел,— дип үпкәләбрәк әйтте Рәсиха.— Шул абый авылда берәү белән дә очрашып сөйләшмәгән. Ә үзен ул Кылыкныкы дигән иде. Туган авылым, әмма мин аны белмим, дип тә искәрткән иде. Тик һигә ул беркемне дә күрергә теләмәде икән? Башта аның машинага да утырасы килмәгән иде. Миңа машинаны баткаклыктан чыгарырга булышкач кына утырды.

— Йомыкыйдыр бер, шуңа күрә авылдашлары белән очрашмагандыр. Моңа аптырыйсы юк. Беткәнме кеше сөймәүче адәмнәр.

— Андый холыклы кешегә охшамаган ул. Сәбәбе бүтәндер.

— Нинди сәбәбе тагын?

— Минемчә, әти-әниләре авылдан күптән киткән кешедер ул.

— Туган җирен ташлап китүчеләр авыл саен күп. Вербовка белән

китүчеләрдән дә авылны онытучылар житәрлек. Әтинең пужумнарның кем урыны икәнен сөйләгәненә игътибар иткәнсеңдер ич. Туган жирне ташлау модасы хәзер дә беткәне юк. Кайнишең Фәрах-философ шәһәр белән авыл арасында киләп сарып йөрмәкче иде әнә. Соң, Кылыкта хуҗалыклар санын иң күп заманындагы дәрәҗәсенә һаман житкерә алганыбыз юк.

— Алай да түгел. Ул абыйның сүзләреннән, хәзер кайтып уйлыйм менә, бүтәнчәлек сизелә иде. Колхозлашу елларында авылдан җибәрелмәдеме икән алар?

— Нигә йомшатып әйтәсең? Кулак буларак авылдан сөрелгәннәрдер, диген.

— Ышанып җитмим. Шуңа күрә икеләнеп кенә әйтәм.

— Исең китмәсен, йомышы булса, авыл советына яки колхоз идарәсенә кермичә калмас иде. Кулак малае икән — аның кем малае булуында гаебе юк. Авылны кулаклар да кайтып күрсеннәр. Теләсәләр. Ләкин чакырып тормыйбыз. Кайтсалар, кире кумабыз. Авыл капкасына арата салмаган.

— Булмаган капкага ничек арата саласың ди? Башта капкасын койдыр син, иптәш председатель!

Әмир учы белән һаваны этәргәндәй итте.

— Аңлашылды, фәрештәкәй. Тәнкыйтьләүгә мин мохтаҗ түгел. Аеруча бүген. Ә шулай да яфрак хуҗасы турында дөрес чамалыйсың бугай син. Аның ерактан разведка ясавы гына булуы мөмкин. Туган ягына тагын кайтуы ихтимал. Димәк, кунакны каршы алырга әзер булырга кирәк. Искәртеп дөрес иттең, фәрештәкәй, уйлана тору зыян итмәс.

Әмир бүген иртәнге якта этисе Газизҗанның авылдан чыгып качкан Әлгый Фәсәхетдине хатыны Тәүфирәдән хат алуын — һәм инде җавап та язып куюын белми иде. Ул көндезге ашка кайтмады, комбайннарга запчасть эзләп, районара базага баргач, тимер юл станциясе ашханәсендә сыек шулпа һәм ботка белән тамак ялгаган иде.

— Юкә яфрагын югалтма. Хуҗасы кайтуы ихтимал. Визит карточкасын кире сорамагае. Кулаклыгы бетмәгән булса. Туктале, нигә монда алып миндән соң әле син ул яфракны?

— Китапханә китабы ич бу. Яфрак шуның эчендә иде.

— Шулаймы?

— Вакытында кайтасыңмы?

— Минем кайткан чак гел вакытында була ич, Рәсиха, беләсең ич инде,— дип елмайды Әмир.

— Әткәй нидер киңәшмәкче, Кәшшафетдин абыйларны да чакырды. Әнкәйгә кунак ашлары әзерләргә кушты. Мин дә озакламыйм, әнкәйгә булышырга кайтам. Син соңлама, дим.

Ишеккә җиткәч, Әмир хатынына борылып тагын елмайды, аның кушуына буйсынуын аңлатып, баш какты. Баскычтан йөгерә-атлый төште дә, урамга чыккач, иркен сулады. Сәер, китапханәдә һаваның тынчулыгына, китап исенә игътибар итмәгән иде ул. Әйе, китапханәдә менә ни өчен гөлләрне күпләп үстерәләр, китап битләре арасына яшел яфрак салалар икән. Үзенә күрә бәләкәй генә сере бар икән боларның.

Һәм Әмир колхоз канцеляриясенә ашыкты. Хатынын күреп сөйләшкәч, көн буена күзгә кылчык булып кадалган, колакка таракан булып кергән ямьсез яклардан бушанып калгандай булды ул. Әйе шул, күңелгә барысын да сыйдырып булмый, күңел дигәнең чиксез түгел, шуңа күрә бушану да кирәкле шәй ләбаса...

*Җәүһәрия көндәлегеннән*

«Мине иң-иң яратучы кеше кем дип уйлыйсыз инде? Бабаймы? Әбиме? Этиме? Әниме? Җиһангирмы? Аларның берсе дә түгел шул менә! Әйе,

лар барысы да яраталар мине. Мин дә аларны яратам. Мине укытучы абыйлар-апалар да. Кылыктагы барлык-барлык кешеләр дә яраталар. Мин дә аларны яратам.

Әмма мине иң-иң яраткан кеше кем? Белмисез. Үзем әйтмәсәм, белә дә алмыйсыз.

Мине иң-иң яратучы — этинең абыйсы Кәшшафетдин абый ул! Сез аның миңа ничек дип эндәшкәнен бер генә тыңлап карагыз әле:

— Се-нел-кә-ем Җәү-һәр-ия!

Кәшшафетдин абый болай ук өзеп-өзеп әйтми үзе. Әмма аның сүзләре Мишә тугаендагы дулкындай тирбәлә, оста биюченең сәхнә түреннән алга бөтерелеп килүе кебек булып тоела миңа.

Бүген сабан туе булачак мәйданны сакладым. Безнең чират иде. Шуннан меңгәндә, Кәшшафетдин абыйны очраттым. Йөзе караңгылыгын еракган ук абайлап алдым. Мине күрү сөенеченнәндер, Кәшшафетдин абый ялт елмаеп җибәрде, мине колачын җәеп каршылады.

— Се-нел-кә-е-ем Җәү-һәр-ия! — дип сөйде.

Кәшшафетдин абый әкиятләр сөйләргә оста. Ул белмәгән әкиятләр юктыр да, үзе дә уйлап чыгарадыр әкиятләрне. Мин Җиһангирга сөйләгән һәм көндәлеккә язып куйган Алпамша турындагы әкиятне китаплардан тапмадым, Кәшшафетдин абый гына белгән әкияттер бу. Менә хәзер Алпамша турындагы яңа әкиятне Җиһангир да белә. Кәшшафетдин абый сөйләмәгән булса, аны без белмичә да калыр идек әле.

Бүген ул миңа әкият сөйләмәде. Ие шул, урам уртасында әкият сөйләп булмый. Әкиятне Кәшшафетдин абый үз өйләрендә сөйли. Башына йомшак түбәтәен киеп куя, мине каршысына утырта, күзләрен йомып, калын кашын атсыз бармагы белән уңайга-кирегә ышкып тора-тора да:

— Борын-борын заманда... — дип башлап китә.

Әкиятнең ахырына җиткәнче, күзләрен кыса төшеп, маңгаен җыерып, каядыр текәлеп карый ул. Аның әкияте әнә шул үзе караган төшкә язылган да, Кәшшафетдин абый шуны игътибар белән укып чыга кебек.

Минем белән очрашкан саен, Кәшшафетдин абый нинди дә булса кызыклы хәл — бабай андый хәлләрне, мәгънәле гыйбарәләр, ди — турында әйтмичә калмый. Җитәкләшеп барганда да ике кызыклы хәл турында сөйләп өлгерде. Юк, сөйләмәде, үзе миннән сорады.

Безнең Арыслан тавының авыл ягында нaратлар үсә. Шундый текә ярда ничек аумыйлардыр инде, төп-төз утыралар. Кәшшафетдин абый шул нaратларга күрсәтте дә миннән:

— Иң биеге кайсысы? — дип сорады.

Мин шуны гына аермаслык бәләкәй түгел, шулай да, Кәшшафетдин абыем сорагач, үпкәләмәдем. Безнең әбиләр йорты булган турыда иң биек нарат.

— Менә,— ди Кәшшафетдин абый,— нигә анысы бүтәннәреннән узып үскән икән? — ди.— Уйлыйк әле, анысы башкаларының үсүен күзәтеп торыр өчен, аларга матур булып күккә күтәрелергә киңәш биреп торыр өчен иң биеге, иң өлкәне булдымы икән әллә соң ул нарат? — ди.

Каян белим ди инде мин моны? Җавап кайтара алмадым. Кәшшафетдин абый моның серен үзе дә аңлатмады.

— Менә син шул хакта уйла-уйла да,— диде ул,— белгәч, миңа да әйтерсең, яме, се-нел-кә-ем Җәү-һәр-ия,— диде.

Аннары:

— Чикләвек яратасыңмы? — дип сорады.

— Яратам, Кәшшафетдин абый, син үзең мине гел диярлек чикләвек белән сыйлыйсың бит.

— Карале, онытканмын да! Сиңа дип чикләвек тутырган идем лә мин кесәгә!

Ул бәләкәй алъяпкычым кесәсенә чикләвек тутырды, Җиһангирга да ватып бирергә кушты.

— Чикләвекнең кабыгы каты, име

— Мин аны чүкеч белән ватам.
— Менә шушы каты кабык эченә тәмле төш ничек кереп үсә икән соң, се-нел-кә-ем Җәү-һәр-ия?
Бу сорауга җавапны да Кәшшафетдин абыйга мин табып аңлатырга тиеш булам инде.
Әти әйткәндәй, шәп икән! Көндәлегем сораулар белән тула икән! Әнинең китапханәсендәге барлык китапларны укып бетерсәм бетерәм, шушы сорауларга җавапны барыбер табам! Бу сорауларны миңа мине иң-иң яратучы Кәшшафетдин абыем бирде ич...
Урта урамнан безнең турыдагы тыкрыкка хәтле җитәкләшеп мендек. Кәшшафетдин абый өйләренә кайтып китте. Бүген ул нигәдер кайгылы күренде, үзе шуны миңа сиздермәскә тырышты. Башка чакта җил-җил очынып йөри торган Кәшшафетдин абый, кулларын артка куеп, салмак атлап китеп барды. Ни булды икән? Бабайга да күренәсе итмәде. И-и, шул Фәрах абый гаепледер әле, әти әйткәндәй, шул философ әкәмәт чыгаргандыр. Арлы-бирле йөрүдән туймады инде Фәрах абый да, китә дә кайта, кайта да китә. Әтигә әйтеп акылга утырттырам әле мин аны!
Кәшшафетдин абый бөкрәебрәк тә йөри башлаган икән. Кечкенә гәүдәсе тагын да кечерәеп калгандай була икән болай. Гаҗәп инде, әти белән бертуган, югыйсә, Кәшшафетдин абый. Ә бер-берсенә һич тә охшамаганнар. Безнең әти әкияттәге Алпамша кебек зур гәүдәле, ул кычкырып көлсә, бөтен Кылык яңгырап тора менә. Кәшшафетдин абый кеткелдәп кенә көлә, кешегә каршы сүз әйтә дә белми ул, ә безнең әтине Киребеткән дә диләр. Әби белеп әйтәдер, олы улым әчтән көеп үзен бетерә, дип, Әмирҗаны калын тиреле, өстәвенә эченә җыймый, дип. Аннары, ди әби, Кәшшафетдине буыны ныгымаган килеш сугыш җәфасын күтәреште, ә Әмирҗаны үскән чакта муллык килде, каравым әйбәтрәк булды, ди.
Сабан туе мәйданында дежур торып кайткач, көндәлегемә Кәшшафетдин абый турында язып куясы иттем әле. Онытылганчы, дидем.
Җиһангир белән инеш буена төшәбез. Эшләремне бетергәч. Кәшшафетдин абый биргән күчтәнәч чикләвек белән энемне сыйлыйсым бар икән ич әле минем!
...Кәшшафетдин абый эндәшкән кебек булды.
— Се-нел-кә-ем Җәү-һәр-ия!..
Колакларыма ишетелгәндәй генә икән лә...»

Сарбай картайган инде, ишегалдын ташлап, ялгызы чыгып китеп йөрми. Янына ук килеп җим чүпләүче кош-кортны да куркытып җибәрми — юашны һәм көчсезне кош-корт та сизә! — бер килеп яткан урынында күзләрен йомар-йоммас йокымсырый бирә. Мал-туарны әйткән дә юк. Сарбайдан курку түгел, санга да сукмый башладылар. Юашсыталар.
...Газизҗанның таягын тотып чыгуын күргәч, Сарбай яткан җиреннән торды. Хуҗасы, таягын алгач, каядыр бара, димәк. Аңардан калырга ярамый, чөнки хуҗасына ияреп йөрү — Сарбай өчен бәхет.
Эт капкага Газизҗаннан алдарак барып җитте.
— Иярәсе иттеңме,— дип, капканы ачты Газизҗан.— Әйдә соң, иптәш булырсың.
Эт капка астына куйган тактаны атлап чыкты һәм юл тузанына җитеп туктады. Урамны уңлы-суллы карап алды. Хуҗасы, капканы ябып, түбән очка борылгач, аңа иярде. Йортны узып, тыкрыкка кергәч, Сарбай салмак юыртып китте. Инешнең сай шарламасы читендә туктап, ялап кына су эчте. Аннары суны ерып чыгып, Арыслан тавына юыртып-чабып бераз менде дә, акрын гына төшеп, Газизҗанны басма төбендә көтте. Аңышып алган иде инде Сарбай, хуҗасы инеш буена төшкәч, димәк, алар Арыслан тавы итәгендә, Әрәмәлек янында соңгы елларда гына салынган йортларга барачаклар. Газизҗан, ихата уртасындагы йортка кереп киткәндә, Сарбайны:
— Китеп йөрмә, шунда гына тор,— дип кисәтте.

Эт хуҗасын аңлады бугай — ишек турысындагы эскәмия астына кереп ятты. Шулай, картайгач, ятып торуга ияләнеп китә һәр җан иясе.

Мөсәвир картның бүлмәсе түрдә. Башы агач шарлар һәм бүтән бизәкләр төшереп эшләнгән караватл тышкы стенага терәп куелган, ян тәрәзә каршында йомры аяклы өстәл, аның астында терәксез урындыклар, дүрт якка да төрле озынлыктагы шүрлекләр сугылган, алар кызгылт-көрәнсу төскә буялган, боларның да башларына челтәрләп киселгән такта бизәкләр сугылган иде. Бу җиһазларны Мөсәвир өеннән монда күчерде һәм аларны да үзе ясаган иде. Карт ял итеп алган икән, урынын җыя иде. Сәлам алышкач, Газизҗан өстәл астыннан урындыкны тартып утырды, таягына, аны аяклары арасына куеп, ике учы белән таянды.

— Син дә таяк белән житәкләшергә гадәтләнеп киттең, кордаш,— диде Мөсәвир һәм термостан чынаякларга чәй агыза башлады.

— Ышанычлы иптәш ләбаса,— диде Газизҗан һәм таягын бөтергәләп күрсәтте.— Юлаучылар бик белеп кадерлиләр икән моны.

— Мин дә кадерлим шул менә аны.— Мөсәвир агач аягын өстәл астына сузды.— Газизҗан, этлек уйлап йөрим бит әле мин,— дип, кинәт бүтән сүзгә күчте ул.

— Һе, моңарчы эшләмәгән нәрсәне булдыра алырсыңмы икән соң? Начарлык кылу өчен дә көч-куәт кирәк, Мөсәвир.

— Шушы озын гомердә кешеләргә начарлык эшләмичә калынмагандыр, төрлесе булгандыр. Нигә белмәмешкә салынасың, синең үзенә үк аяк чалдым ләбаса мин. Беләсең син аны. Кайтарып әйткәнең генә юк. Хәтерлисеңме, Әлгый Фәсәхетдине коткысына бирелеп, колхозны тараткмачы булган идек. Мин дә алар рәтендә идем бит.

Газизҗан эндәшмәде, таягы белән идәнгә шакып кына куйды.

— Мунчаларына жыелып сөйләшкәнче, миңа да яңа суйган сыерның бер санын бирергә вәгъдә иткән иде ул. Хәер, миңа аның ите кирәкми иде. Җирән атымнан аерылу кыен иде миңа. Үзең уйлап кара, гомереңә беренче тапкыр атлы бул да, шуны бер ел җиккәннән соң колхозга бир. Үз байлыгым белән түгел, бурыч бирү ширкәте акчасына алган атым иде ич. Ярый да сез атсыз яшәмәдегез, революциядән соң хәлле хуҗалык идегез.

— Колхозга кереп атларын бирүчеләрнең бурычларын ширкәт сызды бит,— дип искәртеп узды Газизҗан.

— Шулай. Әлгыйләр мунчасыннан чыккач, башкалар кешеләрне жыярга киттеләр, мин агач аягым белән титаклап кәнсәгә йөгердем. Сине кисәтәм, янәсе. Ә үземнең, бүрекне алдын артка киеп, тавышны үзгәртеп, ишек ачып кычкырудан бүтәнгә көч житмәде. Сез чыгып өлгерүдән куркып, титаклап йөгереп качтым. Әлгыйләр килгәнче, түгәрәк өйдә утырдым.

Мөсәвир кызыбрак та сөйләде. Газизҗанның күзләренә карамакчы була, ләкин колхозның беренче председателе башын аска иган, үткәндәге четерекле вакыйгаларны күз алдына китереп, аларны яңача бәяләмәкче булып, уйга талган, кул аркаларын көйгә генә алмашлап ышкып утыра иде.

— Синең якка, колхоз ягына басарга көч житмәде шул чакта,— дип дәвам итте Мөсәвир.— Менә шушы юньсезлегем гомергә күңелдә төен булып йөрде. Җиңеләеп киттем бераз. Шуны сиңа әйткәч.

Газизҗан тагын эндәшмәде, тирән сулап кына куйды.

— Җирән атымнан аерылу җанымны кыеп кына алгандай булды!

— Янды шул атлар...— дип тагын тирән сулады Газизҗан.— Синең Җирәнең дә, минем Бурлы Кашка да...

Алар бераз сүзсез утырдылар.

Утыз дүртенче елда, колхоз азрак хәл алып ныгып килгәндә, Кылыкның Түбәкуак яны дип аталган басуында зур янгын чыкты. Колхоз монда ябулы зур ындыр табагы корган иде. Көлтәләрне шунда кибәнгә куялар һәм сугалар. Атларга шунда киртәләрдән утар ясаганнар, кешеләргә ерак басуда кунып эшләү өчен, Түбән мәчет мулласының йортын күчереп салганнар иде. Янгын төнлә чыкты, кибәннәр һәм салам эскертләре берьюлы

күтәрелеп янды, кибәннәр арасындагы утардан атларны коткара алмадылар, сугу һәм суыру машиналарының тимерләре генә утта кызып кәкрәеп калган иде. Әйе, урак өстенең ялкынлы болытлары ындыр табагын ялмап кына алды.

— Кем ут төрткәне тәки беленмәде шуның. Янгын үзеннән-үзе чыкмады бит инде. Ярый әле үзебез йорттан чыгып өлгердек...

— Район үзәгендәге больницаны кем яндыруы да беленмәде. Дәвалау урыны бит, шунда ут төртергә ни йөрәгең житмәк кирәк, ә? — дип башын акрын гына чайкады Газизҗан.— Димәк, дошманның көче юньсез булган. Моның өчен таш йөрәкле булырга кирәктер. Синең эшләячәк этлегең боларга һичничек тә тиң була алмаячак.

Мөсәвир, көтелмәгән бу нәтиҗәдән куркып, кычкырып җибәрде:

— Син нәрсә?! Минем мичкә генә ут төрткәнем бар! Хәтта кырда учак та якканым булмады. Ай-һай, каты күңелле кеше син, Газизҗан, картайгач, йомшара төш ичмасам бераз. Минем күңелне китүдән дә курыкмыйсың.

— Нишлисең бит, Мөсәвир, күсәк белән тәпәләмәсә дә, замана миңа күп кыен җыйдырды бит. Кан катарлык, йөрәк кырысланырлык булды.

— Анысы бар. Синең өлешкә мулдан чыкты. Алдан ырып-ерып баргач. Ә мин кылырга уйлаган этлекнең,— дип, әңгәмәнең башына кайтты Мөсәвир,— үзенә күрә әйбәт ягы да юк түгел. Әмирҗанны авыл җыенында утлы табага бастырмакчы булам мин.

— Минем малайны? Булдыра алырсыңмы икән?

— Әйе, председателебезне. Авылда су тегермәнен бетерттеме? Бетертте. Иң башлап ул гаепле. Яңасын салдыртсын. Сугыш елларында да Мишәне буа идек. Шунда катнашучыларга хәтта берәр стакан он өләшәләр иде. Хәзер елга буарга көчебез җитмиме? Сугару өчен дип ике буа будылар, ә тегермәнгә ярамый.

— Нишләп ярамый? Бик ярый. Синең бу теләгең әшәкелек кылу түгел.

— Бөтен Татарстанда су тегермәне икәү генә калган әнә, Янгулда да Салавычта. Икесе дә Балтач районында. Ә безнең Мишә Шушмадан кимме?!

— Әйдә, киен, безгә менәбез,— дип кузгалды Газизҗан.— Чәйгә.

— Үпкәләдем әле сиңа, өченче көн күренмәвеңә. Телефоннан шалтыратыр идең.

— Безнең өйдә телефон юк. Әмирҗан куйдырмый. Әйдә, җыен.

— Сезгә хәтле үк сәфәр йөри-алмыйм инде мин, Газизҗан. Югыйсә, синең төшкәнеңне зарыгып көтеп тә ятмас идем.

— Хәзер Фәрахетдин машина белән алырга килә. Кәшшафетдиннәргә дә төшәргә куштым әле.

— Нинди мәҗлес җыймакчы булдың соң әле син?

— Аш мәҗлесе түгел. Картайгач, яшьләргә әйтеп калдырасы сүзләр күбәя икән.

— Анысы бар,— дип, агач аягын сүтеп бәйләргә кереште Мөсәвир.— Үземнең дә Әмирҗанга әйтәсе сүзем калган. Безнең келәтне беләсең бит.

— Беләм. Авылдагы иң борынгы корылма шулдыр.

— Һәм дөрес. Авылның беренче кешесе салган булса кирәк аны. Ул заманда өе шундый булгандыр, без генә келәткә әйләндергәнбездер. Безнең нигездә гомер буе утыргандыр димим, урынын һәм хуҗасын күп алыштыргандыр, бәлки, келәт. Әмма борынгы ул. Җекләрен балта белән түгел, кәйлә белән алган кебек. Менә шул келәтне Әмирҗаннан бүтән урынга күчерттерәм әле. Минем йортка берәр гаилә кертсәк, юньлеме, әдәпсезме кеше туры киләсен белеп булмый, келәтне кадерсезләүләре бик тә ихтимал.

— Кая күчертсен ди аны Әмирҗан? Торсын үз ихатаңда.

— Табылыр урыны. Арыслан тавы түбәсе буш әнә. Шунда күчербез. Түгәрәк өйне дә иң күренә торган төшкә күчереп салырга булдык без Әмирҗан белән. Югыйсә, әнә, колхозның агрономы ишегалдына сыешмый башлаган, түгәрәк өй күзенә арпа кылчыгы булып кадалган...

Йорттан чыгып, Фәрахның машина белән килүен көткәндә генә Газизҗан Мөсәвиргә яңа хәбәр ишеттерде:

— Тәүфирә карчыктан хат бар.

— Кайсы Тәүфирә? — дип сискәнде Мөсәвир.— Әлгый Фәсәхетдине хатыныннанмы?

— Әйе.

— Исән икән, ә? Илле биш елга беренче хәбәр бирүләре. Ниләр яза?

— Үзең укырсың.

Бабасы белән Мөсәвир картны Фәрах авылның югары очыннан ук әйләндереп алып төште. Мөсәвирнең үтенечен үтәү булды монысы. Югыйсә, авылның Арыслан тавы итәге белән Әрәмәлегеннән бүтән җирен соңгы арада күргәнем юк, дип зарланды карт.

Сәхәрия чәй әзерләгән арада, Мөсәвир Тәүфирәнең хатын һәм Газизҗан кордашының аңа җавабын укыды. Чәй эчкәндә, бу хакта сүз кузгатмадылар. Алма бакчасына чыгып, кое янындагы эскәмиягә утыргач кына Мөсәвир:

— Җавабыңны әйбәт язгансың,— дип бәя бирде.— Баш эшли синең. Картайгач та.

— Хуп. Бүген кич шул җавапны бергәләшеп укып карарбыз дигән идем. Әмирҗан да ошатса, бик хәер канә. Тик, уйланып-уйланып йөрим дә, ахырда бер сүз өстисе бар кебек.

— Нинди?

— Җир әйләнә, дип.

— Тел төбеңне аңламадым. Ә-ә, тукта, сез, Әлгый Фәсәхетдиннәре, җирне кояш сезгә караган төштә туктатып тотмакчы идегез, әмма җир әйләнә, дигәнне аңлатыпмы?

— Шулай шул. Нәтиҗә ясалмыйча калган кебек.

— Кирәктер дә. Уйлап карасаң, кешеләр бер нәселдән бит. Кешелекнең нәсел агачын күз алдында тотсаң дим. Кайчандыр, әле кайчандыр, кешеләр арасында дошманлык булмагандыр кебек. Кемнендер үз-үзен генә яратуы көчәюдән башланган, минемчә, дошманлык. Их, Газизҗан, төрле-төрле заманнарны, энҗе-мәрҗән итеп, бер җепкә тезеп булсын иде ул, ә. Кешелекнең матурлыгы күз алдында ялтырап торганда, начарлык кылырга берәүнең дә кодрәте җитмәс иде. Заманнарны бер җепкә тезү синең белән минем генә көчтән килмәс. Шулай да, бәлки, дим, булдыра да алыр идек без моны. Шушы җәһәттән уйлаганда, җавабыңа бу фикерне өстәү кирәкмәс тә кебек. Анда ачулы сүзләр болай да җитәрлек.

Газизҗан Мөсәвиргә җавап кайтармады. Бүген кич Тәүфирә карчыкка җавап хатын тикшерү бәхәссез генә булмаячак икән, дип уйлады ул.

— Әмма, Мөсәвир кордаш, шуны бел син, хатымда мин иманыма хилафлык китермәдем. Дошман белән йөзгә-йөз очрашырга күбрәк миңа туры килде, кордаш. Әйе, дошманлык кайчандыр булмагандыр да, бәлки. Тик, ай-һай. Элек заманда, борын-борын заманда, әкияттә дошманлашу, ихтимал, булмагандыр...

Сарбай кайтып җитте һәм Газизҗанның кулына бәрелеп иснәнде дә, аның аягына терәлеп ятты.

— Озак йөрдең,— дип үрелеп сыртыннан сыйпады аны хуҗасы.— Биләмче.

— Ачуланма,— диде моңа каршы Мөсәвир.— Йөри-йөри дә барыбер өенә кайта. Оясы барын белә. Этләр тугры җанлы булалар. Этләр генәме соң, гомумән, хайваннар кешеләргә тугры бит. Безнең халыкның, дөньяның җәфасы җөп, вафасы-тугрылыгы — так, дигән мәкале хайваннарга бөтенләй дә кагылмый...

Һәм Мөсәвир колхозлашу елларыннан бер истәлек сөйләде.

— Беләсең,— дип башлады ул.— Әлгый Фәсәхетдиннәре, йорт-җирләренә ут төрткәнче, мал-туарын сатып, башкача урнаштырып бетергән булганнар. Тик бер җан иясен онытканнар алар. Кара мәчене. Менә

шул мәчене Әлгыйнекеләр урынында күрдем бит мин. Йортларын эзли, мескенкәй. Кычкыра. Өзеп-өзеп. Өйгә алып кайтмакчы булдым. Күзләрен яшелләндереп карады да басуга чыгып чапты. Нигезенә тугры шул мәчегә оя ясаган идем. Ләкин ул ояга кереп тә карамады, куйган ризыкларыма кагылмады. Икенче чакта кара мәчене Мишәдә күрдем. Беләсең, мин Мишә буенда йөрергә яратам. Олы Китек тугаенда күзләвек янында утыра кара мәче. Боз катмаган ачык урынга алгы аягы белән сугып ала. Өскә чыккан вак балыкны тотуы икән, мескенкәйнең. Аягына боз каткан үзенең. Бу юлы качмады миннән, чакыргач, килде. Изүгә каплап җылыттым, аягындагы бозын учымда эреттем. Әмма, өйгә алып кайтмакчы булып авылга борылуга, усал итеп бер мырлады да түн эченнән сикереп төшеп чапты. Нигезен алыштырырга теләмәде, бахыр. Бала-чага икенче җәйдә дә әле, кыр мәчесе күрдек, дип сөйләнеп йөрде. Колхоз төзегән чакларында син моның ише вак-төякне белмичә дә калгансыңдыр. Кыр мәчесе дигәннәре Әлгыйнекеләрнең шул кара мәчесе булгандыр, дим мин. Мескенкәй, нигезсез калгач, кыргыйланды... Буш, хәзер дә буш Әлгыйнекеләрнең нигезе...

* * *

Фәрахка йомышның берсе артыннан икенчесе табылып кына торды. Район больницасыннан килгән врачны — ашыгыч ярдәм машинасын кайтарып җибәргәннәр иде — илтеп куярга кушты аңа Әмир абыйсы. Кайтышлый, автовокзал яныннан узганда, Казаннан автобус килеп кенә җитүен күргәч, шунда борылып туктады Фәрах — автобуста авылдашлары булуы мөмкин иде. Әмма Фәрах янына килеп белешүчеләргә бүтән якларга кайтырга кирәк булып чыкты. Автобустан иң соңгы төшүче тәбәнәк буйлы кызны күргәч, ул үз күзләренә үзе ышанмады. Фәрзанә ич бу!

Егет машина ишеген селтәп кенә ябып, кызның каршысына йөгерде.

— Фәрзанә!— дип кызга кулларын сузып тукталып калды Фәрах.

Кыз сискәнеп артка тайпылды. Ул зәңгәр кофта-юбкадан, башына да зәңгәрсу косынка бәйләнгән иде. Елтыр күзләрен түгәрәкләндереп, Фәрахка карап торды да, иелә төшеп, бер мәлгә онытылып, көлеп җибәрде.

— Син нишләп йөрисең монда?!— диде ул, көлүеннән туктап. Аның түгәрәк йөзе бер алсуланды, бер агарды.

— Мин...— дип төртелеп калды Фәрах,— мин сине каршыларга килдем!

— И-и, каршыларга килдең инде бик! Алдакчы! Син минем кайтасын... киләсен каян белдең, ди?

— Мин дә белмәгәч, синең тирә-юньне балкытып кайтып төшәсеңне кем белергә тиеш ди инде?! Рәхим ит, Фәрзанә туташ,— дип уң аягын үкчәсенә басып башын иеп чакырды Фәрах.— Менә машина.— Һәм, кыз аңышып өлгергәнче, аны җитәкләп китереп машинага утыртты. Үзе йөгереп кенә машинаның артыннан әйләнде.— Күрешик, Фәрзанә туташ, югыйсә, син икәнлегенә үзем дә ышанып җитә алмыйм. Кулларыңның йомшаклыгы һич яшермичә һәм ышандырырлык итеп әйтеп тора: чыннан да, син икәнсең бит, Фәрзанәкәй!

Ә кыз телсез калды кебек. Читкә борылып күзләрен челт-челт йомгалый да тагын Фәрахка текәлеп карый, авыз читләре еларга җиткән баланыкы сыман дерелди.

— Нигә эндәшмисең соң син?

Фәрах машинаны кабызмакчы булып ачкычка үрелде. Кыз кулын салмак кына күтәреп аның кулына салды.

— Фәрах, ашыкма,— диде Фәрзанә һәм бөтен гәүдәсе белән кызгалып сулады, егеткә табарак күченде.— Ашыкма. Син уйлаганча җиңел генә хәл ителми мәсьәлә, Фәрах.

— Җиңел мәсьәләне авырга әйләндермик, Фәрзанә,— диде Фәрах, кызга таба борылып утырды.— Мин сине барыбер, нинди генә сәбәп-

лəр тапсаң да, җибəрмəячəкмен. Монда килгəнсең икəн, димəк, син мине күрергə телəгəнсең. Синең монда башка танышың юк. Димəк, мине...

— Яратам. Яшермим.

— Синең монда тасмаларың юкмы?— дип Фəрзанəнең сумкасына күрсəтте Фəрах.

Һəм, җавап та көтмичə, кибеткə йөгерде. Бераздан төргəклəре белəн ал һəм ак тасмалар күтəреп килеп тə житте. Фəрзанəне бармагы белəн генə ымлап чакырып чыгарды.

— Нишлəвең бу, Фəрах?

— Күрмисеңмени, сине килен итеп алып кайтам бит!

Егет тасмаларны сузарга ук кереште. Машина яныннан сəерсенеп узган кешелəрдə, кызыксынып карап торучы бала-чагада гаме юк иде аның. Кыз аңа булышмаска телəде, лəкин моңа ихтыяры житмəде. Курчакны алгы тəрəзə каршына утырткач, Фəрах кызга машина ишеген ачты. Фəрзанəнең йөзе шатлыктан балкып ала да шунда ук күзлəреннəн яшь бөртеклəре тəгəри иде.

— Əби сиңа күп итеп сəлам əйтте,— диде ул йөзе шатлыкка тулган арада.— Сине ошаткан ул, əти-əнигə дə ошадың. Минем монда килүемə берсе дə каршы төшмəде. Əби əйтə, шул юаш җанынны гомерлеккə яраткансың икəн, кызыкаем, ди.

— Юаш диме?!— дип тагын хахылдап очынып китте Фəрах.

— Үпкəлəдең мəллə? Мактавы бит аның сине, юмарт җан, ди.

— Күңел дəфтəрегезгə теркəп куегыз. Фəрзанə туташ, мин үпкəлəү дигəн нəмəрсəкəйне белмим. Ə хəзер кузгалдык! Хəерле сəгатьтə! Юлыбыз уң булсын!

— Фəрах...

— Ни булды тагын?

— Ашыкма... Мине кунакханəгə илтче.

— Булмаганны! Кире Ригага илтеп куймыйммы тагын?! Хыялга ярлы дип уйламыйсыңдыр ич мине? Хəзер менə җыелган халыкка безнең өйлəнешүебез турында чыгам да əйтəм!

— Адəм көлдер тагын.

— Нишлəп көлсеннəр ди?! Безнең як халкы кешенең бəхетле булуыннан көлми. Ə минем якташларымнан яшерен гамəлем юк. Əйдə, чыгып басыйк əле үзлəренең каршыларына!

Ни хикмəттер, Фəрзанəнең бу юлы да Фəрахка карышырга ихтыяры житмəде.

— Җəмəгать,— дип башлады Фəрах,— сезнең арада мине белүчелəр дə бардыр, бəлки. Мин Кылыкның комбайнчылары токымыннан булам, Фəрах Газизов ягъни. Ə Рига кызы Фəрзанə минем кəлəшем була. Ул кайтып кына төште. Без өйлəнешəбез!

— Рəхəт гомер итегез! Бəхетле булыгыз!— дип телəделəр машина янына җыелган кешелəр.

...Үр төшеп болын читенə житкəч, сүзсез калдылар алар. Икесенə дə уйланырлык нəрсəлəр бар иде. Фəрах машинаны туктатты.

— Сөекле Фəрахетдине болын чəчəклəре җыеп бүлəк иткəч, минем Фəрзанəмнең теллəре ачылачак,— диде ул, ə үзе каршыда сузылып утырган авылга күрсəтте.— Безнең Кылык авылы шушы була. Əнə, уңга кара син, чатыр түбəле йортны күрəсеңме, яшел калай түбəле? Фəрахетдиннəр йорты шул булыр. Əммə без синең белəн башка чыгачакбыз. Минем ике энекəш бар икəнен белəсең. Һəм нигезне — хəзер сулга, авылның югары очына ук кара — Сəхəрия əбилəр йорты булган урынга ук корырбыз. Мəсьəлəлəр шулай хəл ителə ул, Фəрзанə туташ, ə син жиңел мəсьəлəне дə авырлатмакчысың.

— Нилəр күрергə язгандыр инде миңа синең белəн... Бигрəк тə бер катлы син, Фəрахетдин...

— Дөрес!

— Шаяртмачы... Ашыгасың...

— Ашыкмыйча! Иртәгә таңнан комбайн ремонтына тотынырга кирәк. Болай тезек ул үзе. Ләкин синең янга барып-кайтып йөргән чакта комбайным тәмам сагышка баткан, әй.

— Ашыгабыз... Син белмәгән, мин дә кайтыр алдыннан гына белгән сәбәп бар безнең юлда, Фәрахетдин. Әби аны мин юлга җыенгач кына әйтте, әмма барыбер кайтырга фатихасын бирде.

— Нинди сәбәп тагын?

— Мин дә Кылык нәселеннән булам икән...

— Син?!

— Минем Фәрзия әби ике малае белән — эти кечесе — Кылыктан кулак буларак куылган... Кибет тотучылар булган безнең нәселнекеләр...

Фәрах чәчәк бәйләмен кулына кысып уйга калды. Аннары уң тезенә тезләнде дә чәчәкләрне таратып җибәрде, аларны, уртага зәңгәр чәчәк куеп, тигезләп тезәргә кереште. Кыз аның каршына чүгәләде, болын үләннәренең башларыннан сыйпап торды.

— Мин җәяүләп кенә кире китимме?..

Егет эндәшмәде.

— Шулай да син миңа болын чәчәкләреңне бүләк ит, яме, Фәрахетдин. Мин кирегә китәм. Синең бу чәчәкләреңне яшьлегем истәлеге итеп сакларммын, яме. Мондый болынны минем беренче тапкыр күрүем, кулыңа буяуларыңны ал да күчер дә яса! Синең чәчәкләреңне мин истәлеккә сакларммын. Кипкәч тә...

— Мә, Фәрзанә туташ, сакла.

Фәрах кызның җилкәсенә кулын салды. Фәрзанә, егетнең нинди карар чыгаруын белергә теләп, аның күзләренә текәлеп карый иде. Ул егеткә елышты.

— Җәяүләп тә, машинага утырып та кирегә юл юк сиңа, Фәрзанә. Юл бикле! Ялгызыңа. Бергәләп Ригага барып кайтырбыз. Гадәт саклэмыйча һич тә ярамый. Һәм сине кәләшлеккә сорарга Әмир абыйны да алып барырмын әле мин. Рәсиха җиңги дә барыр. Әти барыр. Самолет очып тора, күп вакытлары узмас. Узса тагын, Фәрахетдин бер генә өйләнә.

Фәрзанә егетнең күкрәгенә башын салды. Ике күзе дә яшь чишмәләренә тиң иде аның... Кыз Фәрахның ак күлмәгенә мул аккан күз яшьләрен ышкып сөртте.

— Син болай сытык түгел идең бит,— дип кочаклап күтәрде аны егет.

— Яратам ич мин сине...

— Һе! Мин яратмыйммы?! Еламыйм бит!

— Син — ир кеше...

— Бутамагыз, Фәрзанә туташ, егет кеше! Ә, гомумән, нәкъ бүген кайтуың шәп булды әле синең. Бүген Газизҗан бабай нәсел җыены уздыра, авылның иң өлкән кешесе Мөсәвир бабайны да катнаштырып. Кайбер мәсьәләләр шул җыенда хәл ителер. Сәхәрия әби белән Рәсиха җиңги катнашында, әлбәттә. Югыйсә, бабай белән Әмир абыйның холыклары бөтенләй дә минем холыкка охшамаган. Һәм дә ки, Фәрзанәкәй, мәктәптә рәсем укытучысы булырсың син. Монысын югары даирәләрдә рәсми сөйләшүләрдә зур тәҗрибәле Фәрахетдинең үз өстенә ала. Җитәр, югыйсә, безнең интим сөйләшүләр озакка сузылып бара. Ашыгырга да кирәк. Әнинең кайнаткан самавыры суынып китмәгәе, булачак киленен сыйларга зарыгып көтә булыр.

— И-и, көткән ди инде...

Әмир, идарә начальнигы Сәйфулов кергәндә, телефоннан сөйләшә иде. Гаянга утырырга ымлап урын күрсәтте, аягүрә басып, трубканы учы белән каплады:

— Казан,— диде һәм аннары трубкага сөйләвен дәвам итте.—

Саранланма, инде, складыңда комбайн частьлары тулып ятканын мин дә күреп торам лабаса. Кемгә дип саклыйсыңдыр, әй, шуларны. Кирәге чыгар? Соң, мена безнең колхозга кирәге чыкты. Дачага ашыгасыңмы? Өлгерерсең лә. Эшеңә шалтыратып тота алмадым, шуңа күрә өеңә дөбердәтүем... Нигә миңа барырга ди? Инженер белән берәр комбайнчыны җибәрермен. Нинди сөйләшәсе сүзләрем бар дисең? Әйт соң. Телефоннан ярамый? Син инде, сабакташ, боргаланып маташма, турыдан ярып сал. Тагын дача корырлык материал кирәк мәллә? Тиресме? Ит калҗасымы? Ярар, инженерга әйтерсең. Сораган частьларның барысын да бир түлке. Карарбыз, түгел инде, алай була алмый. Артыгын сорамыйм. Иртәгә иртүк машина җибәрәм. Минем хәлләр ничекме? Шәп инде, ничек булсын тагын минем хәлләр. Колхозда ашыгыч эшләр бетеп торган чак бит, ял иткәләп йөрим. Бүген көнозын Мишәдә балык тотып утырдым. Син Иделдә тотасыңдыр, Иделдә балык күбрәк, әлбәттә. Бу арада эләкми? Тирес суалчаны кирәк? Балыклар да талымлый, диген. Булыр, дим, тирес. Карәле, сыер абзарын салып бетерәбез, нәрсәләр ышандырганыңны онытма. Сабан туе узгач та барып чыгармын. Сабан туена кайт. Ә-ә, күршеләргә барасың икән. Әмма алар да сабан туен хәмерсез генә үткәрәләрдер, күрше районнар да, дим. Үзең белән аласың? Анысы синең эш. Бездә эчүчелеккә каршы карар көченә кереп бара. Ярар, ярар, иртәгә тугызларга ук барып җитәрләр. Инженер белән минем энекәш Фәрахны җибәрермен. Энекәшне яратасың бит син. Гәпләшегез әле бер рәхәтләнеп. Буш кул белән кайтарып җибәрә күрмә тагын. Исемлектәге әйберләрнең барысын да бир. Акчабыз җитәрме? Җитә, шөкер. Чек кенәгәсе инженерда булыр. Ярый, балыкны күп тот. Хуш иттек...

Трубканы куйгач, Әмир, озын өстәл янына килеп, Гаянның каршысына утырды.

— Запчастьлар булачак, иптәш Сәйфулов,— диде ул, идарә начальнигыннан ачуын яшермичә.

— Бик әйбәт.

— Әйбәт түгел шул. Тирес суалчанына запчасть ала башладык хәзер.

— Суалчан кызганыч түгелдер.

— Аңламадыгыз. Сез начар эшләгәнгә күрә, без суалчан тулы чиләк күтәреп йөрергә мәҗбүрбез.

— Мин начар эшләгән өчен?— дип кашларын җыерды Сәйфулов.— Ничек житкерик соң ул запчастьларны? Менә сез таныш-белешегез аша таба аласыз, ә бит китереп биргәнне көтеп ятучы председательләр дә бар. Комбайннары уракка чыкмаса да кашынмаячак ялкаулары бар. Әллә ялгышаммы?

— Ялгышасыз!— диде Әмир һәм ике йодрыгы белән берьюлы өстәл кырына сукты.— Андый председательләр хәзер юк! Ә нәкъ менә китереп биргәнне көтүче председательләр кирәк иде! Хәзер авыл хуҗалыгының һәр тармагына гаилә подряды кереп бара.

— Мин моны гына белмимме?

— Беләсез. Әмма килешенеп эшләүче гаиләне кирәк әйберләр белән тәэмин итүне башлап председатель кайгыртырга тиеш. Аннары, иптәш Сәйфулов, колхозга да подряд тәртибе ни өчен кирә соң әле? Колхозчылар азаюдан котылу чарасы итеп кенә түгелме? Яки коега да кармак салырга әзер комсызларга дилбегә тоттыру түгелме подряд? Бу алымның ихтыяҗында, нигезендә — азык-төлекне күбрәк житештерү, минемчә. Кеше көче җитмәү түгел. Әйе, авылда эшче көчләр азайды. Техника җитмәгәндә барлык эшне җилкәләрендә күтәрүчеләр инде картайды. Авылда урта буын кешеләр, табигый ки, аз. Табигый, чөнки сугыш елында туучылар юк диярлек, ә сугыш алдыннан туган кешеләрнең күбесе, хәтта барысы да диярлек, шәһәр халкына әйләнде. Яшьрәк буын исә тагын шәһәр белән авыл арасын таптый. Анысы да җомга-як

шәмбе көннәрендә генә әле. Менә ни өчен бит бүгенгесе көндә, колхоз да кем эшләргә тиеш, дигән сорау мөһимгә әверелде. Җавабы гади кебек — колхозда колхоз члены эшләргә тиеш. Ансат җавабы. Әмма дөрес җавабы. Промышленность колач җәйгәндә, эшчеләрне күбесенчә авылдан гына алу дөрес булдымы икән? Һәм шулай эшләп, шәһәрдә бүтәннәр җилкәсен кимерүчеләрне үзебез үк ишәйттекме? Әрәмтамаклар, эш сөймәүчеләр шәһәрдә санаусыз күбәйде, авылда андыйлар юк диярлек. Әйе, авылдан китүчеләр арасыннан чын эшчеләр дә үсеп чыкты. Күбесе исә, бәлки, ялгышамдыр, җирдән аерылганнар сыйныфы оештырдымы? Хәзер аларга дача участогы өләшеп кенә җиргә кайтарып булырмы икән үзләрен, ай-һай? Коммунистик җәмгыять төзегәндә авыл хуҗалыгын сынау полигонына әйләндерәбез түгелме? Инде әйләндермәгән булсак. Җир белән эш итәбез ләбаса, бер яраласаң, аның җәрәхәтен тиз генә төзәтеп булмый. Һәм кайчакта яңа җәмгыять төзү теориясен дә санга сукмыйбыз, хәтта партия съезды карарларын съезд узуга ук онытмыйбызмы? Аннары инде яңа съездга әзерлек турында гына сөйли башлыйбыз, элеккесен онытабыз. Башта менә нинди сораулар да туа бит әле.

Идарә начальнигы колхоз председателенең соңгы фикерләренә җавап бирергә әзер түгел иде, шуңа күрә сүзен подрядка гына бәйләде. Эшче куллар җитмәүдән зарланмаган председатель юк, дип инана иде ул, әмма бу зарның асылын моңарчы нык аңларга тырышып караганы булмады. Совхозда директор чагында үзе дә бу сәбәпне хуҗалыктагы кимчелекләрне аклау өчен файдалана иде.

— Мондый подрядлар колхоз эчендә ширкәт оештыру булып чыкмагае,— дип үз фикерен үстерергә тырышты Сәйфулов.— Бәлки, киң планда специальләштерүне максат итеп, берничә колхоздан олы ширкәт оештырырга кирәктер. Җитештерүне арттыруга китерәчәк бу, шулай бит.

— Бу мәсьәләдә хәзергә төгәл бер фикергә килә алмыйм. Күп эреләндердек тә, күп вакландырдык инде. Әйтәм ич, авыл хуҗалыгын кирәкне-кирәкмәсне сынау полигонына әйләндердек. Уйларга, барысын да үлчәргә кирәк. Әмма шунысын гына әйтә алам, эреләндереп специальләштерү һөнәрияләрен кысрыклауга кайтып калмаска тиеш. Матур итеп яшәү өчен һөнәрләрнең күп булуы кирәк. Кое куласасын әйләндерү дә һөнәрдер, бәлки. Берәүнең чиләге мөлдерәмә тулып менә, икенчесенең чиләге бер стенадан каршысына дөбер-шатыр бәрелеп суы яртылаш түгелә.

— Мин һөнәрчеләрдән сыйныф оештыру яклы түгел, иптәш Газизов. Крестьянны җирдән аерырга да җыенмыйм. Ләкин һәркемнең олы һөнәре бер генә була. Колхозларның киләчәктә нинди буласына күрәзәлек итмим. Әмма алар специальләшкән хуҗалыклар булачак. Тормыш хезмәттән тора, димәк, үзәктә һәрчак кеше баһадир булып күтәреләчәк. Моның өчен арымау, тукталып калмау кирәк, әлбәттә.

— Шулай да, катык өчен бер колхозга йөреп, катыкка турыйсы чөгендергә бүтәненә йөгерергә туры килмәстер.

— Чөгендер игәргә инешләр тамакларын сөрергәдер, бәлки?

— Дисезме? Безнең Кылык инешләре тамакларына кагылмагыз! Алар — авылның җыеннары һәм сабан туйлары урыннары. Безнең уентыклар бозау арканлау өчен дә уңайлы.

— Шул ягын башлап истә тотасыз ахрысы.

— Кайсы ягын өстен саныйбыздыр — бу кадәресен үлчәү тәлинкәсенә үк салып карамадым. Нигә — бозау арканларга кирәк булганы өчен сөрмәвебез начармы әллә? Түгел! Борынгылар киңәшен тоту да кирәк. Алар бит авылны уңайлы җиргә иплә салганнар. Һәм шунысы белән безгә җиргә берегеп яшәргә, игенен игәргә, терлеген асрарга васыять иткәннәр.

— Шәхси хуҗалыктан ераклашырга вакыт җитмәдеме икән, иптәш

Газизов? Югыйсә, крестьянның колхозда эшләргә вакыты калмый.
— Ялгыш фикер һәм нигезсез нәтиҗә. Гап-гади мәсьәләне, ашау-тамак мәсьәләсен онытмыйк. Бакчалар кисеп, крестьянны житештерүчедән кулланучыга әйләндерә яздыкмы? Булды андый хәл. Әйтерсең, кеше, шул киселгән бакча кыйпылчыгына басып, ризыкны ике кулын күккә сузып сорап алырга тиеш иде. Крестьянның шәхси хуҗалыгын үстерүдән курыкмаска кирәк. Бигрәк тә хәзерге этапта. Нәкъ менә хәзер авылның һәр йорты саен диярлек бер пенсионер бар. Аның үз хуҗалыгында терлек-туарын асрарга көче җитә. Шәхси хуҗалыкларда ит-сөтне аз житештерү аркасында базар бәяләре күккә сикерде, иптәш Сәйфулов. Әйе, әйе, иптәш начальник, базар бәясе турында да мин кайгыртырга тиеш булам. Чөнки бу сезнең, юаш итеп әйткәндә, ике ятып бер төшегезгә дә керми. Мыскыллап карамагыз миңа. Мине күз карашы белән генә аяктан егып булмый. Ә уентыкларны исә сез берничек тә сөрдерә алмыйсыз. Мондый ниятегез булса, халык авылга кертми сезне, шуны белегез. Уентыкларга сука төшерергә теләүчеләр булды инде, әмма теләкләре барып чыкмады. Аннары, Гаян иптәш, бу чирәмлекләр кешегә матур яшәү өчен дә кирәк. Эштән арып кайткач, Мишәдә су коенучылар күп була. Су коенып чыккач инде, уентыкларның чыклы үләннәрендә ялан тәпи йөрүләре чөгендер саткан акчага сатып алып булмый торган рәхәтлек ләбаса! Борынгылар уентыкны нигә дамба белән бүлде икән, дисезме. Мишә аша күперга юл турылау өчен генә түгел. Биек дамбаның су коену өчен дә кирәге булгандыр. Бер якта ирләр, икенче якта хатын-кызлар коенгандыр. Борынгы заманда плавки-купальниклар дигән нәрсәләрне шушы дамба алыштырган, димәк. Бу уентыклар ял итәр өчен көйләнгән, иптәш Сәйфулов. Кешегә ял да кирәк.
— Әгәр сөрдерсәк?
— Булмас.
— Район авыл хуҗалыгы идарәсе кушса? Партия райкомы кушсамы?!
— Кушмаячаклар. Сүз җаеннан, мин бит әле бу көннәрдә партоешма секретаре вазифаларын да үтим. Секретарь укуда, институтта читтән торып укый, дәүләт имтиханнары тапшыра, аннары аспирантурага керергә исәбе. Урынбасары авырып китте. Һәм партком миңа секретарьлек вазифасын да йөкләде. Вакытлыча, әлбәттә. Шулай булгач, бу очракта мин сезгә колхоз председателе һәм партком секретаре вазифасын башкаручы буларак фикеремне әйтәм. Партоешма секретаре югында, колхоз председателен бөгеп салуы җиңел булыр, дип уйласагыз, ялгышасыз. Мондый мәсьәләне хәл итәргә безнең колхоз идарәсенең һәм партоешманың көче җитәрлек, партоешманың көче колхозлар оештырган замандагы белән чагыштыргысыз артты. Безнең берәр партия җыелышына килеп утырыгыз сез, мине коммунистларның «Әпипә»гә ничек биетүләрен күрерсез. Ә уентыкларны сөрдерергә ризалык бирсәм, биетеп тә тормаслар.
— Мин сезне аз беләм, әлбәттә. Ләкин сезне үз киресенә бик тә беткән кешегә исәпли барам.
— Менә хәзер ялгышмыйсыз,— дип елмайды Эмир.— Идарә начальнигы булырга тәкъдим иткәч тә киреләндем мин.
— Минем урынгамы?
— Әйе, ризалашмадым. Дөресе, чеп-чи киреләнүдән түгел, үземдә сезнең урында эшләрлек көчем булуына ышанмадым.
— Сез алгарак китеп уйлый торган кешегә охшагансыз. Мин ризалашып ялгышканмындыр, бәлки. Совхоз директоры булган чаклар сагындыра. Үзебезнең районга нияләнелгән дә иде аннары.
— Колхоз белән совхоз арасында аерма зур.
— Һәм идарә белән колхоз-совхоз арасында. Ә сез начар председатель түгел. Һәр колхозда сезнең кебек җитәкче булса, эшләр гөрләп барыр иде ләбаса! Потомственный председатель бит сез.

Әмир начальникның тел төбен аңлап житкермәде, иреннәрен кысып, күзләрен акайтып карады.

— Юк, юк, сезнең традицияне начарга чыгаруым түгел,— дип көлын селтәде Гаян.— Терлекчеләр һәм механизаторлар династиясен мактап, председательләр династиясен кире какмыйм. Ат эзен тай таптый, диләр иде безнең якта. Шәкерт булмыйча, остаз була алмыйсың, дип тә өстиләр иде. Ә минем бүген сезнең авылга өченче тапкыр килүемнең сәбәбе, Әмир иптәш,— диде ул,— бик гади. Әтиегезне күрәсем, Газизжан бабай белән тагын очрашасым килә. Аңлашылмый торган бер халәттә мин: Газизжан бабай мине үзенә якын ук та китерми, еракка да жибәрми...

— Әйдәгез соң, кайтабыз. Әтигә ниндидер хат килгән. Шуңа күрә ул бүген нәсел киңәшмәсе жыя. Бәлки, сезнең өчен дә кызыклы булыр.

*Жәүһәрия көндәлегеннән*

«Кәшшафетдин абыйлар жыелышып төште. Яңа апа — Фәрзанә апа да бар. Фәрзанә апа мине яратты, Жиһангирны да яратты. Әле әби белән аш-су тирәсендә кайнашып йөри Фәрзанә апа. Игезәкләргә бәбәй ашы әзерлибез, ди әби. Бүген туган ике малайга инде. Шофер Шәриф абый белән Хәлыклы Заһирә апа малайларына.

Шәриф абый бүген кибеттән сиртмәле ике арба сатып алды.

— Минем Заһирәм, әйбәт хәлыклы булуы өстенә, дөньяда иң уңган кеше,— ди. Үзенең авызы колакларына житкән...»

Жәйнең кыска төне. Караңгылык төшә. Йортларда утлар сүнә бара. Ә Хәкимжан Газизжаны йортында мәжлес-әңгәмә тәмамланмаган әле. Газизжанның Тәүфирә карчыкка язган хаты турында сөйләшәләр.

Сарбай бер генә өреп хужаларга хәбәр салды. Әмир белән Гаян өй алдына чыктылар. Әмир болдырдагы утны кабызды. Кечкенә капкадан бер кеше күренде. Исәнләште. Авыл советында кизү торучы агай икән.

— Өйләренә телефон да куйдыра белми безнең авыл хужалары,— дип киресенә сөйләнеп алды ул.

— Ни булды тагын?— дип бүлдерде аны Әмир.

— Кунаклар килә.

— Килсеннәр. Сабан туенда безнең авыл кунак белән тула инде ул.

— Болары көтелмәгәнрәк, әллә ниндирәк кунаклар бугай. Тулы бер делегация, ди. Райбашкармадан шалтыраттылар, каршылагыз, диделәр. Еракта, дала якларыннан килгән кунаклар,— диде агай телефоннан әйткәннәрне язып алган кәгазен укый-укый.— Делегациянең житәкчесе Каюм Фәсәхиев дигән кеше, ди. Безнең Кылыкны белә ди, үзе туры безнең авылга килергә теләгән икән...

Кылыкның сабан туе житәр чактагы озын тәүлеге ерактан килгән кунакларны каршылау белән бетте.

*1973, 1984–86*
*Казан — Малеевка — Дубулты*

# *Әхсән Баяновка 60 яшь*



*Каләмдәшебез — танылган шагыйрь, прозаик һәм драматург, 1965 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы Әхсән Баяновка 60 яшь тулды. Әхсән Фәтхелбаян улы Баянов 1927 елның 8 декабрендә Башкортстан АССРның Илеш районы Әшмән авылында туган. 1943 елда күрше Ишкар авылында җидееллык мәктәп тәмамлый, аннан Югары Яркәй авылында, Культура йортында художество җитәкчесе булып эшли; хезмәттән аерылмыйча урта мәктәпне бетерә. 1951 елда Казанга килеп, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә, аны 1956 елда тәмамлап чыккач, озак еллар журналистика өлкәсендә эшли: 1956—1962 елларда — «Социалистик Татарстан» газетасында башта хәбәрче, аннан әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, 1962—1966 елларда «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре, 1977—1981 елларда исә шул ук журналның баш редакторы урынбасары вазифаларын башкара. 1961 елдан КПСС әгъзасы.*

*Беренче шигырьләре республика матбугатында 1951 елдан күренә башлый. 1959 елда аның «Диңгез шавы» исемле беренче җыентыгы басылып чыга. Хәзер ул — дистәдән артык шигырь китабы авторы: җыентыкларда шагыйрьнең лирик һәм фәлсәфи-публицистик шигырьләре, балладалары, «Яшел мәйдан» (1957), «Диңгез шавы» (1958), «Мират» (1959), «Сез аңларсыз мине» (1963), «Сәяхәтнамә» (1969), «Кышкы чәчәкләр» (1974) кебек поэмалары урын алган. Укучылар Ә. Баяновны прозаик буларак та яхшы беләләр. Аның «Яшьлегемне эзлим» (1966), «Дүрт монолог» (1968), «Тау ягы повесте» (1972), «Төлке тоту кыен түгел» (1975), «Тавыш — табигать бүләге» (1977), «Аязучан болытлы һава» (1978), «Аргы яр» (1979), «Мәңгелек бәхәс» (1986) повестьлары һәм «Ут һәм су» (1971), «Таш китап» (1981) романнары укучылар һәм әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан зур кызыксыну белән каршыланды.*

*Әхсән Баянов — «Күзләре нинди иде» һәм «Һәйкәл» исемле драма әсәрләре авторы да. Аның күп еллар дәвамында язган тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләре «Заман сурәтләре» китабында тупланган.*

*Ә. Баяновның рус телендә Казанда «Судьба стучится в дверь» (1980), Мәскәүдә «Вы поймете меня» (Советский писатель, 1968), «Зимние цветы» (Современник, 1975), «Другой земли нет» (Советский писатель, 1983) исемле шигырь китаплары һәм «Ищу молодость» (Советский писатель, 1971), «Повесть Горной стороны» (Современник, 1978) кебек проза китаплары дөнья күрде. Аерым әсәрләре илебезнең башка телләренә дә тәрҗемә ителгән.*

*Әдәбиятны үстерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен Әхсән Баянов 1977 елда «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде. Алтмыш яшен әнә шундый мул иҗат җимешләре белән каршылый әдип. Аны зур юбилее белән котлап, без бу санда укучыларыбызга Ә. Баяновның өр-яңа әсәрен — «Алтын кашбау» исемле шигъри трагедиясен тәкъдим итәбез.*

## Әхсән Баянов

# АЛТЫН КАШБАУ

ШИГЪРИ ТРАГЕДИЯ

Беренче бүлек

### *Тар-мар ителгәч*

Үрә басып, өркеп кешни Вакыт —
Унөченче гасыр уртасы.
Йорт-диварлар тетелеп, эри металл,
Дөрләп яна нигез — чор ташы.
Аунап ята илләр һәм аллалар,
Җыя алмый ята Җир аңын.
Койрык болгый-болгый, ач эт бугай
Канлы кулын ялый тиранның.

Төн. Күзсез төн. Күзсез кара төндә
Кисешәләр утлар, кылычлар.
Ай-елларны теркәп кылычларга,
Уза гасыр. Тик бер заман килә
Җир өстенә сәер, тыныч таң.

Тәхетләр һәм илләр җимерелешен
Соңгы кабат, гүя, күрер өчен,
Кан хәбәрен, үлем гөрелтесен
Яктылыкка, гүя, әверелдерер өчен,
Канлы күзе төннең ачылып куя.
Исән затлар карый тын гына:
Учак кабына, һәм җыр ишетелә.
Җәрәхәтле, җәрәхәтсез куллар
Моңлы яктылыкка сузыла.

Җ ы р *(кызлар тавышы)*

Илебезне таптап, дошман безгә
Ут йоттырды, канда йөздерде.
Йөздек, түздек — инде җитте вакыт,
Бу яшәүдән яуда үлү артык —
Яуга дәшә туган җир безне.

Кем аякка кабат баса алса,
Кулыгызга кылыч алыгыз.
Яу чабыгыз бәлки соңгы тапкыр,
Шунда гына илгә тормыш кайтыр,
Яу чабыгыз, яулар чабыгыз!

...Учак сүнә ләкин һәм тына җыр.
Көнгә ышанмыйча карый күз:
Җир өстендә ауный хәрабәләр.
Хәрабәләр арасында утыра
Ялгыз кыз.

К ы з *(үзенә таба кемнеңдер килүен күреп)*

Балтамар! Сезме соң бу?

Балтамар

Мин, Алсылу, мин бу!

Алсылу

Нигә мүкәйләргә, сөйрәлүче әрвах сымак,
Башны күккә терәп йөрер чакта?

Балтамар

Фетнә тынды, кискәләнде елан,
Кисәкләре мәгәр боргаланып ята.
Синең кебек тиле булсаң гына,
Мөмкин әле безгә курыкмаска.
Их, Алсылу, нишләдең бит!

Алсылу

Нишләдем соң?

Балтамар

Субудайның асыл алыплары
Тыйлыктылар чәңнән сине тыңлап.
Күпме фетнә кавеме, гәрчә әсир төшеп,
Исән калды — менә нишләдең син.
Челпәрәмә кырдың бәхетебезне
Бер селтәнү, бер җыруың белән.
Гыйсъян җырлап, яңа фетнә чакырып,
Күккә ашачаксың үзең тиздән.
Менә нишләдең син!

Алсылу

Бар куркыныч булса — сүз һәм җыру.
Мин сөйләргә әзер һәм җырларга
Гомерем буе.

Балтамар

Дар менепме? Син ризамы дарга?
Алай дисәң, киттек хөкемдарга. *(Алсылу эндәшмәгәч)*
Сүз тыңласаң, бардыр котылу җае.
Акылың булса, шуны эзләп карыйк.
Тик җай кими — тагын арта шаһит.

Алсылу *(читкә күз ташлап)*

Ник куркырга — ул бит угры түгел,
Илдә калган соңгы галим-катиб.

Балтамар

Фетнәнең бер ләшкәрен шул асыл бәндә,
Үзем күрдем, алып килде яуга.
Күр, чат гаепсездәй атлап килә,
Синең белән, гүя, очрашуга.

Алсылу

Сез гел шикләнәсез.

Баян *(керә-керешли)*

Тыныч иртә котлы булсын, кардәш-ыру.

Балтамар

Котлы булсын, гәрчә аны алып килде бары
Сезнең яман җыру.

Баян

Гадәтеңчә, яла якмакчымы?

Балтамар

Чү, акрын!

*Башта тояк тавышлары ишетелеп, аннары хәбәр яңгырап уза: «Күктән — хәбәр, күктән хәбәр килде! Илдә иң акыллы булган кешебезне табыйк. Безгә тәңре тик бер кеше бәясенә тыныч тормыш вәгъдә итә! Меңнәрне исән калдырып, бер кешене бирик! Тынычлык бәясенә бер кешене үзенә сорый Тәңре! Тыныч тормыш, тыныч тормыш бәясенә!»*

Балтамар

Ишетәмсез? Җыру белән генә тынычлык яулап булмый, димәк.
Күккә, аллаларга күбрәк кирәк.

Баян

Әллә сиңамы, Балтамар?

Балтамар

Чү, акрын! Әнә аллаларның, Батый Җиһангирның һәм халыкның
Әмерен эшкә ашыручы казый Изух килә. Баш иегез! *(Билгә кадәр иелеп, Изухны сәламли).*

*Изух белән бергә, ике сакчы яраланган Җику бәкне алып керәләр һәм җиргә ыргыталар.*

Изух

Менә — фетнә башы, аны таныймсыздыр.
Әүвәл биһуш ирде, аңга килде хәзер бу баһадир.

Балтамар

Җикү! Таңда без кыйраткан ләшкәр башы — будыр.

Изух

Җиһангирдан, Батый ханнан ягъни, килде боерык:
Фетнә кавемен хөкем итү безгә тапшырылды.
Иллә ничек икәнлеге ярук түгел бик үк.
Сез — халаек, канки улыр сезнең теләк?

Балтамар

Без халыкны санга суккан өчен
Сезгә рәхмәт, олуг хөкемдар.
Мин әйтәмен шуны: фетнәләрне мәңге
Башсыз итмәк өчен, моны дүрткә киссәк,
Кискәләгәч, Кирәмәт тавындагы бүреләргә бирсәк,
Бик мәслихәт.

Алсылу

Тагын кан! Җитәрме бер заман!

Изух

Сөаль фикер улмас. Сез, Баян бәк, ни диярсез?

Баян *(бераз Балтамарга охшатып)*

Фетнәләрне башсыз итмәк өчен
Баһадирны ярдан суга ату кирәк.
Халык риза, шундый минем теләк.

Алсылу

Баян бәк, сезме соң бу?!
Хурлык! Соңгы баһадирны үзебез харап итәчәкбез.

Җиһангирдан, Субудайдан нинди булсын боерык —
Аларны бит берегезнең күргәне юк.
Үзегез тырышасыз, эш күрсәтмәк булып.

И з у х

Хатын сүзе хак уралмас. Гаепләне якын китерегез.
*(Җикүне уртага китергәч, хөкем карарын әйтә).*
Шәхесне сез расладыгыз, җинаять — хак.
Ул зур чирү җыйнап, олугъ Урда дәүләтенә һөҗүм кылды.
Халаек вә дәүләт наме илә хөкем итәм:
Җикү бәкне, муенына таш тагылган хәлдә,
Әтил-суга ыргытырга.

Б а л т а м а р

Амин.

И з у х

Җинаятьче, соңгы сүзегез бармы?

Җ и к ү *(авырлык белән торып баса)*

Минем янга Баян бәк килсен.

И з у х

Үләчәкнең гозере үтәлә — якын килгел.

Б а я н *(Җикү каршына килеп баса)*

Су булса да, Итилгә таян. *(Күз карашлары белән нидер аңлашкач, Изухка борыла).* Ул кылыч сорый, аңа кылыч бирегез.

Б а л т а м а р

Рәхим ит, җинаятьче *(Җикү Балтамар кылычыннан баш тарткач, Баян бәк үз кылычын бирә)*

Б а я н

Рәхим ит, бәк.

Ж и к ү *(шартлы аңлашканлык сизелер дәрәҗәдә ясалмалык белән)*

Намус наме белән әйтәм: хыянәткә җәза тиеш.
Сез, Баян бәк, халкыбызга хыянәт иттегез.
Дөньядан сез дә китәргә тиеш. *(Баян бәк тезләнеп башын ия).*
Юк, минем кулдан китүгә сез лаек түгел.
Яуладыгыз сез хурлыклы, озак үлем.
Куркытмаса сезне монда үткен булат,
Бәгыregезне талагандай этләр ырлап,
Җаныгызны телгәләсен коръән шигыре.
Бирел сезгә зур хурлыклы шайтан гомере.
Әүвәл горур булган йөзегездәге кара тапка
Ил төкерсен килеп-килеп мәңге.
Балтамардай түбән җаннар арасында
Җирәндергеч ваклык кичереп яши бирегез.

Б а л т а м а р

Җитте! Сакчы, тизрәк аның авызын капла!
Күрче, дәүләт кешесенә пычрак ата!

Б а я н

Илдә — вәхшәт, канлы табан асларында аунап.

Халкыбызның вөҗданы, намусы ята.
Бөтен тормыш әхлаксыз ваклыкка баткан чакта,
Кеше ялгыз саф калалмый, белеп кит, бәк.

Җ и к ү

Үз зурлыгы, иминлеге, үз туклыгы өчен
Илне саткан һәм хурлаган адәм битенә
Бер караудан мең үлгәнең хәерлерәк.
Менә нинди хәлгә төште безнең дәүләт.

Б а я н

Сүзең дөрес, Рәнҗемә, бәк; күсе булып сау калудан
Арыслан булып җан бирү хәерлерәк.

Җ и к ү

Ә кемнәрдер күсе булып кала горурланып.

Б а я н

Бу хурлыкны безнеке дә, илнеке дә димә.
Берсен-берсе ырлап кимерә-кимерә,
Көнлек шөһрәт, еллык сәгадәт наменә
Халык бәхетен җырлап эчә-эчә йоткан.
Соңрак җирне су басса да, гамь белмәгән
Хан-түрәләр хурлыгы бу, белеп кит, бәк.

Җ и к ү

Шулар аркасында ил хурлыкка лаек.
Ләкин безне барыбер кичерер җай юк. *(Кылычны Изух аяклары астына ыргыта).* Алыгыз мине, атыгыз Итил упкынына.
Бүтән җәза безгә харам.

И з у х

Җинаятьче үзе хуплый хөкемебезне.
Аны җиренә җиткерергә! *(Сакчылар Җикүне алып китәләр.)*
Инде шундый дәвам: баш сарайдан фәрман —
Фетнә калдыкларын, вә уннарны тар-мар итәр-итмәс
Чәң-сугыштан тыйлыгып калган чирү газыйларын,
Мисле Җикү, дәхи хөкем итү.

А л с ы л у

Бар халыкны упкынгамы?

Б а л т а м а р

Олуг дәүләтне тар итеп күрүчегә
Теге дөнья — иркен. Барча халык
Баш күтәрсә, шул чакта да урын була табып:
Башы белән су төбенә, ташлар тагып.

А л с ы л у

Барча башка җитәрме таш?

И з у х

Халаек сорый, әйт, Балтамар,
Табарсызмы баш санынча ташлар?

*Еракта́н тавыш: «Тәңре корбан сорый, корбан! Иң акыллы асыл кешебезне үзенә чакыра! Күккә чакыра!»*

А л с ы л у

Менә сиңа тыныч көн!

Изух

Я, житәрме ташлар?

Баян

Таш житүе хаҗәт түгел. Ул яраксыз алыпларны
Кирәмәт тавына кусак, житкән бик үк.
Алар анда, аерылып илдән, әйләнерләр сарыкларга.
Сарыкларга исә бүреләр күп.

Изух

Хыянәтче газыйларның көтүен озатабыз
Упкын илә уратылган Кирәмәт тавына.
Ә сакчылар ул көтүне көнгә чыгармыйча саклар.

Баян

Хөкем — дөрес!

Алсылу

Сез — кардәшләр: Болгар илен соңгы сулышкача
Саклырбыз дип антлар әчкән затлар.
Ничек яшәмәк буласыз, шушы хәтле каргыш җыеп?!

Изух

Хөкем тәмам.

Балтамар

Без, халаек, хөкемегезне хуп күрәбез.

Алсылу *(Изух каршына басып)*

Күзләрегез көн дидарын, ай-кояшны күрмәс булсын —
Сукыраегыз.
Колагыгыз җир авазын ишетмәсен —
Чукраегыз.
Иблис белән бердәй бергә бөкрәегез.
Мәхшәрдә дә, тәмугта да ут йотыгыз.
Итил-әнкә хәрәм булсын, исемен онытыгыз.

Баян

Инде, хөкемдар, китәргә рөхсәт итегез.

Изух

Рөхсәт, китегез.

Балтамар *(Баян китеп барганда)*

Аны... Баян бәкне хөкем итмибезмени?

Изух

Үзебезнең яклыларга кулны сузмаң. *(Китә)*.

Балтамар

Сез әйткәнчә булыр, хөкемдар *(Алсылуга)*.
Шушы кадәр ник соң ак эшләргә син чаласың аяк?

Алсылу

Күрсәтегез, эшегезнең кайсысы ак?

Балтамар

Безнең ак юл — хан Батуга барып

Башны ору һәм алу зур хокук.
Күпме, күпме болай яшәү мөмкин,
Хуҗасыз эт мисалында, куркып?

Алсылу

Әткә хуҗа кирәк — менә ничек!

Балтамар

Нишлим, хәйлә белмим Баян бәк күк.
Төндә бер ләшкәрен яуда кыйраттыргач,
Үзе исән калган акыллы баш,
Мең кешене биреп, тагын калды исән.
Үзең күреп тордың.

Алсылу

Эх, күрдем шул, эх, күрмәгән булсам!

Балтамар

Кечүк дәүләттә дә рәнҗетелгән булгач,
Җиһангирга барып игән ул баш.
Саклап калган шулай җанын, малын.
Җирне ак ат тоягы астына сыйдырган ханның
Кызыл мөһере төшкән кәгазь — кесәсендә аның.
«Кагылгысыз» дигән ярлык. Аңа булмый кагылып,
Батый ханга дошманлыгын расламыйча торып.

Алсылу

Аңлый алмый һичбер нәрсә.

Балтамар

Сиңа Баян бәкнең өенә бару кирәк.

Алсылу

Баян бәккә? Нинди максат белән?

Балтамар *(Ташлар арасыннан зур гына кап алып шуннан кашбау[1] чыгара)*

Күрәсеңме, бу ни?

Алсылу

Кашбау! Алтын кашбау!

Балтамар

Миңа ул кадерле — гүя йөрәк.
Кара, монысы — үзәк бизәк. Шуны ачсаң,
Чыга өнсез кодрәт.

Алсылу

Ул ни?

Балтамар

Чеметем он. Чәенәме, хәмеренәме салсаң...

Алсылу *(чигенә)*

Юк, юк!

---

[1] Кәшбау — ярәшелгән кызның баш киеме. Автор

Б а л т а м а р

Мин бит сиңа яшәү бүләк итәм.
Эшен үтәп кайтсаң, кашбау үзеңә — бүләк!
Азмы шушы? *(Кашбауны кидерә).*
Мин бит әле мәҗбүри дә димим, әйе, һич тә.
Тыныч чара, бүтән җай тапмасаң гына.
Ә кашбауны кара, кояшмыни яна!

А л с ы л у

Күрмим, берни аңлый алмыйм.

Б а л т а м а р

Иң җайлы эш — язмаларын миңа җыйнап бирү.
Ә иң башта — син җырлаган җыруларын.

А л с ы л у

Юк, юк!

Б а л т а м а р

Басып сайрар талы сынган син элекке сарай сандугачы!
Шул йомышны үтәп кайтсаң, безгә ачыласы
Батый ханның ак сарае.
Үзең сайла: шул зур данмы, әллә дармы.
Дан сайласаң, йомыш үтәп кайткач, укытырбыз никах.

А л с ы л у

Никах? Мин бит әле...

Б а л т а м а р

Риза булсаң, йөрәгем белән бергә, кашбау — бүләк сиңа.
Хәзер исә — юлга.

А л с ы л у *(уйланып)*

Ничек... бер ялгызым ничек чыгыйм юлга?

Б а л т а м а р *(якынлашкан тояк тавышын ишетеп)*

Якын кешең анә — ул ярдәмгә килә. Әй, җайдак кыз!
Бире килегез, бире! *(Җайдак кыз күренүгә).*
Әйдә, күк илчесе, ил чибәре!

Җ а й д а к   к ы з

Котлы булсын тыныч көн.

Б а л т а м а р

Күк хәбәрен илгә тараттың шәп.
Ишетмәгән кеше калмады шәт.
Шуның өчен менә сиңа бүләк *(Җайдак кызга муенса кидерә).*

Җ а й д а к   к ы з

Муенса! Нинди матур муенса! Рәхмәт яусын.

Б а л т а м а р

Үзеңә рәхмәт, ил чибәре. Инде яңа эш бар.
Баян бәкнең өенә бару кирәк.

Җ а й д а к   к ы з

Бәк өенә безне кертәләрме?

Балтамар *(Каптан ниндидер сын чыгара)*

Таныйсыңмы моны?

Җайдак кыз

Бакыр кыз, гарип кыз. Күргәнем бар.

Алсылу

Өлкәннәргә — табыну сыны, безгә — күркәм ядкарь.

Балтамар

Мәчет халкы талап алган аны Баян бәктән.
Бүләк диеп, кабат илтеп бирсәң әгәр,
Киереп ачылачак ишек-капкалары.
Тәңре әмерен үти башлыйк шулай. Сезгә — изге сәфәр!

Алсылу

Ә мин берни аңлый алмыйм һаман.

Балтамар

Юлда сеңелең төшендерер. Хушыгыз.

Җайдак кыз

Хуш торыгыз *(Китәләр).*

*Тояк тавышлары яңарып, ул кызлар Баян бәк җәйләвенә җиткәч кенә тына. Караңгы төшеп, тагын яктыра. Баян бәкнең җәйге сарае ачыла. Алдагы яшел мәйданны бүлгәләп, куаклар, сукмаклар сузылган. Өй ишегеннән ерак түгел — зур өстәл. Өстәл янында Баян бәк белән йорт караучысы Тансыкбикә сөйләшәләр. Ә капка янындагы багана башына ниндидер баш сөяге элеп куйганнар. Тынсыкбикә күреп, шуны кулына ала.*

Тансыкбикә

Кирәмәт җибәргән аны, үлем хәбәрен. *(Баян бәк янына күтәреп килә).*

Баян

Кирәмәт бу кадәр явыз түгел. Аның белән безнең ара
Якыная бара.
Бу рәвешле безгә дошман яный — кеше!

Тансыкбикә

Җәнлекләрдән узып, адәм ашый берсен-берсе. *(Баш сөяген куя).*
Шушы адәмнәрне харап иттерергә юл куйганга,
Илгә төшкәндер бу афәт, каргыш булып.
Каргыш төште илнең үз башына — харап булды үзе.

Баян

Хактыр сүзең. Илне чынлап җуйдык.
Калды бары хөсетләшү, кимерү, җимерү, кыру.
Ярый, әйдә чәй әзерлә. *(Баш сөяген кулына ала).*
Саумы, нәсел-ыру!
Беләм, син хөрмәтле ил агасы идең. Каен очына
Үрләттеләр зур акылың аркасында.
Киштәмдә өченче булып ал абруйлы урын.
Дәвер рухын бергәләшеп ерак токымнарга
Җиткерерсез сүзсез. Ә син бик ыржайма
Һәм бел, безнең хәл дә синекеннән шәбрәк түгел.
Киләчәктә нур сирпеми өмет, вәгъдә.
Тик шулай да адәм булып калыйк.
Вәхшиләрнең хәлен төшенеп карыйк.
Сезне аса килгән кемнәр алар, кайда?

Үтереп күпме үзләренә тапкан файда?
Исемнәре — очкан тузан. *(Сөякне куя).*
Ә сез илдән илгә, чордан чорга
Сәфәр кылачаксыз ачы гыйбрәт сыйфатында.

*Капка янында кешеләр күреп, Тансыкбикә шунда китә. Аңа ияреп, Алсылу белән Җайдак кыз керә.*

Тансыкбикә

Әйбәт хәбәрләр белән килегез, узыгыз.

Алсылу

Хәерле иртәләр, хөрмәтле бәк.

Баян

Хуш киләсез. Ераккамы сәфәрегез?

Алсылу

Сәфәребез тәмам бугай. *(Урындыкта баш сөяген күреп)*
Тагын, тагын, ай!

Баян

Курыкмагыз, бу бик затлы адәм.

Җайдак кыз

Әйе, без дә сүзне шундый әманәттән башлыйк. *(Каптан сын чыгара).*

Тансыкбикә

Гарип бала! Кайттымыни кире?!
Әй, сөенеч! Рәхмәт, рәхмәт инде. *(Бакыр кызны элеккеге урынына куя).*

Җайдак кыз

Кирәмәткә рәхмәт укы, апа, ул җибәрде.

Тансыкбикә

Рәхмәт сезгә, рәхмәт Кирәмәткә. *(Өйгә кереп китә).*

Баян

Һәр кодрәтнең үз урыны. Бу нәни пот
Зур аллага каршы күптән күтәрми баш.
Юкка рәнҗеттеләр гарип кызны. Бәлки шулай ук сезне.
*(Тансыкбикә чүлмәк алып чыккач).* Ә без сезгә иң
чын бәхет телик. *(Касәләргә шәраб коя).* Кыстатмагыз, эчемлек
бик йомшак.

Алсылу

Ярыйдыр шул, илдә калган асыл бер зат өчен.

Җайдак кыз

Илнең иң акыллы кешесе өчен. *(Кызлар карашлары белән бәхәсләшеп алалар).*

Баян

Хәзер, мин тиз, сабыр. *(Китә).*

Тансыкбикә

Мин дә хәзер. *(Китә.)*

Ж а й д а к   к ы з *(бераз тынлыктан соң)*

Нинди беркатлылар! Ничек җайлы килеп чыкты!
Әйдә, ач кашбауның ал бизәген.

А л с ы л у

Юк, юк. Ни сөйлисең?! Сеңлем! Бәгърем!

Ж а й д а к   к ы з

Курыксаң, бир, үзем ачам.

А л с ы л у

Рөхсәтем юк! *(Тайпыла).* Оял!

Ж а й д а к   к ы з

Ник алайса, Балтамарга вәгъдә бирдең?

А л с ы л у

Ник?.. Туп-туры дарга барыйммыни?

Ж а й д а к   к ы з

Ник алайса килдең? *(Кулына гөслә тоткан Баян бәк чыга).*

А л с ы л у

Ник?.. ник?.. Мин, Баян бәк, сезне үтерергә килдем.
*(Баян кычкырып көлгәч).* Чынлап, чынлап.

Ж а й д а к   к ы з

Игәч, игәч![1]

А л с ы л у

Менә кашбау, шуның бер бизәген ачсаң...

Б а я н

Алтын белән агу яраша ала. Ә моң белән агу —
һичкайчан да.
Әгәр былбыл чакса, барыбер елан дияр идек.
Җырлый белсә елан, мин ышанмас идем аның агуына.
Сезнең кулдан агу эчә алам — я, салыгыз.
*(Касә тотып, кыз каршына килә).*

А л с ы л у

Бәк, зинһар! Нишләдем мин, нишлим!

Ж а й д а к   к ы з

Шәраб хуш исеннән башың әйләнде, шул гына.

А л с ы л у

Алай түгел, мин бит үз һушымда!

Б а я н

Мин электән гашыйк сезнең җырыгызга.
Ялгышымны күрү миңа кызык булыр —
Я салыгыз агу, я җырлагыз. *(Гөслә уйный).* Көтәм,
Алсылу.

---

[1] Игәч — өлкән кыз туган, апа мәгънәсендә (борынгы төрки сүз). Автор

Алсылу

Сезнең хакка, бары сезнең хакка. *(Җырлый).*
Җирдән кеше аерылмасын берүк.
Җирдә гөлләр, илдә хак ирләр күп.
Безгә кушылып аваз сала җир-күк.
Безне бетерү мөмкин түгел бөтенләй үк,
Суда балык, җирдә халык, без күп, без күп.

*Җыр озак яңгырап тора һәм кинәт тына.*

## *Тыныч көннәр*

*Матур, тыныч көн. Тынычлыкка тояк тавышлары килеп керә. Көчәя һәм узып китә. Тансыкбикә Бакыр кыз каршында укынганда, ишегалдына ят кеше керә һәм утыргычка башын куеп җиргә утыра.*

Тансыкбикә

Син кем? Кем кирәк сиңа? Кара инде... әллә...
Су төбеннән исән чыктың мәллә?
Абау, үлгән кеше терелгән лә!

Җикү

Ертксыч түгел ич мин, нишләп очты котың?

Тансыкбикә

Нишләп курыкмыйм соң үлгән кешедән?

Җикү

Тереләрдән курык, алар яман.

Тансыкбикә

Анысы да хак, Баян бәк тә шуны әйтә.

Җикү *(торып утыра).*

Исән булса, хәбәр ит Баян бәккә.

Тансыкбикә

Хәзер... хәзер дисәм...

Баян *(бакчадан чыга).*

Җикү! Син! Утыр, утыр! *(Кочаклый).*
Ух, Җикү бәк, исән кайттың теге дөньядан!

Җикү

Качтым, тик ул куа килде *(Тыңлана).*

Баян

Барып чыкты гамәл — ышану да кыен.

Җикү

Синең балыкчылар җәтмә корган:
Ярдан очкан, җәен итеп тотканнар да судан,
Сулыш өреп терелткәннәр, яраларны бәйләгәннәр.
Атламасам өстерәлер хәлгә килгәч,
Килдем менә синең янга.

Баян *(көлеп).*

Минем башны кисәргә?

Жику

Рәхмәт, үзеңнекен иттең. Ләкин бармы сөенеч?
Тар-мар ителү мескенлеген кичерү өчен генә
Һушка килү, яшәү — шулмы шәп эш?
Чирүен җуйган гаскәр башлыгының хәле
Үлем әчесеннән җиңелрәкме?

Баян

Син ил өчен — үлгән кеше. Тик дошманнар өчен түгел.
Берсен генә юк итсәң дә үлемнән шул шәбрәк.
Әйе, без кыйралдык. Дүрт-биш дистә калган алыплар да
Әверелде юаш сарыкларга.
Хәзер менә Кирәмәт тавына, табигый төрмәгә сыеныштык.
Тик без беткән кодрәтне дә эшкә кушыйк.
Кирәмәткә ышанучы калган икән,
Ярдәм итсен безгә яңа гаскәр тупларга ул.

Жику

Ә сарыклар кабат әйләнерме алыпларга?

Баян

Дошман гына уйлый сарыклар дип.
Ә чынлыкта алар — юлбарыслар.
Корал гына табыйк. Һәм сизмәсен дошман.

Жику

Берсе килде минем эздән. Килеп җитсә,
Тилгән чебеш типкән төсле алып очар.
Сакчы-нәүгәрләрең чакыр, зинһар.

Баян

Нәүгәрләрне Кирәмәткә мин җибәрдем,
Әсир газыйларны тыныч җиргә озатып торыр өчен.
Шикләнмә тик, тутыкмаган әле үз кылычым.
Хәзер ял ит.

Жику

Аннан? Нишли ала, нишли ала җәрәхәтле гаскәр башы?
Өйдә, илдә куптарылган хәтта нигез ташы.
Инде терлек көтү бәхете кала, ахры.

Баян

Нишлик? Каладагы йортыбыздан, ач үлемнән куркып,
Тычкан-күсе хәтта бетте качып.
Тик исәнбез икән, яшик бераз вакыт.
Кирәмәттә әнә аргамаклар чаба...
*(Балтамар тавышы ишетелә).* Хәзер — өйгә.
*Җику кереп өлгерүгә, Балтамар күренә.*

Балтамар *(керә-керешли).*

Качкы! Җир йоткандай юкка чыкты! Шушы таба чапты!

Баян

Хәерле көн, Балтамар.

Балтамар

Аргы упкын ягыннан ук күрә килдем —
Җәрәхәтле аксак, шундый оста качты, угры, чапты.

Баян

Чапкач алай, тиз үк җитәр килеп.
Менә кымыз, хәл җыя тор.

Балтамар

Ерак китә алмас. *(Эчә).* Сыегызга рәхмәт.
Шулай тиеш тә ул, чөнки чук-чук изгелекләр
Эшләдем бит сезгә мин үзем дә.
Кесәгездә «Кагылгысыз» дигән кызыл мөһер.
Минем өлеш булды аны бирдерүдә.
Кунак ашы — кара-каршы. Сезнең яктан мәгәр
Һич сизелми рәтле караш, юк чакыру өйгә.
Бәк булмавым рәнҗетәме бусаганы?

Баян

Нишлим, хәлнең авыр чагы. Хәлдән килгән чакта...

Балтамар

Сезнең кулдан бик күп килә. Әйтик, Кирәмәттән
Ук-кылычлы чиру курка, ә сез — тыныч.
Көтү-көтү йөри малларыгыз.

Баян

Кирәмәтнең җәза урыны икәнлеген
Уйламый да йөри бирә терлек.

Балтамар

Ай-вай! Сокланам да сезгә ихлас.
Шундый олугъ зиһен! Кечүк дәүләттә дә шундый даныгыз чыгып,
Күккә күчми калалдыгыз җиңел генә.
Бу сарайга тими узды нинди сугыш!
Батый ханның үзенә үк барып баш ордыгыз.
Фетнә оештырып, җиңелгәч тә менә сау калдыгыз.
Бәхәссез бит, сезнең тормыш сокландыргыч.
Мин сокланам, әйе, һәм яратам.

Баян

Яратуың гәрчә бик үзеңчә.
Төлке сөя шулай кош-корт халкын.
Яратуга тузалмыйча, кошның канын эчә.
Син дә мине шулай өзелеп яратасың.
Әйт, Балтамар, дөрес бит бу?

Балтамар *(кәефе китеп)*

Дөрестер дә... Мәгәр онытмагыз,
Яманнарга мин үзем дә яман.

Баян

Менә шулай. Инде эшкә күчик.

Балтамар

Эш бер генә. Кая качты аксак качкы?
Өйгә качты. Ачыгыз ишегегезне. *(Өйгә кермәкче).*
Җиһангирга, Субудайга каршы баш күтәргән
Җинаятьче булыр, синең сыңар, кызыл итек кигән.

Баян

Кызыл итек талыйм дисәң, зур юлга чык.
Монда артыгы юк.

Балтамар

Бик бар. Качкы газый һәм... Алсылу — минем кәләш.
Килдем аны коткарырга әсирлектән. *(Ишекне ачмакчы).*

Баян

Нәрсә, ничек? Кем кәләше?

Балтамар

Җыручы кыз — Алсылу. Минем ярәшелгән кәләш.
Безгә, җиңүчеләр әһеленә, барча юллар ачык.—
Безнең өчен бикле йозаклар юк. *(Ишекне ачмакчы).*

Баян *(кылыч алып).*

Җиңү дәрәҗәсе — хыянәтчегә харам.

*Сугыша башлыйлар. Сугышның кызган мәлендә Алсылу йөгереп керә.*

Алсылу

Бу нинди эш?! Нишләвегез?! Акылга килегез!

Баян

Алсылу! Аһ, Алсылу! *(Алсылуга караган арада, Балтамар чәнчеп өлгерә).* Алсылу! *(Кулбашын тотып, җиргә утыра).*

Алсылу

Балтамар! Нинди вөҗдан белән!

Тансыкбикә *(йөгереп чыга).*

Ерткыч! Кемгә кул күтәрдең?! Балам, нишләттеләр?!

Балтамар

Бәк оялмый алдап тора, сине юк дип.
Алсылу, мин сине коткарырга килдем.

Алсылу

Коткарырга? Кемнән? *(Баянга борылып).* Тансыкбика апа, зинһар,
Тизрәк бәйләр әйбер чыгар. *(Тансыкбикә китә).*

*Баян*

Хәзер үзем, үзем. *(Китә).*

Балтамар

Киттек, Алсылу, тизрәк.

Алсылу

Кая? Мин киталмыйм.

Балтамар

Нишләп?

Алсылу

Соңыннан аңлатырмын.

Балтамар

Минем хәзер төшенәсем килә. Нәрсә тота, нинди сәбәп?

Алсылу

Сәбәп. Әйе, сәбәп! Мин дә теләр идем төшенергә бер нәрсәне.
Әйт, Балтамар, ник бу кадәр каныктың син Баян Бәккә?

Балтамар

Олугъ ватан мәнфәгате, тыныч тормыш хакына.
Әй, сөйләшеп торыр чакмы, киттек!

Алсылу

Үтенеп сорыйм: калдыр аны, калдыр мине тынычлыкта.
Әгәр чынлап сөйсәң.

Балтамар

Ничек дидең? Кабатла әле, монда нинди йомыш белән
килгән идең?

Алсылу

Зинһар — бик аз калган халкыбыз хакына, илне терелтү хакына.
Килешегез, зинһар! Онытгыңмы әллә, син дә бит шул Болгар
улы!
Зинһар!

Балтамар

Сине Кирәмәттә сарыкларга җырлап йөри дигән хәбәр алдык.
Шул рас булып чыга түгелме соң?

Алсылу

Нәсел-ыру исәнлеге хакына, килешегез, зинһар!

Балтамар

Кара, нинди иман! *(Баян бәк күренгәч)*
Ярый, бу чибәрнең бер чәче дә югалмасын. *(Бәкнең аякларына
карый).* Ә Болгарның соңгы итекләре белән масаймагыз —
Алар тузып бара... Хуш, Алсылу, аң бул, кара! *(Китә).*

Тансыкбикә

Үзегез җибәргән баш хәленә кереп ыржаегыз. *(Баш сөяген
Балтамарга ыргытып калмакчы).*

Баян *(баш сөяген Бакыр кыз янына күтәреп куя).*

Ялгышма, апа, яман аяк асларында ауный торган түгел болар.
*Өйдән Җикү чыга. Кулында җыюлы чыбыркы, өстендә — тузган
бишмәт, башында — иске киез эшләпә. Аякларында — кызыл итекләр.*

Җикү

Я, нендирәк гаскәр башы?

Баян

Менә дигән. Тик бу итекләрне салыгыз.
Тансыкбикә апа, кара итек чыгарыгыз. *(Тансыкбикә китә).*
Инде килеп, безнең бурыч... *(Җикү ым белән Алсылу алдында сер
әйтергә ярыймы дигәнне аңлаткач).* Безнең бурыч —
Субудайның кайдалыгын, чирүенең күпмелеген белү.

Алсылу

Бу бурычны үз өстемә алам.

Җикү *(Алсылуга карап).*

Мондый күзләр... алдый белмәскә тиеш.

Т а н с ы к б и к ә *(итекләр чыгара).*

Менә, ярый микән?

Җ и к ү *(итекләрне кия)*

Булды. Әйбәт. Хәзер — сау торыгыз. *(Баян белән кочаклашалар)* Хуш, Тансыкбикә апа, хуш, Алсылу. *(Баш иеп, чыгып китә. Баян бәк озата бара).*

А л с ы л у *(бакыр кыз янына килеп)*

Син — алиһә түгел, бары тик сын.
Ташка уелырлык ләкин безнең аһлар.
Син ишетеп, күреп тордың барсын.
Хәлебезне әгәр сорасалар,
Янына кире кайталмасак әгәр,
Теләк-уебызны җиткер килер заманнарга. *(Баян кергәч).*
Сер әйтмәкче идем мин аңарга.
Үзем ләкин бер нәрсәдән куркам:
Бакыр иреннәрен тибрәтер көч ул табармы?
Сөйли алырмы ул көчле, бакыр тавыш белән
Безнең кан авазын, яшьле аһ-зарларны?

Б а я н

Тыңлый белсәң, әйе, сөйли таш та.
Мин ышанам, бакыр бу иреннәр
Хәбәр әйтми калмас безнең хакта.
Көрәшчеләр туса безнең заттан.

А л с ы л у

Көрәшчеләр туса? Соңгы серем — шулдыр... Аны
Син белергә тиеш иң беренче булып.

Б а я н

Төшенеп җитмим бугай.

А л с ы л у

Бакыр аваз белән бергә, киләчәккә
Барып җитәр төсле безнең кан тибеше.
Минем ялваруны ахры күк ишетте:
Җиргә синең дәвамыңны бирер төсле.

Б а я н

Син чынлапмы, Алсылу?!

А л с ы л у

Син төшендең. Инде сүзеңне әйт.

Б а я н *(Алсылуны кочаклый).*

Сизенүең раска чыкса, йөрәгем, кулым
Һәм — гомерем сиңа бүләк.

А л с ы л у

Рәхмәт, бәк. Бу сүздән соң ут эченә керә алам.

Б а я н

Әмма сак бул. Шикләнүче барын сизсәң,
Шундук кире кайт. *(Чәчләреннән сыйпый).*

Т а н с ы к б и к ә *(өйдән чыга)*

Кашбау... Кашбавыңны оңытасың, бала.

Бизәнмәң дә кала.

А л с ы л у

Калсын, апа. Юлда, барып җитсәм, ак сарайда
Дошман мыжгып тора, талаучылар.

Т а н с ы к б и к ә

Монда аларны кемдер күрсә әгәр... Никахсызлар
Бергә яшәгән дип, таратмасмы яман хәбәр?

Б а я н

Калсын, апа. Янгач һәм тапталгач бәрча канун,
Синең Кирәмәт тә, шәригать тә җуйды көчен.
Ә Алсылу урап кайткач, без барыбер тиз үк
Укытырбыз никах. Шулай бит, Алсылу?

А л с ы л у

Иң зур канун — синең вәгъдә сүзең.
Хушыгыз, исән торыгыз. *(Алсылу белән Баян китәләр).*

Т а н с ы к б и к ә *(бакыр кыз янына килеп тезләнә)*

Дөньялыкта барча котны җыйган кодрәт,
Безнең кавемнәрне исән калдыр, биреп куәт.
Ай-кояш юк, төнне шәмдәй яктыртып тор,
Адашмасын адәмнәрең, чыкса сәфәр.
Сарык булып мәэлдәшкән алыпларны
Тиз арада бәндә сыйфатына кайтар.
Синең сипкән ак нурыңнан барча бәндә
Бер-берсенең йөзендәге матурлыкны
Күрә алсын — миһербанга дәш халыкны.
Барча кавем туган торсын, тату булсын. Амин.

## *Аңлашу*

*Алда — хәрабәләр иле. Якында — җимерек дивар. Рәшәткәләр артында кемнәрнеңдер атлаганы, егылганы, ыңгырашуы, тиргәшүе күренеп, ишетелеп тора. Уң якта, куактан-куакка посып, Балтамар йөренә. Алсылу күренгәч, яшеренә.*

А л с ы л у

Корбаннар! Кан коярга теләмәгән өчен
Ач үлемгә китеп бара изге җаннар! *(Бераздан җыр башлый).*
Алтын гына иде кашбавым,
Кашбавымны суга ташладым.
Кагылмасын дидем ят куллар,
Юсын аны дидем ак сулар.
Кашбавым, кашбавым,
Кашбавымны суга ташладым.

Кашбавымны суга ташладым,
Инде сине көтә башладым.
Дулкыннардан аны аралап,
Башкаема кидер лә кабат.
Кашбавым, кашбавым,
Кашбавымны суга ташладым.

Кашбавымны суга ташладым,
Ал аралап Итил ташларын.
Су төбендә минем серемдер,
Серләремне аңлап сөендер.
Кашбавым, кашбавым...

*Куак артыннан Балтамар калкып чыга.*

Балтамар

Адашкан мал! Ник курыктың, гаебең бик зургамы?

Алсылу

Курыкмыйча... Шундый кинәт.

Балтамар

Шулай тиз үк карачкыга әйләндемме мин — Балтамар?

Алсылу

Балын сизмим, агуы бар... Юк, юк, ни сөйлим мин!

Балтамар

Дөресен әйт, я кабатла!

Алсылу *(үз-үзенә)*

Аһ, ашыгам, ашыгам шул. Мин бит хәзер, бар нәфрәтне җиңеп,
Елмаерга тиеш. *(Елмаерга тырыша).* Ай, җитсә көч!

Балтамар

Тәңре безне дуслык өчен бар иткән дип йөрдем.
Син — алиһә, мин — күләгәң идем.
Өмет итә идек никах, бәхет,
Ак сарайга барасы идек җитәкләшеп.—
Күләгәне аердылар сыннан.
Дуслыкны син алмаштырдың хурлык белән,
Туганлашып коллык белән.

*Койма артында кемнедер кыйныйлар. Тиргәү, ыңгырашу. «Атла тизрәк, атла! Имгәк! Су төбенә атыласы үләт!»*

Алсылу

Аһ, мөнә ник кыйналгандай сызлаган җан!
Менә нигә беткән икән көчем!

Балтамар

Син җырладың бая алар өчен. Җырың яшерен хәбәр иде.

Алсылу

Җырудан сез куркасыз һаман — эшегез харап...

Балтамар

Бәккә барып кунак булгач, ачылдымы күзләр?
Ачылдымы, сарык-сыер арасында җырлап йөргәч?
Кашбау диеп җырладың син бая.
Чынлап җуйдың мәллә, куйдың кая?

Алсылу

Суга карап торган чакта, төште баштан...
Үрелеп алалмадым.

Балтамар

Күр, ничек ул алдый белә! Ә күзләре сөйли чынны!
Әйт ялгансыз, кайда кашбау?
Кайда язма җыру, кайда китап-дәптәр?
Акыллы баш нишләп фаш ителми калды сап-сау?

Алсылу

Кеше зиһенен, миен урлап булмый икән, шуны белдем.

Балтамар

Урлап кына түгел, эчеп, чөмереп була!

Алсылу

Ә моннан соң шәраб булмас адәм мие,
Чынаяк та булмас баш сөяге.

Балтамар

Кашбау юклык җиңел аңлашыла:
Карурманны бергә кичәсе яр,
Бәхет киңлегендә бергә очасы пар
Ярәшкәндә биргән вәгъдә сүзен
Җилгә, суга аткан. Ә мин ахмак
Изге бурыч йөкләгәнмен зиначыга!
Әйт җәһәтрәк, алтын хакын, иман хакын
Нәрсә белән түләмәкче булдың?
Бәрабәргә шулмы — агуларга китеп,
Фетнә чире белән үзең агуланып кайттың?

Алсылу

Син явыз дип тасвир иткән кеше
Изге булып чыккач, ничек үзгәрмисең?
Уф! Ни сөйлим! Ай, нәфрәтем нишләп
Тыелгысыз икән шушы хәтле!

Балтамар

Җитте! Болай булгач, кашбауны мин җәдәчеңдәй каерып алам
Әш үтәми хак алмыйлар, кайтар кире — кайда кашбау?

Алсылу

Кирәмәттән син аттырган ил уллары белән
Бергә ята упкын төбендә.

Балтамар

Сөрмәле шат караш, елмайган каш, якты тавышың назын
Өч мәртәбә син өч иргә сатсаң хәтта,
Каплый алмас иде алтын кашбау хакын.
Баян бәккә бер тиенсез калдыргансың.
Кашбау белән бергә, син без төзегән
Бөек дәүләт мәнфәгатен ташлап качтың.

Алсылу

Бөек дәүләт төзи алмый сездәй вак адәмнәр.

Балтамар

Сез терелтмәк булган иске ил кавеме
Инде — хыянәтче, әнә Кирәмәткә бара.

Алсылу

Хыянәтче була алмый бөтен халык.
Бөтен халык баш күтәрсә, ул ирекккә лаек.

Балтамар

Син, фахиш җан, пычрак телең белән мине алдап,
Үлгән илгә, үләсе иргә бирдең җаның, малың, даның.
Хезмәтеңә лаек менә шушы гына. *(Суга.)* Сөйралчек!

Алсылу

Мескен хәшәрәт!

Балтамар

Тап, тиз тап кашбауны, я бир җанынны.
Соң кат әйтәм, сайла: яшәүме, үлемме?
Бәкме, минме?

Алсылу

Син! Сине алып китәчәкмен гүргә!

Балтамар

Зиначы эт! Зиндан көтә сине. Кайда кашбау?

Алсылу

Упкын төбендә табарсың.

Балтамар

Син үлемгә мине озатмакчы! Ә ул башта
Сиңа тиеш. *(Кыйный.)* Менә шушы — кашбау хакы.
Кызгандыңмы, агу кызгандыңмы фетнәчедән?
Мин кызганмыйм. *(Алсылуны типкәли, буа. Кыз хәрәкәтсез калгач, утыра да кулларын уа, сөртә, үләнгә ышкый, битләрен-күзләрен сыпыра һәм, утырган хәлдә, бәргәләнергә, үз-үзен кыйнарга керешә).* Шул кирәк сиңа, шул
кирәк миңа!.. Инде безгә
Әйбәт булыр иде уртак зиндан икебезгә.
Без шуңа да лаек түгел инде. Әйе, бу ни? Мин нишләдем?
*(Алсылуны селкетә).* Тор, сөеклем, тор, исән кал!
Тиз сулыш ал! Мин бит сине сөям! Елмаеп көлсәнә! Алсылуым,
бахырым, уян, уян! *(Якынлашкан Җайдак кызны күреп,
тын кала да, аннары торып йөгерә).*
Караул! Караул! Кеше үтерделәр! Кеше! Үтерделәр! Караул!
*(Койма артына чыгып кача).*

Җайдак кыз

Бу ни? Игәч, нишләдең?! *(Алсылуга ташлана, кочып, сыйпап, күтәреп карый да кычкырып җибәрә).* Үтергәннәр! Үтергәннәр!
Балтамар! Шул, шул үтерде!
Менә кем икән ул! Менә кемнең күпме
Хәбәрләрен ташыганмын уйнап-көлеп!
Көлке ничек төште үзебезнең башка!
Син үзең дә, игәч, ник ашыктың аждаһалар арасына?!
Миңа кушсаң йомышыңны, үтәр идем җиңел.
Ә син терел, үтенәм, терел!
*(Алсылуны тагын күтәреп карый да өметсезләнеп, торып баса. Иңендәге яшел япманы Алсылу өстенә яба).*
Ярый, игәч, ял ит. Мин хәзер үк кемне тапсам, шуны алып
киләм.
*(Китә).*
*Тиз арада Балтамар белән Изух керә.*

Балтамар

Менә ята — ак сарайның булачак шат сандугачы.
Каерганнар канатларын фетнә калдыклары.

Изух *(япманы ачып)*

Шулай, бик тәәсеф. Ил ишетмәс бүтән аның гүзәл моңын.
Галәм хөкемдары — Батый игътибарын
Җәлеп итү, шәфкать көтү кыенлашты имди.
Җиңүчеләр арасында шул аваз артыннан кермәк идек.
Нишләрбездер, әйтү кыен инде.

Балтамар

Бүтән җай эзләрбез, хөкемдар.

Изух

Нинди хезмәт илә?

Балтамар

Яудан качкан күпме газый башын суга аттык —
Шул түгелме хезмәт?

Изух

Күпме тырышсак та, юк хәзергә хөрмәт, безне белмиләр үк.

Балтамар

Белгертә белергә кирәк.

Изух

Нинди сәләт илә?

Балтамар

Хөкемдарым, сез әйтмәгән бер сәләтем бардыр тагын:
Ул зур сәләт — сезне яратуым, тугрылыгым.
Шул сәләтем мине кеше итте, саклый тәндә җаным.
Ташламасаң, ак сарайда табылыр безгә урын.
Ташламасаң, мин теремен, чәч белән җир себерермен.
Кайтарырмын әҗерен моның — ташлама ла, хөкемдарым!

Изух

Җитте, булды. Вәгъдә бирү читен, ничек булып чыгар.

Балтамар

Хөкемдарым, коткар!

Изух

Тегe якта күпме адәм — сизмәделәр димсең?
Кызның ярдәм сорап кычкырганын хәтта мин ишеттем.
Бер гаепсез бәндәләргә чыгарганда ачы хөкем,
Каушый яздым — җир селкеттең.

Балтамар

Колакларга кереп калган ул авазны
Кешеләре белән бергә упкын йотар.
Синең алда тырнак кере хәтле гөнаһым юк —
Хөкемдарым, коткар.
Кирәк булыр үзеңә минем газиз башым —
Кистермә лә, хөкемдарым, коткар!

Изух

Пычрак уйлар тулы башың Әтил упкынында
Тыныч яткан халаеккa бик түгелдер хаҗәт.
Кем кулыннан киткән җырчы гаурәт.
Шуны тапсаң, бәлки булыр уйлап.

Балтамар *(башын җиргә тери)*

Табам, хөкемдарым, табам. Сиңа олугъ рәхмәт.
Ерткыч җанвар үз корбанын эзли кабат.
Валлаһи дим, кабат күрер өчен ул киләчәк.
Килеп синең гадел хөкемеңә эләгәчәк.

Изух

Җитте, булды. Кемдер килә. *(Тиз генә китә).*

Балтамар

Ерткыч үз корбанын эзләп килә. *(Куак арасына кереп, киемнәрен рәтли, бит-күзләрен сөртә дә, кылычын барлап, үрәката).*

*Мәйданга сакаллы-мыеклы көтүче кыяфәтендә Җикү һәм Җайдак кыз керә.*

Җайдак кыз.

Әшегездән аерганга рәнҗемәгез,
Табалмадым кеше сездән башка.
Үзем генә нишли алыйм? Менә бит ул —
Кайчан гына елмайган һәм көлгән кеше ничек ята!

Җикү *(Алсылу өстендәге япманы ача).*

Җинаятьләр тантанасы дәвам итә.

Җайдак кыз *(Балтамарны күреп)*

Әнә ул, явыз! *(Балтамарга!)* Син! Үзем күрдем!

Балтамар *(гаҗәпләнеп)*

Синме соң бу ил чибәре?
Синме соң бу — Тәңре сүзен илгә җиткерүче илче?
Әллә сине дәме алмаштырып җибәрделәр?
Әллә азрак тоелдымы эшнең әҗере?
Рәнҗеткәнем булмады ла моңа чаклы?
Бәя артыр, бар, курыкма, тарат хәбәр:
Тәңре зарыгып көтә иң гыйззәтле затны.

Җайдак кыз

Кара, нинди изге адәм! Инде ышандырам димә.
Үзем күрдем! Колакларың һәм танавың озынлыгын
Электән үк сизсәм,
Кулың озынлыгын хәзер күрдем. Күреп торам:
Авыз-борының — кып-кызыл кан.

Балтамар

Син дәмени хыянәт иттең? Бу — җинаять!

Җайдак кыз

Җинаятьче — ул син! Тотачаксың җавап.
«Тәңре күккә явыз, пычрак бәндәгезне
Чакыра!» — дип таратырмын игълан.
Сине, сине сагына икән упкын төбе.

Балтамар

Әле без кылабыз гадел хөкемебезне.

Җикү

Вакыт бетте — киттек, тизрәк.

*Җикү Алсылу өстендәге япманы җайдак кызга бөркәндерә дә үзе Алсылуны күтәрә. Алар күпмедер ераклашкач та Балтамар ачы тавыш белән кычкырып җибәрә.*

Балтамар

Ай, таныдым, таныдым! Таный алдым көтүчене — ул бит Җикү!
Әй, сакчылар, тотыгыз, тот!

Әй, үшәннәр, булдыксызлар, тизрәк! Нинди явыз ычкынды ла! Ай!
Юкка чыкты, җир упкандай. *(Изух күренә).*
Кайсы таба киткәнен дә күрми калдым, ычкындырдык.
Кемне диген — Җикү бәкнең үзен!

Изух

Җикү бәкне? Кирәмәттән үзебез аткан Җикүнеме?
Ул — икеме?

Балтамар

Үзе киткәч кенә аңыма җитте — Җикү, Җикү бәкнең үзе!

Изух

Я, улама, аңсыз. Җикү бәкнең Кирәмәттән очканлыгын
Синдәй ишәк кенә оныта алыр, я тумаган бала.

Балтамар

Ишәк һәм мин... *(Җиргә ятып ауный).* Ай бу ботак тишекләрен! *(Күзләренә суккалый)*
Үзе капкан бүрене таныма син!

Изух

Котырган! Сүзләреңне ишетү оят.

Балтамар

Оят, үземә дә оят!

Изух

Синең белән йөреп, үзем тотылырмын сымак.

Балтамар

Тотылучылар бүтән, бүтән, галиҗәнаб!

**Икенче бүлек**

## *Дәүләт исеме белән*

*Юл ягыннан төркем-төркем кешеләр узганы күренә. Кемдер егыла, ыңгыраша, кемдер кыйный: «Я, тор, ятма сыер сымак. Ара якын, тиз арада рәхәткә чыгасың, сикерәсең җәһәннәмгә! Атла, атла».*

*Шул тавышларга колак салып, Изух белән Балтамар Баянбәк ишегалдына керәләр. Беркем дә күренмәгәч, ишек кагалар.*

Балтамар

Ачыгыз, тиз! Кем бар анда? *(Ишеккә кылыч сабы белән суга)*
Җимерәбез яки ут төртәбез. *(Ишеккә типкәли.).* Ачыгыз яхшы чакта.
*(Изухка).* Әгәр ычкындырсак, бу булачак бөек хата.

Изух *(тамак кыра)*

Сорыйм әле, җан иясе юкта: тик бер язык эшне
Тап дип кушсаң, син табасың өчне.
Җинаятьче бик аз — берәү генә. Син төштә дә
Күрәсеңдер Баян бәкне. Әйт, шушы сүз хакмы?

Балтамар *(уңайсызлана)*

Хак сүз бугай... Әйе, әйткәч әйтим:

Ул — муенга минем уралган еландай.
Икенчеләй, эргәсендә бөрешәм, кечерәям.
Ат янында гүя бөҗәк булып калам.
Тырышамын, күрәшәмен кеше булыр өчен.
Шул дәрт аша җәфаланам көн-төн. Кирәк исә
Башымны кис, шушыны язык дисәң. Әйттем чын дөресен.

Изух

Я, я, артык мескенәймә, мин тик болай, кызыксынып кына.

Балтамар

Монысын каптырырга ярдәм итсәң, башкаларын
Тилгән чеби типкән төсле җыячакмын.
Иң әүвәле — Җикү бәкне.

Изух

Үлгәнне дә терелтепме?

Балтамар

Аны мин терелттем инде, җәһәннәмгә кабат
Әйбәтләбрәк озатырга. Бик нык беләм:
Өчесе дә качып ята шушы өйдә. *(Ишек кага).* Әй, ачыгыз!
Олуг дәүләт исеменнән, канун сүзе белән!

Тансыкбикә *(бакча ягыннан чыга)*

Кемнәр анда кычкырына, кояш-көннән оялмыйча?

Балтамар

Бәгең өйгә поскан; ут төртәбез, чыкмый торса.
Бар, кереп әйт, мәче төсле яна юкса.

Тансыкбикә

Өйдә юкка ничек әйтим?

Балтамар

Җир астында булса да тап, йортны кызган.

Тансыкбикә

Бакыр балам, гарип балам, сакла, коткар. (Китә.)

Балтамар

Гөнаһларын алдан белеп, качкан болар.

Изух

Нинди гөнаһ? Минем кулда юк бит әле хәтта
Шикаять тә.

Балтамар

Хөкемдарым, күңелем — изгелектә.
Тырышамын сезне яратуым хөрмәтенә.

Изух

Сөю, нәфрәт... Хаким өчен андый тойгылар ят.

Балтамар

Дөрес, дөрес, мин шикаять бирәм рәсми төстә.
Әйе, кичә иртән мин бакчага керсәм, Алсылу шат
Җыру җырлый. Мине күргәч, сүзен-җырын онытып,

Күкрәгемә ташланды ул, гүя сабый.
Гыйшык фигыльләрен санап тормыйм, мәгънәсе бер — никах.
Мәгәр аңа Баян бәк тә борын сузган икән.
Куак ышыгында аңдып яткан. Бәхет-сәгадәтне бүлеп,
Чыкты килеп, һәм кубарды гауга.

И з у х

Талаучыга вә дә ялачыга — тигез җәза, алдамаска тырыш.

Б а л т а м а р

Хәбәрем — хак, раслый алам. *(Үзе генә килгән Тансыкбикәне күреп)*
Кара, болар нинди байлар — асравы да кигән кызыл итек!

Т а н с ы к б и к ә

Таламакчы буласыңмы?

Б а л т а м а р

Сорауларны без бирәбез. Шулай бит, хөкемдар?

И з у х

Шулай улсын. Әйе, мәгълүм улсын — хөкем каршысында
Ялган сөйләү канун илә тыела. Аңладыкмы шуны?

Т а н с ы к б и к ә

Сүзем дөрес — итек сезнеке түгел.

И з у х

Анысын әйтмим, шулдыр минем сөаль:
Яшәдеме сездә Алсылу атлы гәүрәт?

Т а н с ы к б и к ә

Минә инде... Никах укытырга кеше тапмадылар.

Б а л т а м а р

Никах укытмыйча бергә тордылармы?
Булдымыни качыш-посыш, уйнаш-кочыш?

Т а н с ы к б и к ә

Абау, шакшы тел.

Б а л т а м а р

Алсылу бик затлы бизәнмәләр таккан идеме?

Т а н с ы к б и к ә

Такса, синекен такмагандыр.

Б а л т а м а р

Ә башында бар идеме алтын кашбау?

Т а н с ы к б и к ә

Бөтенесе — үз байлыгы.

Б а л т а м а р

Кичә бирсе дә юк иде, күрдегез бит?
Димәк, талаганнар.

Изух

Бизәнмәләре юк иде, әйе. Тәртип сагы хәбәр салды —
Талаучысы синең бәгең булып чыга.

Тансыкбикә *(Балтамарның кылычына ишарәләп)*

Шул кылычны йоталсагыз ышанырмын.

Балтамар

Талаганга ышанмасаң, ышанырсың үтергәнгә.

Тансыкбикә *(чигенеп)*

Абау, агулы тел. Котырдыңмы әллә?

Балтамар

Үтерүче — Баян бәк.

Тансыкбикә

Шакшы телең чәйнәп төкер, ышанырмын.
Нинди пычрак ыргыталар явыз җаннар!
Ник шуларны озатмыйлар Кирәмәткә?
Нишләп сарыкларга әйләнмиләр алар?

Балтамар

Бу мыскыллый безне — хөкем ияләрен. Хөкемдарым,
Олуг Урда намусын сакла усал рәнҗетүдән.

Изух

Тырышырбыз. Гаепләне табып китерегез.
Табылмаса бүтән көнгә хөкем күчә.

Балтамар

Хәзер, хөкемдар, сабыр. *(Ишекне каерып, эчкә кереп китә).*

Тансыкбикә

Җимерүче! Талаучы! Безне хөкем итмәкче!
*Бакча ягыннан Баян чыга.*

Баян

Бу нинди эш, нинди гауга? Көпә-көндез талау?

Изух

Талау түгел, тигү. Бөек дәүләт намә берлән.

Баян

Кая сезгә дәүләт! Пәри арбасыдай, ышык тапмый,
Бәреләсез, сугыласыз, теләсә кай төшкә.
Үзегез теләп тотындыгыз вәхшилеккә,
Калыкмакчы булып төптән өскә.
Илбасарның ыргытачак сөяген көтеп,
Иснәнәсез, үзегез ялаячак табаннарны күреп төштә.
Туган халык канын эчеп хәл җыясыз,
Ә хурлыгы — безнең өскә, оят — безгә.

Изух

Әүвәл кечүк ил тапшырган хөкем эшен
Минем өстән алдык дигән һич булмады игълан.
Шулай улдыгыннан, ходай вә ил кушкан
Гамәлләрне намус берлән кылам.

Балтамар *(кочак тулы әйберләр күтәреп чыга)*

Әй, бәк, бик вакытлы — җинаять өстендә капты кулга.
Менә, хөкемдарым, карыйк җисми дәлилләрне.
Менә мәктүб: «Кояш тирәсендә Җир әйләнә»— дигән.
Менә җыру: «Без — күп», «Таш пулат» һәм «Яу чабыгыз»—
дигән.
*(Баянга)* Кара, сезнең кулмы язган?

Баян

Синеке түгел, куй урынына.

Балтамар

Илдә беркем әйтмәгәнне сез әйткәнсез,
Күкләр белән шушы хәтле таныш булгач,
Үзегез — күк әһле, урыныгыз — күктә.

Изух

Җиһан серләренә төшенергә базган
Иң югары акыл улыр, шуны исбат кылдык.
Акыл исә ходай гамәленә каршы,
Халаекның борынгыдан килгән горефе илә
Андый адәм җирдән өстен, күккә хаклы.

*Шул вакыт ишегалдына, кораллы сакчылар белән бергә, берничә авыл карты керә.*

Балтамар

Әйдүк, аксакаллар, килүегез вакытлы бик.
Нинди эшләр җимереп йөрү?

Беренче карт

Күктән аваз килгәч, Тәңре өне ишетелгәч,
Юлга чыктык. Сезнең мондалыкны белгәч,
Килдек менә киңәшкә без.
Илдә — афәт, үләт, кырылыш, суеш.
Боларның бер чиге булу тиеш.
Иң зиһенле, укымышлы затыбызны
Тыныч тормыш хакына бирү булыр дөрес.
Изгеләрне биреп, күкнең күңелен күрү —
Безнең бик борынгы йола. Бик күп дәвер
Шуны бозып, аллалардан күрдек җәбер.
Илсез, җирсез калдык, каргыш алдык. Хәзер
Төзәтү тиеш шул хатаны.

Балтамар

Бик тә хак сүз! Моңар чаклы тирә-юньне урап,
Өй борынча йөрдем кереп-сорап.
Иң акыллы кеше Баян бәк дип,
Барча халык калды аны зурлап.
Ә сез ни диярсез?

Беренче карт

Җирне көндез ни яктырта ? Шул — бер кояш.
Кемнән сорап бакма, җавап ике булмас.
Үзе галим, үзе катиб зур зиһенле.
Атап булмый аннан башка бер исемне.
Ул — Баян бәк.

Икенче карт

Баян бәктер — илнең соңгы күзе,
Соңгы күзебезне чокып без чыгарсак,
Кармаланып атлап, халык текә ярдан

Упкын төбенә егылачак.
Бер алла хак — көтми бездән корбан.
Әгәр көтсә, мәгез, алыгыз мине.

Өченче карт

Сынап бактык без күп әмәлләрне,
Тик берсе дә китермәде файда.
Кан эчендә ята ил һаман да.
Сынамакка калды соңгы чара:
Төнгә дучар итеп үзебезне,
Күккә биреп карыйк соңгы күзебезне.

Балтамар

Барча халык сөйли нәкъ безнеңчә!

Баян

Кычкырыгыз күккә һәм сорагыз,
Кирәкме аңа кыргый бу йолагыз?
Адәм үзе уйлап тапкан моны,
Адәм үзе — йолаларның колы.

Беренче карт

Тынычлык бит, тынычлык хакына!

Өченче карт

Актык өмет — соңгы күзне бирик!

Изух

Сезгә рәхмәт, аксакаллар. Алла, халык, йола кушуынча
Хәл кылабыз.

Баян *(кылыч күтәрә)*

Үзегезгә, үзегезгә кирәк хөкем!

Балтамар *(кылыч белән һөҗүм итә)*

Әй, җәмәгать, ни карыйсыз?!

*Баян белән Балтамар сугыша башлагач, сакчылар Баянга озын чылбыр ыргытып, тиз арада аны бәйләп куялар.*

Изух

Алла, Тәңре, халык, йола кушуынча, Баян бәкне
Этил тавындагы иң пакь, иң карт ак каенга
Асу юлы берлә, күккә үрләтергә!
Дога калдык хода наме берлә, Амин.

Балтамар һәм аксакаллар

Амин, амин, амин!

Изух

Алып китегез.

Тансыкбикә *(алып китүчеләргә каршы төшә)*

Ягылмагыз минем языксыз балама, кулыгыз корыр!

Балтамар *(Тансыкбикәне селтәп ата)*

Мәҗүс колы! Әнә, бакыр пәриеңә табын! *(Кешеләр төркеменә)*
Киттек! Изге юлга! Тыныч тормышка!

*Төркем бераз атлагач та, каршыда Алсылу белән Җайдак кыз күренә.*

Б а я н

Алсылу! Син исән!

А л с ы л у

Баян, бәгем!

Б а л т а м а р

Бу нинди төш? Нинди болганыш?
Зинһар, бер сүз әйт, хөкемдар!

Т а н с ы к б и к ә

Әйттем бит мин, бәк изге дип.

Б а л т а м а р

Алсылу, бел, соң кат күрсәтәмен шәфкать:
Ярәшелгән булуыбызны раслыйсыңмы?
Барча ялгышлардан өскә үрләп,
Кайтасыңмы миңа? Өздереп әйт. *(Ерактан быргы тавышлары ишетелә).*

А л с ы л у

Әшәке җан! Чирканыч Албасты! *(Балтамарның битенә төкерә).*

Б а л т а м а р

Бетте! Ил картлары, бәйләгез монысын да!
Тиештер бит зиначы гаурәтне таудан ату суга?
Тиештер бит?

К а р т л а р

Илгә афәт китерә шул да. Дөрес — ярдан.
Зиначыны — ярдан суга! Упкын-суга!

*Сакчылар чылбыр белән Алсылуны бәйләгән арада Җайдак кыз кылыч белән Балтамарга ташлана.*

Җ а й д а к к ы з

Сиңа тиеш иң беренче җәза, хыянәтче, үтерүче!

Б а л т а м а р

Тыегыз бу әнчек этне! *(Сакчылар кызны чолгап кылычын тартып алалар).* Бүләкләрне азсындыңмы? Ач теләнче! Көт аз гына, күккә хыянәт хакын тиз түләрсең! *(Быргы тавышлары көчәя).*

Җ а й д а к к ы з *(сакчылар һәм аксакаллар Баянны һәм Алсылуны алып китә башлагач, Баян алдына тезләнә).*

Иң зур хата — минеке, бәк. Күк сүзе дип,
Шушы этнең явызлыгын илгә чәчтем.
Иң беренче җәза тиеш миңа — үлем ялчысына!
Гафу ит, бәк! Кичер, игәч! Мин дә
Сезнең белән үләчәкмен! Бергә!
*«Ура» тавышлары һәм быргы чыңнары якын ук ишетелә.*

А к с а к а л л а р

Яу килә, яу! Тагын өлгермәдек күк күңелен күреп!
Сукты каһәр, төште башыбызга күк каргышы! *(Йөгерә-атлап тарала лар)*
*Быргы чыңнары астында Җику керә.*

Б а я н *(аның каршысына атлап)*

Җикү! Син! Шул кадәр вакытлы!

Җ и к ү

Син — исән! Өлгергәнбез икән! *(Баян иңендәге чылбырны алып аткач, кочаклашалар.)*

Т а н с ы к б и к ә

Бакыр кызга ялваруым кабул булды,
Ашыгу дәрте килде сезгә ул кушканнан.
Сарыклар — алып булдылар шул догадан.

Җ и к ү *(Баянга)*

Белеп тордык сезнең нинди каһәрләргә түзгәнлекне.
Шуңа күрә ашыктык та. Ләкин сәбәп
Анда гына түгел. Әләкчеләр эттәй йөренә торгач,
Сездә корал исен. Хәбәрләре ак сарайга җитеп,
Ташланачак иде дошман безнең өскә.
Соңгы тапкыр кырыласы идек.
Илбасарның бер алыбын да юк итмичә.
Көтелмәгән тизлек болай безнең якта,
Күпме булса дошман, димәк, кыйралачак.
Гәрчә безне җиңү көтми, көтә үлем,
Барча алып шуңа риза булып бара.
Нәфрәт итеп упкын төбен, күсе гомерен,
Алар чыкты яуга, ярсып юлбарыстай.

Б а я н *(Алсылуны чылбырдан аралап)*

Дөрес. Юлбарыстай үлү мөмкин чакта
Күсе булып яшәү — ирләр өчен оят.
Минем дә шул соңгы бәхетем — яуга, яуга.

Җ и к ү

Бер кузгалгач, тукталу юк. Тик ярагыз төзәлгәнне
Көтү хәерлерәк булмагае.

Б а я н

Барлык җәрәхәтләр тиздән көчен җуяр.

Җ и к ү *(Балтамар белән Изухка күзе төшеп)*

Болар монда нишләп тора, дуслар сыман?

И з у х

Мин — хөкемдар, казый, буйрук көтәм сездән.

Б а л т а м а р

Кечүк илдән бирле мин — әзтабар.
Мин — колыгыз, боерыгыз, кирәк булсам әгәр.

Б а я н

Хөкемдарга боерыйк: җинаятьле явызлыклар кылган өчен,
Ил авазын үтерә язып кыйнаган һәм буган өчен,
Этил-йортка хыянәт кылган өчен
Балтамарны хөкем итсен.

Җ а й д а к к ы з

Күктән хәбәр: ин-иң явыз затны китерергә Кирәмәткә!

Җ и к ү

Ил әмерен тыңла, хөкемдар:

Намус, вөҗдан һәм ватанга хыянәт иткән Балтамарга,
Җырыбызны, моңыбызны буган Балтамарга
Гадел хөкем чыгар.

Изух

Ходай наме, гаскәр башы олуг Җикү исеменнән,
Ирек алган батыр халаек исеменнән каттый хөкем:
Вөҗдан, намус һәм ватанга хыянәт кылган,
Ил авазын вәхшиләрчә буган,
Дәүләт кушкан изге эшне ерткычлыкка алмаштырган
Балтамарга бу ил — харам, башка илгә күчсен.
Балтамарны бу илдән сөрәбез, амин.

Җикү *(Баянга аптырабрак карый)*

Ә? Ничек?

Баян *(чак кына уйлангач)*

Ярый, без алардай ерткыч түгел. Амин.

Җикү

Амин.

Балтамар

Бу нинди эш, хөкемдарым? Ил сакчысын илдән кусаң,
Җыен дошман арасында үзеңә көн булмас.
Хөкемеңне үзгәрт, үзгәрт тизрәк!

Изух

Сине дә тыңлармын, әгәр җиңсәң.

Балтамар *(үпкәләп)*

Ярый, кугач китәм. Карагыз минсез яшәп.
Эзләрсез дә көндез шәм яндырып, мәгәр
Табалмассыз тырыш сакчы минем кадәр.
Иртәгә үк илнең башын дошманыгыз суяр,
Шуны яхшы белеп калыгыз. *(Китә.)*

Җикү *(баш иеп калган Изухка)*

Син дә юлыңда бул.

Изух *(нык гаҗәпләнеп)*

Минсез үк тә яшәп буламыни?

Җайдак кыз

Дүрт ягың — кыйбла.

Изух

Минсез калу — ул гаскәрнең ук-кылычсыз калуыдыр.
Коралсыз вә минсез, димәк, сез — гомерсез. *(Китә.)*

Җикү *(быргы тавышлары көчәйгән хәлдә)*

Хушыгыз, кардәшләр, бәхил булыгыз. Киттек луга, луга! *(Китә.)*

Баян

Хәзер мин дә куып җитәрмен.

Җайдак кыз

Хуш, игәчем. Һәлак булсам, гаепләрем кичер. *(Китә.)*

*Быргы тавышлары көчәеп ала да ерагаеп тына.*

А л с ы л у

Киттеләр. Шомлы, кара, буш дөньяда
Без тагын да ялгыз.

Б а я н

Бәлки әле очрашырбыз.

А л с ы л у

Син? Юк, син китмисең, мин җибәрмим сине беркая да.

Б а я н

Нишләп алай дисең?

А л с ы л у

Торсам, йөрсәм, тынны буа, ятсам, күкрәгемне әле дә изә
Шул албасты.

Б а я н *(Алсылуны кочаклап, утыргычка утырта)*

Ял ит, терел. Исән кайтсам, яныңнан да китмәм.

А л с ы л у

Соңга калдык, артык соңга калдык.

Б а я н

Аңлатыбрак син, Алсылу, бик куркытма.

А л с ы л у

Шул албасты, үтерә язып мине,
Карнымдагы баламны ук урлап качты.
Алып качты синең нәселең, дәвамыңны,
Өметемне талап китте, бөтен ышанычны.
Синсез булсам, куркам, калтырый ук башлыйм.

Б а я н

Албасты — Балтамар атлы. *(Алсылу алдында тезләнә)*
Ничек моңа ышанырга? Кире ал сүзеңне —
Минем балам исән булсын, чөнки бит син — исән.

А л с ы л у

Исән булсын дисәң, китмә. Син югында, өндә булмаса да, төштә
Шул албасты килеп җитә.
Ерткычлардан бигрәк адәм котырганда,
Мине ташлап киталмассың, юк, ышанмыйм.

Б а я н

Илнең соңгы талпынышы анда — кан эчендә...

А л с ы л у *(тезләнеп, Баянның аякларын кочаклый)*

Үлгәндә дә бергә булыйк, үтенәм, ялварам!

Б а я н *(бераз уйлангач, Алсылудан арынып)*

Мин үлемне көтә алмыйм. Дошман белән
Сугышып үлү — соңгы форсат.
Син аңлагач кичерерсең. Ә хәзер хуш, хуш, Алсылу! *(Китә)*

А л с ы л у *(һушын җуйган хәлдә)*

Соңгы өметем, мине бу дөньяда тотып тора алган
Мәхәббәтем, киттеңмени?
Аны да урлап качтымыни шул албасты? *(Елый.)*

Тансыкбикә *(бакчадан китмән тотып чыга)*
Киттеләрмени? Безнеке дәмени? Җәрәхәтле килеш?
Хушлашмый да?

Алсылу

Бик ашыкты, ачуланмыйк, гафу итик.

Тансыкбикә

Гафу итик, исән генә кайтсыннар тик.
Бакыр кызым, бәхет китер, бәкне яуда сакла.
Алсылуның чире бетсен туйга чаклы.
Хәзер кил, имләп алыйк.

Алсылу

Инде миңа имнән файда килмәс, апам.

Тансыкбикә

Җилгә очсын андый сүзең. Терелмичә, япь-яшь көйгә. *(Имли башлый)*
Кер, котым, кер, ишектән дә кер, тишектән дә кер.
Сыер булып мөгрәп кер,
Каз булып какылдап,
Үрдәк булып бакылдап. Тфү, тфү, тфү.
Чык, чирем, чык, ишектән дә чык, тишектән дә чык.
Чучка булып чинап чык,
Тавык булып кытаклап,
Аксак эттәй титаклап. Тфү, тфү, тфү. *(Кешеләр сөйләшкәне ишетелә)*
Әллә кемнәр йөри тагы. Баян улым түгел микән?
*(Кинәт кычкырып) ай, ай!*

Алсылу

Нәрсә булды, апа?

Тансыкбикә

Әнә бит теге албасты, килә!

Алсылу *(Балтамарны күреп)*

Албасты!

Балтамар *(тыныч)*

Курыкмагыз. Сөенечле булмаса да хәлләр,
Яман ният белән йөрмим.

Алсылу

Кирәк түгел синнән һичбер хәбәр.

Балтамар

Син, Алсылу, мине аңлап, кичерергә тырыш.
Кичерә алсаң, килер яңа, матур тормыш. Тырыш.

Алсылу

Йөрәгем, чыда!

Балтамар

Бик кызганыч... Әйе, язмыш шулай кушты:
Баян, Җикү... шәһитлеккә җаяү китте.

Алсылу

Ялган! Ялган!

Балтамар

Җикү алыпларын Субудай газыйлары
Уздылар да кисеп, таптап, турап...

Алсылу

Ни сөйли бу, тыңлап бакчы, апа.

Балтамар

Әйттем мин аларга баштук, гарасатка каршы төкермәгез диеп.
Менә күрдек, нәкъ минемчә — Җикү бәкне турадылар дүрткә.

Алсылу, Тансыкбикә

Ялган! Алар — исән!

Балтамар

Җикү кодрәте беткәч тә миңа булган хөкем юкка чыгып,
Хөкемдарның тәүге хөкеме көченә кайтты.
Ике сакчы Баян бәкне озаттылар Кирәмәткә, дарга.

Алсылу

Елан тел бер генә сүз белә: дар, дар.
Бүтән сүз эзләп бак, тап бүтәнне.

Балтамар

Кичер, ялган сөйли белмим — нәрсә беләм,
Нәрсә күрә күзем, шуны әйтә телем.
Сез дә күрегез менә: бәк булыр Балтамар —
Бу йорт миңа кала... Ә мин сезне кумам,
Башта сак булсагыз, соңра яратсагыз.

Тансыкбикә

Исән генә кайтсын хуҗа, кем бәк икәнлекне тиз күрсәтер.

Балтамар

Исән булса, хуҗа мин булмас идем. Ә ул хәзер
Үзе сөйгән Кирәмәттән дә биектә — күктә.

Алсылу *(хәлне аңлап)*

Ах, син! Син ирештең гомерең максатына!
Ә мин җүләр ышанмаска тырышам.
Соңладым, соңладым бит! *(Ашыгып чыгып китә).*

Балтамар

Ә син, Тансыкбикә, казан ас.

Тансыкбикә

Кара моны... ялчыга кол булып,
Явызлыкка хезмәт итимме әллә? *(Алсылу артыннан китә).*

Балтамар *(үзе дә иярә төшеп)*

Мине миһербансыз диеп ялгышмагыз!
Адашмагыз! Өйдән, уйдан язып,
Бүреләргә булмагыз сез азык.
Кайт, Алсылу! *(Җавап ишетелмәгәч, ишек төбенә килә)*
Күктән миңа түбән хөкем иңгән:
Затлыларга кызыгудан җанны җыерса да көзән,
Чыдап, көлеп ялчылык ит, дигән.
Рәнҗесәм дә табигатькә, аллаларга,
Бар җиһанны каргасам да хаклымындыр.
Табигать һәм алла мыскыл иткән адәм,

Мин сорыймын: нишләп миңа дөнья колдан гына азган
Тупас, ямьсез ата-ана биргән?
Төс белән һәм зиһен, гыйлем җәһәтеннән
Рәтле бәндәләрдән ник мине ким кылган?
Дүрт почмаклы чырай, казып чыгарылган имән төбе сыман
Юан, кыска гәүдәне мин әллә сорап алган?
Ник миңа да зифа сынлы, житез уйлы булып,
Уйнап-көлеп, ай-кояшны көнләштереп бәхет казанырга —
Ал сылу да гөл сылуны сокландырып, гүзәл моңнар яңгыратырга,
Сөелергә — кимсенүсез, ялынусыз, көчләүләрсез генә наз алырга
Насыйп итмәгән ник миңа гына?
Барча өстенлекне бер кешегә чумырып биргән,
Ирек биргән саф яшәргә һәм шәфкатьле булып.
Түбән затка тик бер чара — мәкер, хәйлә, әләк.
Узачаклар юкса көн эчендә таптап, изеп.
Шулай булгач, өлешемне әрсезләнеп —
Җәдәлләшеп алсам, юкмы хакым, бармы?
Табигатьтән, аллалардан һәм тормыштан хокукларны
Тартып, йолкып, талап алу түгелмени гадел мәҗбүрият?
Гаделлекне яклап чыккан адәм мин, ниһаять,
Миһербанлы, чын инсафлы кеше булып гомер сөрәчәкмен.
Илгә керсез җанлы уллар, кызлар бирәчәкмен!
Ниһаять! Ниһаять!

*Ишекне ача да өйгә мәгърурәнә кереп китә.*

## *Саубуллашу*

*Шул ук өй, бакча. Таң ата. Инде кошлар да сайраша. Арыган, талчыккан Алсылу күренә. Эскәмиягә төенчеген куеп, өстәлгә капланып бераз хәл алгач, өс-башын төзәтә. Бераздан ишек кага.*

Балтамар *(эчке яктан)*

Кем бар анда?

Алсылу

Мин бу — Алсылу.

Балтамар *(чыга)*

А язган мал, кайттыңмыни?! Башына тай типмәгән кеше
Шушы шәп сарайны нишләп тау-яланга алмаштырсын!
*(Алсылуның аркасыннан сыйпамакчы була).*

Алсылу *(тайпылып)*

Зинһар! *(Соңыннан йомшаграк итеп).* Зинһар, ашыктырмагыз.

Балтамар

Дөрес, ашыктырмыйм. Күнегерсең. Күнегербез.
Үлгәннәргә ияреп булмый, яшисе бар.

Алсылу

Шулай бугай... шулай.

Балтамар

Шулай, аңлыйсың бит — зиһенең исән икән.
Бергә яши төшкәч. Баян бәк онытыла төшкәч...

Алсылу *(эскәмиягә чүгә)*

Зинһар!

Балтамар

Бетте, бетте. Бүтән кабатламам. Шуны әйтәм:
Төзәлмәгән яра булмас. Төзәлмәсә, кысан булыр
Бу өй генә түгел, бөтен җиһан.
Кинәт кенә борылмассың, беләм, арабызда
Күпме ялгыш, канап торган җәрәхәтләр.
Тик шулай да сөю исән, баш сау икән,
Шөкер кылыйк, башны ташка ормыйк.

Алсылу

Җәрәхәтнең иң авыры — бугазымда һәм карнымда.
Бар тәнемә һәм җаныма агу тулды моң урнына.
Бөтен тәнем, җаным сызлый сулык-сулык.

Балтамар

Кеше чирләмичә тормас. Савыгырсың.

Алсылу

Тансыкбикә апа бәлки ярдәм итә алыр.
Чакырыйк аны.

Балтамар

Тансыкбикә? Кайда соң ул?

Алсылу *(куркып)*

Әллә аны дамы? Кайда апа?

Балтамар

Теге көнне чапкан иде синең арттан. Кирәмәткә.

Алсылу

Кирәмәткә? Әле улап, әле уйнап, туйлап йөри анда бүре өерләре.
Шулар арасында — улмы? Нәрсә калган дисең хәзер аннан?!

Балтамар

Кулы белән эшли торган кеше яшәү кадерен белә —
Күрәләтә барып кермәс бүре өеренә.
Тегермәне булса, ялманырга эт табыла. Кайтыр ул да.

Алсылу

Япа-ялгыз кешене кара буш дөньяда кемнәр яклар?
Ерткычлардан, яман адәмнәрдән кемнәр саклар?

Балтамар

Синең янда мин бар. Саклар шушы кирмән, дивар.
Ул — безнеке, әйе, ышан, бел дә:
Баш сарайдан кайттым кичә генә.
Фетнә бастыруда өлеш керткәннәргә
Байтак булды әҗер. Мин дә, хөкемдар да
Бәкләр хәзер — җирле була алдык,
Алдык менә ярлык! *(Кәгазь күрсәтә).*
Синең җыр да яңгырар галәмнәргә.
Чиксез булыр хәзер сый һәм кадер.

Алсылу

Йөрәгем, түз, чыда, бәгырь.

Балтамар

Инде тынычланыйк. Хәзер ризык булыр. Бәлки, шәраб?

Алсылу

Әйе, әйе, шәраб!

Балтамар

Көн яктыра, күрәсеңдер, кояш калка.
Күнегергә кирәк, таң-иртәгә, көн-кояшка. *(Өйгә кереп китә.)*

Алсылу *(бакыр кыз янына килә)*

Күңелемдә күпме булса моңнар,
Шул кадәрле тулды агу, зәһәр.
Йөрәк ышыгында балам, бәк дәвамы иде,
Каладагы манарадай, ил абруен гасырларга
Илтәсе җан туасы иде, ул юк инде.
Күңелемдә күк зәңгәре — бөек сөю иде,
Ул юк инде — кара зәһәр тулды.
Ә сез, халкыбызның коллык һәм ялчылык хисен көчәйтәсе,
Сату, сатылу осталыгын ишәйтәсе кавем,
Сезне үрчетергә мин дә керешимме бичә булып?
Ул чак изгелек — кол, патша булыр иде хурлык.
Һичкемем юк, уй-серемнең барчасын да
Тапшырырга калды сиңа — җансыз сынга.

Балтамар *(күтәренке күңел белән чыга)*

Менә безгә икмәк, менә шәраб. *(Шуларны өстәлгә куя).*
Озакламый булыр ит тә.
Икебезгә — олы сарай, дөнья. Иртәгәсен
Шуңа син булырсың хуҗабикә.
Моңарчы син усаллык дип йөргән
Барча катылыкны кылдым синең хакка.
Языкларым өчен бик гаепле булсам,
Шулай каты яраттырып мәҗбүр иткән өчен
Син җаваплы, сәбәпче — син. *(Тагын кереп китә).*

*Алсылу төенчеген чишеп кашбауны ала да, шуннан шәраб чүлмәгенә агу коя. Кашбауны киеп, чәч-битләрен төзәткәч, түгәрәк ипине күкрәгенә кыса.*

Алсылу

Үлгәннәрем — Баян бәгърем, Тансыкбикә апам, кардәш-ыруым,
Кичерегез.
Кичерегез, җырым, моңым, тавышым, туган-үскән җирем.

Балтамар *(чыгышлый үк)*

Күрәсеңме, бу ни? *(Чәркә рәвешендәге баш сөяген күреп, Алсылу куркып китә.)* Кыргыйлыктан бәк затына күчкән кешегә бу баш —
Бик гыйбрәтле, бик кадерле мирас.
Атам гомере буе, шуңар салып, шатлык-кайгыларны йотты.
Ата-бабаларга хыянәт була алмый, тик җитте көн.
Иске ыруг рәнҗемәсен,
Бу хушлашу. Сау бул, кара коллык!
Саумы, биттә тимгел калдырмаслык
Бәк нәселе, зәңгәр нәсел, олугъ муллык!

Алсылу

Уф! Зинһар! *(Бөрешә).*

Балтамар *(кашбауны күреп)*

Бә-әй! Кашбау! Алтын к... бау! Югалган бүләгем!
Табылган ич. Рәхмәт, син китәнсең парлы тормыш ямен!
Кашбау — безнең уртак бәхетебез — исән!
Кара, ничек ялтырый ул — кояшмыни! *(Шәраб салып бирә).*

Алсылу

Хәлсезлектән биһуш калырмын ук, моны эчсәм.
Бергә утыра алсын дисәң, эчим кымыз гына.

Балтамар

Бабасы кол булган бәндә өчен бу көн — олугъ сикереш.
Алда шәфкать-миһербанлы якты тормыш.
Шундый сикерешнең сөенечен бүлеш.
Бүлешүең булыр, әгәр җырлап бирсәң.

Алсылу

А, җыр шул инде — ерак хыял. Кичә
Бәк ишетсен диеп, җырлап баккан идем,
Чыкмый тавыш. Аны син үтердең.

Балтамар

Ярый, тавыш икмәк түгел, алтын түгел, яшәп булыр ансыз.
Син җырлап бир, болай, тавышсыз.

Алсылу

Тавышсыз җыр — ыңгырашу буладыр.
Ләкин мин җырлармын... бераз гына итик сабыр. *(Балтамар баш сөягенә шәраб койгач, куркып бөрешә)* Ай, йөрәгем, чыда!

Балтамар

Буш сөяктән куркып ничек яшәү мөмкин?
Ярый, бетсен. Әйе, сау бул, кара коллык.
Саумы, яңа затлы нәсел! Исән булыйк. *(Эчә һәм бераздан куллары бутап куя).* Иске шәрап икән. Нинди пычрак чөмергән бәк!

Алсылу *(бераз җанлана төшеп)*

Акыл өлешен хәйлә тартып алса,
Ачы була аңа бөтен нәрсә.

Балтамар *(тагын салып эчә).*

Баян, йолдызларны, ай-кояшны — күкне сөеп,
Җиргә ялгыш төшкән күк бәндәсе, кабат ашты күккә.
Ходай әмере булды безнең хөкем — гадел бик тә.
Тәңре шулай кушты, кушты канун, йола.

Алсылу *(сызланып)*

Баян бәк, сабыр ит, тиздән мин дә янына китәм.

Балтамар

Синнән, артык акыллы дип, шикләнүче юк.

Алсылу *(көйләбрәк)*

Өнсез җырым — соңгы сүзем шулдыр:
Ил, халык дип сөйли-сөйли, илбасарга
Ир башларын сата-сата, үтердегез халык җанын.
Бәрабәргә илне түгел, шушы өйне яуладыгыз.
Гомер буе шул бәягә табан яладыгыз.

Балтамар

Җыруыңа кушылып әйтим: билне бөгү — көч билгесе.
Горурлыкны җиңә белү бизи җир баласын.
Әнә бөгелә белмәгәннәр хәзер алар кайда?
Ә без олугъ илдә күтәрелдек өскә.

Алсылу

Җыен хәшәрәтне өскә алып чыккан
Дәүләт үзе чыгачактыр юкка.

Балтамар

Мул тормышта яши торгач, безнең дәвам булыр юлбарыстай.

Алсылу

Җирдә адәм рәтле кеше беткәч, җыен гарип-горабадан
Буйга узып көмән үстерүдән чиркана тән.

Балтамар *(кәефе кырылып)*

Тавышсыз җыр шундый гүзәл! Дәвамы нидер.

Алсылу

Бер сәгатьлек сәгадәтнең хакын түләү.

Балтамар

Анысы нәрсә?

Алсылу

Ниһаять, анысы — гомер.

Балтамар

Яңа тормыш, тыныч бәхет хакына нинди асыл затны —
Баян бәкне бирдек, җитмиме шул?

Алсылу

Өстә хәзер аңа үз гомереңне.

Балтамар

Уф, көләр идем аунап, хәлне алды тавышсыз җыр — яман шәраб.

Алсылу

Зирәк башлар җамына салып, яманын да эчалмассың кабат.

Балтамар

Алсылу дим, җитте, рәтләп сөйләш.

Алсылу

Ишеткәнсең: иң зәһәр бер затны сораган хәбәр
Ил буйлата йөрде. Мин үтәдем күкнең шул әмерен —
Шәраб белән бергә агу эчтең.

Балтамар *(торып баса)*

Нәрсә дидең? Я, кабатла, кара елан!

Алсылу

Хактыр, күңелемдә елан бардыр,
Елан җыры агу буладыр.
Ә җандагы кеше асылын үтердең син үзең.

Балтамар

Сөйрәлчек! Агу! Кайдан алдың агу? *(Кашбауга күзе төшеп)*
А, кашбау! Үзем бүләк иткән! Бәккә дигән!

Алсылу

Аңа харам иде, сиңа — хәләл.

Балтамар

Кемгә, кемгә алыштырды мине — үлгән кешегә!

Алсылу

Бик борчылма: синең сатлык гомерең белән чагыштырсаң,
Без күбрәкне җуйдык. Син эт җыймас җаның гына бирдең.
Шатлан, бие, я мукәйлә. Синең бәйрәм бүген, гәрчә соңгысы.

Балтамар

Ялгышасың, син барыбер минем белән булачаксың.
Бу дөньяда түгел исә, тегесендә.
Үзем белән алып китәм, бирмим ятка. *(Чүлмәккә, аннары чәркәгә үрелә, кизәнә дә өстәлгә ава.)* Барыбер алып китәм — кыяматкә! *Куллары белән кеше бугган рәвеш ясагач, тагын егыла.*

Алсылу

Языксыз башлар, күрегез, менә без җиңелдек.
Сез бар иткән китап һәм сарайлар, без көйләгән
Сурәтле моң, моңлы сурәтләр дә киләчәккә бармас,
Чөнки без җиңелдек, җиңелгәндәй әүвәл Тәңре һәм сез.
Әтил балалары, без үзебезне җиңдек үзебез...
Ә җиңелгән — телсез...

Балтамар

Үзем белән, барыбер үзем белән...

Алсылу

Пычрак аяк белән ак тормышка үрләмәкче!

Балтамар

Керәм, барыбер кереп җитәм. *(Тора, егыла).* Ярдәм! Ярдәм!

Алсылу

Илне дошман талап үтергәндә,
Син нишләптер акырмадың ярдәм сорап.
Син ирләрчә яшәмәдең, ә үлгәндә өйрәнергә инде соңрак.
Атла, атлый бир үзеңчә. Атла, я мукәйлә.

Балтамар

Атлыйм... үзз... өемә... үз... үз... *(Күтәрелә алмый).*

Алсылу

Юк, бирешмә — гомер буе күнегелгән
Ысул белән морадыңа әлгәшергә тырыш.
Туры гәүдә белән йөрү сиңа харам, шуыш!

Балтамар

Үз... үзз... өемә... *(Дуртаяклана).* Ак тормышка...

Алсылу

Менә шушылай, сиңа шулай кулай.

Балтамар *(утырып ялвара)*

Шушы хәтле явызлыкны... кайдан алдың?

Алсылу

Синнән!

Балтамар

Үз өемә... өй... үз... *(Шуыша).*

Алсылу *(Бакыр кыз янына килә).*

Сиңа ышанырга куша өметсезлек.
Кешелекне яклап безнең газап чиккәннәрне,
Нинди югалтулар белән гомер кичкәннәрне,
Сораучылар булса, аңлат сөйләп,
Илбасарга, сатлыкларга чишмә серне.
Соңгы гозерем шушы гына инде. *(Өстәлдәге ипине ала).*
Баян бәк ризыгы. Юлда саилчегә бирсәм, аның рухына
Дога кылыр. *(Балтамарга).* Ә ул сиңа харам.
*(Кашбавын Бакыр кызга кидерә дә, ипине төйнәп, шул төенчекне һәм чүлмәкне ала).* Агу катнашса да, бәк шәрабы миңа хәләл,
чөнки ышанычын акламасам да, карынымда булды токымы.
Аңлашырбыз кавышып кыяматтә.
*(Балтамарга)* Ә син мүкәйлә! Мүкәйлә! *(Чыгып китә).*

*Балтамар шуыша. Күпмедер вакыттан соң ишегалдына Җайдак кыз керә. Тәртипсез өстәлне һәм хәрәкәтсез Балтамарны күреп гаҗәпләнә.*

Җайдак кыз

Ялга туктадыңмы, шакшы? Кешелеген җуеп бетермәгән
Кешеләр беттемени, сатар адәм калмадымы?
Пычрак тормышыңда шуышып йөри торгач,
Асыл бусагага инде куйгансың баш.
Шушы җиңүгә дә ышанып бетмәгәнсең, бәлки,
Котлыйм ихлас. *(Бакыр кыз янына килә)* Бакыр адаш!
Сиңа шундый килешә кашбау! Төс белән дә миңа син бик охшаш.
Аерма шул, син — илаһи, бер язуксыз,
Минем исә ялгышларым булды хәтсез. *(Өйгә, бакчага күз ата).*
Нинди матур тәртип! Сокланудан тот та ут төрт.
Явызларга ләкин һич заманда булмас кытлык —
Яндырырлар. Яндырмаса, җил бар, яңгыр, вакыт —
Таркатырлар нигезне үк җимереп, ватып. *(Бакыр кызга).*
Ә син үлмә, гәрчә җирдә синең дә эш беткән.
Үлсәң, терел ерак матур заманнарда.
Ә мин белмим, далалардан далаларга
Күпме чабармындыр, ахры, егылганчы атым.
Син шушында гына торсаң да тын,
Китәчәксең ерак, минем гарип кыяфәтем
Бер дәвердә телгә килсәң, тиеш табып,
Син кабатлый күрмә минем хаталарны. *(Китә).*
*Тояк тавышлары гасырлар аша уза. Күренеш алмашына. Бакыр кыз музей экспонатына әверелгән. Тирәсендә — яңа заман кешеләре. Шулар белән бергә — автор.*

Автор

Тыңлый белсәң, сөйли белә таш та...
Тора торгач котеп чак сулап,
Мин ишеттем, күрдем — бакыр кызның
Иреннәре куйды калтырап:
«Кем акыллы, тыйнак һәм затлы да,
Тәңре шуны үзенә чакыра.
Озатыгыз аны ерак күккә,
Җирдә тыныч яшәү хакына!»

Ямьыш сүзен кемнәр, бәйләп дарга,
Корбан кирәк диеп аңлаган?
«Сак булыгыз!»— дигән чакыру өнен
Ишетә килгән адәм һәр заман.
Кемнәр яшәү, кемнәр үлем даулый,
Хак хөкемен ала азакта.
Ракетадай очып, чор шул хакта
Дөньяларга хәбәр тарата.

*1980—1986*

## Альберт Хәсәнов

# КАДЕРЛЕ КӨНДӘШ

**хикәя**



лар поездда танышты. Җәйнең матур чагы иде. Әле яңа гына гастрольләрдән кайтып төшкән артистларга атна-ун көн чамасы ял бирделәр. Ә репетицияләрдән котылу юк, алары көн дә дәвам итә. Шундый репетицияләрнең берсеннән соң сәхнәгә Валерка Петухов сикереп менде.

Ул күренсә, халык ни булса да көтә инде. Валерка — көндәлек тормышта юктан да көлке чыгарып, эчеңне катыручы әле егерме яшьлек кенә егет. Ә сәхнәгә менсәме, анда ул программаның төп бизәге, Борынгы Мисыр тылсымчысы, агулы еланнар биетүче. Шуңлыктан, барысы да аңа төбәлделәр.

— Иртәгә, хөрмәтле сәнгать осталарыбыз, ял көнеме? Ял көне. Гомер узып барамы? Бара. Тәмам узып беткәнче, безгә дә бер табигать кочагына чыгып, ял итеп кайтырга кирәкме? Кирәк. Иртәгә бөтен әртил белән ял базасына чыгарга дигән тәкъдим бар. Кемнәр риза, исемнәрен терки үк башлыйм.

Тылсымчы һәрчак тылсымчы булып кала. Валерка һава бушлыгына ишарә ясап алуга, кулына бер бит кәгазь иңде.

— Беренче итеп үземне терким.

Артист халкы үзенә калса, дөньяда бер һәвәс халык. Син аңа фикер генә бир, тәкъдим генә яса, «анда нишләрбез, туңып үлмәбезме», дип сорашып тормас, чакырсаң, артыңнан ияреп котыпка ук чыгып китәр. Валерканы да шунда ук:

— Тимер тешле авызыңнан алтын сүз чыкты! Бик хуп! Тумас борын картаеп, йонланып-мүкләнеп барабыз, җәмәгать. Хуплыйбыз, табигать кочагына дигәндә безнең аяклар бүгеннән идәндә,— дип күтәреп алдылар.

Исемлеккә башта иллеләп кеше язылган иде. Сөйләшенгән урынга икенче көнне шуларның яртысы гына килде. Җәмәгать, вокзалга ашыкмыйк әле, башта колхоз базарына сугылып чыгыйк, анда ни хәлләр икән, диючеләр табылды. Ял итәргә катык-каймаксыз, кишер-кыярсыз барып булмый бит. Аларның исә берсе дә артистларның тәрәзә төбендә генә үсми, үрелеп кенә алышлы түгел. Базар хәлен белергә туры килә. Ә базар ул, җаным, ныклап бер учка төйнәлгән зиһенеңне дә бик тиз чуалта. Анда бер эләксәң, тиз генә борылып чыгармын димә. Шуның рас дәлиле: базардан автобуска нибары җиде-сигез кеше

---

*АЛЬБЕРТ БАРИ улы ХӘСӘНОВ 1937 елның 17 декабрендә Татарстанның Биектау районы Кече Кавал авылында туган. 1961 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаганнан соң, ул Лениногорск шәһәрендә газета редакциясендә әдәби хезмәткәр, телестудиядә редактор вазифаларын үти. Шул елларда көндәлек матбугатта хикәяләр, очерклар бастыра башлый. Хәзер ул татар һәм рус телләрендә чыккан «Озын аяк» (1966), «Тугрылык» (1980), «Сөенеч» (1984) — барысы дистәләп китапның авторы. Аның әсәрләрендә табигатькә мәхәббәт уятыла, замандашларыбыз арасындагы мөнәсәбәтләр яктыртыла. Язучы хикәя, повесть кебек жанрларда уңышлы эшләү белән бергә, матбугатта укучылар игътибарын җәлеп итә торган публицистик чыгышлар да ясый.*

*А. Хәсәнов — 1982 елдан СССР Язучылар союзы члены.*

генә кире әйләнеп чыктылар. Ә вокзалдан электричкага сәхнәләрдә дә, телевизор экраннары аша да сандугач кебек сайраучы колоратур сопрано Әкълимә белән дәртле, ялкынлы испан биюләрен тыпыр-тыпыр биюче Руфия генә утырды. Алар да кире борылмакчы иде дә, әйдә балаларыбыз елашып калмады әле, бер җиенып чыккач, барыйк, рәхәтләнеп хет урман һавасы сулап кайтыйк, дип хәл иттеләр.

Ял базасына килү белән кызлар Идел ярына төшеп китте. Аякларын тар басмадан асылындырып, суда вак балык уйнаганны карадылар, акчарлаклар чикылдашуын тыңладылар. Рәхәт иде Идел буенда. Көне дә матур, суы да җылы. Тик янда сөйгән ярлар гына юк. Шунысы бераз үкенечлерәк. Хәер, монысы инде аның бик катлаулы мәсьәлә...

Шулай байтак кына юангач, кызлар якын-тирәдәге дачаларны карап йөрергә, чәчәк җыярга китте. Юкка гына иртәдән шулай бөркү булмаган, юкка гына кояш шулай нык кыздырмаган икән. Түбәтәй хәтле генә бер болыт кисәге урман артыннан күтәрелде дә коеп яңгыр да яварга кереште. Кызлар йөгереп тук-талышка килеп җиткәнче манма су булып чыландылар. Әле дә ярый, шундук электричка килеп җитте.

Вагон буш, яңгыр һаман да сибәләп торганлыктан, ярыйсы җиләс. Кызлар, песи балаларыдай, бер-берсенә сыенышып бер буш урынны биләде. Ничә еллар бер тулай торакта, күрше генә бүлмәләрдә яшәп, гел бер труппада йөреп, аларның инде сөйләшәсе сүзләре сөйләшенгән, серләре дә уртак. Шуңа күрә берсе-сенең кочагына берсе сыенып, икесенә бер йон кофтаны өсләренә ябынып, шәһәргә кадәр татлы йокымсырарга иде исәпләре. Ләкин туры килмәде. Аракчино станциясенә җиткәнче микән, әллә аны узгачмы, вагонга бөтен килеш-килбәте белән күркәм, бик тә сөйкемле бер ир уртасы кеше килеп керде. Ишек катындагы буш урыннарга утырырга теләмәде. Кызлар турысына җиткәч кенә кулындагы зур кәрзинен идәнгә куйды. Өстендә — башлыклы җилән, аякларында — тирән кунычлы саз итекләре. Дачасыннан кайтучы сунарчы, я балыкчы булса кирәк. Юк, аларына түгел, үткер күзле артист кызлар бу ир-егетнең үзе кие, үзе кап-кара мәһабәт сакалына игътибар иттеләр. Сакал гына түгел, хәзинә бу һәм ул хуҗасына бик тә килешә. Аның йөзенә ниндидер бер мөлаем төсмер бирә.

— Кызлар, мөмкин булса, мине дә үз яныгызга сыйдырыгыз әле,— диде сакал хуҗасы, күптәнге танышларына дәшкәндәй итеп.

— Уртага алсак кына инде,— диеште кызлар, бу күркәм ир-егетнең аларга сүз катуын бик килештереп. Хатын-кыз бик практик җан, әле бит сәгать ярымнар кайтасы бар. Ә шат күңелле юлдаш татлы ризыктан татлырак, шифалы дарулардан шифалырак дигәннәр. Шул чак әлеге кәрзин бик сәер генә дерт итеп китте һәм идәнгә шапылдап нәрсәдер төште. Кызларга — куян йөрәкләргә, шул гына кирәк, алар каравыл кычкырырга әзер булып, урыннарыннан ук торып бастылар.

— Нәрсә ул анда сезнең!? Тьфү, тьфү, тәмам котыбыз алынды.

— Әй, кызлар, чын куян йөрәкләр икән үзегез,— дип мәһабәт сакал иясе, идәннән көрәк кадәрле балык алып, кире кәрзингә салды. Кәрзин өстенә япап та куйды әле:

— Шаярышмагыз, тик кенә ятыгыз. Яңгыр явасы булгангадыр инде, бүген иртән шул кадәр нык чиертте, мин бу табаннарны нибарысы ике-өч сәгать эчендә чүпләдем.

Кызлар саклык белән генә кәрзин өстенә иелделәр. Анда берсеннән-берсе симез табаннар ята, аларның күбесе әле тере, авызларын зур ачып һава сулый. Өстен җилән белән каплагач та әле кәрзин дерт-дерт селкенеп куя торды. Руфия шунда Әкълимәнең колагына нидер пышын-пышын килде. «Бу чибәр егеттән сора әле, бер-ике балыгын безгә сатмас микән. Мин аларны бик тәмле итеп кыздыра беләм.»

— Күрәм, күрәм, кызлар, сизеп торам, әле танышып та өлгермәдек, мине инде тәнкыйтьли дә башладыгыз. Үземнән бигрәк сакалымны ошатмадыгыз. Ә бер философ: «Сакалым минем бөтен гакылым», дигән. Соң сез философ мәллә, дисәгез, җавабым аңа да әзер. Дөньяда философ булмаган шәхес юк, әз-мәз генә без барыбыз да философ,— дип кәрзин хуҗасы, эре тешле тарак чыгарып, сакалын тәртипкә китерә башлады.

— Юк, юк, зинһар алай уйлый күрмәгез,— диеште кызлар.— Сакалыгыз сезгә бик килешә. Моны ихластан әйтәбез. Беләсезме, без сездән бераз балык сатуыгызны үтенмәкче идек...

— Йә, йә, шуннан?

— Сорарга кыймый барабыз. Ике-өч кило арттырсагыз, безгә шул бик җиткән.

— Әй кызлар! Тапкансыз уңайсызланырлык нәрсә, әлбәттә, арттырам. Беләсезме, башта танышыйк әле. Чөнки болай гына сөйләшеп бару уңайсыз: Зариф. «Абый» дип тә өстәсәгез, телегезгә йомшаграк булыр.

— Руфия.

— Әкълимә.

— Кулымдагы балдагымның исемнәре Әкълимә.

Иң яраткан күлмәгенә булыр идем ак төймә.

— Күр әле, үземнең исемем турында мондый матур җырны беренче ишетүем,— диде Әкълимә.— Кичә үлгән булсам, белмичә үләсе икәнмен.

— Сез әллә шагыйрьме? — диде Руфия бу танышлыкка шатланган да, бераз гына шикләнгән дә төс белән.

— Гафу итәсез, кадерле туташлар, мин үзем әлегә шагыйрь дә, хезмәт батыры да булырга өлгермәдем. Гади бер врач мин, балалар табибе. Иртәнге якта авыруларның өйләренә үзем барып чыгам, сәгать икедән соң кайсын әниләре күтәреп, кайсыларын әбиләре-бабалары җитәкләп килгән Саша, Машаларны кабул итәм... Кызык алар белән,— дип куйды Зариф, үз эшеннән канәгать булуын сиздереп.— Көннең узганын сизми дә каласың.

Шулай матур гына, күңелле генә сөйләшеп кайтканда Зариф туташлар арасыннан Әкълимәгә күбрәк игътибар итте төсле. Кызлар, әлбәттә, моны бик тиз төшенде. Инде аерылышыр чак та җитте. Өчәүләп вокзал каршындагы мәйданга чыктылар. Зариф балыкларны кәрзине белән кызлар алдына китереп утыртты.

— Бөтенесен дә алыгыз!

— Ә үзегезгә?

— Киләсә, тагын тотармын. Минем барыбер аларны кыздырыр кешем юк.

— И-и, Зариф дус, балаларыңның игелеген күр, кулың-аягың сызлаусыз булсын. Ә бездә оят юк, биргәнне алучылар без,— дип теләнә остарып, Руфия кәрзин өстенә иелде.— Ә кәрзинен нишләтербез? Бигрәк матур үргәннәр бит. Үзегезгә тагын кирәге чыгуы бар.

— Һәй, таптыгыз борчылыр нәрсә! Бер шәһәрдә яшибез ләбаса. Бер күрешкәч бирерсез әле. Миңа, кызлар, яңа микрорайонга. Ә сезгә?

— Безгә моннан ерак түгел. Киров чатына кадәр генә. Тәпиләп кенә китәргә уйлыйбыз.

— Ул чакта хәзергә хуш иттек,— диде Зариф. Кызларның адресын, телефоннарын сорауны килештермәде, ахрысы. Минем эш телефоным менә шушы,— диде.— Вакыт тапсагыз, шалтыратыгыз. Оныкларыгыз чирләсә, аптырап тормагыз, туры үземә килегез.

— Анысы өчен аеруча рәхмәт. Тик кызганычка каршы, оныкларыбыз юк шул. Үзебез күренергә килсәк, кире бормассыз ич? — дип көлешеп, кызлар Зарифны кул изәп озатып калдылар.

Сугымга махсус симерткәндәй, симез табаннарны бөтен тулай торак белән кыздырып ашадылар. Шеф-поварлыкны әлеге дә баягы тылсымчы Валерка үз өстенә алды. Таба өстенә иелеп, серле кыяфәткә кереп, тылсым догаларын бер-бер артлы укыса да, тозны барыбер күбрәк тондырган булып чыкты. Хәер, боткаы май, балыкны тоз бозмый, диләр, сыпырып кына куйдылар.

— Әй, әдәп тә юк инде үзебездә, шушы сый янына балык тотучының үзен дә дәшкән булсак? — диде Руфия, шуны сүзләренә күп мәгънә салып.— Кыздырырга барыбер кешем юк, диде бит. Кем белә, бу минутта ул бөтенләй ялгыз...

Дәшмәделәр шул. Мөмкин иде югыйсә. Әмма кызларның да инде һәр ярыктан шаркылдап көлә, һәр елмайган ир-атның муенына барып сарыла торган үнҗиде яшьлек чаклары түгел шул. Хәтта шалтыратмадылар да. Инде хәзер менә телефонын да хәтерләмиләр. Һич югында хәлен белгән булырлар иде.

— Ялгыз түгелдер әле-е-е,— дип сузды Әкълимә.— Өрлек кебек андый ирләр нишләп ялгыз булсыннар. Шәфкать туташлары, беләсеңме, нинди чая? Андый күркәм ялгыз ирләрне алар бер кич эчендә бармакларына бинт итеп урый.

— Минемчә, дустым, ул сине бик ошатты төсле,— диде Руфия.

— Анысын гына үзебез дә сиземләдек, сукыр түгел. Дәшмәдек шул, хәерлегә булсын,— диде Әкълимә көрсенгән тавыш белән.

Ә менә шушы кыска вакытлы, әмма күңелдә матур хатирә калдырган очрашуның шаһиты булган кәрзин, Әкълимәгә сораулы карашын төбәгәндәй, аның бүлмәсендә тора бирде. Теге чакта Зарифның телефонын язып алмаганга Әкълимәбез хәзер үкенеп тә куя. Җитмәсә, фамилиясен дә белми. Миллионнан

артык халкы булган Казанда Зариф атлы врачны эзләп кара син, табарсың бар. Хәер, әгәренки, чынлап торып керешсәң, нигә тапмаска? Балалар шифаханәләре шәһәрдә санаулы. Берсенең врачлары икенчесенекен белә. Бик матур кара сакаллы Зариф исемле доктор дисәң, хәзер табып бирерләр. Табарга булыр иде, әйе. Шуннан ни? Менә кәрзинегезне китердем дияргме? Моңысы бер. Икенчедән, артист халкының гомере гел көпчәкләр өстендә. Кызларга гастрольгә чыгып китәр чак җитте.

Бу көннәрдән соң ай ярымнар чамасы узды, шәһәрне алсу, кызгылт, сары яфракларга бизәп, алтын көз килде. Кызлар бу юлы шәһәргә тиз әйләнеп кайтты. Инде хәзер концертларны зур Культура сарайларында бирә башладылар. Бу кичне алар Мехчылар клубында чыгыш ясарга тиеш иде. Тик ниндидер сәбәп белән концерт булмады. Артистлар моңа сөенештеләр генә. Ул бит, дускаем, тыңлаучыга, тамашачыларга гына рәхәт. Концертка гомерендә бер килә дә, өенә кайтасы килмичә, кич буе шап-шоп кул чабып утыра. Ә менә син көн саен, кайчакларда көненә икешәр концерт биреп, сәхнәгә чыгып җырлап кара. Артист та кеше бит, малайкаем. Аның да кәефсез, хәтта үзен-үзе күрәсе килмәгән чаклары була. Ә тамашачының анда эше юк. Син аның күңелен күр, сөендер, киләндер. Шуларын уйласаң, артист тормышы да бик баллылардан түгел. Хәер, кем әйтә инде аны шулай дип.

Концертның булмавына ихлас сөенеп, Әкълимә белән Руфия Тулай торакка җәяү генә кайтырга чыктылар. Әкълимә Руфияне култыклап алды.

— Заказ белән соратып алгандай матур, тын кич. Гомер эчендә бер үзебезгә тик үзебез генә хуҗа булып, саф һавада җай гына атлыйк әле.

— Әйе шул,— дип куәтләде аны Руфия.— Башкалар төсле, шундый матур кичләрнең ләззәтен татырга да вакытыбыз булмый. Кемнәрдер кичләрен бер-берсенә сыенышып, назланып кино караганда...

— Ә кинодан соң бакчада сөйгәне белән үбешеп утырганда,— дип бүлдерде аны Әкълимә.

— Әйе, үбешеп утырганда, без һаман сәхнәдә. Концерт бирәбез, башкарган номерыбыз тамашачыга ошармы, кул чабарлармы дип аһ та ваһ киләбез.

— Шуңа күрә вакытында кияүгә дә чыга алмый калабыз.

— Күңел төшенкелегенә һичкайчан бирешмәскә, Әкълимә туташ! Шуны онытмагыз, сез халыкка хезмәт итәсез! Тормышта моннан да зур бәхетнең булуы мөмкинме! — диде Руфия калын тавыш белән. Моныcын ул филармония директорына хас ишарәләр белән әйтте.— Беләсеңме нәрсә, «Татарстан»да икенче генә көн Голливуд фильмы бара. Җанга әллә ни азык бирмәсә дә, пиф-паф җитәрлек, ди. Әйдә шунда атладык. Берәр изгесе бәлкем безгә артык билет алып куйгандыр?

Ике ахирәт адымнарын тизләтте. Бауман урамы, кинотеатр тирәсе бу кичтә ерып узышлы түгел. Әйтерсең, бер-бер бәйрәм, халык, халык! Әйтерсең, бөтен Казан урамга чыккан. Кызлар алай да өметләрен җуймый алгы фойега узды. Кассалар күптән ябык, исәпләре кулдан артык билет эләктерү. Шунда, икесе берьюлы, читтәрәк торган күркәм гәүдәле ир-егеткә игътибар иттеләр. Аның үзеннән бигрәк сөйкемле сакалы аларга ничектер таныш шикелле күренде. Чү! Бу соң, бу Зариф ич! Юк, юк, беренче булып кызларны ул үзе күреп алды.

— Сез һаман бергә икән, сез һаман бергә икән, кадерле туташлар! — дип яннарына да килеп басты.— Әллә артык билетыгыз да бармы? Юк. Алайса, кызлар, алтыннарым, айн момент табабыз аны.

Гаҗәп, ул, чыннан да, бик тиз арада өч билет табып килде. Пиф-пафлар бу фильмда дөрестән дә җитәрлек иде. Киноны алар онытылып карадылар. Инде өчәүләп кайтырга чыктылар.

— Аяк терәп карышмасагыз, туташлар, озатып куярга исәбем бар,— диде Зариф.

— Аяк терәп үк карышмабыз инде,— дип көлеште кызлар. Анысы инде карышып торалармы соң! Озатучылары булганда.

Тулай торакка җитү белән, «Мин нигәдер өшеп торам әле, әллә бераз температурам да «бар», дарулар эчеп, юрганымны башымнан бөркәнеп ятып карыйм әле» дигән булып, Руфия шундук кереп китте.

Кич бик матур. Һава саф. Вакыт та әле бик соң түгел. Зариф, бераз әйләнеп, Болак буйларын карап килергә тәкъдим ясады.

— Рөхсәтме? — дип ул Әкълимәне җиңелчә генә култыклап алды.— Беләсезме? Мин теге чакта шалтыратуыгызны бик көткән идем. Иртәгәсен көнозын телефон яныннан китмәдем. Шунда инде шалтыраткан булсагыз соң?

— Гаеп бездә, Зариф. Кызлар хәтерен үзең беләсең, телефонны шунда

үк язып алырга башыбызга да килмәде. Аннары инде искә төшерә алмадык. Ул арада гастрольләргә чыгар чак житте.

Бу кичтә алар күп нәрсәләр турында сөйләште. Зариф өйләнгән булган. Аерылышканнар.

— Нәрсә житмәде? — диде Әкълимә аңа туп-туры карап.— Нәрсә бүлешә алмадыгыз?

— У-у, тарихы озын,— дип кулын гына селтәде Зариф.— Характерлар туры килмәде.

Зарифның кулында кара дипломат. Ул аны еш кына бер кулыннан икенчесенә күчергәләп тора. Әкълимә күтәреп караган иде, чүт сыгылып төшмәде. Дипломатка, әйтерсең, кирпеч тутырганнар.

— Нәрсә монда? Күтәрешле түгел.

— Һәй, кешеләр чыгарып ташлый, мин жыям. Тимер-томыр.

— Ә сез ни дип жыясыз?

— Хобби! Шундыйга һәвәс мин.

Әлеге кичтән соң алар еш-еш күрешә башладылар. «Акчарлак» ресторанына барып яңа ревю тамаша кылдылар. Мәскәүдән килгән ансамбль концертында булдылар. Шунысы сәер, Зариф теге дипломатын һәрчак үзе белән йөртте. Аның эчендә һәрчак серле тавышлар чыгарып, ниндидер тимер-томыр шалтырады. Берчакны Әкълимә аңа:

— Бу сандыгың бигрәк авыр, әйдә, бездә генә калдырып торыйк,— диде.

— Чын интеллигентка дипломат тотып йөрү, хатын-кызларга күкрәкчә кию кебек кирәк,— диде Зариф.

— Каршы әйтерлегемне калдырмадың, килешәм,— диде Әкълимә.— Төпле дәлилгә корылган фикерләрне гомумән тулысынча кабул итәм.

Тора-бара Әкълимә Зарифның шалтыратуын, килүен көтеп ала башлады. Яшең утызга житкәндә әллә ни сайланып маташа алмыйсың. Ялгызлыкның, туар көннән һаман да нидер көтеп яшәүнең дә бер чиге бар. Сәхнәгә чыксаң, сиңа баш иючеләр, килеп кат-кат кулыңнан үбүчеләр күп. Чәчәкләрне дә кызганмыйлар. Ә менә буш кичең булса, башыңны хет ташка ор. Кыяркыймас кына култыклашып Болак буенда йөрүләрне үзе дә бик тансыклаган иде ул. Дөрес, Әкълимә үзен егетләр кочагында булмаган, аларның назлавын татымаган беркатлы бәндәгә санамый. Әле менә узган ел гына, күрше Ашытбаш егете Мөнир белән таныштырганнар иде аны. Очучы, мин сиңа әйтим. Казанга стажировкага кайткан иде. Ай ярымнар чамасы бергә торып та маташтылар. Тору булмады, мәхшәр булды инде ул. Мөнир, бер артисттан көнләшү кәмите ясап, аның бүлмәсендәге бөтен әйберне кырып бетерде. Әкълимәнең яңагына чалтыратты. Яраттыра, көйләштерә белгән хатын гомер эчендә бер анысын да татырга тиештер дип, Әкълимә эшне зурга жибәрмәде. Стажировкасын бетергәч, Мөнир үзе эшләгән шәһәргә кайтып китте. Китте дә шым булды, хат та, хәбәр дә салмады. Аларны таныштырган Ашытбаш түтие генә: «Ул азгынның анда катыны булган икән, жаным. Шул турыда ник берәүгә ычкындырсын. Лүтчик кеше шул — сер саклый белә, без түгел. Катыны белән торуларының башта бер дә рәте-чираты булмаган. Казаннан кайткач, янәдән кушылганнар, ди. Бала хакынадыр инде, өч яшьлек кызлары да бар икән»,— дип авыз суын корытып сөйләп торды. Хәер, болары аның тормыш сикәлтәләре генә. Мөнир белән алар барыбер бәхетле гаилә кора алмаган булырлар иде. Бер авызына әләксә, бер чүмерә башласа, чиген-чамасын белми. Эчеп алса, кулы тик тормый. Андый дуамаллардан кул-аягың исән чакта котылуыңа мең шөкер ит.

Ә менә күрер күзгә күркәм генә, телгә дә бик ягымлы Зарифны хатыны ни дип аерды икән? Нинди гөнаһлары өчен? Әйе, әйе, хәзер күпчелектә хатыннар ирләрен аера. Халык судында утырышчы итеп сайлангач, моның шулай икәнен Әкълимә үз күзе белән күреп ышанды. Хатыннарда төп терәк. Әгәр тели икән, хатын-кыз гаиләне ничек кенә саклый әле. Ир-ат, бичара, бәйдәге эт сыман. Муенындагы чылбырын ычкындырмый торып, беркая да атлый алмый. Юк, ни генә булмасын, Зариф ошый Әкълимәгә. Әллә инде гашыйк та булып өлгердеме? Ә нигә, аның йөрәгенә дә мук үсмәгән ләбаса.

Кыскасы, Әкълимәнең күңеле түрендә Зариф көннән-көн ныграк, даимирәк урын били барды.

Шулай бер көнне, күңелле сөйләшеп урамда байтак кына йөргәннән соң, Зариф аны үзенә чакырды.

— Бу дипломатны да кертеп бушатырга кирәк, тәмам кулымны талдырды,— диде.— Тәмләп кайнар кофе эчәрбез, телевизор карарбыз.

Алар тугыз катлы кооператив йортның алтынчы катына күтәрелделәр. Зариф, лифтка кергәч, Әкълимәне кочагына кысты, бит уртасыннан үбеп тә алды. Яшүсмерләр төсле йомшак кына итеп Зарифның бөдрә сакалы аның битен кытыклады. Ир назы, дускаем, ир назы шул инде. Хатын-кызга аны ата-ана назы да, иң якын дус-ишләре, якын туганнары назы да алыштыра алмый. Шушы җиңелчә үбүдән дә ана ничек рәхәт булып китте. Әлеге назның сихәте бөтен тәненә таралды. Әкълимә җавап итеп үзе дә Зарифка елышты, башын аның күкрәгенә салды. Борынгы грек философы Демокрит, әгәр мин уйлыйм икән, фикер йөртәм икән, димәк мин исән, яшим, дигән. «Әгәр мине кемдер сөя, назлый, иркәли икән, димәк, мин чибәр, мин мона лаек», дип уйлады Әкълимә. Дөньяда бит аның шунысы гына да ни тора!

Лифттан чыгуга аларны карасу дермантин белән тышлаган зур ишек каршы алды. Аның алдына килеп баскач кына, Зариф кабаланып әле тегe, әле бу кесәсен капшады.

— Аһ, каһәр, ачкычны алырга онытканмын бит! — диде. Әкълимәнең сораулы карашын күреп, кыю гына кыңгырауга басты: — Зарар юк, коллега миннән өйдә калган иде.

Эчтән озак көттермәделәр. Башта аяк тавышлары ишетелде. Аннары шалтырап ишек ачылды. Анда, өстенә калын затлы халат кигән, иңбашына мамык шәл салган, әмма шулай да курчак кебек җыйнак бер хатын күренде. «Коллегасы» шушыдыр, күрәсең», дип уйлап алды Әкълимә. Йөрәге жу итеп китте. Зариф аңа хатыны белән судлашып аерылышулары, өч бүлмәле кооператив квартирада икәүләп аерым яшәүләре турында сөйләгән иде сөйләвен. Сигез яшьлек уллары Азатның Суворов училищесында укуын да белә. Малай училищедан ял көннәрендә генә, анда да ике-өч сәгатькә генә кайтып китә. Боларның барысы турында Әкълимә шулай алдан белсә дә, Зарифның «коллегасы» белән ишек катында очрашырбыз, дип уйламаган да, көтмәгән дә иде. Башка чакны бик батыр, таштан ут алучы туташ коелды да төште. Ләкин ишек каты мөнәсәбәтләр аңлашып, ышаныч кәгазьләре алмашып тору урыны түгел. Тагын шунысы да гаҗәп тоелды: Зарифның «коллегасы» Әкълимәгә һичнинди дошманлык, көндәшлек хисләре сиздермәде. Зариф үзе берни булмагандай:

— Гафу ит, коллега. Ачкычларны онытып калдырганмын, җитмәсә кунагым да бар,— диде.

— Күрдем,— ишек ачкан ханым чөйдә эленеп торган ачкычлар бәйләменә ымлады.— Соңгы вакытта, коллега, гомумән башыгызны җуеп йөри башладыгыз. Нидән икән бу, дип гаҗәпләнгән идем аны. Хәзер төшенәм инде. Рәхим итегез!

Алар күзгә күз очраштылар. Әкълимәгә кире борылырга инде соң иде. Ә нигә борылырга? Басып кермәде ләбаса. Чакырган җиргә кунак булып килде. Зарифның «коллегасы» ягымлы тавыш белән:

— Рәхим итегез, узыгыз! — дип кабатлады.

— О-о, бу склероз зәхмәте! Әллә миндә дә башланамы. Укыган чакта үзебезнең профессор Ниязовтан көлә идек. «Көлке көлә килә, артыннан куа килә» шушы була инде күрәсең,— дип сөйләнде Зариф. Әкълимәне култыклап эчкә алып керде, бүреген салып чөйгә элде, аңа пальтосын салырга булышты. Шулчак алар янына ян бүлмәдән әлеге җыйнак гәүдәле ханым чыкты.

— Коллега, син гафу ит. Миндә Мәрьям утыра. Синең башмакларыңны аңа биргән идем,— диде.

— Ә-ә, Мәрьямбикә ханым! Дөньяда без барлыкны да онытмаган икән әле. Ерак Мали иленнән исән-сау гына йөреп кайткannармы? Тропик бизгәк белән газапланмаганнармы? Хәзер керәм яныгызга, күрешеп чыгам үзе белән,— дип сөйләнә-сөйләнә, Зариф Әкълимәнең чишенеп бетүен, көзге алдында чәчләрен тәртипкә китерүен көтте.

Аннары алар зал аша узып, почмак бүлмәгә керделәр. Заманча зәвык белән пөхтә итеп җыелган. Түрдә эш өстәле, янда түшәмнән идәнгә хәтле китап шкафы, ял-йокы өчен тахта. Зариф аңа тахтадан урын күрсәтте:

— Утырып ял итегез! Тартынмагыз.

Әкълимә әдәп саклап кына як-ягына каранды, күзе каршы як стенага төште һәм аптырап калды. Бу бүлмәнең бөтен стеналары иске йозак белән тулы иде. Аларның монда ниндиләре генә юк: амбарныкы да, сандыкныкы да, портфель-портмоне бигe дә. Барысы да майланган, ялт иттереп кара лакка буялган. Почмакта кечерәк кенә верстак, шүрлектә эш кораллары. Зариф шул арада дипломатыннан верстак өстенә тагын ике амбарны, гаражны йозагы чыгарып салды.

— Хоббием бу минем, Әкълимә кадерлем, һәвәслегем. Башта шаярып кына

керешкән идем, хәзер мена һич котыла алмыйм. Тәмам иләсләндерде,— дип Зариф яңа алып кайткан йозакларын дикъкать белән карарга кереште.— Бүген приемга бер әбекәй китерде, кайчандыр оныгын дәвалаган булганмын. Каян ишеткән диген син! Көчкә күтәреп килдем, ди әле.

— Ришвәт! — диде Әкълимә елмаеп.

— Әйе, нәкъ үзе. Ләкин бик еш эләкми. Ә боларның күбесен тимер-томыр складларына барып актарынып, шәһәр читендәге чүплекләргә чыгып җыйдым.

— Хаҗәтләре шул кадәр зур идемени?

— Булмаска! Беләсезме, һәр йозакның үзенә бер олы язмышы бар. Кызыклы тарихы. Аларның телләре бар, матур итеп сөйли беләләр.

— Ышанам, ышанам,— диде Әкълимә елмаеп.

— Дөрес, аларның күбесе башта минем кулга хаста хәлендә эләгәләр. Ә мин аларны җырлап тора торганнар итеп көйләп куям. Карагыз, хәзер алар барысы да төзек. Телләрен ачарга ачкычларын да үзем ясыйм. Бүлмәмә шуларны сагынып кайтам. Үзләре дә мине сагынып торалар.

— Аларны берәр Пионерлар сараенамы, яшь техниклар йортынамы күргәзмәгә куярга кирәк,— диде Әкълимә.— Югыйсә тиздән монда бөтенләй кысынкы булачак.

— Исәбем бар. Ләкин коллекциямне тагын да тулыландыра төшәсем килә. Беразга сабыр итәргә, ашыкмаска кирәктер, дип уйлыйм. Әкълимә, кадерлем, мин бер генә минутка,— диде Зариф, бүлмә ишегенән япты, ләкин шунда ук кире әйләнеп керде.— Мәрьямбикәбез килгән икән. Бер курста укыган идек. Ире белән чит илдә эшләп кайттылар. Син монда ни дә булса караштырып тор. Ә мин тиз генә кофе өлгертәм.

Зариф кухня ягына чыгып китте. Озак тормады. Бүлмәгә поднос белән кофе чәйнеге күтәреп керде. Өстәлгә матур ике чынаяк алып утыртты. Аларга күе итеп кофе салды. Соңгы минутта гына бер шакмак шикәре дә юклыгы мәгълүм булды. Зариф тагын кухня ягына йөгерде. Анда ул ниндидер калай савытларның берсен ачты, икенчесен япты шикелле. Ахырда аның:

— Коллега, берничә шакмак шикәреңне алып торам, кайтарырмын,— дигән тавышы ишетелде.

Инде тәмләп кенә эчә башлаганнар иде, бүлмә ишеген шакыдылар, анда, аларга ишек ачкан әлеге күркәм ханым күренде.

— Мәрьямбикә күчтәнәче. Малидан кайтышлый самолетлары Корсика атавына төшкән. Шунда аэропорт буфетыннан алган идем, ди. Сине дә сыйларга куша,— дип өстәлгә бик матур тартма белән конфет китереп куйды.— Мәрьямбикәнең үзен дә сыйламакчы идем,— салу белән эри торган кофем беткән.

— Әй, алла! — дип Зариф бот чапты.— Мәрьямбикә уртак кунагыбыз лабаса. Без хәзер залга күченәбез, сез дә шунда чыгыгыз. Бергә-бергә күңеллерәк тә булыр.

Карелия каеныннан эшләнгән затлы мебель белән бизәлгән урта бүлмәгә алар беренче булып чыкты. Түгәрәк өстәл артына утырдылар. Әкълимә тәмам аптырашта. Шайтан белсен мондагы хәлләрне, үзара мөнәсәбәтләрне. Аларга ишек ачкан хатын кем ул? Зарифның сеңелесеме, квартиранткасымы, әллә, каһәр, судлашып аерылган хатынымы? Әкълимә өчен әлегә болар барысы да «Андромеда томанлыгы».

Ул арада күрше бүлмәдәге ханымнар да бу якка чыкты. Икесе дә чибәрләр. Ханымнарның баштанаяк затлы киемнәр кигәне әдәпле генә итеп Әкълимә белән күреште: Мәрьямбикә.

Беркавым бүлмәдә киеренке тынлык урнашты. Уртак бер темага гәп башлап җибәрә алмыйча, кофены башта шулай сүзсез генә эчтеләр. Бигрәк тә Әкълимә үзен уңайсыз хис итте. «Мин соң монда кем? Ашка төшкән таракан түгелме? — дип тә уйлап алды хәтта.— Хәер, бәреп кермәдең. Чакырып китерделәр, кунакта утырасың. Тәмләп кенә, ләззәтен тоеп кына кофе чөмерүеңне бел. Аннары инде, Әкълимә дускаем, озын чәч, кыска акылым, һәркемнең бәхеткә үз хокукы бар. Бәхет ул тилеләргә, ахмакларга гына теш ярып керә. Күпләр аны яулап ала».

Кофедан соң барысы да телевизорга төбәлделәр. Зариф әле тегe программаны, әле монысын борып карады, әмма бу кичтә аларның берсендә дә әллә ни искитәрлек нәрсә күренмәде. Хуҗа ханымның кулында йон йомгак, бәйләү энәләре пәйда булды. Ул әллә кофта, әллә ачык изүле йон күлмәк бәйли иде.

— Нәкъ иңбашына җиткәч тукталдым да калдым, һич кенә очлый алмыйм, үрнәген онытканмын,— диде ул.

— И-и, Гөлшат, дускаем, таптың ярдәм сорар кеше! Чаңгыда чыгарга

кызыма йон бияләйләрне дә каенанам бәйләп бирә бит. Кул эшенә осталыгы булмады да, буласы да юк,— дип Мәрьямбикә аның иңбашына кулын салды.— Әле менә сиңа көнләшеп карап торам.

Кофтага Әкълимә дә төбәп-төбәп карап алды. Бер караудан бәйләде, бәйләмәскә, артист халкы моның ише бәйләү-чигү эшенең остасы бит ул. Алар бәйләгән калфакларны, кофта-свитерларны, алар чиккән яулыкларны хет бүген тот та Парижга халыкара күргәзмәгә илт. Бер бәхәссез приз алачаклар. Чөнки артистлыкның беренче көненнән, беренче сәгатеннән шуның белән мәшгуль бит алар. Аэропортта ике-өч сәгать самолет көтсәләр дә, гастрольләрдән поездларда, пароходларда кайтсалар да, озын юлны кул эше белән мавыгып кыскарталар. Ахырда шушы эшнең осталарына әвереләләр.

Карап торды да Әкълимә, ахырда түзмәде:

— Кая, бирегез әле, мин тырышып карыйм,— дип Гөлшаттан кофтасын сорап алды, җиң утырта торган җиреннән җинел генә бәйләп тә китте.— Сез аның ике күзәнәген сикертеп, өченчесен кабаттан чәлдереп барыгыз. Шулай итсәң, тигез дә, матур да чыга.

— Аңладым, кара ничек җиңел генә икән, рәхмәт,— диде Гөлшат бәйләүне кире үз кулына алып. Аның бу сүзләрендә әз генә дә көндәшлек, янсә ничектер төрттереп әйтү сизелмәде.

— Ә-ә, онытып торам икән бит әле, коллега,— диде өстәлдән чынаяклар җыештырып йөргән Зариф.— Үземнең замша курткам белән бергә көзге пәлтәңне дә химчисткага илттем. Ике атнадан килергә куштылар. Квитанциясе менә, җыеп куй. Соңыннан таптырып йөдәтмә.

— Ай, рәхмәтләр төшкере! Ә мин үзем һаман өлгерә алмый йөрим. Бу диссертациям белән тәмам башым катты...

Зариф, Мәрьямбикә, Гөлшат үзләре дә сизмәстән медицина турында сөйләшеп киттеләр.

Әкълимә башкалар да күрерлек ишарә белән сәгатенә карап алды, китәргә җыенуын сиздерде. Зариф аңа киенергә булышты, тулай торакка кадәр озатып куйды.

Алар моннан соң да очрашуларын дәвам иттеләр. Әкълимә дә Зарифларга килгәләде. Бер килүләрендә Гөлшат аларны кош тоткандай шатланып каршылады.

— Коллега, сөенечкә нәрсә бирәсең! Мин сиңа менә дигән мохер шарф таптым. Әнә өстәлдә. Үз бәясе кырык сум, диләр. Мин ун сум артык бирдем. Чөнки андый затлы әйберләр прилавка өстендә ятмый. Акчаның исә илле сумын гына түгел, йөз сумын да муеныңа урый алмыйсың.

Гөлшат шарфның чыннан да бик затлысын һәм төскә дә бик матурын эләктергән. Зарифка шул хәтле килешеп тора. Шарфны муенына салып маташкан арада Зариф үзе дә:

— Коллега, мин бер дустым белән тагын сөйләштем. Син аңа тагын бармагансың. Нәрсә, ул черек тешеннең акыртып сызлый башлаганын көтәсеңме? Иртәгә ук күрен, көтәрмен дип калды,— дип кисәтте.

Гаҗәп монда хәлләр. Инде ел ярымнар чамасы аерым ашап, аерым эчеп дигәндәй яшәгән бу «коллегалар» арасындагы мөнәсәбәтләрне Әкълимә ни тырышса да аңламый. Ирле-хатынлы булып, күп еллар тату гына гомер кичергән, аяк терәп дөнья көткән парлар да бер-берсенә карата шулай игътибарлы, кайгыртучан буламы икән әле? Ә болар арасындагы мөнәсәбәтләр хәтта сокланырлык. Бу чукынчыклар, судлашып аерылышып уйныйлар гынамы әллә? Әкълимә күңелендә хәтта шундый шикләр дә туып куя.

Икенче бер килүдә ул Зариф квартирасына бер минутка дип кенә сугылган иде. Яңа Бистә ягында бер иске йорт сүтәләр икән. Амбарлары да бар, ди. Менә аннан иске йозакларны табарга була инде. Әкълимәне дә ияртеп, Зариф шунда барып кайтырга булды. Фатирына өс-баш алышырга, чүкеч-балта, каергыч алырга, дип кенә сугылган иде. Ишек ачылуга, бүлмәсеннән тагын Гөлшат атылып чыкты.

— Коллега, миндә Назар Петрович кунакта. Диссертациямне укып чыккан. Булган бу, ди. Шушы яхшы сүзе өчен үзен әз генә сыйламак ниятләгән идем.

— Шуннан? — дип бүлдерде Зариф.

— Ләкин минем бернәрсәм дә юк. Алдан хәстәрләнү башыма да кермәде.

— Анда бит, сервантта нәрсәдер бар.

— Күрдем. Сорамый алырга гына базмадым...

Зариф аягын да салмый залга узды. Гөлшатка Рига бальзамы, башланган коньяк шешәсе чыгарып бирде.

— Сез дә күрсәгез күңеллерәк булыр иде...
— Ашыгабыз.
Планетаның яулык бәйләгән һәр шәхесе — озын борын Мәчтүрә. Әкълимә шул арада да Гөлшатның бүлмәсенә башын тыгып карамый булдыра алмады. Бу Назар Петровичы кем тагын? Карады да көчкә бот чапмады. Бүлмә түрендәге креслода ялтыр башлы, күрсәгы идәнгә салынган картлач утыра. Күзләре, ата мәченеке төсле, майлы. Әкълимә анысын тиз шәйләп өлгерде. Аһ, карт жен, диссертация укырга килгән, имеш.
Ә бу тилебаш чыпчыгы шуның алдында тагын пырх та пырх килә. Креслода утыручының комсыз тилгән, ач күз карчыга икәнен күрми дә, шәйләми дә. «Мин булсаммы! — дип уйлап куйды Әкълимә.— Белер идем аны нәрсә белән сыйларга икәнен. Арт ягына чыбык белән сыптырып чыгарыр идем». Шунда ук икенче Әкълимә аңа: «Анысы, сеңелем, синең эшең түгел, тыгылма. Нәрсә эшләгәнен үзе беләдер».— дип кисәтте. Монысы аның Әкълимәгә һәрчак каршы төшә торганы, аның белән гел бәхәскә керә торганы.
Алар шулай дүрт айлар чамасы очрашкалап йөрделәр. Әкълимәнең хәзер ерак араларга гастрольгә дә китәсе килми иде. Чөнки хәзер аны Казанда Зариф көтә. Шунадырмы, Әкълимә Казанны аеруча сагынып кайта иде.
Кешене якын итү, ярату өчен, беренче чиратта аның белән фикердәш булу кирәктер. Әкълимә Зарифның дөньяга карашындагы күп нәрсәләр белән килешә, аның яклы. Зарифның үз алдына һичнинди матди мәнфәгатьләр куймыйча, хисрәнеп йозаклар җыеп мавыгуын да килештерә. Шушы араларда гына алар Актаныш якларында концертлар биреп кайттылар. Бер авылда Әкълимәне бер ялгызы гомер кичерүче әбигә квартирага керттеләр. Шунда Әкълимә әбинең кыз чакларыннан сакланган бирнә сандыгында үзенә бер сәер йозак күреп алды. Әбигә кибеттән өр-яңа йозак алып кайтып бирде. Әбекәй бу юмарт артист кызга кат-кат рәхмәт укыды. Әкълимә исә Зарифны сөендерде. Алай гына түгел, Әкълимә Зарифның судлашып аерылган «коллегасы» Гөлшатны да ничектер үз күрә, хәтта ярата иде. Ә аңа карата көндәшлек хисен әз генә дә кичерми. Кешеләр арасында бер-берләренә карата туып куя торган мөнәсәбәтләрне һич аңламассың. Аларны аңларга иң соңгы модель электрон-хисаплау машиналарының да башы җитмәс.
Шулай көннәрнең берендә, Казанның неон утларына күмелгән урамнарына иркәләнеп-назланып кына эре-эре кар бөртекләре төшеп торган җылы бер кичтә, Зариф тулай торакка бер кочак чәчәк тотып килеп керде. Шушы кичне ул Әкълимәгә бергә булырга, кушылырга тәкъдим ясады. Көткән иде Әкълимә аның бу адымын. Ә менә хәзер җиңел генә «риза!» диярга ашыкмады.
— Тәкъдимеңә мең рәхмәт, Зариф,— диде ул.— Ләкин син миңа бераз уйларга вакыт бир. Без бит инде икебез дә яшь-җилкенчәкләр генә түгел.
— Шул бераз вакыт мөнәсәбәтләребезгә нинди дә булса яңа төсмерләр өстәр дисеңме? Мин тимерне кызган чагында сугу яклы,— диде ул бераз үпкә белдергән сыман.
— Алай да чак кына көтик, уйланыйк әле, ямме?
Уйларга булгач, уйларга инде.
Бу төнне ул керфек тә какмады. Үлчәү тәлинкәләренә уй-хисапларын тегеләй дә, болай да салып карады. «Кайберәүләр лотереядан отып та машиналы була. Лотереядан откан мал харамга саналмый. Киерелеп, мин сиңа әйтим, йөри бирәләр. Зариф синең лотереядан откан бәхетең, акыллым, ничу юк белән баш катырырга. Тот та кулынны бир», дип әрепләште теге, һәрчак күңелендә аңа каршы төшә торган Әкълимәсе. Икенчесе: «Ашыкма, лотерея, ай саен уйнаса да, һаман машина отып тормый»,— ди.
Кая ул керфек кагу! Бу төндә башыннан узган вәсвәсәләрне, уй-фикерләрне бер җиргә өеп куйсаң, Урал тавыннан биек булыр иде.
Икенче көнне иртән сәгать җиде тулганчы ук барып керде Әкълимә Зарифларга. Зариф «Спидола»сын кабызган, борын эченнән нидер көйли-көйли, кырынып йөри. Андагыдай кара сакалны гел тәртиптә тоту өчен, көзге алдында һәркөн шулай байтак маташырга туры киләдер. Хәер, ул ашыкмый, эшенә тугызга гына йөри. Гөлшат инде өстен-башын киенгән, чыгып китәргә тора. Бу иртәдә дә ул Әкълимәне:
— Әйдүк, рәхим итәсез! — дип якты йөз белән каршы алды.
— Якты йөзең өчен рәхмәт, Гөлшат җаным, мин узармын. Бер генә минутка үзең дә ашыкма әле,— дип Әкълимә аны кулыннан тотып туктатты.— Зариф, сез дә бире чыгыгыз.
Үзе уфылдап урындыкка барып утырды. Тирән итеп тын алгач:

— Юк, булмый икән. Бу мәхәббәт мина лотереядан откан төсле тоела. Очраклы, хәтта хәрәм бәхет бу. Аңлыйсызмы?! Сез бит берни аңламыйсыз! Гөлшат, сез беләсезме, Зариф миңа тәкъдим ясады.

— Ясаса,— диде Гөлшат берни булмагандай салкын кан белән.— Ул ирекле, ихтыяры үзендә. Без аның белән дингездәге кораблар. Һәркем үз юнәлешендә йөзә, очрашканда тик гудоклар гына бирешәбез. Монысын халыкара килешү, конвенция шулай таләп итә.

— Кораблар, имеш! — дип шунда Әкълимә бар көченә өсталгә китереп сукмасынмы. Хәтта буфет, сервант пыялалары, аларның киштәләрендәге бәллүр касәләр сискәнешеп зыңгылдаштылар.— Кораблар, имеш! Берсе менә өч ай инде миңа чәчәкләр ташый, ә өендә курчак кебек хатыны утыра. Икенчегезне әйтер идем инде! Корсагы җирдән өстерәлгән карт алашаны нәртеп кайткан, ә күрше бүлмәдә өрлек кебек ире иске йозаклар майлый. Тьфү! Беләм мин ул март мәчеләрен. Күп тапкырлар очратканым бар. Синең диссертацияң, Гөлшат, беркатлы җанашым, аяк сөртергә дә кирәкми. Нужали шуны күрмисең, аңламыйсың син! Берәр җае чыгып тәмле калҗа эләкмәсме, дип йөрүче козгыннар, комсыз карчыгалар бит алар.

Әкълимә икенче ягына борылып, шушында ук басып торган Зариф өстенә ябырылды.

— Үпкәләштән булмасын, Зариф кадерлем, ир түгел син, чүпрәк син! Теге чакны мәк чәчәге кебек хатыныңны шул капкорсак белән калдырып, кинога чыгып киттең. Синең урыныңда мин булсаммы, җүл-ләр! Алтынчы катның һәр баскычыннан берәрне тибеп озаткан булыр идем. Ярар, аерылган да булдыгыз, ди. Ул бит барыбер синең хатының, ят ир белән үз квартираңда син аны ни дип калдырдың? Тьфү, ачуым да бер килмәгәе!

— Ә син, Гөлшат, шулай ук ачык авыз ябалак,— диде Әкълимә.— Бәхетең инде җаным, әле дә ярады, көндәшең мин булдым. Югыйсәме, шундый хатыннар бар дөньяда нарасыйкаем, Зарифның кебек ирләрне бер күрүдә һап итеп йоталар. Чәйнәп тә тормыйлар! Коллега, имеш. Монысы аңа мохер шарф алып кайткан, тегесе теш врачы белән сөйләшеп куйган. Үзләре һаман да аерылышып уйныйлар. Зарифның усал хатыннарга эләксә, күрер идең аннары коллегаңны. Йөрер идең ялгыз саескан булып, әлеге капкорсаклар кебек, корыган ботакларга кунып. Усал хатыннарны да гаепләмим. Ә нигә? Аларның да ир белән яшисе килә. Алар соң синнән-миннән кай җирләре белән ким? Айлар, еллар буена ни өчен алар салкын мендәр кочаклап ятарга тиеш? Урамда Зариф кебек ирләр барында. Бәлкем, сез моны әхлаксызлык диярсез. Юк шул! Табигать безгә ирләрне чутлап кына бирә. Бу турыда сез, медиклар, бездән яхшырак беләсез. Әгәр кайчакларны артык юмартланып китсә, шунда ук хатасын төзәтергә ашыга, ревизорларын җибәрә: ир женесләрен балыкта суга батыра, энтә ток белән суктыра, юлда кара-каршы мотоциклларны бәрелештерә. Һич югында аларны эчкечегә әйләндереп бетерә. Ирләр белән хатыннар җәмгыятьтә иллегә илле, баланска баланс булалар икән, иртәгә үк чәч бөдрәләтү, тырнак буяту бүлмәләре, косметика кабинетлары ябылачак. Хатыннар иртәгә үк ертык оектан, иске халаттан йөри башлаячак. Ә болай исә гадел көндәшлек! Карата аласың икән, теләсә кайсы ир синеке. Ә син булган иреңне дә кулыңнан ычкындыргансың икән, үзең гаепле, соңыннан мышык-мышык килеп профком ишеген таптап йөрмә.

Бу хәлне, мондый монологны, әлеге финалны башларына да китермәгән «коллегалар», ни әйтергә дә белми, аптырашта тора бирделәр.

— Судлашып аерылганнар, имеш! Оятсызлар, намуссызлар сез. Үз бәхетегезгә үзегез каршы төшүчеләр. Бәхет кошы һәркем өстенә дә алай җиңел килеп кунмый. Ә сезгә ул, күрәсең, бик җиңел эләккән. Шуңа аның кадерен дә белмисез, аяк астына салып таптыйсыз. Я, әйтегез, нәрсә җитмәде, нәрсә бүлешә алмадыгыз? Ә мин беләм сезгә нәрсә җитмәгәнен. Каеш, солдат каешы, икегезне дә ярырга сигезләп үргән камчы җитмәгән сезгә! — дип җикеренде боларга Әкълимә, колоратур сопраноның бөтен мөмкинлекләрен кулланып.

— Әһем,— дип тамак кырды Зариф.— Әкълимә?.. Без бит...

— Безнең бер-беребезгә һичнинди дәгъвабыз юк,— дип әйтмәкче булды Гөлшат.— Без бит җәнҗалсыз судлашып...

— Бирермен мин сезгә судлашып аерылышуны! — дип Әкълимә янәдән өсталгә китереп тондырды.— Зариф, син кадерлем, бүтән минем янга килеп йөрисе булма. Оныт ул сукмакны. Ә теге карт алашаны сезнең өй тирәгездә күрсәм, аягын үзем бәреп сындырам. Ә сезгә исә, кадерлекәйләрем, аңлашырга, кушылырга бер атна бирәм. Киләм, тикшерәм, белеп торыгыз. Әгәр дә ма-

гәр мин дигәнчә булмаса, сезне ничек акылга утыртырга белермен. Мин сезнең турыда республика газетасына, юк, юк, «Работница» журналына язачакмын. Череп таркала башлаган әхлакый йөзегезне бөтен илгә фаш итәчәкмен. Минме?! Сез әле мине белмисез!..

Иртәгесен Әкълимә, авырып киткән бер җырчыны алыштырырга, Әлмәткә очты. Аннары шушы труппа белән Башкортстан якларына чыгып китteләр. Бу юлы алар ике айлар чамасы йөреп кайттылар.

Дөньяда иң шифалы дәва — Вакыт агай. Доктор Вакыт иң өметсез яраларны да дәвалый, иң тирән җәрәхәтләргә дәва таба. Әлеге гастрольдән Әкълимә дә беркадәр баш-күз алып, тынычлангандай булып кайтты. Алай да Казан урамнарына бераз әнгер-меңгер төшү белән, беренче эше итеп, Һади Такташ урамындагы тугыз катлы йорт ягына китте. Алтынчы каттагы таныш тәрәзәләргә озак карап торды. Залда караңгы. Зариф белән Гөлшат бүлмәләрендә генә ут бар. Димәк, өйдәләр. Әкълимәнең күңеле җылынып китте. Бераздан ут әлеге бүлмәләрдә сүнде, залда кабынды. Телевизор карарга чыктылар, кофе эчәләрдер, дип нәтиҗә ясады. Шушы күренеш аның күңелендә һич тә усал көнчелек түгел, ә үзенә бер җылы хис, өмет, шатлык уятты.

Әкълимә гастрольдән йөреп кайткан саен әлеге йорт янына килә торган булып китте. Читтән, ерактан гына озак күзәтеп тора. Ашыга-ашыга эштән кайткан Гөлшатны күргәләде. Хатын-кыз эштән өенә ашыга икән, димәк аны анда көтәләр. Димәк, бу өйдә иминлек.

Бер кулына иске йозаклар тутырган дипломатын, икенчесенә бәрәңге-кишер салган ятьмәсен тоткан Зарифның кибеттән чыкканын очраткалады. Ир кеше өенә бәрәңге салган ятьмә тотып атлый икән, моның серен багучыдан сорашып торасы юк. Ялгыз ир андый эш белән вакланмый: акчасы булса, ресторанда ашый, булмаса — ач куна. Ә Зариф әнә ятьмә тотырып ризык ташый!

«Ай, матурым Гөлгенә, җан сөйгәннәр була бер генә», дип бер дә юкка гына җыр чыгармаганнар шул. Җан сөйгәннәр — бер генә. Әкълимә өчен ул Зариф булды, күрәсең. Такташ урамы чатындагы тугыз катлы йорт янына ул әле дә еш кына барып чыккалый. Ләкин таныш квартирага керми, карап тора-тора да кире борыла.

Марат Мусин

# ИКЕ НОВЕЛЛА

## Ышанам

Эңгер-меңгер. Елганың тар гына култыгында өч ир-ат кармак салып утыра. Салкынча җил искән саен агымсу өсте шадраланып ала, кояшның су көзгесендә чагылган яктысы сүрәнләнгәннән сүрәнләнә бара.

— Шөкер әле, көн сүрелә төште,— диде салам эшләпәле ир.

— Әйе, тик менә чиртми генә бит, каһәр,— дип сукранып алды икенчесе һәм гәзиттән ясалган эшләпәсен чирәм өстенә ыргытты.

— Дөрес сүзгә җавап юк,— диде тегеләрдән шактый яшь егет.

— Зарланмагыз әле,— диде салам эшләпә.— Эңгер-меңгердә шәп чиртә ул. Бу култыкта — бигрәк тә.

— Алайса кичкырын гына килергә иде,— диде яшь егет,— көн буе эсседә әлсерәп утырдык бит зерәгә.

— Ленар, су алып бир әле,— диде салам эшләпә.

Ленар кармагын җайлап куйды да кечкенә пыяла банка алып суга иелде. Бу вакытта яшь егет сигарет төпчеген су өстенә ташлады. Ленар аңа шелтәле карап алды.

— Янгыннан саклану чарасы,— диде егет елмаеп.

— Ай-яй, суы нинди салкын,— диде Ленар һәм сулы банканы салам эшләпәгә сузды.

Салам эшләпә яргаланган коры иреннәрен банка авызына терәде дә готтылдап су эчәргә тотынды. Ирен читләреннән саркыган су агымы муен буйлап агып китте. Салам эшләпәдән бераз түбәндәрәк утырган егет башын күтәреп аңа төбәлде. Бераздан соң карашын янә калкавычына күчерде.

— Тончыга күрмә,— диде Ленар салам эшләпәгә.

— Эчәсеңме? — диде ул банканы егеткә сузып.

— Юк, эчәсем килми, әнә балыкчыны сыйла.

Өчесе дә дәррәү көлеп җибәрделәр. Салам эшләпәле ир җәһәт кенә эшләпәсен салды да аны егетнең башына кигезде. Алар баягыдан да катырак итеп көләргә тотындылар.

— Камил, синеке чиртә бит!— дип кычкырды Ленар.

Эшләпәсез калган адәм карашын су өстенә текәде. Чыннан да, калкавыч берөзлексез чәбәләнә иде. Камил кармак сабын ныклап тотты да калкавычның су төбенә киткән вакытында гына кинәт тартып алды.

— Әһә, менә бу балык, ичмасам. Әйттем бит мин сезгә! — дип шатланып кычкырды ул. Һәм балыкны кармактан ычкындырды да сулы чиләккә ташлады.

— Хәзер каптырачакбыз!

Кояш урман артына качты. Камил, ашыкмыйча гына, кармагын яңадан саплады һәм суалчанга төкергәләп алды. Аннан соң кармагын селтәнеп ераккарак ыргытты.

— Хәзер безнең чират! — диде яшь егет.

— Карап карарбыз,— диде Камил һәм күлмәк кесәсеннән сигарет алып кабызды.

— Көн әйбәт бүген. Нәкъ чын җәй.

— Зарланырлык түгел,— диде Ленар һәм ул да сигарет кабызып җибәрде.

— Озакка барыр микән? — диде егет.

— Ә нишләп озакка бармасын ди. Болай да инде бөтен җәй көз кебек булды. Хәзер дә җәй булмаса, кайчан була ул тагын? — диде Камил, маңгаена төшкән чәчләрен арткарак сыпырып.

Шактый утырдылар, ләкин балык бүтән чиртмәде.

— Туйдырды, бәлки кайтырбыз? — диде яшь егет.

— Утырыйк әле бераз,— диде Ленар.— Балыкларга да акыл керде, ялгышлардан кешеләр генә сабак алмый күрәсең.

— Аңа, мөгаен, өе тынгылык бирмидер,— диде Камил.— Ә мин нәрсә булды микән моңа дип уйлап утырам тагы...

Һәм ул Ленарга күз кысып алды.

Егет кымшанып куйды:

— Сүзнең ни турында барганын аңламый калдым.

— Ничек аңламыйсың инде? Кыланасың тагын.

— Әйе, әйе,— диде Ленар.— Хәзер иң шәп вакыт инде. Әллә син хатыннарны бездән наданрак дип уйлыйсыңмы?

Егет кармагын судан тартып алды һәм җимен барлады да кире суга ыргытты.

— Юк-бар сөйләп утырмагыз әле. Һаман туймадыгызмыни соң?

— Тую, туймаудамыни хикмәт,— диде Камил.— Без монда синең турында кайгыртабыз.

— Ә мин үзем турыда үзем кайгыртырмын.

— Без синең турында кайгыртабыз, ә син...— дип өстәде Ленар.

— Без бит үз тормыш тәҗрибәбездән чыгып әйтәбез,— диде Камил.— синең алдаудан безгә ни файда. Безнең хакта начар уйлыйсың син.

— Нәрсәгә ирешмәкче буласыз соң сез? — диде егет, ачуы килеп.— Үзегезгә аз гына күңелсез була башласа, әллә нәрсәләр уйлап табасыз. Минем гаиләмнең бәхете турында шулкадәр кайгыртмасагыз!..

— Шулай, шулай, ә син шуны аңламыйсың,— диде Камил бернинди шаярусыз.

Егет сигаретын суырды да суга төкерде.

— Менә син Ленарга гына кара, үзе теләп хатынын ташлап киткән дип уйлыйсыңмы әллә син аны?..

Ленар аңа күз кырые белән генә карап алды. Елмайгандай итте:

— Әйе, әйе.

— Син аңа җиңел булгандыр дип уйлыйсыңдыр әле. Шулкадәр алдасын да...

Егет Ленарга карады:

— Әллә чынлап та шулай булдымы?

Камил аның артында елмаеп тора иде.

— Әйе, әйе,— диде Ленар сагышлы тавыш белән.

— Менә күрдеңме.

Егет борылды да суга карады, уйланып алган кебек булды.

— Шайтанына олагыгыз ла! Сез нәрсә, мине җүләргә санныйсызмы? — диде ул һәм елмаерга тырышты.

Камил кулын селтәде:

— Әгәр шулай уйлыйсың икән, димәк, без җүләрләр булып чыгабыз инде.

Ленар аз гына елмаеп куйды.

— Ә ни өчен әле сез нәкъ менә минем белән дә шулай булырга тиеш дигән нәтиҗәгә килдегез? Мин үземнең Әминәмә ышанам.

— Һәркем ышана,— диде Камил Ленарга ымлап,— әнә ул да ышана иде. Тик хатыннар бөтенесе бер иш алар. Хәтереңә салып куй.

— Юк, юк, ул андый түгел,— диде егет каршы төшеп.— Әйдәгез, ташлыйк әле бу сөйләшүләрне.

— Үзеңә кара инде,— диде Камил.

— Әйе, үзеңә кара,— дип кабатлады Ленар да.

— Ышан, әмма тикшер... Син менә монда утырасың, ә ул бәлки...— диде Камил.

— Шайтанына олагыгыз,— дип кисәк кенә кабынып алды егет һәм сикереп торды да кызу-кызу адымнар белән сукмак буйлап китеп барды.

— Син кая киттең?

— Тукта!

Ул кулын гына селтәде. Болар елмайдылар. Бераздан соң алар егетнең самимилегеннән көлешеп алдылар. Аннан, кирәк-яракларын җыйнап, ашыкмый гына кайтырга кузгалдылар.

Шул ук көнне төнлә милиция бүлеге бер күңелсез хәбәр алды: Аргыяр урамында үз-үзен үтергән бер яшь егетнең мәете табылган.

# Иртәгә — соңгы көн

Чикерткә моңсу гына чәрелдәп алды. Малайлар әле һаман йокламаган, шау-гөр килеп сөйләшеп ята. Ул эскәмиядән торды да башын ачык тәрәзәгә тыкты:

— Ничек уйлыйсыз, йокларга вакыт түгел микән?

Шуклануларыннан туктый алмыйча, малайлар пырхылдап көлеп җибәрде һәм бераздан тынып калды. Ул янә эскәмиягә чүмәште. Кайдадыр учак якканнар булса кирәк, төтен исе килә. «Әйе, иртәгә соңгы көн»,— дип уйлады ул.

Менә ничә ел рәттән инде, җәйге каникул вакытында, Ләмига балаларны аның янына авылга кайтарып җибәрә. Бу җәйне дә, гадәттәгечә, балаларын көтеп алды ул һәм хәзер соңгы көн турында уйламаска тырыша. Әмма бернишләп тә булмый. Ялгызлыкның нәрсә икәнен ул бик яхшы белә. Уйлап карасаң, шул җәйне генә көтеп яши дә инде...

«Әйе, иртәгә, иртәгә»...

Балаларны һаман йокы алмый, аларның пышылдашып сөйләшкән тавышлары да колакка ап-ачык ишетелә.

Ул аяклары тирәсендә җемелдәгән нәни утны шәйләп алды. Иелебрәк караса, утлы бөҗәк икән.

«Йолдызлар күккә җилем белән ябыштырылгандыр»,— дип уйлады ул.

— Тиздән әни кайтып җитәр инде. Аз гына булса да монда тагын торасы иде,— диде Айрат. Ул Равил абыйсыннан ике яшькә кечерәк.

— Әйе, җәй сизелмичә үтте дә китте,— дип җөпләде аны Равил.

Утлы бөҗәк тагын да якынайды һәм аңа аягын читкәрәк алып куярга туры килде.

— Ә ни өчен әни белән әти бергә яшәмиләр? — дип сорады Айрат.

— Белмим. Бәлки бер-берсеннән туйганнардыр, мин синең җүләр сорауларыңнан туйган шикелле. Нигә йокламыйсың?

— Ә син нигә йокламыйсың?

— Анда синең эшең юк.

— Алайса, минем йокламавымда да синең эшең юк.

Ул янә торды һәм башын тәрәзәгә тыкты:

— Әле сез һаман йокламыйсызмы? Күрәсең, үзем генә балыкка барырга туры килер инде.

— Иртәгәме?— Малайларның икесе бертавыштан кычкырып җибәрде.

— Әйе. Әмма сез, күрәм, барырга бик атлыгып тормыйсыз бугай...

— Ура! — дип кычкырдылар малайлар һәм аркаларын бер-берсенә терәп йокларга яттылар.

Таң аязып атты. Елгадан җиңелчә генә искән җил вакыт-вакыт көймәне чайпалдырып ала. Балык шәп каба, шуңа күрә дер инде кәеф тә күтәренке. Шулай да тиздән аерылышу хисе күңелгә моңсулык иңдереп куя.

«Безнең бергә булуыбыз әйбәт әле».

— Әти, балыкка барырга бүген дөрес уйлаганбыз, әйеме? — диде Равил.— Мин инде бүтән бармабыз дип уйлаган идем.

— Ә мин сезнең тагын уха ашарга теләвегезне белдем,— диде ул.

— Шә-әп,— диде Айрат.

Калкавычлар су өстендә күңелле генә уйнаклый. Уртача зурлыктагы чиләк бик тиз балык белән тулды.

«Язмышта ниндидер капма-каршылык бар,— дип уйлады ул.— Гел китәргә дип ашкынып яшә дә кабат шунда кайт инде. Парадокс түгелмени бу? Күптән онытылган сулышны монда тойдым. Мөгаен, шул кире кайтаргандыр да әле».

Балаларны озаткач, ул янә эшкә тотыначак һәм язачак та язачак. Бәлки бүгенге көн турында булыр. Реаль чынбарлык турында яисә кешелекнең иң мөһим мәсьәләләре турында.

— Әти, син кичкенә чакта ниләр эшли идең?— дип сорады Айрат һәм ике бармагын суга тыкты.

— Балык тоттым.

— Шул гынамы?— дип гаҗәпләнде Равил.

— Юк, әлбәттә,— диде ул елмаеп.

— Ә тагын?

— Хәтерләмим,— диде ул һәм уңай җавап бирә алмавына үзе дә гаҗәпләнде.

Айрат бу вакытта учына кызыксынып карый иде.

— Син ни эшлисең анда?— дип сорады Равил.

— Черки,— диде Айрат.

— Нинди черки тагы?

— Суда йөзә иде ул. Үтерергә кирәк дип уйлап торам. Инде үлмәгән булса. Әллә суга батырыйм микән?

— Җүләр дә инде син. Һәрвакыт нинди дә булса берәр юк-бар эш белән маташасың.

— Син үзең җүләр,— диде Айрат.

— Чыннан да, ташла,— дип сүзгә кушылды әтиләре.

— Бернәрсә дә аңламыйсыз сез. Бүтән тешләмәсен әле дип шулай әйткән идем мин.

Тегеләр җәелешеп көлделәр. Айрат аларга гаҗәпсенеп карады. Аннары черкине ташлады да:

— Нәрсәгә көләсез соң сез?— диде.

— Чыннан да, бер тешләүче кимеде,— дип буыла-буыла хихылдады Равил.

Алар ярга аяк басканда, кояш шактый биеккә күтәрелгән иде. Уханы шушында, яр буенда ук пешерергә булдылар һәм коры-сары әзләргә керештеләр. Аннан соң ул битләрен чылатып алды. Малайлар кычкырышып сөйләшә-сөйләшә, куак араларын караштырдылар. Кайвакыт аларның тавышлары ишетелми, сөйләшмиләр иде, күрәсең.

Куаклар тирәсеннән күләгәле урын тапты да ул җиргә ятты.

«Менә безнең җәй дә тәмамланды». Ул кинәт үзенең комсызланып тартуына игътибар итте.

«Һәрвакыт шулай тарта идем микән?»

Автобус тулы халык. Бернichә кеше аягүрә басып бара. Утырганнарның күбесе йокымсыраган, беришләре юлга караган, кайберәүләр сөйләшә. Шул сөйләшүчеләр арасыннан ике хатынның тавышы аеруча аерылып тора. Дөресрәге бер хатынныкы. Икенче хатын беренчесенең сүзләрен дәшми генә тыңлап бара яисә ара-тирә берәр сүз кыстырып ала.

— Ә мин аңа әйтәм: «Кадерлем, ярамый бит болай бер җүнсез аркасында гомер буе ялгыз яшәргә!» дим. Ә ул тыңларга да теләми. Я булмаса: «Кызым зур инде, барысын да аңлый», ди. «Соң, минәйтәм, кызың зур да булгач, озакламый кияүгә чыгар, ә син бер ялгызың утырып калырсың», дим. «Әгәр бергә булсалар, хәтта җәнлекләргә дә читлек эчендә яхшы»», дим. «Аңла, хәтта җәнлекләргә дә!» дим. Ә ул карашын бер ноктага төбәгән дә ни турындадыр уйлана. «Соң мин дә кайгыртмасам, сине кем кайгыртыр?» дим. Ә ул миңа карап ала да янә элекке халәтенә кайта. Аңлыйсыңмы?

— Аңламаска инде. Ай, хәлләр бар икән монда. Я, шуннан?

— Шуннан шул. Тыңлый-тыңлый да бер сүз дә әйтмичә китеп бара. Төрлечә әйтеп карадым. Юк, берничек тә җиңеп булмый. Карап торырга кызганыч. Һәрвакыт ялгызы. Берәр яхшы ир кирәк аңа. Ул бит үзе бик әйбәт, менә шуңа да кызганыч. Башта мин, теге җүнсезе тайгач, бу тагын шундыйга тап булмагае дип уйлаган идем. Алар бит башта барысы да яхшы. Яшәп карагач кына беләсең аларның чын йөзләрен. Карыйм — бер ел үтте, ике ел, өч ел үтте. Бу хәтле дә уйларга кирәкми бит инде. Ә ул, бактың исә, ул хакта бөтенләй уйлап та карамаган икән. Ә бит мин кибеттәге теге сарыбаш белән качкан сөйрәлчегенең кызына акча түгел, хәтта кош теледәй хат та җибәрмәгәнен белми идем.

— Хайванның да хайваны булган икән!

— Шуны белгәннән соң, йорт каршындагы мәйданчыкта Леночканы очраттым. «Ничек, әтиең берәр нәрсә язамы?» дим, ә үзем эчтән генә: «Нинди кабахәт кеше», дип уйлыйм. Леночка, «Юк, белмим», диде дә торып йөгерде. Мин тегеңәргә: «Нишлисең син? Әйдә, тизрәк судка бир, алимент ал», дим. Ә ул «Мин аны бөтенләй оныттым инде, шулай булгач, миңа аның акчасы нигә», ди.

Ләмига тыңламаска тырышты, туйдырды аны бу әңгәмә, ләкин тегеләр капчык төбен селкүне дәвам итте:

— Шуннан? Судка бирмәдеме?

— Юк.

— Инде ул, тилекәй, яхшы мөгамәләне аңламый икән, сөйләшеп торасы да юк.

— Кызганыч шул. Әйбәт кеше бит ул. Тагын кем аңа ярдәм итәр...
Автобус янә бер борылыш ясады. Ләмига урыныннан торды да чыгарга дип алгы ишеккә атлады.

Уха гөбер-гөбер кайный. Кечкенә казаннан пар күтәрелә. Кояш сүрелеп барган вакытта уханың ямьшы хәл ителгән иде инде. Хәзер алар тук һәм канәгать хәлдә җәйләшып күләгәгә яттылар. Ул, аякларын як-якка ташлап, күзләрен кыса төшеп, сигарет суыра. Гүя ул шул сигарет төтене белән тагын бер елга аерылу уен куалый иде.
— Әни!— дигән тавыш тынлыкны бүлде.
Башта ул кем тавышы икәнен аңышмыйча калды.
— Әнә, әни килә,— дип кабатлады Айрат һәм урыныннан сикереп торды да, аяк астындагы комнарны туздыра-туздыра, алга йөгерде. Ул терсәгендә генә күтәрелде дә елга буйлатып биредә таба атлаган Ләмиганы күреп алды. Равил дә торып басты, әмма урыныннан кузгалмады.
Ләмигага караган килеш ул аның йөз сызыкларын шәйләргә тырышты. Әмма ара ерак иде шул. Ул Ләмига килгән саен һәрвакыт шулай эшләвен исенә төшерде.
Ләмига кулларын җиңелчә хәрәкәтләндереп атлый. Айрат аның янына килеп җитте дә биленнән кочып алды. Ул иелде дә Айратны үпте.
— Я, ничек хәлләрегез? — дип сорады Ләмига һәм Равилгә карады.
— Барысы да яхшы,— дип җавап бирде ул.— Уха ашыйсың килмиме?
— Бик шатланып,— диде Ләмига һәм елмайды. Шулчак ул аның элеккечә үк матур икәнен, тик ирен читендәге сызыкларның гына тирәнәя төшкәнен искәрде. Гәрчә монда әллә нинди аерма булмаганын аңласа да.
— Син иртәгә килергә тиеш идең. Бер-бер хәл килеп чыкмагандыр бит? — дип сорады.
— Әйе,— диде Ләмига бераз дәшми торгач,— безгә монда тагын берәр атна ял итеп яту зыян итмәс иде, дип әйтергә килдем.

Ләбиб ЛЕРОНОВ тәрҗемәләре.

# Рәниф Шәрипов

## «Оштарма» көе

Шәмсегаләм апа, син җырлаган
Нинди матур көй ул, борынгы?
Ничә еллар саклап килдең ничек
Бу «Оштарма» дигән җырыңны?

Сәхнәләрдән әлек җырланмаган,
Бай йортларда түргә узмаган —
Бу бит халык җыры, халык моңы,
Күпме җырланса да, тузмаган.

Кеше белән кайчак җыр да үлә,
Кеше белән яши исәне.
Аз түгелдер картлар белән үлгән,
Без белмәгән җырлар исәбе...

Тагын кемнәр истә тота икән
Халыкның бу моңлы гозерен?
Җыр гомерен халык башласа да,
Җырлар үлчи халык гомерен.

## Гармунчы карт сүзе

Гармун уйныйм, ә күңелдә сагышлы моң —
Тиңсез көйләр ятим кала, нишләргә соң?
Эшләдек тә, җырладык та кирәк чакта.
Моңлы булдык, горур булдык туган якта.
Туып-үскән, чәчеп-урган җиребез бар.
Җир йөзендә хур булмаслык җырыбыз бар.
Саклый белдек иске көйләр хәзинәсен.
Беркем: «Илсез килмешәкләр сез»,— димәсен.
Гомер үтә, картлар бетә, заман башка.
Бу көйләрне белүче юк миннән башка.
Гомер чиге якынлаша, яна йөрәк.
Әй, оланнар, сезгә дә бу көйләр кирәк!
Җырсыз, моңсыз, нәселсез һәм тарихсыз — тук
Бәндәләрнең беркемгә дә кызыгы юк.
Булмас аңа таянучы, булмас аның таянычы.
Килми калмас сынык җанга хәтерсезлек аянычы.
Кабатланмас көйләребез — хәзинәбез,
Җырлый белсәк, беркемгә дә баш имәбез...
Гармун уйныйм, ә күңелдә сагышлы моң —
Бу гармунны кайсыгызга тапшырыйм соң?!

*

Бөек хисләр, сөю йолдызлары
Очып йөри хыял күгендә.
Чынбарлыкта бер тамчы наз тапмый.
Эссе чүлдә калдым бүген дә.

Инде август. Әле һаман эссе.
Ява бары йолдыз яңгыры.
Җиргә төшә сөю йолдызлары,
Үз-үзләрен юлда яндырып.

*

Сакламадым кулымдагы кош баласын,
Өметләнеп һавадагы торнага.
Ә кошчыгым мин: «Торна!»— дип аһ органда,
Качып киткән, мине көтеп тормаган.

Әнә оча, аваз бирә матур торна,
Аста кала безнең яшьлек даласы.
Миннән качкан нәни кошчык — булган икән
Чыпчык түгел, чып-чын торна баласы...

*

Көйдем... Сөйдем... Ирештем...
Күкләргә менеп төштем.

Төштем сагыш җыярга,
Кимеп купме хыялга.

Җир болытлы, күк аяз.
Шулмы сөю? Шулмы наз?

Кая бәхет? Кая моң?
Гүргә иртә... Күккә соң...



**А. Н. Хәйруллов,**
КПССның Апас райкомы беренче секретаре

# ЗӨЯ БУЕ ЙОЛДЫЗЛАРЫ

Без матурлыгы бизәк булып җырларга кучкән мәшһүр Зөя буенда яшибез. Сәер елга: урманнар-кырлар аша, чал Иделне эзләп, аның белән янәшә үк, ләкин «үргә» — төньякка йөгерә ул. Апас җирендә аңа дистәләгән кечкенә елгалар килеп кушыла һәм куәтен арттыра. Районның файдаланудагы ике йөз мең гектардан артык җире, утыздан артык авылы нәкъ шушы Зөя тирәлегенә урнашкан. Бу кыр-басулар калкулыкларга да күтәрелә, үзәнлекләргә дә төшә, күп урында ышна җирләрен дә били.

Мәгълүм ки, һәр төбәкнең, анда яшәүче халыкның гасырлар кичкән бай тарихы һәм якты киләчәге бар. «Подберезье» колхозы кешеләре шул исемдәге авылның үзәк мәйданында, мәһабәт культура йорты каршында бөек Ленинга һәйкәл куйдылар. Элек бу урында җир өчен көрәшкә күтәрелгән Подберезье авылы крестьяннарының каны тамган. Патшаның ышанычлы ялчысы булган губернатор, рәхимсез казаклары белән шушы төбәккә килеп, бары тик җир-су теләгән ярлыларны җәзага тарткан. Тагын берчакны, «тарих мең дә сигез йөз дә туксанынчы санәдә», безнең Шәмбалыкчы авылы тирәсендә ышна җире өчен дәгъва куба. Бу турыда халык авыз иҗатында «Ышна бәете» дә бар:

*«Губернатор киләдер,*
*Казаклары артында.*
*Балыкчылар Себер китте*
*Ышна җире хакында».*

Монда да тормыш өчен, бары тик тамак хакына меңьяшәр урманнан, агач тамырларын актара-актара һәм түтәрәмләп җир даулап алган Шәмбалыкчы крестьяннарының кулына богау салына.

Алтмышынчы еллар ахырында «Байрак» колхозчылары Тутай авылында революция солдаты, ялкынлы агитатор Садыйк Әктәмовка һәйкәл ачтылар. Садыйк Әхтәмов ленинчылар белән янәшә зур революцион эш алып бара. Ул Ленинның ялкынлы докладын тыңлый, Калинин белән очраша. Гражданнар сугышында Октябрь казанышларын яклап сугыша, Н. К. Крупская белән бергә «Красная Звезда» пароходында йөреп, Идел һәм Кама буйларындагы халык арасында яңа тормыш өчен зур агитация эше алып бара. Апас ягында революционерка, народниклар тарафдары Вера Фигнерның балачагы уза. Вера Николаевна үз исемен йөрткән колхозга Совет власте елларында да кайтып йөри. Апаслылар большевик-көрәшче һәм журналист Вәли Шәфигуллин, Беренче татар полкы командиры Әхмәтша Сабитов кебек революция һәм Ватан өчен батыр хезмәт күрсәтүче якташларыбызны горурлык белән искә ала.

Шунысы кызыклы, борынгы кешеләр утрак тормыш өчен иң беренче безнең Тау ягын сайлаганнар. «Шундый поселокларның калдыклары,— дип язган «Татарстан АССР тарихы»нда,— Татарстанда Зөя елгасы буена урнашкан Кабык Күпер авылы... янында табылган». Хәзерге Дәвеш авылы тирәсендә яшәгән борынгы кешеләр торагыннан да хезмәт һәм аучылык коралларын табып алганнар. Безнең Зөя яклары борын-борыннан кешене шулай үзенә тарткан, аңа үзенең байлыкларын күрсәткән. Сүз уңаенда, Татар-

станда тәүге гидроэлектростанциянең дә Зөядә. Дәвеш авылы янында корылуын, аның колхозара ГЭС саналуын һәм тирә-як авылларга да электр уты бирүен әйтсәк, урынлы булыр.

Мәгълүм булганча, Бөек Октябрь җиңүеннән соң В. И. Ленинның ГОЭЛРО планын төзүгә һәм аны тормышка ашыруга керешәләр. Шатура электр станциясенең нигезен салуда Апас районы егетләре дә актив катнаша. Мингали Хөсәенов бригадасы аеруча зур фидакарьлек күрсәтә. Чирмешән авылыннан киткән бу егетләр анда ярыш байракларын яулап алалар. Шатура сазлыкларында Ильич лампалары кабынгач, апаслылар станциягә ягулык белән тәэмин итүдә шефлык булдыралар. Бер Чирмешән авылыннан гына да ел саен торф чыгаруда сиксәнгә якын кеше катнаша. Монда эшчеләр белән крестьяннар арасында чын дуслык бөреләнә һәм ныгый. Шатура эшчеләре Чирмешәндә клуб сала, яңа оешкан колхозга трактор бүләк итәләр. Бу — тирә-якта беренче машина була.

В. И. Ленин исемендәге Мәскәү метрополитенының беренче линиясен төзегәндә исә безнең Чүрибураш авылыннан барган Вазыйх Җамалетдинов һәм аның якташлары матур үрнәк күрсәтә. Күренекле шагыйрь Е. Долматовский Җамалетдиновны «асылташлардай кыйммәтле казылмалар белән тулы кеше-тау» итеп сурәтли. Чехословакиянең милли герое, ул чагында Мәскәүдә «Руде право» газетасы хәбәрчесе Юлиус Фучик метро төзүчеләргә багышланган очеркында: «Вазыйх Җамалетдинов — Метростройда бик яхшы бригадир»,— дип яза. Илнең индустрия флагманы булган Магнитогорск металлургия комбинатын төзүдә оештырылган ярышта Нурулла Шәйхетдинов, Зариф Сәгъдиев бригадалары алда бара. Безнең Кормаш авылы кешеләреннән төзелгән Хәбибулла Галиуллин бригадасы бетон салуда дөнья рекорды куя. Бригада Бөтенсоюз социалистик ярышында да җиңүче була. Американың 1931 елда Советлар Союзына килгән «Мак-ки» фирмасы инженеры Девис үзенә аңлаешлы булмаган иҗади күтәренкелек турында шаккатып сөйли, ниндидер татар эшчеләре бетон салуда, американнарны уздырып, дөнья рекордлары куялар, дип, аптыравын белдерә. Галиуллин Магниткада — Ленин орденына, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнарына лаек була. Бригада члены, якташыбыз Мөхәммәт Зиннуров монда «Магнитка йолдызы» булып үсә, аңа 1951 елда Дәүләт премиясе лауреаты исеме бирелә, язучы А. Фадеев Зиннуров һәм аның хезмәттәшләре батырлыгы турында «Кара металлургия» исемле роман яза башлый. Магниткага нигез салучыларның уллары, оныклары хәзер анда корыч коя. Көрәктән башлаган безнең егетләр гигантлар белән идарә итәләр. Әле ничек кенә! Апас урта мәктәбен тәмамлаган Владимир Садовников Урал заводларының берсендә ике мәртәбә Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булды.

Мәгълүм булганча, ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Үзәк башкарма комитеты 1931 елда «Татарстанның социалистик төзелеш Герое» исеме бирүне гамәлгә кертәләр. Ул — производствода югары нәтиҗәләргә ирешкән, илнең җәмәгать һәм политик тормышында активлык күрсәткән кешеләргә республика Үзәк башкарма комитеты карары белән бирелә. Бу исемне беренчеләрдән булып «Искра» (хәзерге «50 лет Татарии») колхозы терлекчесе Герман Иванович Ионов ала. Республикада мәгарифне оештыруда һәм кадрлар хәзерләүдә күп хезмәт куйган талантлы педагог Мозаффар Мөштәриев тә шундый зур исемгә ия була. Бу героебызның теләкләре тормышка ашканын район мисалында да күрәбез. Хәзер мәктәпләрдә җиде меңнән артык бала укый, аларга алты йөздән күбрәк педагог белем бирә. Районның үзендә үк музыкаль һәм профессиональ-техник белем дә алырга мөмкин. Ә гомумбелем мәктәпләре дүрт дистәгә якын исәпләнә. Чирмешәндәге — урта. Мәлкидәге сигезьеллык мәктәпләр йөз еллыкларын бәйрәм иттеләр. Анда белем нигезләрен өйрәнгән һәм вузларда укып белгечлек алган яшьләр илебез халык хуҗалыгында уңышлы хезмәт итә.

Апас районы 1930 елда төзелә. Күмәк хуҗалыкларга берләшкән авылларда, ызаннары кушылган кыр-басуларда беренче хезмәт йолдызлары кабына. Республикада тәүге машина-трактор станцияләреннән саналган Мөрәле МТСында җир хезмәтенең чын талантлары үсеп чыга. Утызынчы еллар башында тракторчы булган комсомолка, тракторчылар бригадиры Нурдидә Вәлиеваның исеме бөтен республикага билгеле. Ул колхоз ударниклары сафына баса. Нурдидә үрнәгендә бик күп хатын-кыз тракторчылар тәрбияләнә. Энгельс исемендәге колхоз механизаторы Камәрия Җиһаншина кырык елдан артык тракторда эшли, Ленин ордены белән бүләкләнә. «Байрак» колхозының алдынгы механизаторы Мөнирә Сәмигуллина, туган кырларында намуслы һәм нәтиҗәле эшләп, хөкүмәтнең Хезмәт Кызыл Байрагы орденына лаек була.

Ул елларның хезмәт сәхифәсендә бик күп батырларның исемнәре язылган. Мәгълүм булганча, трактор эшләренең һәм бер тракторга эшкәртүнең дәүләт планын үтәү буенча Татарстан 1935 елда СССРда беренче урынны алды. Иң яхшы унбиш тракторчы Ленин ордены белән бүләкләнде. Алар арасында безнең районның танылган тракторчылары Кашаф Садриев һәм Гали Галиуллин да бар иде. Олы бүләккә лаек булучыларның беренчесе Бөек Ватан сугышы фронтларында батырларча һәлак булды, икенчесе гомеренең соңгы көненә кадәр игенче исеменә тугры калды. Садриев үскән Зур Русак авылында бүгенге көннең танылган механизаторы Рәхим Рәхмәтуллин яши. Ул Ленин ордены һәм ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде. Гали ага Галиуллин Тукай исемендәге колхозның Шыгай авылыннан иде. Бу хуҗалык районда иген культураларыннан мул уңыш алуы белән танылды. Монда ил шаулаткан тракторчылар эшен бик яхшы дәвам иттерердәй Хезмәт Даны орденнарының тулы кавалеры Василий Игнатьевич Аверьянов кебек механизаторлар үсеп чыкты.

Тарих шаһит: 1938 елда илдә СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән Социалистик Хезмәт Герое дигән яңа почетлы исем кертелде. Бу исемне районыбыз кырларында Антонина Ивановна Евдокимова яулады. Сугыштан соңгы авыр еллар иде ул. Эшче куллар җитешми, техника аз. Әмма Бөек Җиңүдән рухланган колхозчы хатын-кызларыбыз сугыш җимереклекләрен бетерүгә күтәрелгән илне ашлык белән тәэмин итү өчен яңа дәрт, икеләтә тырышлык белән эшлиләр. Антонина Евдокимова звеносы «Подберезье» колхозында гектардан 30,1 центнер уңыш алуны тәэмин итә. 1948 елда батыр игенченең күкрәгендә Алтын Йолдыз һәм Ленин ордены балкый. Социалистик Хезмәт Герое исеменә Мөрәле МТСы комбайнчылары Бари Гарифуллин белән Рифкать Кәлимуллин (икесе дә Борындык авылыннан) лаек булалар. Хәзер Социалистик Хезмәт Герое исемен яулаган якташларыбыз арасында Мәгъсүмә Кәлимуллина, Мария Турунтаева, партиянең XXII съезды делегаты Семен Никитин, Аграфена Сергеева, Рәис Заһидуллин кебек терлекчеләр, эшче һәм транспортчылар бар. Евдокимовалар беренчеләр иде. Алар хезмәт батырлыгына юл салдылар. Ул елларда партиянең XIX съезды делегаты, СССР Верховный Советы депутаты, ике Ленин орденлы комбайнчы Закир Фатыйхов зур хезмәт батырлыклары күрсәтте. Ленин орденлы көшчы, КПССның XXIII съезды делегаты Асия Закирова намуслы хезмәтнең илдә хөрмәтләнүен тагын бер кат танытты. Апаслылар һәрчак шулай хезмәтнең үзәгендә кайнадылар. Без Ленин орденлы механизаторларыбыз Александр Куликов, Рәхимулла Зиннуров, Раһип Гайнуллин, Нәриман Гыйльметдинов, СССР Верховный Советы депутаты Расим Шәрәфуллин һәм башка талантлы колхозчылар белән горурланабыз. Бишьеллыклар чорында хөкүмәтебезнең олы бүләгенә районның йөзләгән кешесе лаек булды. Татарстан АССР Верховный Советы депутаты Габделхәмит Вәлиев җитәкләгән Ленин исемендәге колхозда терлекче Шәрәфетдин Галиуллин, зоотехник Эфраим Ибәтуллин, колхозның элекке председателе Кәбир Ибраһимов күкрәкләрендә Ленин ордены йөртәләр. Артталыктан күтәрелгән бу хуҗалык басу һәм ферма продукциясен күбрәк җитештерү өчен көрәшүче колхоз һәм совхозлар ярышын әйдәп бара.

Ирекле тормыш, тыныч хезмәт кадерен белгән һәм ныгытырга омтылган Апас кешеләре Бөек Ватан сугышында ил азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен арысландай көрәштеләр. Моңа сугыш ветераннарының орденнары шаһит. Якташларыбыздан Дмитрий Горбунов, Андрей Кошкин, Рем Афзалов, Салават Кәримов, Михаил Кузьмин, Иван Федоровның фронттагы батырлыклары Советлар Союзы Герое исеме белән билгеләнде. Районда Дан орденнарының тулы кавалерлары да бар.

Апас ягы — моңлы як, җырчы як. Ул илебезгә бик күп әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре биргән. Г. Тукайның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнгәндә шагыйрь Габдулла Харис белән дә танышабыз. Ул — безнең як кешесе, укытучы, бөек шагыйрь белән бер чорда иҗат иткән, Тукайдан күп киңәшләр алган. Чүти авылында туган шагыйрь, прозаик, әдәбият тарихына караган монографик хезмәт һәм мәкаләләр авторы Зариф Бәшири дә Тукай белән бер елларда иҗат итә, хезмәтенә карата Тукайның фикерен ишетә. Якташыбызның әсәрләрен башкортлар да, чувашлар да яратып укый. Аның «Чуваш кызы Әнисә» исемле повесте берничә телдә басылган. Әбрар Сәгыйди, Мансур Крымов, Садри Җәләл, Әгъзам Камал да әдәбиятка бездән юл тотканнар. Уфада һәм Мәскәүдә яшәп иҗат иткән әдәбият белгече, тәнкыйтьче Шиһап Шәһәретдиновның туган ягы — безнең Чирмешән авылы. Якташыбыз, татар совет поэзиясендә бай әдәби мирас калдырган Гали Хуҗи (ул Карамасардан) авылдашлары, бертуган Габдулла һәм Рахман Ильясов-

лар иҗаты турында сокланып яза. Габдулла Ильяс — күп санлы хикәяләр һәм күләмле әсәрләр авторы. Рахман Ильяс сәхнә әсәрләре, Грозный нефтьчеләренә багышлап «Горизонт» исемле повесть иҗат итә. Ул сугышта — миномет ротасы командиры, батырларча һәлак булганнан соң Кызыл байрак ордены белән бүләкләнә. Зур Кайбыч егете, хәрби юрист һәм язучы Әбрар Шамин да әдәбиятта якты эз калдырды. Әдәбият мәйданында районда белем алып һәм хезмәт итеп чыккан шагыйрь Шәүкәт Галиев Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә һәм халыкара бүләккә — Г. Х. Андерсен исемендәге Почетлы дипломга лаек булды. Без якташыбыз, шагыйрь Илгиз Кәлимуллин иҗатына да сокланабыз.

Тел һәм әдәбият белгечләрен дә юмарт биргән Апас. Күренекле әдәбият галиме профессор, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе Мөхәммәт Гайнуллин безнең Кызыл Тау авылында туган. Галим гомере буе туган ягы белән элемтәсен өзмәде. Филология фәннәре докторы, профессор Габдрахман Таһирҗанов, тәнкыйтьче, әдәбият тарихчысы һәм тел галиме Җамал Вәлиди, дәреслекләр авторы Шәриф Сайкин да — безнең якташлар. Апас чишмәләре саекмый. Бүгенге әдәбият сөючеләр һәм башлап язучылар «Тамчылар» әдәби берләшмәсендә иҗат итәләр.

Зөя җирләре академик Гайфетдин Галиев, профессор Коновалов һәм башка йолдызлырны кабызган.

Апаслылар сәнгатьтә дә өлгер булып чыктылар. Шәмбалыкчы — РСФСРның халык артисты, республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты татар опера театры тарихында тирән эз калдырган җырчы Фәхри Насретдинов дөньяга килгән авыл. Аның туганы, опера сәнгате остасы, РСФСРның халык артисткасы Бану Вәлиева да Шәмбалыкчыдан. Ул Уфада башкорт тамашачысын сокландырып яшәде. Якташыбыз Галия Кайбицкая (ул Кече Кайбыч авылыннан) зур ихтирамга опера сәхнәсендә иреште, халыкка җыр, моң белән хезмәт итте. Галия Кайбицкая — Татарстанның халык артисткасы. Шундый зур исемгә якташыбыз актер Каюм Бариев та лаек булды. Балет остасы Вәли Галкинга Татарстанның атказанган артисты исеме бирелде. Шушырмә авылында татар курчак театрына нигез салучы, гомере буе шунда әкият геройларының образын тудыручы, Татарстанның халык артисты, драматург һәм тәрҗемәче Фуат Таһиров туган. Аның хатыны Галия Таһирова да курчак театрында Татарстанның атказанган артисты исемен алды. Монда талантлы артист якташыбыз Вәли Гафаров та эшләде. Танылган композитор Әгъзам Фәттах — Шәмәк авылыннан. Ә Рус Ябалагы (Бүәле) авылында туып-үскән мәшһүр композитор Латыйф ага Хәмиди Муса Җәлил шигырьләрен көйгә сала, аның сүзләренә тәүге әсәрләреннән саналган «Беренче вальс» һәм «Дәртле яшьлек» маршын яза. Аның казах дуслар илендә иҗат иткән «Казах вальсы» дөнья гизә, «Абай» һәм «Түлегән Тохтаров» операсы олы сәхнәдә күрсәтелә. Ике хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры, Казахстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Латыйф Хәмиди апаслыларга хас матур хезмәт юлы үтә. Без якташ рәссамнарыбыз Таһиров, Фәсхетдинов һәм Баһаветдиновның да рәсем сәнгатендә үз юлларын табуына шатланабыз.

Апас җирендә культура учакларының киң челтәре бар, халык театры, ветераннарның «Садә» ансамбле, һәвәскәр рәссамнар түгәрәге эшли. Яшьләрдән дистәләгән кеше культура һәм сәнгать уку йортларында белем ала.

Узган юл матур. Яшьләребез исә һәр тармакта яңа гүзәл сәхифәләр язарга тырыша. КПССның XXVII съезды карарларын намус белән үтәү өчен көрәш бара. Ленин исемендәге, Куйбышев исемендәге, «Восход», Горбунов исемендәге һәм башка колхозлар ярышып эшләүчеләрнең авангардын тәшкил итәләр. Ашлык, шикәр чөгендере, ит, сөт һәм башка төр азык-төлекне күбрәк җитештерү өчен көрәш дәвам итә. Зөя басуларыннан һәм фермаларыннан, киң урманнарыннан дәүләткә байлык китә. Нәтиҗәле, максатлы хезмәт кешеләребезнең гомер юлында, йолдызлар булып, якты эз калдырып бара.

Казан утлары АЭС әдәби пост

## Хәмзә Бәдретдинов

# ТӨЕННӘРНЕ ЧИШКӘНДӘ

Ут капкан диярсең, ишекне дә шакып тормыйча, комсомол секретаре бүлмәсенә бер егет атылып керде. Ул, кулындагы конвертын болгый-болгый, йөзенә чыккан шатлыгын уртаклашырга ашыкты.

— Надяның әтисеннән хат килде!

Реактор бүлегенең машина залын төзүдә катнашучы «Турбострой» участогының комсомол-яшьләр бригадасы җитәкчесе, Зәй егете Владимир Крылов кулында җавап хаты иде. Ә моңарчы утыз эшче Киев шәһәре белән үзләре элемтәгә керделәр. «Комсомольская правда» газетасында басылган «Дусларын эзлим» дигән ун юллык хәбәрне уку белән, Чернобыль атом электр станциясендәге янгынны сүндерүгә беренчеләрдән булып керешкән, үлгәннән соң Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган Владимир Правикның хатыны Надяга утыз имза куелган хат салдылар. Анда түбәндәгеләр язылган иде:

«Исәнмесез, Надя!

Сезгә яңа төзелүче Татарстан атом электр станциясенең Советлар Союзы Герое Владимир Правик исемендәге комсомол-яшьләр бригадасы коллективы яза. Сез, «Комсомолка» аша, Правик дусларының тавыш бирүләрен сорагансыз. Дөрес, без хәзергә аның иптәшләре исемлегенә теркәлмәгәнбез. Шулай да сезнең җавабыгыз безне дуслаштырыр дигән уйда калабыз.

1986 елның октябрендә, АЭСның беренче блогын төзүдә катнаша башлагач, бригада егетләре Владимир Правикны үз сафларына алырга карар иттеләр. Аның исеменә җыелучы хезмәт хакы Бердәмлек фондына күчерелә. Правик — безнең өчен егетлек һәм батырлык үрнәге. Күңелсез вакыйгаларның шаһиты булган Правик безгә: «Мондый хәлгә бервакытта да юл куймагыз!»— дип әйтә сыман.

Электр энергиясенең илгә һава кебек кирәклеген белгәнгә күрә, без табигать көйсезлеге, производство кыенлыклары белән исәпләшмичә эшлибез. Иң авыры — торак мәсьәләсе. Дөрес, соңгы вакытта бу юнәлештә берникадәр алга китеш сизелә, 980 урынга исәпләнгән тулай торак, 20 ишекле биш катлы йорт салынды. Ике балалар бакчасы төзелеп беткәч, нарасыйлар өчен дә уңайлыклар артачак. Ә балалар бездә күп. Челтерәп аккан чишмә тавышы сыман, һәр ишегалдында сабыйларның яңгыравыклы һәм шат авазы ишетелеп тора.

Украинадан, Кара туфраксыз зонадан, Урта Азия һәм Кавказ арты республикаларыннан төзелешкә бик күп егетләр-кызлар киләләр. Турысын әйтик, барысы да яшәп китә алмый. Аның каравы, кыенлыклар белән көрәшергә сәләтлеләр, матур киләчәккә ышанучылар, чын хезмәт батырлары монда калалар. Алар синең Володя кебекләр, бүгенге көн каһарманнары!

Безнең чордашлар Володя турында күбрәк белергә тиеш, аның тормыш юлы белән тәфсилләбрәк таныштырсагыз, без бик шат булыр идек».

Җавап озак көттермәде. Надяның әтисе Иван Андреевич язган иде хатны. «Хәзергә кызымны куанычлы хәбәрләр белән дулкынландырырга ярамый,—

дигән ул.— Шуңа күрә кулга үзем каләм алдым. Бу көннәрдә безнең гаилә сезнең Володяга күрсәткән игътибарыгыз тәэсирендә яши. Карап торышка, киявебез тормышында искитәрлек бернәрсә дә булмады кебек, ә шулай да аның турында озын-озак итеп сөйләргә мөмкин. Володя балачактан ук янгын сүндерү эше белән мавыкты, дәфтәренә Лев Ошанинның «Ут хуҗасы» исемле поэмасын күчереп язды. Ул аны яттан сөйли иде... Ә берничә елдан шул ук шагыйрь Лев Ошанин Володя Правикның үзе һәм аның иптәшләре турында баллада язды»...

Менә ул баллада каһарманы! Киевтан җибәрелгән фоторәсем Татарстан атом электр станциясен төзүчеләрне Владимир белән күзгә-күз «очраштыра». Карточкадан гади генә егет карап тора: чәче янга таралган, түшенә Бөек Ленин сурәте төшерелгән комсомол значогы беркетелгән, карашы ниндидер билгесез биеклеккә төбәлгән. Һәр совет кешесенә хас портрет. Кирәксә, шушындый гади егетләр ил өчен утка керәләр! Саф күңелле, батыр рухлы Володя, планета иминлеге хакына, туганнарын, хатынын, ике баласын калдырып, ялкынлы бөҗра эченә ташланган. Менә нинди була ул патриот! М. С. Горбачев ВЛКСМның XX съездында әйткәнчә, «патриот — Ватанга мәхәббәт турында матур сүзләр сөйләүче түгел, ә кыенлыкларны һәм хәл ителмәгән проблемаларны күргәндә сукранмаучы, төшенкелеккә бирелмәүче, үзенең эгоистлык дәгъвалары белән йөрмәүче, ә җиңнәрен сызганып киртәләрне бетерә баручы кеше ул». АЭС төзелешенә бүген нәкъ шундыйлар кирәк!

Татарстан атом электр станциясе төзелешенең комсомол комитеты секретаре Владимир Фомин батыр егетнең рәсеменә озак карап торды. Аннары түшенә Алтын Йолдызын тагарга өлгермичә арабыздан китеп барган Геройның фотосын Түбән Кама шәһәреннән Кама Аланына эшкә урнашырга килгән эретеп ябыштыручы Р. Мингалиевка сузды:

— Менә кемгә охшарга тырышу кирәк, Ринат! Володя, әнә, утка кергән, ә кайбер яшьләр тыныч җирдә дә юньләп эшләргә теләмиләр. Акча гына булсын аларга!

Секретарь сынаулы караш ташлады:

— Менә яшермичә әйт әле, бу төзелешкә нинди уйлар белән килдең?

— Минме? — Егет чатлатып әйтеп бирде.— Өр-яңа шәһәрне, шундый заманча станцияне төзүдә катнашасым килде. Хатыным — тәрбияче.

Егетнең сүзләре «Эшкә килүчеләр» кенәгәсенә теркәлде. Ә янәшәдә — китүчеләр исемлеге. Андыйлар да бар. ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты 1985 елның январеннан «Республиканың иң мөһим комсомол төзелеше» дип игълан иткән АЭС төзелешеннән нигә китәләр соң? Дәфтәргә аларның китү сәбәпләре дә язылган. Балта остасы Сергей Будин — гаилә хәле буенча, шофер Хәмис Хабибелханов — торырга урын булмаганлыктан, нормировщица Зөлфия Саматова тормыш шартлары ошамаганлыктан китү ягына борылган. Ә менә Брежнев шәһәре кызы Зөлфия Шабановага нәрсә җитми? Булмасе, эше булса да, ул берничә ай буе хезмәт урынына килеп тә күренми. Ни өчен болай кылана ул? Сорауларга ачыклык кертү ниятеннән, сылаучы-буяучыны комсомол комитетына чакырдылар. Әңгәмәне секретарьның идеология эшләре буенча урынбасары Николай Крюков башлады:

— Чираттагы ялдан соң Зөлфия югалды. Исәптә бар, бригадада юк. Нигә эшкә чыкмыйсың, Зөлфия? Барысы турында да ачыктак-ачык сөйлә әле!

Унтугыз яшьлек кыз дәшми. Берни булмагандай, гамьсез карашын стенага төбәп, астыртын гына елмаеп утыра бирә. Йөзендә оялуның әсәре дә юк! Япь-яшь килеш дөньяга битараф булырга кай арада өлгергән ул?!

Тынычлыгын саклап калырга, кызып китмәскә тырышып, сүзгә комсомол комитеты секретаре В. Фомин кушылды:

— Зөлфия, ничә бала үстерәсең?

— Сигезәү, мин төпчеге.

— Эшләмәгәч, нәрсә хисабына яшисең соң син? Кайберәүләр кебек, бүләмәдән-бүлмәгә йөрисеңме?

— Юк, эти-әниләр ашаталар. Иптәш кызым ашханәдә эшли...
— Кеше җилкәсендә күпме яшәргә уйлыйсың?
— ...
Тагын тынлык. Бу ни хәл? Зөлфиянең Кама Аланыннан китәсе дә, эшлисе дә килми. Җитмәсә, аны инде Виктор Менжарев бригадасына кабул итәргә дә теләмиләр. «Безгә бер көн эшләп, өч көн ял итә торган кешеләр кирәкми!» — диләр. Бары бер генә юл кала: З. Шабанованы хезмәт турындагы законнар кодексының 33 нче статьясы нигезендә эштән куарга! Хезмәт кенәгәсенә мондый тамга салынгач, кая барып урнашыр соң ул? Эшче кулларга кытлык сизелсә дә, мондый җилкуарны Татарстан АЭСы төзелешенең бер генә участогына да якын җибәрмиләр бит. Бөтен ил буенча таралган чакыру-игъланнарда бу турыда ачыктан-ачык язылган: «РСФСРның хезмәт турындагы законнар кодексының 33 нче статьясы, 4 нче пункты нигезендә хезмәт дисциплинасын бозган өчен эштән чыгарылучылар, бер елда өч ай буе сәбәпсез хезмәттә катнашмаучылар, үз теләкләре белән эшләрен еш алмаштыручылар, җинаять кылган өчен җавапка тартылучылар, паспорт режимын бозучылар эшкә кабул ителми» — диелгән. Хезмәт биографиясен яңа гына башлап җибәргән кыз ни өчен моның белән исәпләшергә теләми?

— Зөлфия Брежнев шәһәренең 47 нче һөнәр училищесын тәмамлаган,— диде Н. Крюков авыр сулап.— Безгә бөтен группалары белән килделәр. Күбесе монда төпләнә алмады. Гариза яздылар да Брежневка сыздылар. Бу кызларның кыланышлары кырга сыймый! Тарталар, эчәләр, алар яшәгән тулай торакта шикле ампулалар, шприцлар да очраштыргалый иде...

— Мондый юлдан язганнар бик күп икән диген фикердә калмагыз тагын.— Үз ризалыгы белән гаять катлаулы участокка, «Татэнергострой» идарәсеннән килгән комсомол комитеты секретаре В. Фомин шулай диде.— Андыйлар бармак белән генә санарлык. Төзүчеләребезнең җитмеш проценты утыз яшькә кадәрге егет-кызлар бит! Аларны торакка урнаштырып, эш белән генә тәэмин ит!

Сүзен дәлилләр белән ныгытырга теләп, Володя китап шкафы өстеннән калын альбомны алды:

— Менә безнең нинди уңганнарыбыз бар!

Төзелеш барышын чагылдыручы фоторәсемнәр, тарихи фактлар теркәлгән альбом ВЛКСМның XX съезды уңаеннан «XX съездга — 20 удар атна!» девизы белән барган ярышны сурәтли. Беренче атна. Ул 1986 нче елның 10—17 ноябрь көннәре. Атнаның җиңүчесе — йортлар төзү комбинатындагы 12 нче төзелеш-монтаж идарәсенең Надежда Макеева бригадасы. Коллектив планны 128,9 процентка үтәгән!.. Егерменче атна. Татарстан атом электр станциясе төзелеш идарәсенең 5 нче төзелеш участогындагы Артур Уразаев бригадасы беренче урынга чыккан. Егерме атналык эшкә йомгак ясаганда А. Галкин, У. Наурбиев, Н. Алимбәков җитәкчелек иткән комсомол-яшьләр бригадаларын билгеләп үткәннәр. Шәхси беренчелектә монтажчылар Фәрит Хәсәншин, Рәшит Хисамов, Рафик Журманов, ташчы Самат Сәхәбиев, сылаучы-буяучылар Галина Кулакова, Халидә Боргашева, Лиза Мельникова, скреперчы Николай Титков, бетончы Хәнәфи Сәләхетдиновка тиңнәр табылмаган. Альбомда аларның хезмәт җитештерүчәнлеге, эш алымнары турында да байтак мәгълүмат тупланган. Шәһәр тарихы музеенда урын алырлык елъязма бу!

Удар комсомол төзелеше штабы каршындагы стендны да шундый хәлдә күрәсе килгән иде. Тик ул шып-шыр. Анда ярыш нәтиҗәсен, эштәге кимчелекләрне чагылдырган ник бер «Яшен» яисә «Комсомол прожекторы» булсын?! Монысы 900 гә якын егет-кызны берләштергән комсомол оешмасының бик матур эшләренә күләгә төшереп тора. Бу хакта сораштыра башлагач:

— Штаб председателебез Наил Туйкинны поселок Советына алдылар, шуңа күрә. Анда да энтузиастлар кирәк бит!

Республиканың удар комсомол төзелеше штабын күпме хуҗасыз тотарга

мөмкин соң? КПСС өлкә комитетының май аенда (1987 ел) узган бюро утырышында комсомол оешмалары алдына конкрет бурычлар куелды. Анда билгеләп үтелгәнчә, «атом электр станциясе объектлары комплексын төзү директив срокларДан шактый артта калды. Төп корылмалар буенча эш бер елга соңарып башланды. Узган ел бетон заводын, җибәрү-резерв котельныен һәм сигез километр озынлыктагы җылылык трассасын, кайбер башка объектларны файдалануга тапшыру тәэмин ителмәде. Станцияне проектлау һәм яхшы сыйфатлы проект-смета документлары белән тәэмин итү канәгатьләнерлек алып барылмый. Торак, социаль һәм культура-көнкүреш объектлары төзү темпының түбән булуы аркасында эшче көчләр җитми». Ә 1987 елда төзелеш производство базасының барлык объектларын салуны тәмамларга, 1989 елга кадәр 2, 3, 4 нче энергоблоклар коруда эшне киң җәелдерергә, 1990 елда беренче энергоблокны файдалануга тапшырырга кирәк. Алда менә нинди гигант бурычлар тора! Аларны хәл итүдә удар комсомол төзелеше штабының роле зур булырга тиеш!

Эшне нәрсәдән башларга? Көннең мөһим бурычлары нинди? Һәр атнаның чәршәмбесендә уза торган штаб утырышларында бу сорауларга төгәл җавап табыла. Бу көнне Кама Аланында берничә җыелыш уза. Ленин орденлы «Камгэсэнергострой» берләшмәсе начальнигы Евгений Батенчук — производство, аның урынбасары Надир Салихов көнкүреш мәсьәләләрен анализлыйлар. Ике атнага бер мәртәбә берләшмәнең профсоюз комитеты председателе Юлия Пронина социалистик ярышка йомгак ясый. Комсомол комитетының эш алымына яңалыклар менә каян табыла?!

Комитет секретарена бигрәк тә Ю. Пронинаның эш стиле ошый. Юлия Сергеевна килү белән производство участокларында, социаль-көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларында, тулай торакларда йөреп чыга. Яңа салынган культура йортында эшлекле әңгәмә уздыра.

Беренче юлы килгәч, аны культура йорты директоры Сергей Бровкин туктаткан иде:

— Юлия Сергеевна, бию залына күз салыгыз әле?!

— Әйдәгез, карыйбыз.

— Яз-көзләрен бик эссе монда, вентиляция юк.

— Нәрсә эшләргә киңәш итәсең, Сергей?

Директор урындыклар янына килде, утыргычтан бармагы белән тузан сөртеп алды:

— Бию «сөреме» бу, Юлия Сергеевна, урын кысанлыктан, бөтен дөньяны тузан баса. Мәйданчыкны киңәйтәсе, кая да булса урамда ясыйсы иде.

— Яхшы, Сергей, уйлашырбыз.

Профком председателе вәгъдә сүзен биреп, залга керде. Анда аны профсоюз комитетлары председательләре, комсомол җитәкчеләре көтәләр иде.

— Я, кемдә нинди фикерләр, тәкъдимнәр бар? — диде Юлия Сергеевна.

Залдагылар бер-берсен бүлдермичә, тыныч кына, киңәш-тәкъдимнәрен әйтә башладылар.

— Альберт Сизов җитәкчелек иткән икенче ашханәдәге комсомолъяшьләр коллективы өстеннән дәгъвалар күп. Икенче сменада эшләүчеләр өчен азык-төлекне җитәрлек хәзерләмиләр. Тупаслар. Тәкъдимнәр кенәгәсендәге кисәтүләр игътибарсыз калдырыла икән.

— Тулай торакларда кайнар су юк. График буенча җибәреп булмасмы? Эшчеләр төзелештән тиргә батып, буялып кайталар бит.

— Атом станциясен төзүчеләргә — 6, социаль-культура объектларын салучыларга 4 сотый җир бирәләр. Кем чыгарган закон бу? Нигә коллективларны үзара талаштырырга?

— Ял йортларына путевкалар бирелү турында информация юк. Ике атна алдан хәбәр итсеннәр иде!..

Татарстан атом электр станциясе төзелешенең координацион үзәге председателе урынбасары Тимер Сәфәргалиев та биредә. Ул тәнкыйть сүзләрен дикъкать белән тыңлый һәм көндәлегенә язып бара. Әледән-әле залдагыларга мөрәҗәгать итә:

— Тагын кемдә нинди сораулар бар?

Җыелышка үзтәнкыйть рухы биргәч, сөйләүчеләр табылып кына тора.

— Николай Соловьев җитәкчелек иткән комсомол-яшьләр бригадасын эш киемнәре белән тәэмин итү начар. Үзенә 60 нчы үлчәмдәге костюм биргәннәр. Өстенә кararга уңайсыз.

— Матбугат үзәге оештырып булмасмы икән? Ул вакытта, ярышка йомгак ясау нәтиҗәләрәк булыр иде.

— ГДР проекты белән эшләнгән тулай торакларда телевизорлар, суыткычлар юкка чыкты. Кая китте соң алар?

— Урыннарда күчмә сатуның графигын белмиләр.

— Хезмәткә түләү мәсьәләсендә аңлашылмаучанлык бар. Тракторчылар һәм шоферлар бер үк эшне башкаралар, акча алганда, 100 сумлап аерма чыга...

Җылылык үзәге предприятиесе профсоюз комитеты председателе Виктор Иванщенко канализация мәсьәләсенә тукталгач, аны бүлдерделәр:

— Производство киңәшмәсендә түгел ич без.

Виктор Игнатьевич сүзен дәвам итте:

— Түгел. Шулай да тормышчан мәсьәлә бу. Торбалардан көнгә 1400 куб метр сыеклык узарга тиеш. Чынлыкта 2800 әр куб метр су ага. Чистарткыч корылмалар төзүне кичекмәстән тизләтергә кирәк. Шунлыктан яңа йортларга су җибәреп булмый...

Сораулар, кискен мәсьәләләр... Күп алар. Һәрберсе чишелеш сорый. Шуңа күрә дә профком председателе Ю. Пронина киләсе очрашуга тармак җитәкчеләрен чакырырга булды. Килсеннәр, эшләре турында отчет бирсеннәр, информация ясасыннар.

— Безнең «Комсомол прожекторы»на эш җитәрлек монда,— диде җыелыштан чыкканда В. Фомин.— «КП» штабы председателе Рафис Мингалиевны бүген үк күрергә кирәк. Комитет членнарын да эшчеләр янына чыгарып җибәрәм. Очрашсыннар, сөйләшсеннәр, булышсыннар.

Володя үзе төп объектка — АЭС төзелешенә чыгып китте. Менә ничәнче мәртәбә инде аны бирегә «Комсомоллар һәм яшьләр! Төзелештә корчагиннарча эшләгез!» дигән плакат каршы ала. Чынлыкта егетләр-кызлар бу сүзләргә тугрымы соң? Секретарь шундый уйлар белән япан кырда үсеп чыккан беренче энергоблокка таба атлый. Шактый кеше эшли монда. Өчтән бере — илебезнең төрле якларыннан килгән яшьләр, тәҗрибә тупларга өлгергән өлкәннәр дә бар. Мәш киләләр! Мондагы тамашадан күзләр камаша! Әнә, кеше күтәрмәслек тимер-бетон плиталәргә таба кран муенын суза. Якында гына, чың-чың килеп, чүкеч тавышы ишетелә. Шунда ук бульдозер да эшли, балчыкның астын өскә китерә. Эретеп ябыштыру агрегаты тир-юньгә утлы очкыннар чәчә. Машиналар узыша-узыша ком ташыйлар. Яз-җәйләрен алар артыннан, гадәттә, тузан болыты күтәрелеп кала. Юлга көн саен сибелә торган су гына «болытның» куелыгын бераз кимәтә төшә. Ә яз-көзләрен? ВЛКСМның Түбән Кама шәһәр комитеты беренче секретаре Рөстәм Бикмуллин сүзләре белән әйткәндә, «монда — пычракның классик формасы, озын балтырлы резин итексез төзелеш мәйданы янына якын килерлек түгел». Машиналар турында әйтсәң дә юк, объектка керә алмыйлар. Шуңа күрә төзелеш материалларын көз өчен җәйдән, яз өчен кыштан китереп куярга туры килә. Юкса, эш туктала. Дөресрәге, булгаладый андый хәлләр. Эшчеләр акчасыз калдылар, гариза язып, китеп бардылар. Производствода кеше җитмәүнең бер сәбәбе менә кая?!

Секретарь шулай уйлана-уйлана «Аппаратстрой» идарәсенең С. Сидоров җитәкчелек иткән участогына таба атлады:

— Сергей Александрович, көн саен биеккәрәк күтәреләсез бит, ә?!

— Бер урында озак таптандык бит инде,— диде участок начальнигы.— Тагын күпме сүгелергә мөмкин, Володя?

— Болай эшләсәгез, бирелгән вакытка сыешасыз сез.

— Сыешабыз! Тик күңелне бер нәрсә борчый. Төзелешнең барышын фотоларга төшереп бармыйбыз. Киләчәк буынга истәлек калдырырга иде!

— Мәнә безнең төзүчеләр нинди актив,— диде В. Фомин елмаеп.— АЭС тарихы турында кайгырталар! Монысын хәл итеп була. Ә кайбер вакытта мена... Стенага китереп териләр. Нәрсә диярга дә белмисең. Берсендә кабинетка Үзбәкстаннан килгән ике кыз керде. Ульяна Субаева белән Лола Кулиева. «Әйдәгез, ат чабышы секциясен оештырып җибәрик әле»,— диләр. «Уйлашырбыз, иртәгә керерсез»,— дидем. Ә үзем уйга калдым: моны ничек хәл итәргә? Аптырагач: «Сорау бирүчедә — тәкъдимең булсын!» дигән өндәмә язып элдем.

— Икенче көнне керделәрме соң ул кызлар?

— Керделәр. Яннарында тагын бер иптәшләре бар иде. Одессадан Эля Полковникованы иярткәннәр. Күрешкәч, мин стенага таба ымладым: укып карагыз әле?! Кызлар кәлешеп алдылар. Аннары манеж сызымын сорап, туган якларына хат язарга булдылар.

— Сызым белән генә эш бетми бит әле?

— Урын мәсьәләсен хәл иттек. «Прикамский» совхозының яшьләрне яратучы директоры Тәлгать Кәримов Куйбышев районының «КИМ» совхозыннан атлар сатып алырга вәгъдә бирде. Ни дисәң дә, монда сүз спорт турында гына түгел, яшьләр күңелендә изге хисләр тәрбияләү турында да бара бит...

Володя Кама елгасы буендагы төзелештә йөргәндә, аның оештыру эшләре буенча урынбасары Виктор Крулев яшьләр торак комплексына юл тотты. Бу — Түбән Кама районы өчен яңалык.

— Монысы бик әйбәт,— ди яшьләр-торак комплексы комитеты председателе Саша Мартюшев.— Тик мена хезмәтне оештыру начар. Без, утыз дүрт кеше, төп эшебездән соң төзелешкә атлыгып килсәк тә, юклык кулдан тота. Я измә, я кирпеч юк. Манаралы краннны куймый интектерәләр. Икенче торак төзү комплексы начальнигы Владимир Малофеев җыелышта чакта: «Эшегездә тоткарлык булмас»,— дигән иде, югыйсә. Үзара килешү дә төзедек, куллар куештык. Вакыт уздыру өчен түгел, квартира кирәклеккә йөрибез бит без монда, гаиләбезне шатландырасыбыз килә, ә кайбер егетләр өйләнергә, яңа бүлмәдә туй үткәрергә җыеналар.

Казан дәүләт университетын тәмамлагач, Татарстан атом электр станциясе төзелешенә комсомол путевкасы белән секретарьның идеология эше буенча урынбасары булып килгән Н. Крюков профсоюз җыелышыннан соң чәчәкле болынны хәтерләтеп, ал, кызыл, яшел, зәңгәр өйләрдән торучы поселокка ашыкты. Унсигезенче тулай торакта тәрбияче бүлмәсенең ишеген какты. Виктория Мингалиева өенә кайтып киткән иде, икенче сменага эшкә Роза Петухова килгән.

— Роза, анкеталар ни хәлдә?

— Тапшырып бетермәделәр әле, беразы бар. Менә.

«Түбәндәге сүзләргә җавап бирүегезне сорыйбыз. Сезнең эчкерсез җавапларыгыз поселок яшьләренең ялын оештыруны яхшыртырга булышлык итәр» дигән кереш сүз белән башланган анкеталар алты йөз егет-кызга таратылган иде. Яшьләр сораулар чолганышында калдылар. Сез АЭС төзелешенә ничек килеп чыктыгыз? Кама Аланында ялны оештыруны ничек бәялисез? Нинди түгәрәкләргә йөргәнегез бар? Беренче булып кайсы секцияне ачарга теләр идегез? Нәрсә белән мавыгасыз? Сезнеңчә, кайсы оешма ялны яхшыртуга күбрәк өлеш кертә: партия, комсомол, профсоюз оешмаларымы, Совет органнарымы, аеклык җәмгыятеме, культура йортымы, ДОСААФмы, ирекле спорт җәмгыятеме?.. Барысы утыз дүрт сорау. Алар тутырылгач, яшьләр күңелендәге уйларны өлешчә белергә мөмкин булачак! Аннары инде эшне оештыру ягын карыйсың...

— Ә диспутны кайчан үткәрәбез?

«Үзгәртеп коруның мөһимлеген мин ничек аңлыйм» дигән тема буенча сөйләшүгә әзерлекнең торышы белән кызыксынып, Николай Розага шундый сорау да бирде.

— Тарихи китапларны, партия карарларын караштырам инде,— диде тегесе.— Сораулары бик четерекле бит. Илдә нинди үзгәртеп корулар булды?

Польша вакыйгалары дөньякүләм әһәмияткә ияме?- Тулысынча хуҗалык исәбенә күчү өчен ничә ел кирәк булыр? Идарә итү үзидарәдән нәрсә белән аерыла? Социалистик идеологияне ныгытуны ничек күз алдына китерәсең? Боларга җавап бирү өчен күп казынырга кирәк әле.

Яшьләрне мондый әңгәмәгә чакыруга комсомолның XX съезды этәргеч ясады. «Комсомолда, никтер, дискуссия аз,— диелгән иде анда.— Ә бит комсомолда дискуссия — политик позицияләр, гражданлык формалаштыруның төп методы».

Кызып-кызып сөйләшеп утырганда, ишекне егетләр ачты.

— Роза, теннис бир әле?

— Юк бит, егетләр, Брежневта, Түбән Камада кермәгән кибетебез калмады инде. Өстәлен ясатып куйсак та, уен коралларын таба алмый интегәбез.

Николай кызыксынуын дәвам итте:

— Тагын нинди кыенлыклар бар, Роза?

— Тулай торак җиһазларга бай, яшәүчеләргә бөтен шартлар тудырылды, тик стеналар буп-буш.

— Төзүчеләр арасында рәсем ясый белүчеләр юкмы соң?

— Күргәзмә үткәреп, аларны ачыкладык. Сергей Хижняк, Сергей Окутин — шәп рәссамнар. Тик егетләр көне буе эштә бит. Кич белән аларның плакат ясарлык кына вакытлары кала. Ә безгә холларны, ял һәм спорт бүлмәләрен бизәргә кирәк.

— Идарә штатында рәссам бар бит.

— Партбюро секретаре Владимир Судорев күптән вәгъдә итеп йөри инде...

— Тагын?

— Тәрбия мәсьәләләре турында китаплар аз. Семинарлар үткәрелми. Тәҗрибә уртаклашу юк. Бездә тәрбиячегә тулай торакка тәртип салучы итеп кенә карыйлар. Күтәрергә иде аның дәрәҗәсен. Тәрбияче, минемчә, идеолог, художество җитәкчесе, оештыручы булырга тиеш. Бу сүзләрне комсомолның шәһәр комитеты секретарьларына җиткерсәгез иде.

Тулай торак мөдире Тамара Ильинична Ошанина үзе янына менә нинди белгечләр туплаган! Шуңа күрә бирегә иҗади эзләнүләр хакимлек итә.

— Әйдәгез, теләсә кайсына керәбез,— диде Р. Петухова.

Монда бүлмәләрнең ишегенә шакырга кирәкми, кыңгырау төймәсенә генә басасы.

— Керегез, узыгыз,— дип каршыладылар 504 нче бүлмә хуҗалары слесарь Николай Усов белән электрик Константин Кереченко.

Егетләрнең бүлмәсе ялт иткән: табак-савыт шүрлектә, тәрәзә төбендә гөлләр үсә...

— Тулай торакның һәр бүлмәсе шундый! — диде Роза шатланып.— Без «Үрнәк тулай торак» исемен алу өчен көрәшәбез.

Аны егетләр күтәреп алды:

— Тәртип булыр, тулай торак советы яхшы эшли бездә, тикшереп кенә торалар. Ә менә су белән нишләргә? Бигрәк тә кайнар суга кытлык зур. Ванналы бүлмәдә яшәп тә, эштән соң рәхәтләнеп юына алмыйбыз...

Владимир Фомин, Николай Крюков, Виктор Крулев кайда гына булсалар да, әнә шулай, эчкерсез әңгәмәләр үткәрәләр. Очрашулар вакытында яшьләр аларга күңел сандыкларындагы бөтен уйларын ачып салалар.

Комитет членнарының башкарган эшләре байтак. Ә эшләнәселәре күпме?! Проблемалар артканнан-арта бара. Ни өченме? Кама Аланында комсомоллар ел саен уртача өч йөзгә арта. Төзелеш темпы күзгә күренеп үсә. 1981—86 елларда барлыгы 102 мең квадрат метр торак төзелсә, бу күрсәткеч 1987 елда — 50, 1988 елда 100 мең квадрат метрга җитәргә тиеш. Яшьләр яшәгән җирдә бала күп туа — быел 400 нарасый көтелә. Алар өчен ясле-бакча өлгертергә кирәк. Ә иң мөһиме — 1990 елда беренче энергоблокны файдалануга тапшырасы бар... Бу бурычларны үтәү өчен, АЭС төзелеше янына эленгән өндәмәдәге сүзләрне кабатлап: «Комсомоллар һәм яшьләр! Төзелештә корчагиннарча эшләгез!» — дияргә генә кала.

# БЕЗГӘ НИЧЕК ХЕЗМӘТ КҮРСӘТӘЛӘР

Журналыбызның быелгы беренче санында шундый исемдә басылып чыккан мәкаләдән соң редакциягә язучылардан һәм укучыларыбыздан байтак хатлар алынды. Аларның авторлары хезмәт күрсәтү сферасындагы уңай яклар белән бергә, үзләрен борчыган кимчелекләр турында да ачынып язалар, кайбер тәкъдимнәре һәм фикерләре белән уртаклашалар.

Түбәндә шул хатлардан аерым өзекләр урнаштырыла.

ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВА /шагыйрә/:

Мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балаларының ялы, ял итү, уйнау урыннары турында үземне борчыган мәсьәләләр белән уртаклашасым килә.

Зур парклар, бакчалар, әлбәттә, тиешле оешмалар күзәтүе астында; аларны чистартып, төзекләндереп торалар. Ә кечкенә бакчалар, ишегаллары, андагы балалар мәйданчыклары турында тиешенчә кайгыртучы бармы? Турысын әйткәндә, юктыр, ахрысы. Күптән салынган иске йортларның ишегалларын телгә алып сөйләрлек тә түгел. Хәтта — такта белән әйләндереп алып, чиста ком салу өчен генә дә мөмкинлек юк. Нәниләрне кайда уйнатырга — бу мәсьәлә беркемне дә борчымый булса кирәк. Бигрәк тә Бауман, Идел буе, Киров районнарындагы иске урамнар ташландык хәлдә.

Ленин районындагы яңа кварталларда, Горки кебек яңа микрорайоннарда зур-зур йортлар араларында киң, иркен ишегаллары калдырыла. Аларның күбесендә балалар уйнар өчен төрле корылмалар бар. Болар балаларны физик яктан да, эстетик яктан да тәрбия итәрлек чын заманча рухта эшләнгәннәр. Әмма күпчелек урыннарда алар тупас — тимер-томырдан яисә шомартылмаган да бүрәнәдән ясалган. Кечкенә өйләр, таганнар, таучыклар, карусельләр, турник ише корылмаларның күбесе аннан-моннан гына кораштырып куелган. Мәсәлән, Адоратский урамының 31 нче һәм 33 нче йортлары каршындагы мәйданчыктагы карусель бик тупас. Ул җирдән шулкадәр биек, аңа нәниләр түгел, зурлар да көчкә менеп утыра. Әйләндерү өчен олы кешенең дә көче җитми. Электр белән эретеп ябыштырылган «җөйләре»нә тиеп китсәң җәрәхәт аласыңны көт тә тор.

Ә бит менә кышын Яңа ел бәйрәме чорында балалар чын мәгънәсендә шатлык кичерә: төрле төстәге электр утлары белән бизәлгән мәһабәт чыршылар, чыршы тирәсендә әкият шәһәрчекләре!.. «Черек күл» паркы аеруча матур әкият иленә әйләнә. Ләкин бу санаулы көннәрдә генә шулай. Яз, җәй, көз көне бу парк балаларны һич шатландырмый. Анда төзеклек тә, чисталык та җитми. Иске биналар, уен, спорт корылмалары төзәтү көтә. Бу паркта да, башка мәйданчыкларда да нәниләр өчен махсус урын билгеләнсен иде. Хәтта ки ул урыннар тәбәнәк кенә койма белән әйләндереп алынсын иде һәм «Бары тик нәниләр өчен генә!» дип язып куелсын иде.

Нәниләрнең ялларына бәйле тагын берничә сүз — кафелар, буфетлар турында. Яшь тамашачы театрында клиндер, күмәч кебек тәмле ризык рәсеме төшерелгән буфет еш кына эшләми. 24 март көнне без оныгым белән бу театрда бик күңелле спектакль карадык. Бала арыды, аның ашыйсы, эчәсе килә башлады. Буфетка ышанып үзебез белән бер ризык та алмаган идек. Оныгымны юатам: юл уңаенда Восстание урамындагы «АБВГДейка» кафесына керербез, дим. Кафеда исә менюында язылган 10—15 ләп ризыкның берсе дә юк икән. Нибары бер-ике төрле сок кына. Таза, чибәр, матур итеп киенгән өч-дүрт кыз бик тупас итеп: «Бүген кафега бер ризык та китермәделәр, мороженое, пирожное ашыйсыгыз килсә, шимбә яисә якшәмбе көнне килегез!»— диделәр. Без бик туңган идек, алайса, чәй генә булса да бирегезче, дидек. Кызлар күзләрен зур итеп ачып, гаҗәпләнеп: «Кара! Оялмыйча бездән чәй сорыйлар!»— дигән кыяфәт белән, тупас җавап бирделәр: «Чәй булмый бездә! Хәтта плитәбез дә юк! Нинди чәй тагын сезгә!..» Әйтерсең, чәй шул кадәр дефицит яисә шундый деликатес! Март аенда балалар кафесына туңып килеп кергән балаларга салкын сок урынына кайнар чәй эчерү шулкадәр зур мәсьәлә микәнни?! Ә бит бу — март ае — балаларның язгы каникул вакыты иде. Каникул вакыты да бу кафе хезмәткәрләре өчен бернигә дә тормый икән.

Партиябез һәм хөкүмәтебез эштә, тормышта, яшәештә, көнкүрештә күп нәрсәне яңабаштан үзгәртеп кору политикасы алып барган бу эшлекле көннәрдә нәниләребез турында чын кайгырту кирәк. Алар — безнең киләчәгебез!

МӘХӘММӘТ САДРИ /шагыйрь/:

Кышкы зәмһәрир салкыннарда, шагыйребез Тукай әйтмешли, Кабан күле кеше йөрерлек булып чыңлап каткан, колак-борыннарда куык өрелгән көннәр һәм айларда безнең компрессор заводы йортларында менә ике ел инде җылы, рәхәт булды. Аңа кадәр кышкы салкыннарда әле бер, әле икенче йортта җылылык өзелә, суык була иде. Бигрәк тә картлар, бала-чага тилмерә иде мондый чакларда, чөнки заводның торак-коммуналь бүлегендә булдыксыз җитәкчеләр эшләде. Ул чакларда хатыным белән мин үзем дә салкын тиеп бик еш авырдык.

Ул исерек башларны, ниһаять, алып ташладылар.

Заводның торак-коммуналь бүлегендә яңа җитәкчеләр /начальнигы коммунист Кыям Яхин, инженеры — Анатолий Караванов/ чынлап эшкә керешкәч, өйләргә һәм җанга җылы керде. Бер генә салкын көнне дә күрмәдек.

Быел январь аенда Мәскәү заводларының берсендә эшләүче кызыбыз Гөлнур безнең хәлне күреп-белеп китәргә кайтып, ун көн торды. Киткәч җибәргән хатында, «Кадерле әтием һәм әнием, сезнең рәхәт, җылы өегезне инде сагына башладым,— дип язды.— Бездә салкын...»

Яңа җитәкчеләр, өйләрне җылы итү белән бергә, башка эшләрне дә онытмыйлар, әйтик, узган ел кыш кар бик күп яуды бит. Шундый чакларда өй тирәләрен, бик киң тротуарларны бульдозерлар китереп чистарталар, агачларны кадерләп саклау, язын аларны тигезләп тору турында кайгырталар.

Без яшәгән йортта почта бүлеге, спорт әйберләре кибете, ашханә дә бар. Аларның чүп-чары күп була. Шуңа да карамастан, ишегалларын чиста тоту өчен тиешле чаралар күрелә.

Себер тракты, Заря урамы, тагын берничә урам-квартал кешеләренә Совет районы азык-төлек сәүдәсенең 374 нче кибете /директоры — Галина Кузьминична Пак/ хезмәт күрсәтә. Халык бу кибеткә «Казан» дип исем бирде һәм анда бик яратып йөри. Кибет зур, якты. Азык-төлек әйберләре күп. Үткән ел аракы сатуны бетереп, кибет эчендә җиләк-җимеш сулары бүлеге ачылды. Алардан да халык өзелеп тормый.

Кичкә таба керсәң, сатучыларның эш күплектән арыганлыгы сизелә, шулай да алар сатып алучыларны кунакка килгән дусларын каршылагандай, ачык йөз белән каршы алалар. Кибет коллективында бик күп еллардан бирле эшләүче Асия Хәирова, Миңзифа Сәмигуллина, Ольга Любимова, Илдар Ишалин, Людмила Пыскина кебек сатучы иптәшләрне халык бигрәк тә ихтирам итә.

В. ВӘЛИЕВ /Әлмәт шәһәре/:

Мин «Казан утлары» журналын утыз еллап алам инде. Бик әйбәт әйберләр басыла, сыйфаты елдан-ел яхшыра бара. Журналның быелгы беренче санында «Безгә ничек хезмәт күрсәтәләр?» дигән язманы укыгач, үзем дә кайбер фикерләремне уртаклашырга булдым. Бик кирәкле мәсьәләләр күтәрелә анда. Аерым алганда, Фәнис Яруллин бик дөрес яза.

Менә мин үзем автобуслар гаражында шофер булып эшлим. Запчастьны без күп вакыт сатып алабыз. Складта юк. Бер вакыт алгы пыялам коелып төште. Эшләргә кирәк, көтеп ятсаң, акчасыз каласың. Үзебезнең механиктан сатып алдым. Сер түгел, үз чиратымда бу акчаны мин, кеше утыртып, кайтарам. Хәзер хезмәтсез керемнәр турында сүз бара. Узган җәй үзебезнең бакчага бер ярты сәгатькә туктаган идем, килеп бәйләнделәр... Ә бит шушы автобусны төзек йөртү өчен мин ярты гомеремне аның астында үткәрәм, запчастьлар сатып алам. Без аерым оешмаларга — нефтьчеләргә хезмәт күрсәтәбез. Үз кирәгенә начальник кая гына җибәрми: Уфага чаклы барып җитәбез. Ул гынамы, туганнарына, дусларына бирә безне. Безгә нәрсә, путевкага күбрәк сәгать язылса, шул җиткән. Без, шофер халкы, тәкәббер түгел: путевкага кул куям дисә, убырлы карчыгыңны да утыртып йөрибез.

Хәзер менә үзгәртеп корулар чорына кердек. Бик тә кирәкле эш дип саныйм мин аны. Тик яңача эшләүгә бездәге начальниклар әзер түгел, өйрәнгәннәр берсен-берсе алдап яшәргә, үзенә комачаулаганнарны куып чыгарырга. Мондыйларны алып ташлап, булдыра алырдай яшьләрне куярга кирәк. Шунсыз булмый.

Хезмәткә сәгатьләп түләүне дә дөрес түгел дип саныйм. Сәгатьләп түләп кешеләрне эштән биздереп бетердек инде. Болай начальникка әйбәт бит. Иртән бер килеп күренә дә

теләгән җиренә китеп бара. Ә эш нәтиҗәсеннән түләнсә, мин аның якасыннан алам: «Давай материал, давай тегесен, монысын». Эш башыннан түләгәндә дә кешене кыркырга омтылу бар. Кешеләр шул гаделсезлектән качып чыгып китә, башка эш эзләргә мәҗбүр була.

Мин үзем уртача 300 сум алам. Шулай ук алып эшләгән башкаларны да беләм. Минем бернием дә юк. Аларның гаражы да бар, машинасы да тора. Бармак саен алтын йөзек, алтын тешләр. Ел саен ял йортларына барып акча туздыралар. Без акчаны тота белмибездер инде... Әллә аларның башка чыганагы бармы? Бар шул. 80—90 сумга эшләгән склад мөдирләре, кибетчеләр алтынга төренеп яши. Менә шундыйларның байлыгын исәпләп чыгарып, законсыз булганнарын дәүләт файдасына аласы бар.

Менә шундый хәлләр, иптәшләр!

**Г. АНИЯ** (Балтач районы):

Сез бәлки минем хатымны укып кына карарсыз да ертып ташларсыз. Шулай да язарга булдым.

Мин 1986 елның декабреннән район больницасында яттым. Аннан соң диагнозның дөреслеген ачыклау өчен республика больницасына җибәрделәр. Дүшәмбе көнне иртәнге 6 сәгать 30 минутта Казанда республика больницасында идем инде. «Кем ахыргы?»— дип сорагач: «Монда чират тору юк, кем көчле, шул — беренче»,— диделәр. Бик аптырадым моңа. Монда бит авыру кеше килә, аның күпме көче, түземе булыр? дип уйлыйм. Ялгышканмын икән. Сәгать 7.45 тә ишекне ачтылар. Ачылу булды, мине бер почмакка сылап куйдылар да, этә-төртә керә башладылар. Андагы хәлләрне күрсәгез иде, ул кычкырыш, ул русча-татарча сүгенү, елау — барсы да бар. Ярар, ишектән ничек кирәк алай кереп чиратка бастым. Чынлап та, кем көчле, дөнья шуныкы. Бөтен ир-ат алда. Минем төсле хәлсезләр, карчыклар — иң артта. Бабайларның эш җайлы, алар сабыр гына, кенәгәләрен төтып чиратның иң башына барып басканнар. Торабыз шулай кысыла-кысыла көтеп. Читкә чыгып бассаң, кабат керәсеңне өмет тә итмә. Авырулар дип тә әйтмәссең, салсал батырлармыни: кысып күрсәтәләр, эчәгеләрең авызыңа менеп җитә.

Ярар, сәгать 8.10 да берәү күренде регистратурада. Иркенләп чишенде, бизәнде. Җайлы гына килеп утырды. Бабайлардан башлады. Шуның хәтле әкрен, җайлап кына эшли, җитмәсә берүзе. Шушылай бер генә кеше эшләсә, мондагы чират иртәгә дә бетми ич әле, дип кайгырышып, сөйләшеп торганда, сәгать 8.30 да тагын берәү күренде. Ул бер кешенең карточкасын нәкъ ун минут эзләде. Су буе чират торганнар әллә бар, әллә юк моңа. Дөрес, көн саен шушының кадәр кеше күрә-күрә туеп та беткәндер. Әмма шуның кадәр итеп кешегә ваемсыз да булып булмыйдыр инде ул. Анда бит кызык өчен йөрмисең. Бер атна буе авыру килеш кабинеттан кабинетка чабып йөрисе дә бар бит әле. Җитмәсә, ишек төбе саен чират торасы. Авыру кешегә я аяктан егылырга, я, әй, ник кенә чәнчелми, барыбер кайчан да булса үләсе дип, кул селтәп кайтып китәргә генә кала.

Шунда чиратта нәкъ 3 сәгать тә 10 минут тордым мин. Һәм бер фикер туды.

Һәр тәрәзәгә биш район исемен язып куярга иде дә, тәрәзә саен кеше утыртырга иде дип хыялландым. Шулай итеп булмый микән?! Минемчә, теләсәләр, буладыр. Нигә ике тәрәзәгә шуның кадәр халыкны өеп куеп сугыштырырга! Килсен дә кеше үз районы тәрәзәсенә бассын. Анда чистый эштән чыкмыйча бармый да бит әле авыл халкы. Шул тәрәзә төбеннән рухың сынып, башында шундый ваемсызлык булгач, эчендә дә әллә ни игътибар булмас дип, врач янына тәмам өметең өзелеп, кәефең кырылып керәсең. Ярый әле, анда якты йөз белән каршы алып, игътибар белән карыйлар. Анысына бик сөендем. Бер атна йөрсәң йөрисең, авыруыңны белеп, рәхмәт хисе белән кайтып китәсең.

Хөрмәтле редакция! Бәлки минем фикерләрем белән хисаплашып, больницаның җитәкчеләренә тәкъдим итеп карарсыз. Сугыш ветераннарына, инвалидларга аерым тәрәзә билгеләү дә чиратны киметә төшәр иде.

## Фоат Галимуллин

# ИЗГЕ НИЯТ БЕЛӘН



Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз диләр икән, бу сүз иң әүвәл Мөсәгыйт Хәбибуллинга кагыладыр кебек. Оренбург өлкәсендәге Габдрахман авылында туып үскән уналты яшьлек яшүсмер Магнитогорскида токарь була, күрше Башкортстанда нефть эзли. Илленче еллар урталарында авыл хуҗалыгын механикалаштыру буенча хезмәт итә. Аннан соңгы елларда Баулы якларында аны шофер, автомеханик дип беләләр. Сугыш чорында укуы өзелеп калган егет бары тик алтмышынчы еллар башында гына урта белем алуга ирешә. Нәкъ шушы вакытта район газетасында каләмен сынап караган Мөсәгыйть икеләнеп калмый, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә читтән торып укый... Менә шундый урау юллар аны әдәбиятка алып килә.

Тормышның үзендәге кебек үк, М. Хәбибуллин әдәбиятта да чынбарлыкның бер өлкәсеннән икенчесенә күчә торды, төрле тәҗрибәләр ясады. Аның беренче җыентыгының «Җиде юл чатында» дип аталуы да очраклы булмагандыр. 1951 елда яшьләр җыентыгында басылган беренче хикәясеннән башланган бу иҗат төрле темаларга сукмак салды. Җитмешенче еллар башында язылган «Икмәк кадере» повестенда ук М. Хәбибуллинның җыйнак, тыгыз һәм, әйтергә яраса, ачык сюжет төзү осталыгы күренеп калды.

Тормыш дәреслегенә тугрылык «Унсигезенче яз», «Тау белән тау очрашмаса да» повестьларында, «Чоңгыллар», «Сулар үргә акса да...», «Кубрат хан» романнарында тагын да ачыграк күренде. Укучылар игътибар иткәндер: бу әсәрләрдә күтәрелгән тема, сурәтләнгән вакыйгалар төрлелеге ярылып ята. Нефтьчеләр, КамАЗ гигантын төзүчеләр, колхоз авылы кешеләре, милиция хезмәткәрләре тормышы һәм, ниһаять, ерак үткән тарихыбызга мөрәҗәгать итә автор.

Бу нәрсәдән соң? Шушы сорауга җавап табасы килә. М. Хәбибуллин — бик кызыксынучан, бөртекләп күзәтүчән кеше. Юк, ул гадәттән тыш хәл-әхвәлләргә генә игътибар итми. Үзенчәлекле вакыйгалар, сәеррәк кешеләр гадәти кеше күңелендә дә бик тиз уелып кала. М. Хәбибуллин исә гап-гади әйберләрдә дә, бик үк күзгә күренми торган кешеләрдә дә, ниндидер яңа яклар таба, төбенә, асылына җитмичә туктыйсы юк. Бу инде чын иҗат кешесе өлешенә генә тия торган сәләт, әйтергә кирәк, газаплы сәләт.

Кешеләрне яратсаң, үзең дә мәхәббәттән өлешсез калмассың диләр. Бу хакыйкать һәрдаим расланып килә. Таҗикстанның Ленинабад шәһәре тирәсендәге мәшһүр Рудаки исемендәге урта мәктәптә тарих һәм җәмгыять белеме укыткан вакытларда М. Хәбибуллин игелеклелек, җылы сүз, яхшы гамәлнең кешеләргә гаять көчле тәэсирен, алар күңелендә тирән эз калдыруын тагын да әйбәтрәк төшенә. Язучы — шул ук укытучы бит ул. Берьюлы йөзләрчә кешеләр күңеленә яктылык иңдерүче. М. Хәбибуллин моны бигрәк тә «Казан утлары» журналының 1969 ел беренче санында «Унсигезенче яз» повесте басылгач укучылардан алынган күпсанлы хатлардан сизде. Әле тормышта яңа гына мөстәкыйль адымнар ясаган үнсигез яшьлек кызның күңел дөньясы шактый осталык белән

сурәтләнүе күпләрне сокландыра. Бигрәк тә кызның яктылыкка, бәхеткә омтылган эш-хәрәкәтләре теләктәшлек уята.

М. Хәбибуллин әсәрләрен даими күзәтеп баручы буларак, юлда барганда тукталып хәл җыйган юлчы кебек, кайчак уйлана башлыйсың. Прозаик тормышның төрле кишәрлекләренә кереп-кереп ала, аларның һәрберсен үзенчә күрүе сизелеп тора. Бу әсәрләрне берләштергән иң төп сыйфат — геройларының кешелеклелек сыйфатлары белән көчле булуы. «Тау белән тау очрашмаса да» повестенда физик һәм рухи көчле Ислам нәзберек күңелле, лирик табигатьле Зөлфәткә каршы куелган. Ләкин ахыр чиктә физик көч түгел, күңел матурлыгы өстенлек итә. Биредәге Сәгъди образы да саф хисләргә, яшьлек мәхәббәтенә хыянәт итмичә, шушы байлыкны гомер буена саклап илтергә кирәклеген искә төшерә. Бу әсәрнең җитмешенче еллар яшьләре яраткан китапка әверелүенә төп сәбәп — образларның әнә шундый кешелеклелек сыйфатлары белән сугарылуында иде.

«Таңана» хикәясендә язызлыкның киләчәктән мәхрүм икәнлеге аеруча зур көч белән расланган. Үзен кешеләрдән өстен исәпләп, аллалар белән тиңләшергә теләүче хаким табигатьнең үзе тарафыннан ук юкка чыгарыла.

«Хәтер ярлары» повестенда исә М. Хәбибуллин әсәр үзәгенә бик әһәмиятле әхлакый проблема куя. Кеше дигән олы исем белән аталу өчен, һәркем иң әүвәл чын мәгънәсендә кешелекле булырга тиеш. Аннан соң гына ул бәхетле булырга исәп тотарга мөмкин. Үзен өзелеп яраткан кешегә эт өстереп талаткан кыз никадәр шыксыз, рәхимсез булып күзаллана. Мәхәббәт мавыгуыннан аңы томаланган Нәүфәлнең шул аянычлы вакыйгадан соң күп нәрсәгә күзе ачыла. Дөрес, ярату хисләренә каршы усаллык кылырга мөмкин булуын аңлау җиңел түгел. Шуңа күрә күп еллар буена егет шуны төшенә алмыйча җәфалана. Ләкин мәхәббәт бәрабәренә алган гариплек бу фаҗигане даими искәртеп тора...

Халисә дә яшьлектә үзе кылган явызлыкка үкенгәләп куя. Ире Гайсә кулы белән, соңгарып булса да, Нәүфәлгә ярдәм итәргә дә тели. Ләкин яхшы белгеч, оста хирург Гайсә бу очракта эгоист булып кала. Бердән, ул операциянең уңышлы чыгачагына тулысынча ышанып бетми. Икенчедән, көнчелек хисләреннән өстен булырга үзендә көч таба алмый. Табип кешегә шәхси хис-тойгыларын алгы планга чыгару, кешелеклелек кануннары ягыннан гына түгел, бәлки профессиональ этика таләпләре белән дә рөхсәт ителми. М. Хәбибуллин әсәре мондый риялы затларга карата укучыларда нәфрәт тәрбияли.

Безгә китап ике төрле юл белән йогынты ясый. Еш кына тискәре образларны шыксыз итеп сурәтләп, алардан кеше күңелен биздерү максат итеп куела. Бу, әлбәттә, шактый үтемле юл. Ләкин шулай да уңай үрнәгендә тәрбияләү отышлырак. Нәфисәләр, Миңлекамаллар, Сәфәргалиләрне без ни өчен яратабыз? Рухыбызны алга ашкындырган, идеал булып хезмәт иткәннәре өчен. М. Хәбибуллин сурәтләгән геройлар да табигый эчке матурлыклары белән мөлаем. Юк, язучы аларны ботаксыз-чатаксыз идеал итеп кенә дә күрсәтми,— үз җайларына куеп, тәкъдим ителгән шартларда ирекле яшәтә. Менә ни өчен киң катлау укучылар бу иҗатка тартыла.

М. Хәбибуллинның хикәя жанрындагы табышлары игътибарга лаек. Соңгы унъеллыкта ул, бик еш булмаса да, прозадагы кече жанрның әйбәт кенә үрнәкләрен бирә килә. Бигрәк тә «Туй балдагы», «Яңа өй», «Өченче вагон» хикәяләре сюжет киеренкелеген тәэмин итүче фикер һәм хис киеренкелекләре белән хәтердә калган.

Язучы өчен иң әһәмиятлесе — әсәрдә сурәтләнгән кешенең күңел дөньясын ачып бирү. Образның нинди дә булса гамәл кылуын тасвирлау күпкә җиңелрәк, ә менә кешенең шул адымны ясауга китерүче психологик нигезләү — иң авыры. Монысы бөтен кешегә дә баш биреп бетерми торган аргамакка тиң.

«Яңа өй» хикәясен искә төшерик. Кайчандыр үзе ташлап киткән сылу хатыны янына адәм карамаслык инвалид хәлендә кайтып төшкән Ярулланың хәле, укучы күрә, бик мөшкел. Чөнки элеккеге җанкисәге инде дөнья җимертеп Нурислам исемле егет белән торып ята. Биредә чын мәгънәсендә «өченче кеше артык». Ә кем артык? Әлбәттә, сау-сәламәт, көчләре ташып торган Хәнифә белән Нурислам түгел, яшьтән үк изге хисләрне кадерләп сакларга сәләтсез Ярулла кирәксез кеше булып чыга. Бу соңгысының һәлакәте алдыннан булган кичерешләре бирелү сәнгатьлелек көче белән тәэмин ителгән. М. Хәбибуллин хикәяләрен укыганда, тагын бер тапкыр инанасың: явызлык, нинди генә көчле кыяфәттә гәүдәләнмәсен, изге күңеллелек алдында җиңелеп кала. Мәхәббәт хисеннән дә көчлерәк әйбернең булганы юк әле бу дөньяда дип раслый автор. Бары тик мәхәббәт кенә, шыксыз күренешләр, явыз кешеләр белән бәрелешкәндә, нәфрәт тудыра һәм кара көчләрне җиңәр өчен кешегә көч бирә.

М. Хәбибуллин иҗатында укучыны аеруча җәлеп иткән әсәрләр, минемчә — «Чыңгыллар» һәм «Кубрат хан» романнары.

«Чыңгыллар» романының бер мөһим сыйфаты — анда кеше күңеленең катлаулы табигате сурәтләнә. Әнә шул катлаулылык аша кешелеклелек дигән олы төшенчәнең асылы ачып бирелә.

Язучыга, тормышны бөтен катлаулылыгында күрсәтү өчен, еш кына бүгенге белән

үткәннәрне яңәшә куеп эш итәргә туры килә. Бу аңа образларның дөньяга карашындагы контрастлыкны бирергә ярдәм итә. Мәсәлән, әсәр ахырына таба егерменче елларда авылда ярлылар комитеты председателе булган Әюп Латыйповның очраклы рәвештә сөякләре табылу күренеше бар. Шул ук көнне теге елларда әлеге активистны үтергән Гайзулла да җан бирә. Әсәрдәге төп персонажларның берсе колхоз председателе Бикмуллин әйткәнчә, «берәүләр әнә читән буенда катып үләләр... Икенче берәүләр ирек даулап, көрәш кырында корбан була». Кулы кеше канына буялган Гайзулла җирдә күбрәк яши, ләкин «бүген килеп тоталар, иртәгә фаш итәләр» дип, гомерен һәрдаим калтыранып үткәрә. Эшләгән җинаятьләрен үзе үк совет иле законнары бизмәненә салып карагач, аның коты оча. Даими курку хисеннән аерылмау Гайзулланың күңелендә кешеләргә карата бары тик усаллык көчәюгә генә сәбәп булган. Үз гомерендә ул беркемгә дә игелек китермәгән. Алай гына да түгел, баш миенең ерак бер почмагында совет властеның бер көн килеп бетәсенә ышаныч саклап йөрткән. Ник дигәндә, байтак кына байлык иясе ул. Каенатасы Рәхим бай кулына төшкән бер пот алтынны үзенә алып кала алган Гайзулла гомере буе шушы хәзинәсенә өметләнеп яши. Алтын сөрен белердәй кешеләрне дә берәм-берәм юк итә баруы аның ерткыч табигатен тагын да ачып бирә. Хатыны — Рәхим бай кызы Таҗелбанат та — гомер юлын кеше үтерүдән башлаган, ягъни «алтын эшелон»дагы колчак офицерын үтереп, байлык туплап куярга омтылган. Сары шайтанга табыну, дин сөреме белән агулану бу кешеләрне эчтән кейдергән, күңелләрендә әйләнә-тирәдәгеләргә карата дошманлык хисе генә тамыр җәйгән. Әлбәттә, алар малайлары Кәнзелне дә үзләредәй миһербансыз итеп үстергәннәр.

Әмма бу бәндәләрнең өмете акланмый, совет власте ныгыганнан-ныгый, колхоз авылы үскәннән-үсә. Кәнзел, Таҗелбанатлар дөньяга булган ачуларыннан тыңлаусыз каҗәләрен кыйнаудан башка берни дә кыла алмыйлар. Бер-берсенә булган мөнәсәбәтләрдә дә алар бүрелек инстинкты белән эш итәләр: улы — атасына, атасы улына ышанмый. Ерткычлык билгеләре киеренке хәл-әхвәлләрдә бу гаилә кешеләренең һәммәсендә уянып-уянып ала. Укучы алдан ук сизеп тора: мондый хәл бер көн килеп трагедия белән тәмамланачак. Бу шулай булып чыга да.

Дөрес, Гайзулла да, үткәннәрен искә алып, үзе өчен генә булса да хакыйкатьләр әйтеп куйгалый. Тоткан юлының дөрес булмавын тану аңа авыр. Беренче хатыны, колхоз төзелеше өчен җанын фида кылган Сабираның каны түгелүдә үз гаебен тою да картайган көнендә аның тән йокыларын качыра. Сабирадан туган малае Кәримулланы тәрбияләп үстермәгән булуын тану туктаусыз йөрәк итен кимерә. Соңгы сулышларында, үе яктырып китеп, «Сабирә», «Кәримулла» исемнәрен пышылдавы әнә шуннан килә. Кулак кызы белән бөтен гомерен үткәреп, барлык гамәле белән байлык артыннан куса да, ул үзенең авыр елларда халык белән бергә атламавын, ахыр чиктә дөрес яшәмәвен аңлый. Шул рәвешле, автор сәнгать чаралары ярдәмендә, психологик анализ аша укучыларга сиздерми генә тормыш дөресе бирә.

Ә менә алга туры карап бару, халык белән бергә атлау иртәме-соңмы бәхеткә китерә. Бу хакыйкать Әюп Латыйповның каһарман образы ачыклыгында тагы да ачык күренә. Хезмәт кешеләре бәхете өчен көрәштә һәлак булган әлеге кешенең истәлеге авылдашларның күңелен һаман нурландырып тора. Нәрсә генә эшләмәсеннәр, яңа тормыш хәрәкәтенең башында торган Әюп исеме телгә алынмый калмый. «Берек» колхозындагы уңышларның нигезе әнә шундый легендар буыннарга барып тоташа.

Әюпнең улы Гариф бүген абруйлы галим булып җитешкән. Гарифның кызы Әдилә дә халык мәнфәгатьләрен иң алга куеп эш итә торган белгеч буларак хөрмәт ителә. Шул рәвешле, Әюп Латыйпов нәселен автор ил тергән тәшкил итүчеләр буларак күрсәтә, бу фикерне аларның кылган гамәлләре белән раслый.

Рәхимсез сыйнфый көрәш һәм бугазга-бугаз килүләр бәрабәренә җиңеп чыккан яңа тормыш бүген ничек дәвам итә? Әюпләр койган кан бүгенге буыннар тарафыннан ничек аклана? Әсәрнең хәзерге көн вакыйгаларына багышланган бүлекләреннән әнә шушы сорауларга җавап эзлибез.

Колхоз председателе Талип Бикмуллин образын сурәтләүгә язучы аеруча әһәмият иткән. Ул җитәкләгән «Берек» колхозы районда иң алдынгылардан. Председатель, белеме буенча юрист булса да, авыл хуҗалыгын шактый тирән белеп җитәкчелек итә. Ул үзенә берниндиташлама ясамый.

Шул ук вакытта Талип Бикмуллинда, кайбер җитәкчеләргә хас булганча, теләсә нинди юл белән план үтәү, югары оешмалар алдында яхшы атлы булып күренү өчен иген үстерү технологиясе белән исәпләшмәү кебек яклар да юк түгел. Сортлы борчакны җиргә ашлама кертмичә чәчү — шуларның берсе. Нәтиҗәдә бу басу силоска чабып алудан башкага ярамый.

Әйе, Талип — сөттән ак, судан пакь кеше түгел. Масаю, үзсүзлелек, башкалар фикере белән исәпләшмәү кебек яклары калыккалап ала. Ләкин совет чынбарлыгы, коллектив акыл аның ялгыш адымнарын төзәтә килә. Мәсәлән, бригадир Зарифны партиягә алу

җыелышында Талип үз тәкъдимен уздыра алмый. Председатель кадәр председатель үзе яклап чыгыш ясауга карамастан, коммунистлар эштә хилафлыклар ясаган Зарифны үз араларына кабул итүне кичектерәләр. Талип исә моннан үзенә тиешле сабак ясарга мәҗбүр була.

Күтәрелгән проблемалар буенча дисеңме, кеше характерларын сурәтләү буенчамы, публицистик кайнарлык ягыннан карыйсыңмы — «Чоңгыллар» романы кыю язылган. Ул авторның гражданлык позициясенең аныклыгы, ныклыгы һәм сугышчан булуы турында сөйли. «Роман,— дип язган иде Хәсән Сарьян,— әдәби яктан да нык кул белән эшләнгән һәм ул авторның осталыгы әсәрдән-әсәргә үсә барганлыкны раслый. Хәбибуллинның әдәби теле нык...»

Роман РСФСР Язучылар союзы бүләгенә лаек булды, өч тапкыр Мәскәү нәшриятларында басылып чыкты. Бу, әлбәттә, хәзерге татар совет прозасы өчен күңелле күренеш.

Тормыш ваклыкларыннан өстен була алган һәркем бүгенге көн өчен генә борчылмый, ул ерак үткәннәр һәм киләчәк турында да уйланмый кала алмый. Дөресрәге, үткәнне белү аңа хәзергене тирән төшенү һәм иртәгәгә дөрес уйлар белән атлау өчен кирәк.

Тарихтан хәбәрдар булган кешеләр болгар тарихында иң күренекле фигураларның берсе Кубрат хан икәнлеген яхшы беләләр. Тик шулай да әлегә кадәр, Кубрат хан дигәндә, күз алдына килеш-килбәте, холык-фигыле, акылы-сәләте мәгълүм булган кеше түгел, ниндидер бер абстракт исем генә шәйләнә иде. Мөсәгыйт Хәбибуллин, «Кубрат хан» романын язып, шушы тарихи фигураны җанлы образ итеп күзалларга ярдәм итте.

Бу әсәре белән язучы иҗади мөмкинлекләренең яңа сәхифәсен ачты.

Романда сурәтләнгән вакыйгалар күп тармаклы. Ләкин шул катлаулылыкның бер үзәге бар. Кубрат феодаль нигезгә корылган дәүләт төзи. Бу берләшмә, үз вакыты өчен шактый көчле булу сәбәпле, күп илләрнең игътибарын үзенә тарта, алар аның белән төрле элемтә урнаштырырга омтылалар. Ханның исә бөтен кайгысы дәүләтне тагын да ныграк итү, уларының берсенә тәхетне исән-имин тапшыру. Беренче карашка гади булган бу ният гаять катлаулы булып чыга. Эчке һәм тышкы каршылыклар бихисап күп. Шушы шартларда без Кубрат ханны акылы белән көчле кеше итеп күрәбез. Ул дәүләттә мөмкин кадәр гаделлек урнаштырырга омтыла. Гаепсез кешеләрне җәберләүгә, кол белән сәүдә итүгә, илдәшләренең шәхси ирекләрен кысуга юл куймаска омтыла. Эш күчмә тормыштан утрак яшәүгә күчүгә таба бара, шәһәр, төрле кирәкле корылмалар төзелә. Боларның һәммәсендә Кубратның зирәклеге күренә.

Ләкин политик җитәкче — акылына гына түгел, бәлки үз артында торган реаль көчкә күбрәк таяна. Әсәрдә сурәтләнгән Византия императоры «гаять дәрәҗәдә вакчыл, интриган, мин-минлек чире белән балачактан ук чирле» башлаган кеше булса да, дәүләтнең хәрби көченә таянып, күрше илләр белән мөнәсәбәттә тавышын бөереннән чыгарып сөйләшә. Бу хәл Кубратны борчый. Шул ук вакытта ишәеп килгән Ашина ыруы башлыгы Йулыш каганның гаскәр җыюы да аны шиккә төшерә. Мондый шартларда Кубрат ханга дәүләтне эчтән ныгыту, аның тышкы яктан иминлеген тәэмин итү өчен ике корал кирәк: беренчесе — иҗтимагый аң сыйфатында дәүләттә урнашкан идарә тәртипләренә бәрабәр килерлек йола, тагын да дөресрәге — яңа дин. Чөнки, аның уйлавынча, «Болгарда бердәмлек югалып бара, һәр илхан үз җәйләвен кайгырта». Икенчесе — греклар уйлап тапкан утлы коралны кулга төшерү. Ә нигә кирәк ул аңа? Моңа ул турыдан-туры җавап бирә: «грек уты кулыма төшү белән, мин Йулыш каганны җир йөзеннән юк итәчәкмен». Ләкин әле моннан Кубратны агрессив җитәкче дип санап булмый. Яшь чакта күп яу чапкан булса да, соңгы битләрдә сурәтләнгән сугышка кушылырга аны күрше төрки ырулар мәҗбүр итәләр. Сугыш ахыр чиктә болгарлар файдасына тәмамланса да, бик зур югалтулар китерә. Кубрат хан үзе һәлак була. Автор моннан бик гыйбрәтле нәтиҗә ясый: «җиңеп җиңелгән иде Болгар бу орышта». Димәк, сугыш җиңүгә ирешкән якка да күләгәсез бәхет китерә алмый.

Тирән фикер йөртүче, кыю нәтиҗәләр ясый алучы Кубрат ханга карата укучыда хөрмәт уяна. Чөнки ул ашыгып карар кабул итүдән сакланырга тырыша, һәр күренешнең асылына тирән төшенергә омтыла. Мәсәлән, нәрсә ул йола, ышану, кайсы дин иң дөресе кебек бик катлаулы мәсьәләләр турында баш вата ул. Кешегә шул йолалардан нинди роль бирелгән? Язмыш белән кешенең кылган гамәлләре арасындагы бәйләнеш нәрсәдән гыйбарәт? Яшәеш аның алдына менә шундый фәлсәфи сораулар китереп куя. Кубрат — тар карашлы кеше түгел. Ул бу сорауларга кистереп җавап бирә алган булыр иде. Ләкин алай итми, башкаларның да фикерен тыңлый. Моннан файдаланып, дәүләттәге дин башлыгы төптәңре Ирсан белән Византиядән килгән философ Иоанн Фасиан Кубрат ханга көчлерәк йогынты ясау өчен көрәш башлыйлар. Әгәр Ирсан тәңрегә шикләнеп карамыйча гына инанырга кушса, философ исә һәр нәрсә турында төптән уйлап кына үз фикереңне булдырырга өнди. Дөрес, ул да, үз файдасына аргументлар китерә-китерә, Кубратны христиан диненә тартырга тырыша. Кубратның акыллылыгы шунда күренә, ул,

Ирсан белән Фасиан сүзләрен чагыштырып карап, үз хөкемен чыгара. Кубрат бу мәсьәләдәге карашында шактый югарылыкка күтәрелә, теләсә кайсы диннең иҗтимагый зарурлыкка хезмәт итүен аңлардай хәлгә килә. «Мин сабыр итәргә булдым,— ди ул Фасианга,— дин-йола алыштыру — рух алмаштыру дигән сүз. Рум — Болгарга, Болгар Румга игелек кылсын. Игелек итү халыкларны бер-берсенә бәйләр, дуслыкны ныгытыр, дуслык белән йола мәсьәләсе дә хәл ителер». Җиденче гасыр урталары өчен генә түгел, бүгенге көнебездә дә актуаль булырлык сүзләр. Чыннан да әйткәнме мондый фикерне Кубрат хан? Тарихи шәхес турында язганда, авторның уйлап чыгарырга хакы бар. А. Н. Толстой, мәсәлән, бер хатында болай ди: «Сез тарихи шәхеснең биографиясенә «үзеңнән өстәргә» мөмкинме дип сорыйсыз. Мөмкин. Ләкин моны шундый итеп эшләргә кирәк, бу (ягъни уйлап чыгарылган) чынбарлыкта булмаган булса да, булырга тиешле итеп бирелсен». Кубрат хан турында, реаль кеше буларак, чыганаклар гаять ярлы булуга карамастан, М. Хәбибуллин әнә шундый «үзеннән өстәү» ярдәмендә бөтенлекле холык-фигыль иясен иҗат итә алган.

М. Хәбибуллин сюжет төзүдә, образлар тудыруда төрки халыклар авыз иҗаты һәм язма әдәбияты алымнарыннан һәм стильләреннән оста файдалана. Кубрат хан, мәсәлән, әкиятләрдәге ак сакаллы акыллы картны хәтерләтә. Малайлары Батбай, Кодрак, Аспарух, Балкыр, Аслан хикмәтле атаның булдыклылык ягыннан төрле-төрле дәрәҗәдәге улларын искә төшерә. Ә кызы Чәчкә, гомумән, әкият кызыдай, «зәңгәр күзле, чәче алтын җептән». Сюжетка лириклык өстәүдә һәм киеренкелекне көчәйтүдә Чәчкә образына әһәмиятле бурыч йөкләнә. Ул ызгыш-талашлар эчендә бер кулдан икенчесенә күчеп йөри, мажаралылыкны арттыра.

Романда әкият алымнары бар дибез икән, ул барыннан да элек Кубрат ханның тәрбиягә алып үстергән улы Илбарыс образына карый. Таза, көчле, матур, кыю, тәвәккәл, хәйләкәр, берничә тел белә, оста сугышчы — әкияттәге егетләрдә нинди сыйфатлар булса, шуларны Илбарыста табарга мөмкин. Кубрат хан аңа берсеннән-берсе хәтәррәк йомышлар куша тора. Илбарыс аларның һәммәсен җиренә җиткереп үтәп килә. Ул Кубрат ханның үз улларына караганда булдыклылыгы белән аерылып тора.

Шунысын да әйтергә кирәк: автор Кубрат хан малайларын ачыграк буяулар белән сурәтләү мөмкинлекләрен табып җиткермәгән. Алар әсәрдә шактый пассив. Индивидуаль сыйфатлары да күбесенчә хәрәкәттә түгел, бәлки персонажлар һәм автор бәяләве аша гына ачыла. Кубрат хан үлгәч, малайлар мөстәкыйльлек ала. Димәк, әсәрнең дәвамын язарга уйласа, автор аларны мөмкин кадәр тулы канлырак итеп сурәтләргә тиеш булачак.

Империя башлыгы Ираклий тар эгоистик карашлардан чыгып эш итүче, бөтен кешедән шикләнеп яшәүче мәкерле идарәче буларак гәүдәләнә. Ул бер үк вакытта хазарларны да, болгарларны да коралландыра, аларны бер-берсенә өстерәп сугыштырырга тели. Кардәш ырулар арасындагы мондый кырылыш Ираклийга алар өстеннән хакимлек урнаштыруны җиңеләйтәчәк. Болар һәммәсе империалистик илләрнең бүгенге агрессив политикалары белән авазлаш. М. Хәбибуллин язган тарихи әсәрнең заман белән авазлашлыгы — барыннан да элек әнә шул усал көчләрнең асылын, кешелеккә каршы кылган гамәлләрен яхшырак аңларга ярдәм итүдә, явызлыкка каршы торуда иң сыналган корал — дуслык, бердәмлек булуын искәртүдә.

Әйе, М. Хәбибуллинның «Кубрат хан» романы әдәбиятыбызда яңа сүз булды, укучылар күңелендә лаеклы урын алды.

...Язучының каләме кәгазь өстеннән йөгерә. Аның кешеләргә ул гына әйтә ала торган кадерле сүзләре бар. Ләкин еш кына каләм тукталып та кала, берничә көн язучы аны кулына да алмый. Ник дигәндә, кәгазьгә төшкәнче, сүзләр бик нык уйланылган, тикшерелгән, кичерелгән булырга тиеш. Иң мөһиме — алар җанлы кешедәй ягымлы, аһәңле булсын, укучыларга игелекле фикерләр генә алып барсын.

Язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин каләмен әнә шул изге максат хәрәкәткә китерә.

# ДУСЛЫК КӨЧЕ

Күп кенә халыкларда: «Агач — тамыры белән, кеше дуслары белән көчле»,— дигән мәкаль бар. Моны аерым кешегә карата гына түгел, бөтен-бөтен халыкларга карата да куллану урынлы. Бүген, Бөек Октябрьгә 70 ел тулган көннәрдә, СССРда яшәүче халыкларның үзара дуслыктан бетмәс-төкәнмәс көч алуы бигрәк тә тулы чагыла.

Кыргыз һәм татар халыкларының үзара тарихи мөнәсәбәтләре, уртак культура элементләре дә ерак гасырларга барып тоташа. Архив мәгълүматларына караганда, революциягә кадәр Казан, Уфа, Оренбург, Троицк уку йортларында укыган казах һәм кыргыз яшьләре, рус, татар иптәшләре белән кулга-кул тотынышып, революцион-демократик оешмаларда, түгәрәкләрдә катнашкан. Татар театр труппалары гасыр башында Урта Азиягә гастрольгә барганда кыргыз интеллигенциясе, яшьләре аларны кочак җәеп каршылаган, мөмкин булганча ярдәм күрсәтергә тырышкан. Үз чиратында, кыргыз халкының да ирешкән уңышлары татарларда сөенеч уяткан, хезмәттәшлеккә этәргеч биргән. Мәсәлән, дөнья культурасының кабатланмас җәүһәре «Манас» 1896—99 елларда өлешләп-өлешләп Казанда басылган.

Ул замандагы газета-журналларны актарсаң, эчкерсез дуслык чагылышларын күп табарга була. «Аң» журналының 1916 елгы 5 нче санында татарның олы язучысы, революционер Г. Ибраһимовның «Телләребез төрле булса да, күңелләребез бер» дигән мәкаләсе басыла. Анда язучы төрки телләргә карата буржуаз-реакцион карашларга кискен каршы чыга, казах, кыргыз телләрен кыю яклый, аларның гасырлар буена үсә килүен, үзенчәлекле булуын, тел культураларының мөстәкыйльлеген нигезле итеп раслый. Бер үк вакытта, татар әдәби мирасын баету өчен, казах, кыргыз әдәбиятларын киң өйрәнергә кирәклеген күрсәтә. Аның 1924 елда атаклы «Казакъ кызы» романын язуы да тугандаш халыкларның тормышын, культурасын бик якын күрүен искәртә.

Чын дуслык — тел, культура һәм традицияләр уртаклыгы гына түгел ул. Бөек Октябрь социалистик революциясе йогынтысы астында татар һәм кыргыз халыкларының үзара элемтәсе, бер-берсен баетуы тагын да көчәя.

Петербургта чыгып килгән «Вестник воспитания» журналы 1906 елда Урта Азиядә, Казахстанда наданлыкны бетерү, халыкны укырга-язарга өйрәтү өчен гасырлар кирәк булачак дип яза. Ләкин буржуаз каләм әһелләре нык ялгышалар. Урта Азиядәге Совет республикаларының хәзерге тормышы шул хакта сөйли.

Кыргызстан экономикасы нык үскән республикаларның берсенә әверелде. Аның культурасы, әдәбияты, сәнгате дә зур биеклеккә иреште. Әлбәттә, кыргызларның элек тә халык талантлары, Туктагул, Т. Мулда кебек шөһрәтле акыннары бар иде. Әмма иҗат көчләренең, милли талантларның чын чәчәк атуы Бөек Октябрьдән соң гына башланды. Ул А. Токымбаев, Т. Сыдыкбәков, С. Карачев, Ж. Җамгырчиев, И. Абдырахманов, К. Баялинов, К. Җунусов, С. Сасыкбаев, К. Маликов, Н. Байтимеров кебек бик күп талантлы акыннар, язучыларга юл ачты.

Октябрь революциясе кыргыз һәм татар халыкларының күптәннән килгән культура элементләренә дә шифалы йогынты ясый. Социалистик Хезмәт Герое, Кыргызстанның халык шагыйре, академик Аалы Токымбаев 1972 елда, РСФСРда кыргыз әдәбияты көннәрен уздырганда болай дип искә ала: «Беренче шигырьләремне язар өчен миңа эмоциональ көч, иҗат дәрте биргән шагыйрь Тукай булды. Зур талантлы, чын халыкчан, әгәр шулай әйтергә яраса, төбе-тамыры белән интернациональ шагыйрь иде ул... Без, өлкән буын үзбәк, казах, кыргыз, әзербайҗан, төрекмән, таҗик язучылары, рус классикларының җәүһәрләре, хәтта бөтен дөнья классик әдәбияты үрнәкләре белән дә аларның татар теленә тәрҗемәләре аша, күренекле татар әдипләре, укытучылары ярдәме белән таныштык... Яшь әдәбиятчыларыбыз, укучыларыбыз аерата Җәлил иҗатын якын кабул итәләр. Җәлил иҗатында, бигрәк тә аның Моабит төрмәсендә язган шигырьләрендә, Бөек Ватанга мәхәббәт, туган илгә карата олы хисләр көчле патриотик кичереш белән бирелгәннәр» («Социалистик Татарстан», 1972 ел, 10 сентябрь).

Аксакал хаклы: «Туктагул һәм Тукай — ике тугандаш әдәбият күгендәге сүнмәс йолдызлар. Муса Җәлил һәм Чулпанбай Түлебердиев — тугандаш ике халыкның ике Герое, үз гомерләрен биреп, фашизмны җиңүгә зур өлеш керткән ике батыр. Чулпанбай үз күкрәге белән дошман амбразурасын каплаган булса, Муса каләмен штык итте. Монда герой шагыйрьнең поэзиясен көрәш чаңына тиңләгән Ч. Айтматов сүзләрен китерү урынлы булыр: «Ул аларны татар телендә әйтте, ә мин шуларны ук кыргыз һәм рус телләрендә ишетәм» («Социалистик Татарстан», 1975 ел, 24 август).

Ике халыкның интернациональ дуслыгын, культураларын үстерү өчен Татарстанның язучылары, җәмәгать эшлеклеләре дә күп нәрсә эшләде. Монда мәшһүр политик эшлекле, язучы Галимҗан Ибраһимовның хезмәтләре зур. Аның киң танылган «Тирән тамырлар», «Безнең көннәр», «Казакъ кызы» романнары һәм башка әсәрләре бөтен союз укучысының мәхәббәтен казанды, бик күп тапкырлар басылып чыкты. Кыргыз әдәбияты классигы Касыймалы Баялинов заманында болай диган иде: «Дөресен генә әйткәндә, мине әдәбиятка танылган татар язучысы Галимҗан Ибраһимов әсәрләре алып килде. Ул минем беренче мөгаллимем булды» («Социалистик Татарстан», 1984, 8 декабрь).

Танылган галим-филолог Кәримкул Абдылбәковның 1982 елда «Кыргызстан» нәшриятында чыккан «Яңалык чалымнары» диган фәнни-популяр китабында СССР халыклары әдәбиятларының үзара йогынтысына зур урын бирелә. Ул кыргыз халкының культура үсешенә тирән эз салган М. Горький, А. Фадеев, М. Шолохов, М. Әуэзов, Д. Фурманов иҗатына җентекләп анализ ясый. Галим кыргыз һәм татар культураларының, бер-берсен баетып үсүе турында сөйләүче күп санлы архив материалларына да киң урын биргән. Татар культурасының талантлы вәкилләре Гали Рәфыйков һәм Каюм Мифтаховка багышланган битләрне кызыксынып укыйсың. Бу кешеләр революциядән соң Кыргызстанда халык мәгарифен, полиграфия промышленностен, матбугат эшен үстерү өчен зур көч куйганнар. Г. Рәфыйков, мәсәлән, 1909 елда Казан мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Кыргызстанга килгән һәм бөтен көчен прогрессив кыргыз культурасына хезмәт итүгә багышлаган. Халыкның телен, көнкүрешен өйрәнгән, кыргызлар тормышыннан язган шигырьләре «Вакыт», «Аң», «Шура» журналларында чыгып торган. Шагыйрь Жума Җамгырчиев, фольклорчы «Манас» эпосын төзүче Ибрай Абдырахманов аның шәкертләре, соңрак көрәштәшләре булалар. Г. Рәфыйков кыргыз әдәбиятында беренчеләрдән булып татар язучыларының әсәрләрен кыргызчага тәрҗемә кылган Садыйк Карачев, Касыймалы Баялинов белән дә иҗади хезмәттәшлек итә.

Шуның белән берррәттән К. Абдылдабәков китабында тугандаш культураларның совет чорындагы үзара мөнәсәбәтләре киң чагылыш табуын әйтеп үтәргә кирәк. Мәсәлән, герой шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган бүләкләр тирәнлеге, дәреслеге белән игътибарны җәлеп итә. Кыргыз язучыларының М. Җәлилнең үлемсез шигъри мирасын тәрҗемә итүдә һәм популярлаштыруда гомумән роле зур. Монда өлкән сүз осталары К. Маликов, Т. Байзаков, К. Жунусов, Т. Шамшиев белән бергәттән яшь акыннар Р. Рыскулов, К. Артыкбаев, Б. Караголов, А. Күчәрбаев, тәнкыйтьчеләр К. Укаев, А. Садыйков, Н. Жаркынбаев, К. Кудайбиргәнов, Г. Касыймов, Р. Шамбетсәитов, Т. Касыймалиев, Ж. Бешимов, тәрҗемәчеләр А. Стамов, А. Мәдәтбәков, Т. Элеманов зур өлеш кертте. Б. Ашимбаев һәм С. Җигитовларның актуаль тикшеренүләре һәм матбугатта чыгышлары киң иҗтимагый резонанс алды.

Культураларыбызның тыгыз элемтәләрен гомумиләштереп, Ч. Айтматов шундый тирән фәнни нәтиҗә чыгара: «Татар халкы рус культурасын беренче булып үз итте, беренче булып газета-журналлар чыгара башлады, беренче булып үз театрын ачты. Революцион идеяләр безгә татар теле, әдәбияты аркылы үтеп керде» («Социалистик Татарстан», 6 май, 1982 ел).

Күрәсез, СССРдагы тугандаш халыкларның, шул исәптән кыргыз һәм татар халыкларының үзара элемтәләре фән, әдәбият, сәнгать эшлеклеләренең, шулай ук киң җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә. С. Карачев, К. Баялинов, К. Рәхмәтуллин, А. Убукеев, А. Токымбаев, Т. Сыдыкбәков, Ч. Айтматов кебек Совет Кыргызстанының мәшһүр культура эшлеклеләренең армый-талмый эзләнүләре күп рәхмәткә лаек. Ош педагогия институтының кафедра мөдире, интернациональ дуслык җырчысы Николай Морадымов үзенең фәнни-тикшеренү һәм җәмәгать эшчәнлеге белән олы ихтирам казанды, ул кыргыз, татар һәм СССРда яшәүче башка төрки телле халыклар арасындагы элемтәләрне ныгытуга сизелерлек өлеш кертә.

Безнең уебызча, татар культура эшлеклеләре дә кыргыз коллегаларыннан калышмыйлар. Бу юнәлештә фән докторлары, профессорлар М. Госманов, Ә. Кәримуллин, язучылар Ә. Исхак, Н. Арслан, З. Нури, Л. Хәмидуллин, Т. Әйди, С. Шакир, М. Хөсәен, Р. Даутов, М. Харисов актив эшләп киләләр. Безне Кыргызстан белән тарих кына түгел, бүгенге көнебез дә бәйли. Шуны күздә тотып, Кыргызстан ССРның халык язучысы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты академик Түгелбай Сыдыкбәков болай

дип язды: «Татар халкының гүзәл традицияләргә бай, үзенчәлекле әдәбияты күзгә күренеп үсте, заманыбызның илебезнең зур бер әдәбияты булып җитлекте.

Без, ягъни төрки әдәбиятлар язучылары, татар әдәбиятының нигезе булган халык иҗаты үрнәкләре, бай фольклоры белән әдип һәм галим Нәкый Исәнбәтнең өч томлык хезмәте аша яхшы таныш. Габдулла Тукайдан башлап Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким кебек татар шагыйрьләрен, Галимҗан Ибраһимовтан башлап Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Гадел Кутуй, Габдрахман Әпсәләмов кебек язучыларның әсәрләрен, романнарын, повестьларын кыргыз укучылары яхшы белә. Аерата «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар», «Язгы җилләр», «Намус» романнары, «Тапшырылмаган хатлар» повесте безнең укучыларның сөйгән әсәрләренә әверелделәр.

Татар совет әдәбиятының үсешен, анда булган һәр яңалыкны кыргыз язучылары даими күзәтеп баралар. Моны бездән тормыш үзе таләп итә. Шулай булганда гына милли әдәбиятлар үзара иҗади элемтәдә торалар. Һәм бу элемтә әдәбиятлар үсешенә нәтиҗәле йогынты ясый ала. Иҗади элемтәләрне тагын да үстерү өчен бездә бөтен мөмкинлекләр, уңай шартлар бар» («Социалистик Татарстан», 1972 ел, 10 сентябрь).

1972 елда Татарстан хезмәт ияләре Совет иле тарихында беренче тапкыр кояшлы Кыргызстан әдипләрен үзләрендә кабул иттеләр. Күтеп алган кунакларның килүенә Татарстан китап нәшрияты кыргыз язучылары әсәрләренең зур җыентыгын чыгарды. Кыргыз дусларыбызны Казанда, Әлмәт, Лениногорск, Түбән Кама шәһәрләрендә һәм авыл районнарында якты чырай белән каршыладылар.

Шунысы игътибарга лаек, кунакчыл Татарстан җирендә булу кыргыз язучыларына, шагыйрьләренә яңа әсәрләр иҗат итәргә көч бирде. Мәсәлән, К. Маликов үзенең «Ленин Казанда туган», «Габдулла Тукайга», «Үзем татар булмасам да» дигән танылган шигырьләрен иҗат итте, Н. Байтимеров «КамАЗ канатлары» дигән поэма язды. Т. Адышева «Казан», Ж. Абдыкалыков «Сабантуй» дигән әсәрләрен язарга илһам таптылар. Башка әдипләр онытылмас тәэсирләр алып, күңелләренә яңа иҗат дәрте, илһам иңдереп киттеләр.

Аннан соң унбиш ел үтте инде. Шулай да күп санлы фоторәсемнәрдә, газета-журналларда, махсус чыгарылган китапларда Кыргызстан кунакларының котлаулары, җылы сүзләре, кояшлы елмаюлары саклана. Дусларыбызның автографлары, сувенирлары кыргыз әдәбияты декадасы көннәрен хәтердә яңарта, шундый иҗади очрашуларны тагын да кабатлау теләге уята.

Социалистик әдәбиятлар дуслыгы, рухи байлыклар алмашу — өзлексез процесс. Шунлыктан таләпчән укучыбыз үз әдәбиятында гына түгел, тугандаш әдәбиятларда да яңа ачышлар ясалуын, яңа талантлы исемнәр дөньяга килүен түземсезлек белән көтә. Китап сөючеләребез кыргыз әдәбиятын туган телләрендә укулары белән горурлана. Кыргыз китаплары күптән инде бер культураныкы гына түгел, чөнки алар барыбызны да борчый торган гомуми, актуаль проблемаларны кузгаталар. Кыргыз әдәбиятындагы «Гасырга тиң көн», «Ахырзаман» («Плаха»), «Сынган кылыч», «Бунтарь һәм сихерче» кебек танылган романнарның һаман зуррак уңыш казануы шуның белән аңлатыла.

Бездә Ш. Абдырахманов, К. Бобулов, М. Гапаров, К. Каимов, Ж. Мәүленов, Ш. Садыбакасов, А. Саспаев, И. Сөләйманов, О. Даникеев, А. Жакынбеков, Х. Жапаров, К. Жусубалиев, С. Сасыкбаев, К. Жусуповның да татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләрен яратып укыйлар. Кыргыз шигырьләре һәм җырлары бездә шәһәр һәм авыл культура йортлары сәхнәсеннән, радио һәм телевидение аша яңгырый. Кыргыз әдипләреннән Т. Мулда, Б. Алыкулов, А. Җутәкеев, Н. Байтимеров, С. Эралиев, К. Акыев, А. Усенбаев, М. Әлебаев, Ж. Турусбеков, Ж. Беконбаев, А. Осмонов, Т. Өметалиев, М. Жангазиев, С. Жусуев, Б. Сарнугаев, О. Солтанов, М. Әбелкасыймовларның шигъри әсәрләре «Социалистик Татарстан» газетасында, «Ялкын» журналында, шулай ук аерым җыентыклар булып та чыктылар.

Татар укучылары кыргыз әдәбиятын оста тәрҗемә итүче Зәки Нури, Әхмәт Исхак, Нури Арслан кебек һәм башка каләм осталарыбызга бурычлы. Кыргыз әдәбиятын бер яратып алган укучыбыз яңа тәрҗемәләр турында мәсьәләне бик урынлы куя.

70 еллык юбилеен каршылый торган күп милләтле Ватаныбызның көче — халыклар дуслыгында. Совет милли культураларының үзара аерылгысыз бәйләнеше — шуның нигез ташы.

Мәгъсум **НАСЫЙБУЛЛИН**,
Татарстан АССРның атказанган
культура хезмәткәре

библиография

# ТАРИХ ҮЗЕ ШАҺИТ...

Ни өчен кайбер әсәрләр укылганнан соң кат-кат искә төшеп уйландыралар? Образлары, вакыйгалары күңеленә кереп кала да, хәтер аларны кайта-кайта яңарта? Икенче бер әсәрләр исә, шактый кызыксыну уятуларына карамастан, ни өчен бик тиз истән чыга?

Өлкән әдибебез Афзал ага Шамовның «Чын хикәяләр»[1] исемле китабы күпмедер дәрәҗәдә әнә шул сорауларга җавап бирә. Тормыш чынлыгы, тормышка ышаныч — әсәрләрдәге иң төп сыйфатларның беренчеседер, мөгаен. Афзал Шамовның китабына кергән хикәясе булсын, очерк яки истәлеге булсын — һәрберсе фикерне уята, татлы бер кичерешкә әверелеп күңелне кузгата, шәфкатьлелек, кешелеклелеккә өнди.

Тормышка ышаныч — һич тә чынбарлыкны якты буяуларга буяп, матур һәм илле якларын гына күпертеп күрсәтү дигән сүз түгел. Тормыш вакыт катламнары аша саркып чыккан саф сулы чишмә кебек тансык та, гади дә һәм үзенә хас челтерәве белән серле дә. Афзал аганың геройлары әдәбият һәм тормышның тыгыз берлегендә яшиләр: җанлы, тулы канлы образлар әдәби әсәрләр кысасына күчсәләр, хикәяләү процессындагы бизәлмәгән дөреслек ялкынлы автор сөйләме аша тормышка әйләнеп кайта. Шуңа күрә авторның шәхси, хәтта үтә шәхси кебек тоелган кичерешләре дә киң масштаблы вакыйгага үсә һәм укучыга барып ирешә, ә конкрет шәхесләр турындагы истәлекләре гади мемуарлар киртәсен чыгып, авыр, әмма данлы юл үткән татар совет әдәбияты һәм культурасының тарихы булып күзаллана. Гражданнар сугышы чорыннан алып, бүгенге көн уйлануларына кадәрге вакыйгалар барысы да диярлек Афзал аганың иҗат дөньясында чагылдырылдылар.

Яшь совет дәүләтенең беренче көннәре. Авыр еллар. Бер телем икмәкнең бәяләп бетергесез вакытлары. Икмәк кадере... Китаптагы хикәяләрнең бер өлеше шул циклга берләштерелгән. Тормыш һәм икмәк. Бу сүзләрнең нинди мәгънәгә ия булганын Гражданнар сугышында ук кулына корал тотып Ватанны саклаган әдип-солдаттан да яхшырак аңлаучы бар микән? «Икмәк кадере...» «Бер кашык ботка» хикәясендә ризыкны мәсхәрә иткән өчен «командир дядька Фәхретдиннең» якасыннан бөтереп алган яшь солдатны да, ятим гаиләгә очрагач соңгы икмәген биреп калдырган яралы кызылармеецны да («Язны көткәндә»), фашистлардан яңа гына азат ителгән шәһәрдә тетрәнүләр кичергән совет офицерын да («Бер йотым сөт») бер хис — икмәкнең кадерен белү, тормышның тоткасы икәнен аңлау хисе берләштерә.

«Икмәктән дә кадерле әйбер юк дөньяда»— язучы тарафыннан эпиграф итеп алынган татар халык мәкале авторның күп хикәяләрендә кызыл җеп булып сузылып бара. «Канлы чокыр» исемле хикәядә азык-төлек җыя торган отряд комиссарының кулаклар кулыннан ерткычларча үтерелүе турында легенда китерелә. Кан бәрабәренә, көрәшчеләр гомере хисабына яуланган икмәк автор фикерен тагын да үстереп, мәгънәсен тагын да тирәнәйтеп җибәрә. Шундый гыйбрәтле тарихы булган икмәккә бүгенге көндә мөнәсәбәт үзгәрмәдеме? Авторны бу да борчый. Кызганычка каршы, туклык, мул тормыш ваемсыз, гамьсез адәмнәрне дә тудырды. Арзан хакка сатып алырга мөмкин булган икмәк аерым кешеләр өчен мал ризыгына әйләнде. Тирәлекнең битарафлыгы әнә шул черек шөгыльләрнең яшәвенә китерде. «Якташым» хикәясендәге Хәлил шул хәлгә җаны әрнеп болай ди: «нигә шундый егетләрне әти-әниләре шул чаклы гамьсез, игътибарсыз битараф җан итеп үстерәләр? Нигә ипинең бик кадерле, кыйммәтле, мөкатдәс азык икәнен, аны эшләп, тир түгеп табалар икәнен ана сөте белән кертмиләр аларга?!»

Герое белән бергә автор да ачына, нәфрәтләнә. Чынлап та, кечкенә мәсьәләләр түгел бу. Кеше иң әүвәл икмәккә булган мөнәсәбәте белән бәяләнә. «Күңел хакы өчен тешләп тә, кабып та карамаган булканы туп итеп типкәләүче» малайлардан киләчәктә кем чыгар да, кемнәр булып тәрбияләнерләр алар? Җәмгыятебезнең киләчәге хакында уйланган бер генә кешене дә битараф калдырмаска тиеш болар. Яки, «Сәлимә әби чәчәкләре» хикәясендәге ялгыз карчык янына килеп тә карамаган, ә вафатының икенче көнендә үк мал бүләргә килеп җиткән «варисларның» җан өшеткеч кыланышлары —

[1] Шамов А. Чын хикәяләр: хикәяләр, очерклар, истәлекләр. Казан, 1986. 440 б.

болар да бит бүгенге көн драмасы. Ә геройлары — шушы тирәлектән, шушы җәмгыятьтә яшәүчеләр. Җәмгыятебезгә ят булган әнә шул күренешләрнең нигезендә битарафлык, гамьсезлек ята. Битарафлык әрәмтамакларның, комсызларның яшәвенә юл куя, хәтта ул чирнең көчәюенә дә булышлык итә. Битараф булмаска! Гамьсез булмаска! Язучы әнә шуңа чакыра. Гомер — бәрәкәтсез нәрсә. Кеше үзеннән соң нәрсәдер калдырырга тиеш. Киләчәк буын сине кылган эшләреңә карап хөкем итәчәк. Яхшыдан булса да, начардан булса да... Авторның укучыга адресланган теләгендә дә шул мәгънә яңгырый: «Кешеләр үз гомерләрендә киләчәк буыннар өчен бер төп кенә булса да агач утыртсыннар иде, агач!» «Кешеләр үзләреннән соң җир йөзендә һаман шулай чәчәкләр калдырсыннар иде, чәчәкләр!»

Китапның икенче бүлегендә язучының төрле елларда иҗат ителгән очерклары, истәлекләре урын алган. Бер җыентыкта тупланып бирелүләре белән алар татар совет әдәбияты һәм культурасы тарихын тулырак күзалларга ярдәм итәләр. Гыйбрәтле, кызыклы, фикерне кузгата торган язмалар. Китап битләреннән татар совет әдәбиятының башында торган, бүгенге көндә дә укып, сокланып туймаслык классик әсәрләр тудырган шәхесләр калка. Менә сабыр, үйчан «салмак кына агылып чыккан тавышы», күңелеңне әсир итәрлек оста һәм логикалы сөйләве белән залны үзенә каратучы Ф. Әмирхан... Ачык йөзле, киң күңелле, мәҗлеснең, шигъри кичәләрнең җаны булган Г. Кутуй... Егерме яшендә интернационал легионның комиссары булган, татар телендә эфирга беренче тапшырулар оештырган, урам театрлары булдыру һәм «җанлы газета» чыгару хыялы белән рухланган, үзенең бетмәс-төкәнмәс энергиясе, көчле фантазиясе белән башкаларны да янып эшләргә ашкындырган тынгысыз җанлы Ш. Усманов... Сизгер, таләпчән, югары зәвыклы тәнкыйтьче Г. Гали...

Китапта Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Ф. Кәрим, К. Нәҗми һәм башка әдипләрнең җанлы образлары туа. Сәер бер хис кичерәсең. Ш. Усмановлар, Г. Ибраһимовлар яшәгән, иҗат иткән еллар бүгенгедән шактый ерак, һәм серле, легендалар белән өретелгән вакыйгаларга бай тарих булып күзаллана. Ике арадагы якты идеаллар белән тулы 20 еллар, коллективлашу чоры. Бөек Ватан сугышы, сугыштан соңгы авыр, бөек төзелешләр дәвере шундый хис уяталар күрәсең. Без ул чорларны күз алдына тулырак китерү максатыннан тарих китапларын актарабыз, архив материалларына мөрәҗәгать итәбез. Ә шул ук вакытта бүгенге көндә дә актив иҗат белән янып яшәүче өлкән әдибебез Афзал ага Шамов безгә шул зур дәвернең — каты сугышлар, көрәшләр, югалтулар, җиңүләр белән үткән дәвернең шаһиты буларак җай гына сөйли.

Утлы еллар, дәһшәтле еллар, данлы еллар. Һәрберсе гасырга тиңләштерерлек еллар. Була шундый әдипләр, алар барыннан да бигрәк үзләре турында түгел, ә башкалар турында, чордашлары — татар совет әдәбиятының алгы сафында барган каләмдәшләре, Ватан өчен барган сугышларда иңгә-иң торып көрәшкән, иҗат иткән дуслары турында сөйлиләр, аларның батырлыкларын чагылдырып калырга тырышалар. Башкаларның уңышларына сөенәләр, алар белән горурланалар, үзләре исә шул шанлы вакыйгаларны сөйләүче, теркәп баручы гади бер шаһит булыбрак калалар. Афзал ага әнә шундыйлардан. Тыйнаклыкмы бу, янсә авторның үзенчәлекле стилеме, һәрхәлдә безнең әдәбиятта шактый күбәеп киткән мемуарчыларга гыйбрәт тә, киная дә, үрнәк тә булырлык сыйфат. Югыйсә, кайбер авторлар тәмам хисләнеп бетеп балачак шуклыкларын — күрше бакчасына кыяр чәлдерергә керү кебек вак-төяк хатирәчекләрен дә укучыга сөйләүдән тайчанмыйлар. Кемгә-кемгә, ә ике сугыш ветераны, татар совет әдәбиятының башында торган, аны үстерүгә армый-талмый көч куйган, татар журналистикасы тарихында беренче булган «Яшь ленинчы» газетасының беренче санын, аның беренче басма юлларын әзерләшкән Афзал аганың укучыга әйтер сүзе бар. Кызганычка каршы, китапта урын алган истәлек — очерклар зур тормышның аерым сәхифәләре генә әле. Язучының укучыга сөйләрлек хатирәләре, уртаклашырлык вакыйгалары күп дип ышанасы килә. Хәлбуки, сүз уңаеннан телгә алынган көндәлек дәфтәре, фронт блокнотлары шуңа өметләндерәләр.

Бу җәһәттән, китапта бер нәрсә игътибарны аеруча җәлеп итә — ул да булса, Бөек Ватан сугышында катнашкан батыр татар кызлары турындагы истәлекләр. «Меңнәрчә вә меңнәрчә сугышчыларны үлемнән алып калган» кызларыбыз турында, «кулларына корал тотып, ирләр белән бер сафта торып, дошманга каршы сугышкан каһарман кыз туганнарыбыз» турында...

Белүебезчә, татар әдәбиятында бу тема тиешле дәрәҗәдә яктыртыла алмады әле. Моның җитди сәбәпләре дә бар: әдәбиятта шактый көч, тәҗрибә туплаган күп әдипләребезне шәхес культы давылы йотты, күбесе Бөек Ватан сугышында ил азатлыгы өчен башларын салды, илгә исән-сау әйләнеп кайтканнарыннан да күпмесенең сугыш яралары вакытсыз гомерләрен чикләде. Уйлана-саный башласаң шактыйга җыелалар алар. Ә утны-суны кичкән, сугыш афәтен җилкәләрендә күтәргән фронтовиклардан гайре тагын кем ул чор турында сөйли алыр? Сугышны бары тик ишетеп, укып, кинофильмнар аша гына күреп үскән буынмы? Белмим, андый язучы никадәрле генә талантлы булмасын, әмма бөтен дәһшәтне йөрәге аша үткәргән, чигенүләрнең ачы хәсрәтен кичергән, җиңү шатлыгын татыган

солдат хәтле тоя да, сөйли дә алмастыр.

Бөек Ватан сугышында катнашкан татар кызлары турында бөтенләй язылмады дип әйтергә җыенмыйм. Аз да язылмаган кебек. Әмма бу тема ничектер күбрәк мәхәббәт планында яктыртылды, ә героинялар романтик буяулар белән бизәп сурәтләнделәр. Солдат булып сугышның бөтен авырлыгын ирләр белән бергә күтәргән кызлар андый ясалма купшыландыруга мохтаҗ түгелләр. Аларның үз тормышлары соклангыч, биографияләре, батырлыклары тирән ихтирамга лаек. А. Шамов «Танышларым белән очрашу» исемле очеркын Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар кызларына багышлаган. Очерк битләреннән снайпер кызлар М. Туктамышева, М. Вәлитова, командирын үз гәүдәсе белән каплап һәлак булган санитарка Суфия Баязитова образлары калка. Әкияттәге «җиде кыз» кебек җиде медицина хезмәте лейтенант Нәҗибә Аслам кызы Карипова, Хәлимә Габдрахман кызы Шаһиева, Әнисә Шәрәфетдин кызы Терегулова, Суфия Закир кызы Баязитова, Хәзинә Фәсхетдин кызы Фәсхетдинова, Хәтимә Исхакова, Әминә Гариф кызы Уразгилдиева — алар һәм башка күпләр, бик күпләр «бөтен көчләрен, белемнәрен, сәләтләрен явыз дошманны җиңүгә багышладылар; кеше җаны күтәрә алмаслык авыр шартларда, ут, ялкын астында меңнәрчә яралыларны үлемнән коткардылар, дәваладылар; кирәк чакларда каннарын бирделәр һәм алар яңадан аякка баскач, кулларына корал тотарлык хәлгә килгәч, аларны якын туганнары шикелле итеп иркәләп, рухландырып, күңелләрен күтәреп, яңадан алгы сафтагы окопларга озаттылар». һәрберсенең исемен атап искә аласы иде аларның. Тыйнак һәм гаярь сугышчы татар кызы образын мәңгеләштерәсе иде. «...аларның һәркайсы фронтта күрсәткән патриотик хезмәтләре, хәрби батырлыклары белән әерым әсәрләрнең, очеркларның, поэмаларның каһарманнары булырга лаеклы». Авторның егерме ел элек язган бу юллары бүген дә актуаль яңгырыйлар, бүгенге татар язучылары алдында торган мөһим мәсьәләләрнең беренчеләреннән булып калалар.

Афзал ага Шамовка, хәрби корреспондент буларак, сугыш юлларында күп кешеләр белән очрашырга, сөйләшергә туры килә. Аның очеркларында гадәти тормышта «йомшак табигатьле, кызларча оялчан» булган, ә сугышта курку белмәс баһадирга, фашист ерткычларына мәрхәмәтсез кыю сугышчыга әверелгән коммунист Исхак Закиров, батырлыгы белән даны бөтен дивизиягә мәгълүм лейтенант Шәриф Гәрәев, үзе һәлак булганнан соң да ротасына «Шәриповчылар ротасы» исеме бирелеп, рухы белән, эше белән, батырлыгы белән яшәүче исеме легендага әйләнгән командир Рахман Шәрипов, соңыннан Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган гаярь разведчик Фазылҗан Әхмәлетдинов, дошман тылына үтеп кереп, аның бронепоездын шартлаткан һәм берничә күперен күккә очырган Мөнир Сәфәрмитов һәм башкалар, тагын бик күпләр турында сөйләнелә.

Бу батырлыкларның чыганагы, нигезе кайда икән дип уйланасың. «Егерменче елда» очеркындагы аклар тарафыннан атылганда да «Интернационал» җырлап үлгән курсантлардан килә бу ныклык, патриотлык, фидакарьлек. Халкыбызның батыр уллары һәм кызлары белән горурлану хисе кичерәсең, шул ук вакытта күңелдә ачы моң да кала. Шулай. Җиңү кеше гомерләре бәрабәренә, югалтулар, беркайчан да онытылмаслык югалтулар бәрабәренә яуланды. Сугыш китергән «хәсрәт шәрабен соңгы тамчысына чаклы эчкән тол хатыннар», сугыш китергән кайгылардан каны саркып торган йөрәкләр әзмыни әле илдә. Киләчәккә ашкынган бер чорда ул данлы да, хәсрәтле дә елларга хәтер әле тора-тора кайтыр. Бөек Ватан сугышында һәлак булган каһарманнарны искә алу, исемнәрен мәңгеләштерү буенча бүген нәрсәләр эшләнә?— автор шуны уйлап борчыла. Сугыш корбаннары хакында мәгълүмат туплаудагы җитешсезлекләрне күреп фронтовик язучының җаны әрни: «Киләчәк буыннар моның өчен, бу игътибарсызлыгыбыз, гамьсезлегебез өчен безне гафу итмәс». Җиңүнең ни бәрабәренә яулануын бүгенге буын кешеләре дә, киләчәк буыннар да белсеннәр, һәм белергә тиешләр дә! Китапта күңел тетрәндергеч бер факт китерелә: «кечкенә генә Татар Әҗәлесе исемле авылдан бертуган өч Яруллин һәлак булган, Хәйруллиннар — дүртәү, ә Җамаловлар бишәү һәлак булган! Барысы да бер ата, бер ана балалары... Бу юлларны укыган кешеләр, онытмагыз, исегездә тотыгыз, Җамаловлар бишәү булганнар: Гарафетдин, Низаметдин, Хисаметдин, Ярхаметдин, Җәләлетдин исемле егетләр!

Бу — зур тормыш мәктәбе узган өлкән әдибебезнең үтенече дә, таләбе дә, наказы да булып яңгырый.

Була шундый шәхесләр, аларның гомере, кылган гамәлләре, бөтен язмышлары кайтакайта уйландыра, сокландыра, тирән хөрмәт уята. Афзал ага Шамов узган юл да шундый авыр юл, мактаулы юл. һәрбер елы әерым сөйләүгә, өйрәнүгә лаеклы матур гомер, сокландыргыч гомер. Күренекле татар әдибе, җәмәгать эшлеклесе Афзал ага Шамовның фидакарь тормышы яшь буынны янып яшәргә, бөек идеаллар өчен куркусыз көрәшергә чакыра, матур киләчәк өчен җиң сызганып эшләргә өнди.

**Фәрит БӘШИРОВ.**



**Риза Фәхретдиневкә мемориаль такта куелган йорт**

«Правда» урамы, 9 йорт

# РИЗА ФӘХРЕТДИНЕВ ОРЕНБУРГТА

*«Хөрмәтле Ризаэтдин — бер кямил зат!»*

Акмулла

Халкыбызның рухи дөньясында тирән эз калдырган фән-культура эшлеклеләренең истәлеген мәңгеләштерү йөзеннән алар яшәгән йортларга, хезмәт иткән биналарга мемориаль такталар кую күркәм гадәткә әверелде. Оренбургта да күп алар. Татар культурасының гына түгел, гомумсовет әдәбиятының, культурасының гүзәл сәхифәләрен язган Муса Җәлил, Шәриф Камал, Җәүдәт Фәйзи һәм башка олуг шәхесләргә куелган мемориаль такталар әнә шундый. 1986 елның 1 сентябрендә аларга тагын берәү — күренекле татар галиме, язучы, тарихчы, журналист һәм педагог Риза Фәхретдиневнең якты истәлегенә багышланганы өстәлде.

Оренбург, күп кенә атаклы шәхесләребез тормышындагы кебек үк, Риза Фәхретдинев язмышында да аерым урын били. 1906 елда ул үз теләге белән Диния назаратындагы казыйлык вазифасын ташлап, властьлардан газета чыгарырга рөхсәт алган Шакир һәм Закир (Дәрдмәнд) Рәмиевләр чакыруы буенча гаиләсе белән Оренбургка күчеп килә. Монда килгәнче үк инде ул татар дөньясында язучы һәм галим буларак танылып өлгерә. Казан, Оренбург басмаханәләрендә замандашларының игътибарын җәлеп иткән, татар әдәбиятында проза жанрын үстерүгә зур өлеш керткән «Сәлимә яки гыйффәт», «Әсма» кебек әдәби әсәрләре, энциклопедик «Асарь», «Рихләте Мәрҗани», «Исмәгыйль сәяхәте», «Ибн Рөшд», «Мәшһүр ирләр», «Мәшһүр хатыннар» һәм башка бик күп тарихи, педагогик хезмәтләре дөнья күрә. Беренче карашка бер кешегә болары да бик җиткән кебек. Ләкин беренче карашка гына. Оренбург чоры Р. Фәхретдинев тормышында иң нәтиҗәле еллар булып милли тарихыбыз сәхифәләренә кереп калган. Монда ул баштанаяк журналистлык, педагоглык хезмәтенә чума. Революциягә кадәрге атаклы татар мәдрәсәләренең берсе — «Хөсәения»дә укыту, 1906 елда чыга башлаган «Вакыт» газетасында эшләү, яңадан-яңа гыйльми хезмәтләр иҗат итү кебек мәшәкатьләр белән ел артыннан ел үтеп тора.

1908 елдан 1918 елга кадәр ул Октябрь революциясенә кадәрге татар вакытлы матбугатында бай эчтәлеге белән аерылып торган «Шура» журналының баш редакторы була. Айга ике тапкыр дөнья күргән бу басма яшь бала сыман үзен гел карап, мәкалә-материаллар белән «туендырып» торуны таләп итә. Авторлар туплау, күпсанлы укучылар белән язышу (хатлар чит илләрдән дә килә) өстенә ул үзе дә «Шура»ның төп авторына әверелә. Профессор М. Госманов исәпләүләренә караганда, журнал битләрендә дөнья күргән җиде йөзгә якын мәкалә һәм төрле характердагы язмалар Р. Фәхретдинев каләме белән язылган. Иҗатының Оренбург чорында ул берничә дистә китап бастырып чыгара, «Асарь»нең яңа кисәкләренә материал туплый.

Әйе, Оренбургта башка һава, башка мохит. Уфадагы мөфти-казыйлар урынына монда фикердәшләр, монда шагыйрь Дәрдмәнд, туганы, язучы һәм журналист Ф. Кәрими, атаклы «Хөсәения» мөгаллимнәре, язучылар, журналистлар, монда газета-журналлар, матбагалар...

Оренбург чоры гел шатлык, куанычлардан гына тормаган, әлбәттә. Бер яктан, шунда ук чыгып килгән «Дин вә мәгыйшәт» журналы битләреннән галим өстенә пычрак атылса, икенче яктан, полиция тынгы бирми. 1911 елның 12 февраленә каршы төндә үткәрелгән тентү вакытында әле дөнья күрмәгән әсәрләренең кульъязмаларын, хатларны, «Шура» өчен хәзерләнгән мәкаләләрне ящикларга тутырып алып чыгып китәләр. Күп мәшәкатьләрдән соң аларның бер өлеше кире кайтарылса да, галимнең йөрәк җылысы сеңгән, күз нуры иңгән кульъязмаларның күбесе полициядә «югалып» кала. Ләкин боларның берсе дә аның рухын сындырмый, ул туган халкына хезмәт итүдән, аның күпгасырлы катлаулы тарихының буталчык сәхифәләрен тикшерүдән, аны армый-талмый пропагандалаудан туктамый. 1918 елда Оренбургтан китәргә мәҗбүр булгач та, Риза Фәхретдинев бу игелекле эшен әле бик озак еллар, гомеренең соңгы көннәренәчә дәвам иттерә.

*Ж. Миңнуллин тексты*

*А. Тимергалина рәсеме*

# КҮРЕНЕКЛЕ ӘДИП, ГАЛИМ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ

*Инде хәбәр иткәнебезчә, быел язын илебезнең башкаласы Мәскәүдә, язучыларның А. А. Фадеев исемендәге Үзәк йортында татар халкының күренекле улы, әдип, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 100 ел тулуга багышланган зур әдәби кичә булган иде. Анда ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары профессор М. Х. Хәсәнов Г. Ибраһимовның эшчәнлеге турында доклад сөйләде. Кичәдә илебезнең танылган язучылары, тугандаш республикалардан килгән кунаклар — СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. И. Суровцев, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, «Литературная Россия» газетасы баш редакторы М. М. Колосов, украин язучысы В. Г. Гримич, Үзбәкстанның Хәмзә исемендәге дәүләт премиясе лауреаты прозаик П. К. Кадыйров, Казахстан Язучылар союзы идарәсе секретаре К. К. Торсынколов, Башкортстан Язучылар союзы идарәсе председателе драматург Ә. М. Мирзаһитов чыгыш ясады.*

*ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. А. Миңнуллин йомгаклау сүзе белән чыкты.*

*Түбәндә шушы кичәдәге чыгышлар нигезендә авторлар тарафыннан журнал өчен махсус әзерләнгән материаллар тәкъдим ителә.*

## Юрий Суровцев

Галимҗан Ибраһимовны без хаклы рәвештә күпмилләтле совет әдәбиятына нигез салучылар сафында күрәбез. Әйе, бер татар әдәбиятының гына түгел — бөтен ил әдәбиятының, тагын да тулырак итеп әйтсәк — күпмилләтле совет социалистик культурасының чишмә башында торган беренчеләрнең берсе ул.

*Беренчеләр!* Дикъкать итик әле бу төшенчәгә. Сүз бит яңа культураның асылын билгеләүдә турыдан-туры, һәрьяклап катнашкан, әзлекле рәвештә нигез ташларын салышкан шәхесләр турында бара. Нәкъ шул чорда культурабызның киләчәге билгеләнә — 20 нче, 30 нчы елларда, сугыштан соңгы дәвердә ачылып китәсе яралгылары формалаша. Бүгенге көндә дә тормышыбызның бөтен рухы, халәте культура өлкәсендә революцион борылыш булган ул елларның тәҗрибәсенә илтифатлы булуны таләп итә.

Әйе, Галимҗан Ибраһимов яшәгән чор — вакыт исәбен Бөек революция таңыннан хисаплый башлаган кискен социаль һәм милли яңарышлар заманы.

Ул заманның тарихи бурычлары безнең хәзерге көнебез, үзгәртеп кору һәм яңарыш процессы куйган бурычларга охшамаган. Әмма социалистик илебезнең, яңа культураның нигез ташларын салучылар алдында баш июебез аларның үткәндәге хезмәтен яд итү яки гади итагатьлелек билгесе генә түгел. Бу — шәкертләрнең остазларына, дәвамчыларның алдан юл ярып баручыларга хөрмәт һәм рәхмәт хисе. Аларның хезмәт сабагы, рух сабагы безнең бүгенге бурычларыбызны хәл иткәндә дә бик кирәкле, бик актуаль.

Г. Ибраһимов мирасының иҗтимагый һәм тарихи-әдәби әһәмияте турында кызыклы хезмәтләр язылган. Мин исә татар халкының зур улы, «татар Горькие» булган бу шәхесне беренче чиратта шул сабак-гыйбрәт җәһәтеннән искә алыр идем.

Сүз, чыннан да, кеше буларак бик үзенчәлекле, якты, зур шәхес турында бара. Аңарда үз чоры, шул чорның казанышлары һәм офыклары чагыла икән, бу — котылгысыз хәл. Әмма Ибраһимов шәхесе, беренче, Горький кузгаткан дулкындагы башка бөек язучыларыбыз кебек үк («бөек» сүзеннән курыкмыйк!), узган заманга — яшәгән, гомер иткән елларына гына сыеп кала алмый. Ул бүген дә тере, бүген дә хәрәкәттә. Иҗаты, үрнәге белән арабызда яши.

Г. Ибраһимовның өч сабагын аерып алып әйтәсем килә.

Иң әүвәл — халыкчанлык сабагы. Юк, бу — социаль-сыйнфый эчтәлекне бер читкә кагып, үтә патриот булып уйнаучы, адым саен «халкым» дип лаф оручы ябышкак «халыкчанлык» түгел. Бу — асыл сыйфатлары һәм максаты белән социалистик, яңа тип халыкчанлык: монда үз халкыңа, милли культураңа ихлас мәхәббәт белән интернациональ хис, гомумкешелек дәрәҗәсендәге карашлар бергә кушыла. «Безгә фәкать үз кабыгыбызга бикләнеп калырга мөмкин түгел... Безгә гакыл вә фикеребезне гомумкешелек офыгына таба юнәлдерергә — ...татар әдәбиятыннан үтеп, бөтендөнья әдәбиятының тарихи агымнары белән дә танышырга лазем булачак».

«Казакъ кызы» һәм «Безнең көннәр» авторы, татар дөньясына дөнья мәдәнияты киңлекләренә чыгу, Байроннан алып Фозулигәчә киңлекләрне иңләү, рус классикларыннан өйрәнү хаҗәтен йөрәк каны белән язган Г. Ибраһимов нәкъ менә бүгенге аңлавыбызча, заманыбыз рухында халыкчан. Ул безнең барыбызны да шәхес камиллегенең бер сыйфаты, рух хезмәтенең бик мөһим мәгънәсе буларак халыкчанлыкка өйрәтә.

Г. Ибраһимов — Владимир Ильич Ленин тарафыннан «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» исемле хезмәтендә үк, яңа әдәбият кадрлары турындагы атаклы фикер рәвешендә, алдан әйтеп куелган һәм «бишенче елны уянган» фидаиләрнең берсе. Социализм идеясе һәм хезмәт ияләренә тәләктәшлек — шушы аерылгысыз бердәмлек Г. Ибраһимовның, күпмилләтле совет әдәбиятына нигез салышкан башка әдипләрнең тормыш һәм көрәш нигезе булып тора. Әлеге бердәмлек аларның һәркайсында үзенчә чагыла: әйтик, Айни — Упитка, Хәмзә — Коласка охшамаган, әмма нигез бер, нигез уртак.

Хәзер менә «социализмны күбрәк, демократияне күбрәк» дибез икән, бу бит әдәбиятыбызга да турыдан-туры кагыла: үсә баручы, камилләшә баручы социализм идеяләре нигезендә — демократик тәләктәшлек, демократик хисләр!

Икенче сабак: язучы Ибраһимовның, политик Ибраһимовның, тарихчы Ибраһимовның — кыскасы, философиядә дә, сәнгатьтә дә, тел яисә музыка гыйльмендә дә үзенең карашлар системасы булган, шуңа да карамастан үзенең белгәнен әле дә җитәрлек түгел дип санаган энциклопедист Ибраһимовның искиткеч караш киңлеге. Әдип һәм журналист, галим һәм дәүләт эшлеклесе буларак та, гаять бай мәгълүматлы, зәвыклы кеше буларак та, ул гомере буе үсүдән, камилләшүдән туктамаган...

Хәзер инде энциклопедистлар заманы узды, безнең гасыр — бер тармакта басылып эшләү, дифференциацияләшү дәвере, дигәнне еш ишетергә туры килә. Ләкин, беренчедән, бу әле — тараю, тарлык дигән сүз түгел, ә икенчедән, без яшәгән чор дөньяны күпкырлы һәм бербөтен итеп, иңләп күрүне дә таләп итә. Психологик яктан, нәкъ менә Ибраһимов замандашлары ниндидер бер өлкәдә «үз коеңны гына казу» күренешен ничек тә булса аңлата алырлар иде. Бәхеткә каршы, әдәбиятыбызга, яңа культурабызга нигез салучылар, максатларына гаять тугрылыклы булган хәлдә чикләнеп калмаганнар, гаҗәп киң сфераларны колачларга омтылганнар. Чөнки аларның карашы үз дәверләрен узып, бик еракка төбәлгән булган.

Бүген дә безгә нәкъ менә дөньяга карашы киң, кызыксынулары чәчелеп китми торган бер көлтәгә бәйләнгән, тормышны яхшы белә һәм аның күпкырлы бербөтенлеген тирәнтен аңлый торган язучылар кирәк. Алар — иртәгәге көнгә юл салып баручылар. Иллюзияләргә, төшенкелеккә, куркаклыкка бирелми торган намуслы реализм язучылары кирәк безгә. Аларның кояшны яхшы тоюлары кирәк, югыйсә тормышыбызны ямьлерәк итү юлларын күрү кыен булачак. Ул кояш Г. Ибраһимов прозасында, мәсәлән «Тирән тамырлар»ында, даими мотив-сөземтә булып бара, 1915 елгы бер мәкаләсендә ул «гакыл вә фикеребезне бәни адәм кешелек дөньясы кояшы белән яктыртырга» чакыру булып та күренә.

Ниһаять, Г. Ибраһимовның тагын бер сабагы. Бу — фидакарьләрчә, куркусыз рәвештә чынлыкны эзләү, шул юлда яну. Галимлегеннән килә әлеге сыйфат, дип әйтергә мөмкин. Ләкин ул гына җитми. Ибраһимов язучы, сәясәт эчендәге большевик буларак та чынлыкны эзли. Бу аның ныклап формалашкан, табигый *шәхес сыйфаты*. К у р к у с ы з дигән сүзне дә мин басым ясап әйтәм. Шул сыйфат аны Колчак тылына алып китә. Милләтчеләр белән дәвамлы, ныклы бәхәскә тарта. Әнә, 1917 елда, Милли Шура корылтаендагы кебек... Күзгә күренерлек җиңүгә ирешү мөмкинлеге алдан ук киселгән, ә ул барыбер бара. Һәм интернационализм ягына тарафдарлар яулап кайта... Шул куркусызлыгы аркасында ул Кырым санаторие «тоткыны»ннан элеккечә үк мәгариф өлкәсенең актив хезмәткәренә социалистик культураның актив төзүчесенә әверелә. Үзенә гаять таләпчән, кульъязмаларын тагын да камилләштерүдән туймаган әдип булып кала!

Бу яну, куркусызлык яктысы, язучы шәхесенең нурлары аның яраткан персонажларына — Ибраһимов прозасының кешелекле, хөр күңелле, армый-талмый эзләнүчән, горур һәм кыю холык-фигыльле геройларына күчеп калган.

Бүгенге прозабыз, шул исәптән татар прозасы да, шактый озын үсеш юлы үтте. Ибраһимовлар заманында булмаган сыйфатлар белән баеды. Ләкин XVII гасырның бер

канатлы сүзен онытмыйк (аны Ньютон белән Маркс та кабатларга яраткан): безнең ерактан күрүебез — алыплар җилкәсенә менеп басканга күрә.

Безне күтәргән алыплар арасында Галимҗан Ибраһимов та бар.

# Михаил Колосов

Татар халкы талантларга гаҗәп бай. Әле генә татар халкының бөек уллары, күп милләтле зур гаиләбезнең горурлыгы булган Тукай һәм Җәлил бәйрәмнәрен билгеләп үткән идек. Инде бүген энциклопедик белем һәм талант иясен, чын мәгънәсендә Яңарыш чорына лаеклы шәхес — әдип галим, революционер Галимҗан Ибраһимовның 100 еллыгына җыелдык.

Г. Ибраһимов гади язучы гына түгел, ул — хәзерге заман татар әдәбиятының башында торучы, аңа нигез салучы да.

Нигез салу гомумән гадәти нәрсә түгел, әдәбияты гасырлар тирәнлегенә тоташкан халык вәкиленә исә — бигрәк тә. Чөнки бу очракта үзеңә кадәр хасил ителгән барлык культура хәзинәсен үзләштерергә һәм аны үз талантың белән баетырга кирәк. Сан ягыннан ишәйтү әле бер хәл, әлегәчә тиңе булмаган, дәверләр карашын үзгәртерлек яңалык алып килү таләп ителә.

Галимҗан Ибраһимов әнә шундый юл уза һәм үз иҗаты белән халкын яңа биеклеккә күтәрә, аңа юл ача.

Ибраһимовның тормышы шундый бай, тыгыз эчтәлекле, күпкырлы, эшлекле һәм нәтиҗәле ки, ирексездән гаҗәпкә каласың: ничек боларның барысын да эшләп өлгергән ул, ничек вакыт җиткергән... Аның эшен, тормышын биш, ун кешегә бүлеп бирсәң дә, аларның һәркайсы үзенчәлекле шәхес кенә түгел, ә зур йолдыз, мәшһүр язучы яки галим, яисә дәүләт эшлеклесе булыр иде шикелле.

Илле еллык гомер эчендә Г. Ибраһимовның әдәби хезмәтләре генә дә 700 ләп табакка җыела: дүрт роман, өч повесть, дистәләгән хикәяләр, пьеса. Ул революцион хәрәкәт тарихына әдәбият гыйльме һәм тарихы, эстетика һәм тел гыйльменә караган 12 фәнни китап бастырган, 350 ләп теоретик, публицистик һәм тәнкыйть мәкаләсе язган. Тел һәм әдәбият буенча дистәдән артык дәреслек авторы да — Ибраһимов.

Ә бит ул кабинетта бикләнеп утыручы «кәгазь корты» булмаган, йөргән юлларын картадан гына карасаң да баш әйләнерлек. Казан, Киев, Оренбург, Уфа, Кавказ, янә Казан, янә Киев, Мәскәү, Петроград, Одесса, Ялта, Керчь, Сухуми, Сембер, Красноуфим, Екатеринбург, Төмән, Ишим, Курган һ. б. җирләр. Болар бит туристик сәяхәттә күргән калалар түгел — аларда ул укыган, эшләгән, партиянең катлаулы йомышларын үтәгән. Аның революцион эшчәнлеге тулысынча актив эчтәлекле һәм шуңа күрә хәтәр борылышлар белән тулы. Дошман тылында партия кушкан бер эшне башкарып чыгу гына да ни тора. Ул гомерен кыл өстенә куеп, Колчак гаскәренең тылында йөри, әмма бурычын уңышлы үти һәм бай разведка мәгълүматлары алып кайта.

Ә Татарстанда һәм Башкортстанда совет власте урнашу чорында Ибраһимов нинди катлаулы һәм гаять мөһим эш алып бара! Буржуаз милләтчеләр, мөселман реакционерлары белән көрәш, аннары, революция һәм гражданнар сугышыннан соң, әдәбият, фән һәм мәгариф өлкәсендә киң колач белән, ару-талуны белми эшләү. Халыкның яңа тормышындагы бер генә әһәмиятле чара да Ибраһимовның актив катнашлыгыннан башка узмый: туган тел сафлыгы өчен көрәшме ул, татар язуы реформасымы. Ибраһимов — РСФСР Художество фәннәре Академиясенең хакыйкый әгъзасы... Аның бөтен эшләрен, хезмәтләрен санап бетерү дә бик кыен. Тикмәгә генә, 1928 елда, ВЦИКның М. И. Калинин кул куйган Карары нигезендә, Г. Ибраһимовка Хезмәт батыры исеме бирелмәгәндер.

Шул ук вакытта Ибраһимовның милли культура, әдәбият һәм фән өлкәсендәге эшчәнлегендә зур интернационалист булуын аерым басым ясап әйтәсе килә. Бөек кешеләргә һичкайчан да тәкәббер шовинизм, тар милләтчелек чире йокмаган, алар һәрвакыт чын интернационализм биеклегендә кала алганнар.

Галимҗан Ибраһимовтагы интернационализм, минемчә, татар халкының киң күңелле табигатеннән килә. Беренче тапкыр Совет әдәбияты көннәрендә Татарстан туфрагына аяк баскач, бу төбәк үзенең интернациональ рухы белән, күп милләтле, бердәм, хезмәт сөючән халкы белән минем туган Донбассымны хәтерләтте.

Казан — төрле милләт балаларын үз куенына сыендырган, бик күп бөек кешеләргә «тормыш университетлары» булган. Ленин беренче революцион чыныгу алган шәһәр.

Татарстанда Совет әдәбияты көннәре уздырылганнан соң инде берничә ел вакыт үткән, ә аның гүзәл халкына булган җылы хисләр бездә әле дә сакланалар. Һәм алар җуелмас та.

Гаҗәеп тыйнаклык һәм күңел юмартлыгы, башка халыкның үзенчәлегенә сак, ихтирамлы мөнәсәбәт белән бергә үз халкыңның милли аң үсеше, иҗтимагый-тарихи урыны

белән хаклы рәвештә горурлану — татарларның менә шул сыйфатлары аеруча истә калды. Кыскасы, мин татар халкының асылында интернациональ колачны тойдым. Г. Ибраһимов юбилее көннәрендә —,аның үз хезмәтләрен, аның турында төрле истәлекләр, мәкаләләр укыганда да, мин шул тәэсирләрне искә төшердем. Моннан җитмеш-сиксән ел элек булган хәлләрне күз алдыннан кичергәндә, нигезен Ибраһимовлар салышкан бүгенге Татарстан күз алдыма килде. Ибраһимов үз халкының бөек улы, халкына лаек улы, дип уйладым. Ә татар халкының үзенә лаек уллары күп: Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Гафур Коләхметов, Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури, Шәриф Камал, Шамил Усманов, Муса Җәлил, Кави Нәҗми, Һади Такташ, Хәсән Туфан... Берәүләре өчен ул варис, традицияләренең дәвамчысы булган, икенчеләрен рухландыручы, аларга юл күрсәтүче, ә кайберләренә остаз... Еллар үткән саен, тарих яңа сәхифәләр ача, күпләр анда бер яктырып, күзгә чалынып кына китә, аннары югала, онытыла, әмма буыннан буынга кабатлана килә, яктыра барган исемнәр арасында ул да бар. Кулына быел гына Әлифба алган сабыйлар ул исемне иҗекләп укыйлар: *Галимҗан Ибраһимов!*

## Виль Гримич

Йөз еллык — дәрәҗәле һәм тәэсирле вакыйга. Зур саннар, «түгәрәк» даталар, грандиоз төзелешләр һәм шундый ук масштабтагы җимерелүләр кешеләрне гомумән нык әсәрләндерә. Әйтерсең лә тормышның бөтен мәгънәсе аларга гына салынган. Югыйсә хаят дигәнебез һәркайсы мөстәкыйль кыйммәткә ия булган бихисап мизгелләрдән, көндәлек эш һәм мәшәкатьләрдән гыйбарәт. Адәм баласының яшәеш батырлыгы да әнә шулай, әкренләп, тамчылап, һәр көнне кылган фидакарьлекләрдән җыела. Инде без бүген күренекле шәхеснең йөз еллыгын билгеләп үтәргә җыелганбыз икән, «түгәрәк» сан уңаеннан дан җырлау белән мавыкмыйча, аның кабатланмас эчтәлекле, гыйбрәтле тормышындагы барча юллар һәм сукмаклар буйлап яңадан бер тапкыр үтәргә тырышыйк.

Әйе, зур юбилейларны билгеләп үтәргә өйрәнеп җиттек инде без. Үткән ел бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның йөз еллыгына Украинада аның сайланма шигырьләр китабы нәшер ителде. Ул, нигездә, яңа, юбилей уңаеннан махсус әзерләнгән тәрҗемәләрдән төзелде. Гәрчә Павло Тычина һәм аның замандашлары хезмәте нәтиҗәсендә дөнья күргән элеккеге басмалар да игътибардан читтә калмаган иде. Герой шагыйрь Муса Җәлилнең тууына сиксән ел тулу мөнәсәбәте белән, «Днiпро» нәшрияты аның легендар «Моабит дәфтәре»н яңа басма итеп, ике телдә — татарча һәм украинча, фронтовик шагыйрьләребез тәрҗемәсендә бастырып чыгарды. Әлеге китапның бөтен тиражы—34 мең данә — ике атна эчендә таралып та бетте. Моңа, билгеле, тиражның бер өлеше — Татарстан китап сәүдәсе оешмаларына китүе дә, шуның өстенә Киевнең үзендә кырык меңләп татар яшәве дә сәбәпче булгандыр, әмма әлеге китапның төп адресаты барыбер украин телендә укучылар иде, һәм аның шулай җылы кабул ителүе — безнең халыкта Җәлилнең тормыш һәм иҗат батырлыгына хөрмәт һәм мәхәббәт саклануын күрсәткән мөһим дәлил булды. Г. Ибраһимов әсәрләренең украинчага тәрҗемәдә тизрәк дөнья күрүен дә ничек кызыксынып көтүебез аңлашыладыр. Бу әдипнең тормышында җитмеш биш ел элек Украина җире, украин халкы белән бәйләнгән сәхифәләр булуы әлеге кызыксынуны көчәйтә генә.

Яшь, дәрт-дәрманы ташып торган Галимҗан Ибраһимов Киевкә 1912 елда килеп төшә. Максаты — мөселман шәкертләре һәм яшьләренең тормышы белән танышу, алар арасындагы революцион оешмалар белән яшерен элемтә урнаштыру. Бу эш бер ел чамасы уңышлы гына бара, әмма 1913 елның 17 апрелендә Г. Ибраһимов үзенең фикердәшләре белән кулга алына һәм төрмәгә элгә. Тоткында әллә ни озак ятарга туры килми, әмма шул хәлләрдән соң, 1913 елның июненнән алып тәмам 1917 елга кадәр яшь язучы һәм революционерның һәр адымы диярлек полиция күзәтүеннән читтә калмый. Бөек язучылар тормышындагы бер генә вакыйганың да гадәттә эзсез югалмавы мәгълүм. Ул чордагы хәлләр эзеннән, тәэсирләр кайнар чагында ук «Безнең көннәр» романы языла. Ул әсәр детальләр һәм характеристикалар төгәллеге, революцион көрәштә катнашучыларның тоткындагы кичерешләрен ышандырырлык итеп тасвирлавы белән сокландыра.

Патша ялчыларының тырышлыгы аркасында, Г. Ибраһимовның украин җире белән беренче танышуы әнә шулай күңелсезрәк тәмамлана. Шуңа да карамастан, берничә ай үтүгә, ул янә Киевкә килә. Соңыннан, Киев вакыйгаларын, үзенең 1912—13 елларда бирегә булуын «файдалы мәктәп» дип санар Г. Ибраһимов. Әлеге мәктәптә ул алган иң мөһим сабаклардан берсе, һичшиксез, бөек украин шагыйре Тарас Шевченконың тормыш һәм иҗат язмышы белән танышу булгандыр. «Малорус халкы Шевченконы шул дәрәҗәдә якын хис итә, аның исемен шул дәрәҗәдә йөрәгенә ала ки, моңа гаҗәпләнмәскә мөмкин түгел»,— дип әсәрләнеп яза Г. Ибраһимов.

Прогрессив җәмәгатьчелек нәкъ шул вакытларда, патша властьларының тыюына карамастан, бөек Кобзарьның 100 еллыгын билгеләп үтәргә җыена. Әлеге вакыйгалар тәэсиреннән 1914 елның 26 февралендә Казанда чыга торган «Йолдыз» газетасында Г. Ибраһимов «Каһарман шагыйрь» дигән мәкалә бастыра. Ул анда, художник һәм патша самодержавиесенә каршы көрәшче буларак, Тарас Шевченконың әһәмиятен югары бәяли. Шул көннәрдә Украина җирендә хөкем сөргән гаҗәп күтәренке атмосфера, халыкның бөек шагыйрьгә карата булган кызыксынуы һәм мәхәббәте турында Г. Ибраһимов сокланып һәм рухланып яза. «Кавказга үтешли миңа Киевкә туктарга туры килде,— ди ул әлеге мәкаләсендә.— Бу шәһәр, гомумән бу тараф, Шевченко белән тулган. Монда булып та Шевченко хакында язмый үтү — һич мөмкин түгел. «Шевченконы әдип, барыннан да элек, хөррият каһарманы, патша самодержавиесе тарафыннан изелгән һәм кимсетелгән халыкның тарихи идеалларын җырлаучы буларак искә ала.

Катгый тыю шартларында әлеге бәйрәмдә катнашу гына да кешеләрдән шактый кыюлык таләп иткәнлектән, бөек Кобзарьның 100 еллыгына әзерләнү атмосферасын дөрес тасвирлау һәм бәяләү ягыннан әлеге мәкалә безнең өчен аеруча кыйммәт. Аждаһага каршы чыккан яшь баһадир сыман, шундый заманда ачыктан-ачык чыгыш ясаган каләмдәшебезнең батырлыгын да ничек кенә бәяләсәң дә аз булыр кебек.

Тарас Шевченконың СССР халыклары телләренә тәрҗемәләнгән әсәрләре, аның иҗаты хакында төрле телләрдә басылган хезмәтләр бүген башлыча әдәби-эстетик әһәмияткә ия булсалар, тарихыбызның Бөек Октябрьгә кадәрге чорында алар әле моннан тыш гаять дәрәҗәдә революцион көрәшкә рухландыручы бер көч тә булганнар. «Ятимнәр бер-берен тиз аңлыйлар,— дип язганда, Г. Ибраһимов та Шевченко иҗатының минә шушы тәэсирен бик төгәл билгели.— Шевченконың халкы белән безнең татарның язмышында күп уртак нәрсә бар. Шевченконың йөрәгендә кайнаган ...күп дәрт вә хәсрәтләр бездә, безнең татарда да бар... Мин шагыйрь-каһарманның үзендә, халкының язмышында, милли кайгыларында безгә куәтле бер якынлык күрәм».

Мондый сүзләрне бары тик халыклар дуслыгына нык инанган чын интернационалист кына яза ала.

Әдипнең бөеклеге — аның иҗатында, диләр. Бу — Г. Ибраһимовка да карый. «Татар хатыны ниләр күрми» һәм «Яшь йөрәкләр», «Безнең көннәр» һәм «Кызыл чәчәкләр», «Казакъ кызы» һәм «Тирән тамырлар», күп санлы хикәяләр, гыйльми хезмәтләр — бөеклекнең нигезен әнә шулар тәшкил итә.

Әдипнең бөеклеге — аның халыкка мәхәббәтендә һәм халыкның аңа мәхәббәтендә! Бу да шулай ук Г. Ибраһимовка хас сыйфат. Үзе исән вакытта ук зур талантын тану, аерым алганда, 1928 елда аңа «Хезмәт батыры» дигән исем бирелү, ниһаять, менә бүгенге тантаналар да моңа бик нык дәлил.

Әдипнең бөеклеге — рух ныклыгында! 140 ел аша ерак сөргеннән безнең Кобзарьның: «Газап чигәм... мәгәр тәүбә итмим!»— дигән сүзләре ишетелә. Г. Ибраһимов та тормышының барлык дәверләрендә шундый ук рухи ныклык белән аерылып торган.

Без, бу бәйрәмгә килгән мәскәүлеләр һәм кунаклар, өйләребездә төрле телләрдә сөйләшәбез, әмма бүген барыбызны да уртак хисләр берләштерә. Моның өчен без бөек татар язучысы Галимҗан Ибраһимовка бурычлыбыз. «Телләр башка булса да, күңелләр бер»,— дип язган ул үз вакытында. Бер мәкаләсен шулай дип атаган. Бу — безнең Павло Тычинаның «Бердәм гаилә тойгысы» дигән сүзләренә гаҗәп аваздаш. Әйе, безне бердәм гаилә тойгысы, күңелләр берлеге якынайта. Уртак уңышларыбыз һәм җиңүләребезнең нигезе дә шунда.

## Пиримкол Кадыйров

Галимҗан Ибраһимов — татар халкының зур тарихы һәм культурасы белән тәрбияләнгән үлемсез шәхес. Аның эшчәнлеге ирексездән тарихи җирлек, тирән тамырлар турында — илебез халыкларының рухи якынлашуын һәм үзара культура бәйләнешләрын үстерүдә казан татарлары тоткан урын турында уйландыра.

Академик Конрадның мең еллык тарих мисалында гомумкешелек дөньясының бердәмлеген, аның көнчыгыш һәм көнбатыш тармаклары арасындагы үзара бәйлелекне раслаган фикере бар. Халыклар һәм аларның культуралары арасындагы мөнәсәбәтләр миңа кайчакта күк җисемнәре хәрәкәтен хәтерләтә. Үзара йогынтыдан гыйбарәт бөек көч, аларга мәгълүм дәрәҗәдә мөстәкыйльлекләрен һәм шул ук вакытта галәмдәге даими үсешне, гармонияне сакларга ярдәм итә...

Шәрык һәм Гарәп халыкларының үзара тартылу тәэсиренә тарихта мисаллар бихисап. Шулардан татар теленең аерым тарихи чорларда Россиядә халыкара мөнәсәбәтләр теле булуын гына искә төшерү дә кызыклы. Иван III кә бер илдән теле һәм язуы аңлашылмаган хат килгәч, ул: «Рус патшасы илчелеге чит илләр белән тик рус, латин һәм та-

тар телләрендә генә язышa».— дип җавап биргән. Мәсәлән, патша Алексей Михайлович-ның Һиндстан шаһиншаһына, ә Михаил Федоровичның монгол ханына гарәп хәрефе белән татарча язылган грамоталары саклана...

Россия белән Көнчыгыш халыклары арасында алдынгы фикер һәм рухи культура илчеләре булaрак Татарстан улларының эшчәнлеге революцион күтәрелеш чорларында аеруча югары үсеш ала. Революциягә кадәр безнең тарафларга, үзбәк халкына Пушкин, Толстой, Крылов сүзе беренче тапкыр татар газета һәм журналларындагы тәрҗемә аша килеп керә. Шул ук вакытта Галимҗан Ибраһимов кебек чын революционерлар татар халкының гына түгел, илебездәге бөтен мөселман халыкларының иң кискен милли проблемаларын беренче булып күтәреп чыгалар. Шәрыкның изелгән халыкларына карата бердәнбер дөрес ленинчыл милли политиканы эшләүгә дә Г. Ибраһимов һәм аның көрәштәшләренең хезмәте зур этәргеч ясый. Мин моны әдәбият галиме Мансур Хәсәновның Мәскәүдә басылып чыккан китабын укыганда аеруча ачык аңладым.

«Казакъ кызы», «Безнең көннәр», «Яшь йөрәкләр», «Тирән тамырлар» кебек үлемсез китаплары белән Г. Ибраһимов безнең төрки телле халыкларда революцион аң уянуга йогынты ясады. Зур язучыбыз Айбек: «Без Г. Ибраһимов романнарын татар телендә укыдык. Чын-чынлап алардан аерыла алмый идек. Аның әсәрләрен яраттык һәм аның эзеннән барырга омтылдык».— дип сөйли иде.

Г. Ибраһимовның иҗат эшчәнлегенә егерме ел тулуны билгеләп үткән көннәрдә, 1928 елда Ташкентта үзбәк телендә «20 еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт итүенә атап чыгарылган мәҗмуга» дигән мәкаләләр җыентыгы басыла.

Нәкъ шул елны дөньяга килеп, берничә еллар үткәч, мин, яшүсмер малай, әдипнең «Тирән тамырлар»ын үзбәк телендә укып никадәр әсәрләнгәнемне хәтерлим. Фәхринең үлеме, аның хатыны Гайшә һәм эшче дусты Садыйк язмышы өчен ничек борчылуым әле дә күз алдымда тора. Безнең буын өчен дә Г. Ибраһимов китаплары, әнә шулай, халык күңеле белән тоташтырган тирән рухи тамырлар булып әверелде.

«Галимҗан Ибраһимов татар халкының гына түгел, ә бәлки бөтен көнчыгыш халыкларының бөек язучысы».— диюе белән Сәмәд Вургун мең кабат хаклы.

Г. Ибраһимов хәзергә хәтле көнчыгыш белән көнбатыш арасындагы рухи күперне, бер-берсенә тартылу көчен гәүдәләндерүе белән дә бөек.

Галәмдәге җисемнәрне тотып торган гаҗәеп механизм белән халыклар, культуралар арасындагы мөнәсәбәтне тикмәгә генә чагыштырмаган идем. Әгәр шундый көч, тигезлек булмаса, планеталар үз кучәрләреннән ычкынып бер-берсенә бәрелерләр дә, коточкыч фаҗига килеп чыгар иде.

Кешелек дөньясына да һәрвакыт шундый куркыныч янап тора. Халыкларның, илләрнең бер-берсенә бәрелү, бер-берсен юк итү көченә каршы торучы үзара тартылу көче — җир йөзендә иминлекне тәэмин итүче бердәнбер терәк. Нәкъ менә шуңа күрә халыклар арасындагы бәйләнешләрны тирәнәйтү, ныгыту өчен хезмәт итүчеләрне без чын күңелдән хуплыйбыз һәм хөрмәтлибез. Г. Ибраһимов — кешелеккә әнә шул рәвешле хезмәт итүче бөек шәхесләрнең берсе.

Сүземне: «Галимҗан Ибраһимовның исеме һәм эшләре гасырлар буена яшәсен, дөньяга аны тудырган татар халкына дан!»— дип тәмамлыйсым килә.

## Калаубәт Торсынколов

Гасырыбызның беренче чирегендә яшәгән милли зыялылар иңенә гаять зур бурыч йөкләнә — алар культура һәм мәгърифәт өлкәсендәге барлык мәсьәләләр белән шөгыльләнергә тиеш булалар: алар әдәби әсәрләр, фәнни һәм публицистик мәкаләләр язалар, алдынгы карашларны тормышка ашыруда, җәмгыять тормышын агарту һәм демократлаштыруда турыдан-туры катнашалар. Илебезнең шундый киң колачлы эшлеклеләреннән берсе Галимҗан Ибраһимов була. Теләсә кайсы халыкның бөек уллары беренче чиратта интернационалист табигатьле шәхесләр, үзләренең уйлары һәм гамәлләре белән гомумкешелек мәнфәгатьләрен яклыйлар, шул якты идеяләрне тормышка ашыруга бөтен гомерләрен багышлыйлар.

Г. Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлы казах даласы белән тыгыз бәйләнгән. Әле ул чакта туып кына килүче яңа казах мәдәнияты һәм әдәбияты эшлеклеләре татар культурасы үзәкләрендә беренче чирканчык алалар: Троицкида казах телендәге беренче журнал — «Айкап» нәшер ителә, Уфада казахның зур әдипләре булып танылачак шәхесләр белем ала. Хәтта Колчак тылында да язмыш Г. Ибраһимовны үзе кебек үк патриот, революционер, шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Сәкен Сәйфуллин белән очраштыра, дуслаштыра. Казах язучылары Г. Ибраһимов фигурасының зур тәэсирен һәрвакыт тоеп, аннан дәрт-дәрман алып иҗат итәләр. Казах әдәбиятының үсешенә ул ясаган уңай йогынты төрле рәвешчә чагыла.

«Яшьлегендә Г. Ибраһимов казах күчмә авылларында яшь мөгаллим булып, балаларны татарча укырга-язарга өйрәтә: ә ул заманда әле казахның үз милли мәктәбе юк иде. Шул еллар язучыга «Казакъ кызы» кебек менә дигән роман иҗат итәрлек гаять зур материал бирә. Халкыбызның хәятен мәхәббәт белән сурәтләве өчен казахлар Ибраһимовка һәрвакыт рәхмәтле булып калырлар»,— дип яза казах совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе Сабит Моканов. Г. Ибраһимов белән беренче очрашуын ул менә болай тасвирлый: «Танышкач та миндә шундый тәэсир уянды, әйтерсең лә аны бик күптән белгәнмен. Ул хаста иде, еш йөткерә, авыр сулый, әмма, шуңа да карамастан, казах авылы, аның кешеләре турында иркенләп, бик хисләнеп искә алды (ә сөйләшүе саф казахча иде). Мин аның казах халкының телен, гореф-гадәтләрен һәм культурасын ни дәрәҗәдә яхшы белүенә тагын бер тапкыр ышандым».

Әйе, Г. Ибраһимовның казах халкын бик яхшы аңлавы хак. Ул аның тарихын гына түгел, шул замандагы хәлен дә белгән, ерак киләчәгенә дә өмет белән караган. Ибраһимовның милли культуралар үсешен яклап язган мәкаләләре хәзер һәркемгә билгеле. Аерым алганда, ул анда казах яшьләренең тәрәккыяткә омтылуын, ана телендә матбугат һәм дәреслекләр чыгара башлавын да хуплап телгә ала. Буржуаз милләтчеләргә һәм пантюркистларга каршы чыгып, Г. Ибраһимов яңа реалистик казах әдәбиятын һәм казах әдәби телен барлыкка китерүдә Абай Конанбаев уйнаган гаять зур рольне күрсәтә. «Бу көнгә казах халкы үзенең көнкүреше, хәят ихтыяҗлары белән башка төрки кабиләләрдән бик нык аерыла,— дип язды Г. Ибраһимов,— бу халыкның рухында бик куәтле самобытность бар. Боларның халык әдәбияты башка һичбер төрле кабиләнекенә охшамас дәрәҗәдә бай һәм зурдыр. Безгә, казахларны татар теле вә әдәбияты астына кертү хыялыннан бигрәк, әдәби хәзинәбезне баету өчен казах халкы әдәбиятын киң рәвештә өйрәнү тиешледер... Казахлар да беразгача татар мәдәниятенә вә татар әдәбиятына шәкерт булырлар. Ләкин бара торгач алар үзләренең мөмтаз (үзгә) рухлары белән парлак (якты) мәйданга чыгачаклар. Моны һичбер куәт туктата алмаячак». Бу — казах культурасы һәм әдәбиятының гына түгел, илебездәге барча милләтләрнең һәм халыкларның киләчәген яклау иде. «Һичбер халыкның авызына һичбер вакытта, аның табигый телен тартып алып, үзең теләгән яңа бер тел куяр хәл юк, ди Г. Ибраһимов. Әдәби тел һичбер вакыт ясалмый. Ул халыкның үз рухындагы мәгънәне нинди тел белән әйтергә теләвеннән килеп чыга». Шул ук вакытта ул якты киләчәк хакына идеяләр бердәмлеген, көрәш юлларының уртаклыгын куәтли һәм әлеге хезмәтен «телләр башка булса да, күңелләре бер» дип атый.

Г. Ибраһимов белән бер елларда «Галия» мәдрәсәсендә казах совет әдәбиятына нигез салучылардан Баембәт Майлин, танылган казах язучысы Ж. Тилепбергенов һ. б. лар укый. Алар анда «Садак» исемле кульязма журнал чыгаруда да катнашалар. Баембәт Майлинның иң яхшы әсәрләреннән берсе — казах хатыны язмышына багышланган «Шуга» да нәкъ менә шул елларда языла. Кем белә, остазының шәрык хатын-кызларын агарту, азатлыкка чыгару турындагы карашлары да моңа этәргеч булгандыр.

20 нче еллар совет әдәбиятына кыйммәтле өлеш булып кергән «Казакъ кызы» романы да татар прозасының иң күренекле әсәрләреннән санала бит. Хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе гасыр башында бөтен Көнчыгыш зыялыларын дулкынландырган. Революциягә кадәр үк казах язучысы һәм мәгърифәтчесе С. Кубеевның «Калым» исемле романы, шагыйрь С. Торайгыров «Камәр-сылу» дигән шигъри романы шул темага багышланган. 20 нче елларда Мохтар Әуэзов, Сабит Допентаев әсәрләре дә әлеге традицияне дәвам итә.

Казах язучыларының мондый иҗади эзләнүләрендә, татар шагыйрьләре Габдулла Тукай һәм Акмулла белән беррәттән, Г. Ибраһимов иҗаты да гаять зур роль уйнаган. Аларның өчесен дә казахлар үз әдипләре итеп хөрмәтлиләр икән, бу тикмәгә генә түгел. Аларның әсәрләре — якты киләчәк хакына көрәш байрагын күтәргән барлык халыклар өчен уртак хәзинә.

Фикеремне янә язучы-академик Сабит Моканов сүзләре белән беркетеп куясым килә. «Казахлар Г. Ибраһимовны үз, казах әдибе дип саныйлар... Шәп кеше һәм шәп язучы булган Г. Ибраһимов исеме күпмилләтле социалистик культурабыз тарихына гомерлеккә кереп калды».

## Әсгать Мирзаһитов

Башкортстан туфрагында туып, Уфаның атаклы «Галия» мәдрәсәсендә белем алган, башкорт халкы исеменнән революцион Россиянең иң югары вәкаләтле оешмаларына сайланган күренекле язучы, революционер һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан ага Ибраһимов Башкортстан Автономияле Совет Социалистик Республикасында иң тирән хөрмәткә лаек исемнәрнең берсе. Аның рухы безнең тарихыбыз сәхифәләрендә һәм көндәлек эш-

ләребездә яши. Республиканың иң әйбәт колхозы, Уфа каласының иң ямьле бульварларыннан берсе Г. Ибраһимов исемен йөртә, туган авылы Солтанморатта аның мемориаль музей йорты, һәйкәле бар.

Сабак биргән генә остаз түгел, шәкертләре булган — остаз, диләр. Г. Ибраһимов башкорт әдипләре өчен нәкъ менә шундый остазга әверелде. Үзе исән вакыттагы ук шәкертләре Шәехзадә Бабич белән хәзер 94 яшькә җиткән, Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи Кудаштан алып, бүгенге иң яшь язучыларга кадәр аның идея-эстетик йогынтысын кичереп киләләр. Г. Ибраһимов биргән сабак нәтиҗәле һәм гомерлек була.

Ул иҗат юлының башында ук халыклар дуслыгы җырчысы, чын интернационалист булып танылды, самодержавие тарафыннан изелгән халыкларның бөек рус халкы белән дуслыгында социалистик дәүләтебезнең какшамас нигезен күрде. Бөтен тормышы, иҗаты, киң колачлы фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлеге белән дә ул үзенең интернациональ рухын раслады.

Галимҗан Ибраһимов Октябрь революциясен колач җәеп кабул итү генә түгел, революционер-ленинчылар белән бер сафта торып, күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм художник-реалист буларак, эзәрлекләүләр һәм төрмәгә ябулардан курыкмыйча, үзенең гыйсъянчы рухы белән дә якынайтты. Октябрь революциясеннән нур алып балкыган бу гаять зур шәхес халык массаларының чын лидерына әверелде.

Мулланур Вахитов, Шәриф Манатовлар белән бергәләп, РСФСР Милләтләр Халык Комиссариатының Үзәк мөселман комиссариаты җитәкчеләреннән берсе буларак, ул ленинчыл милли политиканың чыганаклары янында торды, әлеге политиканың җиңүе һәм тантана итүенә үз өлешен кертте. Без, бу бөек тәгълиматның варислары, бүген ленинчыл милли политиканың катып калган бөек монумент түгел, ә мәңге хәрәкәттәге процесс, бөтен Совет кешеләренең халыкларыбыз дуслыгы һәм туганлыгы турында даими һәм сизгер кайгыртучанлык күрсәтүе, Коммунистлар партиясе тирәсенә тыгыз тупланoccupational

Шуңа күрәдер дә Г. Ибраһимовның күпкырлы һәм биниһая олы талантына халык мәхәббәте чиксез. Художник буларак ул замандашларыбызның эстетик ихтыяҗына һәм сәнгатьчә зәвыгына җавап бирә, ә бу — чын классика сүз сәнгатенең мәңге тере һәм саф чишмәсе ул, дигән сүз.

Кайчандыр зур рус язучысы тарафыннан әдәбият титаны дип аталган Г. Ибраһимов татар әдәбиятында гына түгел, бөтен төрки Көнчыгышы өчен ифрат зур фигура булды һәм шулай булып кала. Ул һәрвакыт безнең идеология фронты солдаты, ә аның китаплары хәзинәбездәге тутыкмас корал булачак. Г. Ибраһимов исеменә, бу олы һәм кабатланмас талантны тудырган татар әдәбияты исеменә әйтелгән мактау сүзләренең мәгънәсе һәм әһәмияте менә шунда.

# Туфан Миңнуллин

Гаҗәп хәл: культурабызның революциягә кадәрге иң күренекле эшлеклеләре бер үк елда диярлек дөньяга килгәннәр. Узган ел без бөек Тукайның 100 еллыгын билгеләп үттек, соңрак аның дусты — күренекле язучы һәм публицист Фатих Әмирхан, аннан соң татар профессиональ театрына нигез салучыларның берсе — режиссер һәм актер Габдулла Кариев юбилейлары. Һәм менә бу елның башында эшчәнлеге белән милли иҗтимагый фикер үсешендә тулы бер этап хасил иткән Галимҗан Ибраһимовның йөз еллыгын билгелибез. Аларның әсәрләрен, аеруча публицистик мәкаләләрен укыганда хыялымда ак сакаллы, карт акыл ияләренең сурәте пәйда була. Иң озак яшәгәне — Галимҗан Ибраһимовка да якты дөньядан киткәндә илле бер яшь кенә була. Ә инде үз халыкларының җитлеккән фикер ияләре буларак чыгыш ясый башлаганда, дөнья мәшәкатен иңнәренә күтәргәндә аларга исә нибары егерме дүрт-егерме биш яшь булган.

Бәлки урынлы да түгелдер, әмма аларны бүген яшәүче һәм иҗат итүче язучылар белән чагыштырасы килә. Миңа калса, без күп яктан оттырабыз һәм иң мөһим нәрсәдә — кеше буларак җитлеккәнлектә оттырабыз.

Төрле чорда кеше төрлечә формалаша. Шунысы бәхәссез, 1905 елгы революция чорында, самодержавие тарафыннан изелгән халыклар уянган һәм баш күтәргән чорда замана милли интеллигенциянең алдынгы яшь вәкилләреннән гражданлык кыюлыгы таләп иткән. Без башка төрле заманда яшибез һәм әдәбиятыбыз алыплары күләгәсендә үзебезгә җил-яңгыр тигермичә генә яши бирәбез, утызда да, кырыкта да һәм хәтта илледә дә йөзләребездә дөнья гаме сизелми. Әмма безнең көннәр дә кыю адымнар, гражданлык батырлыгы сорый. Хәл иткәндә үлчәү тәлинкәләренең бер ягына шәхси мәнфәгать һәм муллык, икенче ягына шактый корбаннар таләп итүче көрәш куела торган проблемалар азмыни? Кызганычка каршы, без еш кына шәхси иминлекне өстенрәк күрәбез. Шу-

лай тынычрак, мәшәкатьсезрәк, кайгы-хәсрәтсез генә балда-майда йөзеп яшәргә мөмкин. Ялкын гомеренең бер мизгел икәнен дә беләбез. Аңлашыла ки, бу хакыйкатьне бүген без данлый торган бөек шәхесләр дә белгән. Ләкин алар пыскып ятуга караганда ялкынланып янып бетүне өстенрәк күргәннәр. Иң гаҗәбе шунда, кыска гомерле ялкынның яктысы көчлерәк, ә мәгънәсез пыску тетенен исә заман җилләре бик тиз куып тарата.

Галимҗан Ибраһимов — шәкерт. Ә мәдрәсәләрне без ярым надан фанатик руханилар әзерли торган урын дип санарга күнеккәнбез. Без университетлар тәмамлаган кешеләр. Ирексездән тагын бер чагыштыру үткәрәсе килә. Ихтимал, без мәгълүматка баерактыр, ә Галимҗан Ибраһимов һәм аның шәкертләрендә исә тормышны танып белү процессы киңрәк һәм тирәнрәк. Чөнки алар кеше һәм гражданин буларак тормыштагы урыннарын яхшы белгәннәр, үзләрен бөек максатка әзерләгәннәр, туктаусыз камилләшкәннәр.

Традицияләр турында сөйләгәндә без иҗат талантына гына түгел, ә чын кеше булу талантына ия буынны тирән рәхмәт хисе белән искә алабыз. Үзебезне әнә шул иң яхшы традицияләр үрнәгендә тәрбияләү һәм аны киләчәк буыннарга тапшыру изге бурычыбыз дияр идем.

Г. Ибраһимов юбилее көннәрендә аның тормышы, үлемсез әсәрләре турында искә алганда мин күбрәк үзебез, әдәбиятыбызның киләчәге хакында уйландым. Шулай булмый мөмкин дә түгелдер. Әсәрләре белән халык алдында, киләчәк алдындагы бурычыбыз турында даими искә төшереп тормаса, классик — классик та булмас иде.

# МӘГАРИФ КАҺАРМАНЫ

Дусларның чираттагы очрашуы. 1982 ел. Бу аларның күптәннән бирле дәвам итеп килгән традицияләре. Тик очрашучыларның саны ел саен кими бара, табигый хәл. Очрашулар гадәттә Иделдә, теплоходта үтә иде. Монда запастагы подполковник К. С. Абдразаков, партия работнигы һәм ветераны Х. Д. Әмиров, галим-педагог Т. Рахмаева, хәрби врач, запастагы капитан А. Ш. Рамазанова, республиканың атказанган укытучысы М. Ш. Маликова, халык мәгарифе отличниклары Н. М. Шәрипова, Э. Ш. Хөббиева, Е. С. Иванова һәм башкалар. Алар якташлар — Урта һәм Түбән Идел төбәгендә туып үскәннәр, балачакта барысы да 1921—22 еллар ачлыгын татыган, күбесе балалар йортында тәрбияләнгән, шунда башлангыч мәктәп бетергәннәр, үсмер чакта бергәләп Саратов педагогия техникумында укып, укытучылык профессиясен үзләштергәннәр. Шуңа күрә, теплоход Саратовка якынлаша барган саен, үткәннәрне сагыну хисе арта бара, «хәтерлисеңме, исеңдәме?» дигән сораулар ява. Еш кына сорауларның иң күп өлеше Шиһап абый Рамазанов турында була. Аның турында алдагы очрашуларда, аерым алганда 1973 елдагы йөздән артык кеше катнашкан очрашуда да, сүз күп булган икән. Шунда бу хөрмәтле укытучы, галим турында хатирә булырлык әдәби әсәр кирәклеге турында теләк-карар да кабул ителгән булган.

Саратов шәһәре минем өчен дә бик якын. Саратов губернасы Новоузенск шәһәрендә хәрби хезмәттә булдым, шәһәрнең үзендә яралардан дәваландым, ул Түбән Иделнең край үзәге булган чакта, Сталинград вәкиле буларак, курсларда укыдым, өлкәсендә уку-укыту эшләрен оештыруда катнаштым. Шул юлда хәзерге юлдашларымның кайберләренең аталары белән, шәһәрдәге һәм урыннардагы работниклар белән таныштым. Алар арасында Ш. Рамазанов аерым урын алып тора иде. Уникә көнлек очрашуда истәлекләр аз булмады. Минем хатирәләр ветеран яшендәге юлдашларымның балалык чорына туры килгәнлектән, аларда тирән кызыксыну уятты. Нәтиҗәдә алар минем вакытлы матбугатта катнашуымны искә алып, хатирәләрне кәгазьгә төшерүне үтенделәр. Каршы килә алмадым. Үзем өчен дә якын булган кеше — Шиһап Рамазановның образы чиксез күп кешеләрнең хәтерендә саклана, меңләгән укучылар аның дәреслекләре ярдәмендә туган тел байлыгын үзләштерделәр. Көчемнән һәм хәлемнән килгән кадәр тырышып, шәхси хатирәләремне яңартып, төрле кешеләрдәге материалларны һәм башка чыганакларны да ярдәмгә алып, шушы язмамны укучылар хөкеменә тапшырам.

Шиһап Алимович Рамазановның (1887—1948) биографиясе гадәти дип әйтергә мөмкин һәм гадәттән тыш дип тә. Ул Саратов губернасы, Петровск өязе, Иске Карлыган авылында туа. Ата-анасы — грамотасыз крестьяннар. Шуның өчен алар балаларын укымышлы итүне беренче чиратка куялар. Беренче булып Шиһапны мәчет каршындагы мәктәпкә бирәләр. Шунда киләчәктә галим булачак Шиһапның белем алуы башлана һәм тәмамлана да. Аспирантурага кадәр аңа уку йортларына керәп укырга туры килми.

Мулла-мунтагай, кулак һәм сәүдәгәрләр үзләренең балаларын зур шәһәрләргә, мәдрәсәләргә укырга җибәрәләр. Алим аганың улын читләргә җибәреп укытырга хәленнән килми, әлбәттә, шунлыктан Шиһап ул белемнәрне үзлегеннән үзләштерергә карар кыла. Китапларның иң күп өлеше гарәп телендә була. Моның өчен гарәп телен үзләштерә, төрки телләр нигезләре белән таныша. Бара-тора хәзрәт аны ярдәмчелектән коткарып, укытучы (хәлфә) итеп билгели, авыл халкы аны мөгаллим дип хөрмәтли. Бу вакыт аңа 16 яшь тә тулмаган була. Шул ук вакытта Шиһап рус теле өйрәнүгә дә керешә, күрше авыл рус укытучысының ярдәме аркасында, К. Насыйриның сүзлек һәм дәреслекләреннән файдаланып, XIX йөздә туган прогрессив мәгърифәтчелек хәрәкәте идеяләре белән таныша.

Россияне тетрәткән 1905 ел революциясе бу уңайдан да киң мөмкинлекләр ача. Хәзер уку ана телендә, ирләр һәм хатын-кызлар өчен гомуми булырга, туган телдәге мәктәптә рус теле дәресләре кертергә вакыт җитте лабаса, дигән ялкынлы фикерләр аны чолгап ала, шул көенчә яшь мөгаллим эшкә керешә. Үзе ир балаларны укыта, хатыны Сабира ханымны (Ш. Рамазанов яшьли өйләнә) һәм кыз туганы Мәргубәне балаларга

грамота өйрәтерлек дәрәҗәдә хәзерли дә, Карлыганда бу якларда беренче булган кызлар мәктәбе ача. Хәтта зурларга да укырга-язарга өйрәтә башлый.

Беренче рус революциясенең җиңелүе үзәкләрдән еракгагы татар авылына да барып житә. Динче фанатиклар һәм башка реакцион көчләр яшь мөгаллимнең яңалыкларына, шул сәбәптән хезмәт иясе халыклары арасында авторитет казануына күптән ачынып торалар иде, хәзер үч алу вакыты килде дип полициягә донослар яудыралар: «Рамазанов дин боза, яшьләрне аздыра, падишаһ хәзрәтләренә каршылык күрсәтергә өнди»,— диләр. Ахырда 1910 елда Рамазанов кулга алына, төрмәгә ябыла. Аннан чыкканнан соң да аңа мәктәпләрдә укытучылык итү тыела. Материаль ягы авыр булу сәбәпле Ш. Рамазанов берара әтисенең хуҗалыгында эшли һәм үзенең туганнарын өйдә, хосусый рәвештә укыта. Шуңа карамастан кара көчләр һаман тынычлана алмыйлар. Мөгаллим 1912 елда яңадан кулга алына һәм Актүбә якларына сөргенгә җибәрелә. Бәхетенә каршы анда татар мәктәпләрендә рус теле укытучыларга ярдәм курслары оештырылган була, шунда кереп укый, яңадан укыту эшенә керешергә теләсә дә, рөхсәт бирелми.

Мин Шиһап ага белән 1917 елда таныштым. Ул болайрак килеп чыкты. Февраль революциясеннән соң Новоузень өязендә халык мәгарифен оештыру эшенә үз инициативалары белән ике кеше эшкә керешәләр: Мәгъсум Шәрипов һәм Бәкер Яфаров. Өченче санап мине дә бу эшкә тарттылар (ул вакытта мин шәһәр кырыендагы запас полк солдаты идем һәм бу эшкә полк командиры рөхсәте белән кушылдым). Безнең теләкләр зур, максатлар изге, омтылыш чиксез, тик реаль шартлар гына юк дәрәҗәсендә иде. Өязнең күп сандагы татар авылларының берсендә Сафаркада (русчасы Сафаровка) яшәгән рус-татар мәктәбе генә земство карамагында иде. Хәзер башка авылларда да мәктәп ачу, аларны һәм моңа кадәр булганнарның материаль ягын яхшырту өчен земство чылтәренә кертү бурычы килеп туды. Эш катлаулы. Минем иптәшләрем бу эшкә ул вакытта Узень мәктәбендә укыткан Шиһап Рамазановны да тартырга кирәк дип табалар. Шул вакытта мин алардан ул авылда тирә-юньдә дан тоткан җәдит мәктәбе барлыгын белдем. Мәктәп заманга күрә яхшы программа нигезендә эшли, татар һәм рус телләрендә укучыларга шактый төпле белем бирә, укытучысы бөтен губернада иң хәзерлекле кеше. Тиз арада Ш. Рамазанов Новоузенск шәһәренә килеп тә җитә. Миңа, фәкать авыл мәктәбендә сигез ел гомер үткәргән, укытучымнан башка укымышлы кеше белән аралашмаган кешегә, яңа шартларда бар әйбер дә гаҗәп тоела. Бигрәк тә иптәшләремнең укымышлы, белемгә бай, сүзгә оста, «казан» телендә ягъни татар әдәби телендә җыйнак кына, аңлаешлы итеп, фикер-уйларын тыңлаучыга җиткерә белүләре — барысы да минем өчен күрелмәгән, хәйран калдырырлык күренешләр. Өстәвенә Мәгъсум шул ук осталыкта русча да аңлаша, аралаша.

Ә Бәкер Яфаров атаклы татар мәдрәсәсе «Галия»дә (Уфа шәһәрендә) укыганнан соң Беренче Бөтендөнья сугышына кадәр Петербург мәдрәсәсендә тел-әдәбият укыткан. Сугыш вакытында армиягә алына, икебез дә бер полкка туры килгәнбез, шунда беренче танышу да.

Ш. Рамазанов килгәч, «инициатив группа»ның (без үзебезне шулай дип атый идек) эшләре гаять дәрәҗәдә активлашып китте. Иптәшләрем өчесе дә тәҗрибәле кешеләр, кем белән очрашырга, ничек сөйләшергә, нинди документлар хәзерләргә икәнен яхшы беләләр иде. Миңа секретарьлык вазифасы йөкләнде. Алдагы иптәшләремә ияләшеп житкән идем инде, ә танышмас борын, югары бәя алган укытучы Ш. Рамазанов белән сөйләшергә, якыннан аралашырга тартынып йөри идем. Көннәрдән бер көнне ниндидер документны күчергәндә:

— Шиһап әфәнде! Менә бу сүзне аңлап җитә алмыйм, ничек укырга?— дип сүз башларга батырлыгым җитте.

— Габдрахман иптәш, мине әфәнде итеп санавыгыз урынсыз. Мин крестьян баласы, үзем дә җирдән аерылганым юк, кыш көннәрендә балалар укытам, җәй көне ирлехатынлы икәүләп әтиемнең хуҗалыгында эшлибез. Безнең гаилә зур, ярдәм кирәк,— диде.

Авыл шартларында олырак балаларның ярдәмче булулары миңа таныш, ләкин Рамазанов бу ярдәмнең икенче, миңа билгеле булмаган ягын да ачыклады: ул заман татар укытучысы кыш көннәрендә укыткан чакта гына сөйләшкән күләмдә хезмәт хакы ала, җәй көне исә теләсә ничек тамагын туйдырырга мәҗбүр иде.

Әйтмәсәм дә аңлашыла, үзем өчен зур дәрәҗә иясе кешегә минем шикелле малайшалай диярлек, ярым-йорты белемле кеше ничек итеп иптәш булсын ди инде! Ул вакытта бу сүз гадәткә кермәгән иде әле. Шиһап абый, минем уйларны сизгәндәй, сөйләшүне дәвам иттерә һәм тиз арада үземә сиздермичә, минем соң дәрәҗәдә кыска биографиямне дә сөзеп чыгара.

— Минем күзәтү һәм аңлавымча, сез сәләтле егет, әдәбият һәм матбугат белән таныш булуыгыз шиксез. Китап һәркемнең белемен баета, ләкин системалы рәвештә уку кирәк, югыйсә, зиһен юк-бар хәбәрләр белән тула, тулаем белем барлыкка килми,— диде ул.

Танылган укытучының дусларча, яшь, белем һәм дәрәҗә аермасын сиздермичә, тигез санап сөйләшүе сәбәпле минем тартынучанлык ничектер таркалгандай булды, үзем дә сораулар куярга, системалы уку турында тулырак аңлатуны үтенергә җөрьәт итә алдым. Җаваплар, табигый, тулы һәм файдалы булды. Сүз азагында ул:

— Тагы мөнә нәрсә: безнең формаль образование дә, башлангыч практика да бер төсле. Омтылышыгызга зарар китермәсәгез, киләчәктә белемле, бәлки алдынгы да, укытучы булырсыз дип өмет сакларга нигез бар, хәтта миндә ышаныч та туды,— дип, сөйләшүне очлады.

Бу гәпләшү беренче иде, бәхеткә каршы, дәвамы 20 елга сузылды, якын иптәшлек, самими дуслык тойгылары тууга сәбәп булды. Бергә эшләргә туры килмәде, ләкин язышу-күрешүләр өзелмәде. Бигрәк тә 1934—37 елларда еш очраштык — ул Казан пединститутында, мин дә шул чакларда Татарстанда Алабуга педучилищесендә эшли идем.

1917 ел уртасындагы хәлләргә кайтыйк. Земство белән сөйләшүләр аз нәтиҗә бирде: Бәкер Яфаров татар мәктәпләре инструкторы итеп билгеләнде, мәктәп земство чөлтәренә кертелде. Бар кадәр мәктәпләрне челтәргә кабул итү, яңаларын ачу мәсьәләсендә җиңел чыга алмаслык киртәләр корды земство. Ш. Рамазановның фикеренчә, земствоның стеналары калын, чиновникларының тиресе аннан да калын, һәм аларны тишеп чыга алырлык аргумент булып бары тик төрле җыелышларның карарлары гына булачак. Озын сүзнең кыскасы, хәзерлекләр күреп, укытучылар һәм мөселманнар съезды оештырылды. Бу съездларда төп докладлар белән Ш. Рамазанов чыгыш ясады һәм карарлар да аның редакциясеннән ерак китмичә кабул ителде. Йомгаклап әйткәндә, алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Уку-укыту ирләр һәм хатын-кызлар өчен гомуми булыр.
2. Мәктәптә уку-укыту билгеле рәвештә фәнни программа нигезендә ана телендә алып барылырга һәм дөньяви булырга тиеш.
3. Башлангыч сыйныфларда ук рус теле укытылыр.
4. Һәр авылда хәзердән үк башлангыч мәктәпләр ачылырга тиеш, бар кадәр укытучыларның белемнәрен тирәнәйтү һәм яңадан укытучылар хәзерләү курслары оештырырга кирәк.

Хәзерге күзлектән караганда бу карарлар элементарь булып күренергә мөмкин, ләкин моның 1917 елда булуын онытмаска кирәк. Мөселманнар съезды дип аталган җыелышта бу карарларга да каршы торучылар табылды. Иске фикерле делегатларны ачуландырган әйбер — хатын-кызларны укыту һәм укуның дөньяви булуы. «Нигә кирәге бар сезнең аба-табаларыгызның? Өйрәтегез балаларны каләме шәриф укырга, намаз-нияз тирәсен төплерәк белергә, дога-сүрәләр үзләштерергә кирәк, шул безгә җитә, артыгы кирәкми. Ә хатыннарга уку нигә кирәк? Аларның эше — «әнә кайда, җеп шунда», «ире ни кушар, шуны эшләр»,— дип кычкыручылар да табылды. Алдан хәзерлек күрү үзен аклады, җыелышлар нәтиҗәсез булмады, земство да йомшарырга мәҗбүр булды. Шул елның көзендә бөтен татар авылларында ир һәм кыз балалар өчен мәктәпләр ачылды. Билгеле, бу мәктәпләр барысы да 1918 ел башында совет мәктәбенә әверелделәр. Тик чамаланган рәвештә укытучылар курслары оештырып булмады. Шулай да Ш. Рамазанов бу эшне үз өстенә алды һәм Узень авылында бер айлык курслар ачуга иреште. Бу эшкә һичкем бер тиен акча түләмәде, һәркем үзе белгәнчә торак тапты, ашау-эчү ягын кайгыртты. Курсантларны тартуда һәм башка оештыру эшләрендә М. Шәрипов һәм олырак яшьтәге укытучы Солтан Абдразаков ярдәм күрсәттеләр. Курсантларның күпчелеге Ш. Рамазанов мәктәбендә укыган үсмерләр, арада Мәргубә Рамазанова-да укыган берничә кыз да бар. Бәкер Яфаров инструктор сыйфатында курсантларның составы, курсларның эше белән танышканнан соң, эшнең куелышы югары дәрәҗәдә дип таба, үзе дә хәзерге татар әдәби теле темасына лекцияләр укый. Программа Ш. Рамазанов тарафыннан төзелгән иде, лекцияләрнең иң күп өлешен ул үзе укый.

Самара губернасындагы башлангыч мәктәпләрнең иң күренеклесе һәм характерлысы Узень мәктәбе иде. Аның барлыкка килүен очраклы күренеш дип әйтергә була. Зур гына, яхшы тормышлы бу авылда меңләгән дисәтинә җир хуҗасы Йосыф байның улы Җәлал үзенең һәм туганнарының балаларын рәтле тәрбияләү максаты белән үз хисабына мәктәп бинасы салдыра. Заманына күрә җиһазлап, күргәзмә материаллар белән тәэмин итә дә, «Кирәгенчә тырышып укыт» дип мөгаллим ихтыярына тапшыра. Бәхеткә каршы, мөгаллим булып Шиһап Рамазанов чакырыла. Җәлал мәктәпне хосусый, ягъни «частная домашняя школа» исемендә рәсми рәвештә формаль ныгытып та куя. Мәктәпкә муллалар якын да җибәрелми, бай кешенең хосусый мәктәбенә полиция дә борын тыга алмый. Сөргеннәрне татып, сөйгән эшеннән аерылып торган мөгаллим биредә билгеле дәрәҗәдә иркенлек сизә һәм уку-укыту эшләренә кайбер үзгәрешләр кертергә мөмкинлек таба. Мәктәп бинасы архитектура ягыннан күзгә бәрелерлек түгел. Әмма анда ул вакытта табылган әсбапларның барысы да бар, хәтта глобус та. Җиһазларның иң әһәмиятлесе кара класс тактасы һәм «парталар». Көрси исемендә йөргән бу әйбер

партаның пародиясе булса да, укучылар һәм укытучылар үзләрен бәхеткә ирешкән дип саныйлар, чөнки кадими мәктәптә мондый әйберләрнең исе дә юк.

Ш. Рамазанов мәктәп өчен программаны рус башлангыч мәктәпләре программасы нигезендә үзе төзи, шул мәктәпләрдә булган бөтен фәннәр керә. Фән буларак, ана теле һәм рус теле өйрәтелә. Гарәп теле исә укытылмый. Ш. Рамазанов укытуның сыйфатын яхшырту йөзеннән күрше рус авыллары укытучылары белән таныша һәм аралаша, бергәләп, бер-беренең дәресләрендә булалар, фикер алышалар. Берничә һәм төрле-төрле классллы мәктәптә бердәнбер укытучының бөтен фәннәрне укытуы ни дәрәҗәдә катлаулы икәнен, күпме көч һәм вакыт алуын күз алдына китерү авыр эш түгел. Шуның өстенә ул үзенең белемен үстерү эшен дә читкә куймый, иҗат белән дә шөгыльләнә, шушы дүрт ел эчендә матбугатта унлап мәкалә бастырып чыгара, хәбәрләр, фельетоннар, хикәяләр яза. Кыскасы, мөмкинлек булгач, тәне-җаны белән, көнне төнгә ялгап эшли. Шул көенчә үрнәк булырлык, бөтен губернага даны таралган мәктәпне Октябрьгә кадәр җиткереп совет мәктәбенә әверелдерә.

Октябрьдән соң, беренче елында ук ярдәмчеләр килә, укытучылар саны унбергә җитә, тик Ш. Рамазановның эшләре кимеми: ул укытучыларны укыта башлый һәм алар кыш буена бер еллык педагогик курсларның программасын үзләштерәләр. Табигый, бу эш тә түләүсез, бушлай эшләнә. Югарыда күрсәтелгән шартлар Рамазановка интенсив һәм чагыштырмача тыныч эшләргә ирек бирде. Ләкин җиңеллек китерде дип әйтеп булмый. Чөнки керәш тукталмый, дәвам итә. Полиция күзәтүе — баш өстендәге кара болыт — революциядән соң гына тарала.

1918 елның көзендә Ш. Рамазанов туган иле Петровск өязенә кайта. Ул монда яңа көч белән яңадан совет идарәләре сафында халык мәгарифе эшләренә чума. Хезмәт нәтиҗәсез калмый һәм губерна җитәкчеләре тарафыннан тиешенчә бәя ала. Ахырда Саратов губернасы мәгариф бүлеге аны Саратовка чакыртып ала. Аңа киң күләмдә татар мәктәпләре өчен укытучылар хәзерләү, булган укытучыларның белемнәрен камилләштерү эше тапшырыла. Башта бу эш шәһәрдә яшәгән рус педтехникумы каршында бүлек рәвешендә башлана, соңрак аерым татар педтехникумы оештырыла, һәр ике очракта җитәкчелек Ш. Рамазанов өлешенә төшә. Бу эштә аның оештыручылык таланты тагын да киң колач җәя...

1932 елда Түбән Идел партия крайкомы һәм крайның халык мәгарифе бүлеге Казан пединституты каршындагы аспирантурага керү өчен аңа командировка бирә.

Шиһап ага Казанга килгәндә шактый танылган мәгариф эшлеклесе иде. Аны Казан пединститутының тел белеме кафедрасы каршындагы аспирантурага кабул итәләр һәм шул ук вакытта кафедрада укытучы итеп тә билгелиләр. Аспирантураны уңышлы тәмамлагач ул институт кафедрасында фәнни тикшерүләр алып бара. Аңар филология фәннәре кандидаты һәм доцент дәрәҗәләре дә фәнни казанышларының әһәмиятен, практикага ашырылуын игътибарга алып, диссертация якламыйча бирелә.

Гомумән алганда, аның Казандагы гомере пединститутка бирелә, фәкать соңгы алты ел (институтта лекцияләр белән өзелмичә) СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында һәм В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында үтә; тулаем алганда 61 еллык гомеренең 45 елы уку-укыту эшләренә, педагогик кадрлар хәзерләүгә багышлана.

Миңа Шиһап Алимовичның дәресләрендә утырырга, лекцияләрен тыңларга туры килмәде. Шулай да очрашу-күрешүләр, телдән тыңланган киңәшләр, басылган әсәрләренең күпчелеге белән якыннан танышлык аны остазларымның берсе дип атарга хокук бирә. Миңа да, авыл мәктәбендә сигез ел укыгач, Шиһап абый шикелле, укытучы ярдәмчесе, аннан хәлфә булып эш башларга туры килде. Армиядә булу, совет төзелешендә актив катнашу һәм башка сәбәпләр югары уку йортларына кереп укырга урын калдырмады. Урта мәктәп күләмендә үз өстемдә эшләп экстерн имтихан тоттым, Казан пединститутында тел-тарих факультетында читтән торып укыдым. Остазымның беренче күрешүләрдә уянган өметен акларга тырыштым, башта татар балаларын ана телендә укыттым, аннан соң 30 елга якын рус теле һәм әдәбияты укытып, укытучы кадрлар хәзерләүдә актив хезмәт күрсәттем. Аннан Горький шәһәре университетының тарих-филология факультеты студентларын гарәп язуы белән таныштырып, укырга-язарга өйрәттем. Өлкән яшьтә булуыма карамастан, җәмәгать эшләренә катнашудан һаман да туктаганым юк.

Юл ярып баручылар өлешенә авырлыклар күбрәк төшә: безнең буын кешеләренә корал тотып, совет властен якларга, ныгытырга, ачлык, тиф һәм наданлык белән көрәшергә туры килде. Исән калганнарыбызга бездән соң килгән буыннарның социалистик илне явыз дошман һөҗүменнән саклап, производствода, культурада, фән өлкәсендә югары уңышларга ирешүен күреп шатланырга насыйп булды.

**Габдрахман ӘБУБӘКЕРОВ,**
*Горький шәһәре, 1984 ел.*

# *Культура тормышы көндәлеге*

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

20 октябрьдә Татарстан Язучылар союзының отчет җыелышы булды. Анда доклад белән Язучылар союзы партия оешмасы секретаре тәнкыйтьче Р. Мостафин чыкты. Фикер алышуларда Ә. Еники, С. Баттал, Н. Дәүли, И. Нуруллин, Б. Гыйззәт, Д. Вәлиев, Р. Гатауллин, Ә. Гаффар, К. Сибгатуллин һ. б. катнаштылар. Җыелышта бюроның яңа әгъзасы итеп шагыйрь Р. Фәйзуллин сайланды. Йомгаклау сүзе белән Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин чыкты.

## КУЛЬТУРА ПРОБЛЕМАЛАРЫ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

21 октябрьдә Пресса йортының конференцияләр залында республикада культураны үстерү мәсьәләләре буенча матбугат конференциясе булды. Массакүләм информация һәм пропаганда чаралары работниклары алдында ТАССР культура министры М. М. Таишев, ТАССР Кинофикация дәүләт комитеты председателе Р. Х. Ногманов, халык депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитеты председателе урынбасары И. С. Донская, ТАССР мәгариф министры урынбасары М. Л. Гайнетдинов, культура работниклары профсоюзы өлкә комитеты председателе Ә. З. Сафин, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. А. Миңнуллин, ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе В. М. Маликов, ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе М. З. Яруллин, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры М. Х. Сәлимҗанов, Казан кинохроника студиясе директоры И. Н. Алексеев, Таткинопрокат директоры Р. Г. Гарипов чыгыш ясадылар. Алар республика культура тормышының төп проблемаларына тукталдылар, журналистларның күп санлы сорауларына җаваплар бирделәр.

## ОЕШТЫРУ КОНФЕРЕНЦИЯСЕНДӘ

14 октябрьдә Мәскәүдә В. И. Ленин исемендәге Совет балалар фондының оештыру конференциясе булды. Конференциядә Татарстаннан профсоюзлар өлкә советы председателе, Социалистик Хезмәт Герое, КПСС Үзәк Комитеты члены Г. С. Баштанюк, «Камгэсэнергострой»ның маляр-штукатурлар бригадиры, РСФСР Верховный Советы депутаты Ю. С. Барсукова, Казаннан ат белән йөк ташучы Әсхәт Галимҗанов һәм «Яшь ленинчы» газетасы редакторы шагыйрь Роберт Миңнуллин катнашты.

## ҖАМАЛ ВӘЛИДИГӘ БАГЫШЛАП

22 октябрьдә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты Гыйльми советының татар әдәби тәнкыйте һәм әдәби-эстетик фикерен нигезләүчеләрнең күренекле вәкиле, телче, фольклорчы, философ һәм педагог Җамалетдин Җәләлетдин улы Вәлидовның (1887—1932) туууына 100 ел тулуга багышланган киңәйтелгән утырышы булды. Институт директоры профессор М. З. Зәкиев тарафыннан алып барылган утырышта филология фәннәре кандидатлары Р. С. Мөхәммәдиев Җамал Вәлидинең татар әдәби тәнкыйте һәм әдәби эстетик фикерен формалаштырудагы роле, М. Г. Мөхәммәдиев Җ. Вәлидинең татар тел гыйлеме өлкәсендәге эшчәнлеге һәм М. С. Мәһдиев Җ. Вәлиди мирасын өйрәнү һәм пропагандалау мәсьәләләрен күтәргән докладлар белән чыктылар. Докладлар буенча фикер алышуларда чыгыш ясаган Ә. Еники, И. Нуруллин, Г. Халит, Һ. Мәхмүтов күренекле галим турында истәлекләре белән уртаклаштылар, киләчәктә аның иҗат мирасын өйрәнү, пропагандалау һәм исемен мәңгеләштерү турында эшлекле тәкъдимнәр керттеләр. Гыйльми совет утырышында Җамал Вәлидинең кызы Әминә ханым Җамалетдинова да катнашты.

## ТАТАР АРТИСТЛАРЫ ЯПОНИЯДӘ

24 сентябрьдә Япониядә Татарстан АССР Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең бер айга якын дәвам иткән гастрольләре башланды. Шул ук көнне «Синдзюку бунка сентр» концерт залына Татарстан АССР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле чыгышын карарга килгән Токио тамашачылары дәртле татар биюләре карадылар. Тамашачылар Япониягә гастрольгә килгән Совет Татарстаны артистлары чыгышын озакка сузылган көчле кул чабулар, «Браво!» авазлары белән алкышладылар. Совет артистлары Токиодан тыш Киото, Осака, Кагосима, Ниигата һәм башка шәһәрләрдә чыгыш ясадылар.

Япониядә гастрольдә булу вакытында Татарстан АССР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле Япония коммунистларының «Акахата» газетасының 28 нче бәйрәмендә чыгыш ясадылар. Ул 10—11 октябрьдә Япония башкаласының Тиофу бистәсендә уздырылды.

«Акахата» Япониягә концерт программасы белән килгән татар артистлары турында мәкалә урнаштырды. Ансамбль, дип яза газета, Советлар Союзының төрле төбәкләрендә чыгыш ясый, шулай ук чит илләрдә гастрольләрдә була.

## ДИҢГЕЗЧЕ ПРОЗАИК ИҖАТЫНА БАГЫШЛАП

29 октябрьдә Казанның Актерлар йортында язучы Миргазиян Юнысның иҗат кичәсе булды. Язучының тормышы һәм иҗаты турында Г. Бәширов, Ш. Галиев, М. Мәһдиев, Н. Фәттах һәм Г. Рәхим сөйләде. М. Юныс үзенең чыгышында һәм тамашачыларның сорауларына җавапларында бүгенге үзгәртеп кору шартларында совет әдәбияты алдында торган бурычлар, татар әдәбияты проблемаларына тукталды. Халыкара рейсларда йөрүче диңгезче булараң, дөньяның төрле илләрендә алган тәэсирләре турында сөйләде.

Шундый ук иҗат кичәсе язучының туган ягында — Баулы районының Исергәп авылында да үткәрелде.

Анда М. Юнысның иҗаты турында ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Г. Рәхим һәм Татарстан язучыларының Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Н. Әхмәдиев сөйләделәр. Кичәдә КПССның Баулы райкомының беренче секретаре И. Х. Мәүлетхуҗин катнашты һәм чыгыш ясады.

## Р. ҖИҺАНШИНАНЫҢ ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

17 октябрьдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы, РСФСРның театр эшлеклеләре союзының Татарстан бүлеге председателе Р. А. Җиһаншинага 70 яшь, аның иҗат эшчәнлегенә 50 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе булды.

Кичәне кереш сүз белән ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты.

КПСС өлкә комитеты секретаре Н. Х. Кадырметов юбилярга ТАССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасын тапшырды һәм аңа яңадан-яңа иҗат уңышлары теләде.

Р. Җиһаншинаның иҗаты һәм җәмәгать эшчәнлеге турында ТАССР Культура министры М. М. Таишев сөйләде.

Юбилярны республикабызның партия, совет органнары, җәмәгать оешмалары, хезмәт коллективлары, иҗат союзлары, культура учреждениеләре вәкилләре, Мәскәүдән һәм күрше республикалардан килгән кунаклар котлады.

Кичәнең икенче өлешендә академия театрының юбиляр катнашкан спектакльләреннән өзекләр күрсәтелде.

## МАРИ ЭЛДӘ ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Мари совет әдәбияты классигы, мари совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе Сергей Чавайн туган көндә Йошкар-Олада Шигырь бәйрәме уздыру матур бер традициягә әйләнде. Быел да 6 октябрьдә шигырь сөючеләр С. Чавайн һәйкәле янына җыелдылар.

Шигырь бәйрәмен Мари АССР Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары шагыйрь Александр Селин ачып җибәрде. Анннары Мари халык язучысы, Мари АССРның атказанган фән эшлеклесе Ким Васин, мари халык шагыйре Миклай Казаков, Татарстан Язучылар союзы вәкиле шагыйрь Ш. Маннапов һ. б. лар чыгыш ясады. Шкетан исемендәге Мари дәүләт драма театры артистлары С. Чавайн шигырьләрен укыдылар.

Йошкар-Оладагы Шигырь бәйрәме халыклар дуслыгы рухында алып барылды. Анда китап сәүдәсе дә оештырылды.

## БӨТЕНСОЮЗ КИҢӘШМӘСЕ

СССР Эчке эшләр министрлыгы һәм СССР Язучылар союзы Кишинев шәһәрендә матур әдәбиятта әдәп-әхлак һәм хокук мәсьәләләрен яктыртуга багышланган өченче Бөтенсоюз киңәшмәсен уздырды. Анда Татарстаннан язучылар Мәгъсум Насыйбуллин һәм Тәүфикъ Әйди катнашты.

## ФРОНТОВИК ШАГЫЙРЬ ЮБИЛЕЕ

Мари АССРның Бәрәңге районында туып үскән фронтовик шагыйрь Мансур Гаязны якташлары онытмый. Бәрәңге авылының бер урамы һәм мәктәпнең пионер отряды шагыйрь исемен йөртә, кайчандыр ул укыган мәктәп диварына мемориаль такта куелган. Мәктәп укучылары ил азатлыгы өчен газиз гомерен биргән шагыйрь абыйларының тормыш юлын чагылдыручы фотоальбом төзегәннәр.

Быелның 5 октябрендә Бәрәңге авылында М. Гаязның тууына 70 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Анда шагыйрьнең иҗаты турында пенсиядәге укытучы Фәүзия Нигъмәтҗанова доклад белән чыкты. Дания Габбасова, Мәрьям Әхмәдуллина, Роза Садриева, Габдерәхим Хәлилрахманов, фронтовик шагыйрьнең абыйсы Магруф Гаязов һ. б. М. Гаяз турында истәлекләр сөйләделәр.

Кичәдә КПССның Бәрәңге райкомы беренче секретаре В. Н. Мөхәммәтгалиев, мари шагыйре Дәүләт Исламов, татар шагыйре Шамил Маннапов Бәрәңге халкын якташ шагыйрьләренең олы юбилее белән котладылар, аларга хезмәтләрендә зур уңышлар теләделәр.

Әдәби-музыкаль кичәдә авыл үзешчәннәре башкаруында М. Гаязның шигырьләре, кайчандыр ул яратып җырлаган җырлар һәм композиторларыбызның хәзерге җырлары яңгырады.

Бәрәңге районында татар һәм рус телләрендә чыга торган «Коммунизмга» газетасы бу юбилейга багышлап үз укучыларына махсус сәхифә тәкъдим итте.

## М. ӘҮӘЗОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Казах әдәбияты классигы атаклы «Абай юлы» эпопеясы авторы Мохтар Әүәзовның тууына 90 ел тулу датасы ил күләмендә киң билгеләп үтелде. Сентябрь ахырында Алма-Атада, әдипнең туган җире Семипалатинск өлкәсендә һәм башка урыннарда үткәрелгән тантаналар бөтенхалык бәйрәме

төсеп алды. Бу бәйрәмгә илебезнең төрле республикаларыннан күпмилләтле совет әдәбиятының күренекле вәкилләре җыелган иде. Анда Татарстаннан шагыйрьләр Равил Фәйзуллин һәм Әхмәт Рәшитов катнаштылар.

### ТУКАЙ МУЗЕЕНДА

Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның Казандагы музее яңадан-яңа экспонатлар белән тулылана бара. Өлкән педагог, шагыйрь тормышын өйрәнүче, «Тукай эзләре буйлап» исемле китапның авторы Зәкия Рәсүлева музейга Зәйтүнә Мәүлүдова фотоальбомының күчермәсен бирде. Анда шагыйрьнең 1908—1912 елларда эшләнгән уникаль фоторәсемнәре тупланган. З. Рәсүлева күп еллар дәвамында үзе тарафыннан төзелгән «Габдулла Тукай һәм аның туганнары» исемле фотоальбомны да музейга тапшырды.

### АРХЕОГРАФИК ТАБЫШЛАР

Быел июль аенда Казан дәүләт университетының Археографик экспедициясе тикшеренү эшләрен ике төркемгә бүленеп алып барды: тарих фәннәре докторы, профессор М. Госманов һәм И. Гыйләҗев җитәкчелегендәге зур төркем Горький өлкәсе Кызыл Октябрь районы татар авылларында, ә составында тарих фәннәре кандидаты Р. Шәйхиев һәм журналыбызның тәнкыйть һәм фән бүлеге өлкән редакторы Җ. Миңнуллин булган икенче төркем Ульяновск өлкәсе Иске Кулатка районында эшләде. Бу ике төркем алып барган археографик тикшеренүләр нәтиҗәсендә төрле эчтәлектәге йөзләп кульъязма тупланды. Иң кыйммәтле әдәби, тарихи җәүһәрләр арасында атаклы болгар-татар шагыйре Кол Галинең мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» дастаны кульъязмалары, элек татар халкында киң таралган «Яр-яр» исемле борынгы йола җырының бер нөсхәсе, җыр-бәет дәфтәрләре, юриспруденция буенча китаплар бар.

### ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Хезмәт ияләренә музыкаль-эстетик тәрбия бирүдәге уңышлары өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең бер төркем артистлары һәм хезмәткәрләре, СССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 14 октябрь Указы нигезендә СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнде:

**Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән**

Авзалова Әлфия Авзаловна — җырчы.
Мәҗитов Илгиз Габидуллович — художество җитәкчесе.

**Халыклар Дуслыгы ордены белән**

Садыйков Мөҗип Юсупович — җырчы.
Таҗетдинов Марат Габдрахманович — директор.

**«Почет билгесе» ордены белән**

Праченко Владимир Васильевич — җырчы.
Таишева Римма Мөбарәковна (Римма Ибраһимова) — җырчы.

**«Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән**

Җәләлетдинов Эмиль Усманович — җырчы.
Сөләйманова Флера Зыятдиновна — җырчы.
Теркулова Нәҗия Габдрахмановна — җырчы.

**«Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале белән**

Әхмәтвәлиева Әлфия Фатыйховна — өлкән редактор.
Варшавский Владимир Валентинович — концертмейстер.
Миңнуллин Мәсгут Зарифович — артист.

### МӘҖИТ РАФИКОВНЫҢ МИРАС КОМИССИЯСЕ

Кадерле укучылар! Язучы Мәҗит Рафиковның иҗатына кагылышлы әйберләрне (хатлар, рәсемнәр һ. б.) түбәндәге адрес белән җибәрүегезне үтенәбез: 420012, Казань, ул. Комлева, д. 14, Татарстан Язучылар союзы.

### ТӨЗЕЛЕШ ЕЛЪЯЗМАСЫ

Редакциянең Татарстан АЭСындагы штаттан тыш хәбәрчесе Роберт Талипов белдерүенчә, Т. Вәлиуллин җитәкчелегендәге бригада Кама Аланы балалары өчен яңа бакчаның стеналарын өеп бетерделәр. Бу — поселоктагы дүртенче бакча. Шулай да төзүчеләрнең ихтыяҗы тулысынча канәгатьләндерелә алмый әле, чөнки Кама Аланы үскәннән-үсә бара. Хәзер монда яшәүчеләрнең саны ун меңнән артып китте. 1987 елның җиде ае эчендә генә дә 187 бала туды.

И. Рәҗәпов җитәкчелегендәге механикалаштырылган комплекслар атом электр станциясенең икенче энергоблогы урнаштырылачак базның нигезен эшкәртә башладылар. 63 нче һәм 25 нче комплекслар арасында социалистик ярыш оештырылды. 63 ченең егетләре алдынгылыкны бирмәү өчен тырышалар.

1987 елның 5 нче октябрендә ТатАЭС төзүчеләре янына язучы Мәхмүт Хәсәнов килде. Ул төзелеш идарәсе партком секретаре Рифкат Кәтиев, Түбән Кама районының культура бүлегеннән Әлфия Гыйльмиева иптәшләр катнашында АЭС объектларында булды. Төзүчеләргә «Казан утлары» журналының киләчәккә планнары турында сөйләде. Әдәбият сөючеләр Мәхмүт Хәсәновка аның «Язгы аҗаган» романы буенча күп төрле сораулар бирделәр.

# «КАЗАН УТЛАРЫ»НДА 1987 ЕЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

## БӨЕК ОКТЯБРЬНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

Мустаев Ш. Ә. **Октябрьдән нур алып.** № 11.

Арсланов Н. **Котлау.** Шигырь. № 11.

Гыйләҗев А., Литвин А. **Августның алтысыннан соң...** Роман. № 7, 8.

Дәүли Н. **Октябрь байрагы.** Шигырь. № 11.

Мәхмүтов Х. **Көрәшкә рухландырган җырлар.** № 11.

Чанышев Я. **Казан кремлен штурмлау.** № 11.

Шакиров З. **Революция солдаты, журналист һәм галим.** № 11.

## КАЗАН СТУДЕНТЛАРЫНЫҢ В. И. УЛЬЯНОВ-ЛЕНИН КАТНАШЫНДА УЗГАН СХОДКАСЫНА — 100 ЕЛ

Жуков В. **Кокушкинода, 27 август көнне.** № 12.

Низамиев Р. **1887 ел, 4 декабрь.** Шигырь. № 12.

Нәфиков Р. **Сходкада катнашучыларның язмышы.** № 12.

## ПРОЗА

Ахунов Г. **Идел кызы. Роман.** № 1, 2.

Бәйрәмова Ф. **Күл балыгы.** Поэма-фантазия. № 9.

Вәлиева М. **Гарлавач.** Хикәя. № 6.

Гази И. **Без комсомол чакларда.** Парчалар. № 4.

Гаффар Ә. **Яшиселәр алда иде әле.** Повесть. № 9.

Гыйләҗев А., Литвин А. **Августның алтысыннан соң...** Роман. № 7, 8.

Дәүли Н. **Кояшка йөз беләи.** Повесть. № 8.

Еники Ә. **Соңгы китап.** Повесть. №№ 3, 4.

Зәйнуллин З. **Үрләр аша.** Повесть. № 10.

Ишморат Р. **Гомер сукмаклары.** Истәлекләр. № 11.

Камалов Б. **Күрәчәк күз ачтыра.** Хикәя. № 6.

Кашапов Г. **Лачын кошка күкләр кадерле.** Повесть. № 9.

Маликова М. **Басып сайрар талы бар.** Роман. №№ 3, 4, 5.

Мирхәйдәров Р. **Оренбур шәле.** Хикәя. № 9.

Мифтахетдинов А. **Кыз урлаучы.** Хикәя. № 10.

Мостафин Җ. **Ике язмыш.** Хикәя. № 5.

Мусин М. **Ике новелла.** № 12.

Мушинский Ә. **Ак бүре.** Повесть. № 10.

Мөхәммәдиев Р. **Истәлек өчен — Гыйлемханга...** Повесть. № 4.

Низамиев Р. **Беренче мунча.** Хикәя. № 8.

Низамов И. **Бер карадым.** Парчалар. № 11.

Нуруллин В. **Җавап бир, кеше.** Повесть. № 6.

Тохфәтуллин Р. **Чатта тукталу.** Повесть. № 7.

Хәбибуллин М. **Таңана.** Хикәя. № 6.

Хуҗин М. **Урак өсте болытлары.** Повесть. №№ 11, 12.

Хәсәнов А. **Кадерле көндәш.** Хикәя. № 12.

Хәсәнов М. **Сыймас Садри.** Хикәя. № 11.

Юныс М. **Таңда Босфор аша.** Повесть. №№ 1, 2.

Әбүбакирова Р. **Картлар нигә туңа.** Хикәя. № 5.

Әмир М. **Чират.** Хикәя. № 4.

Әхмәдиев Н. **Рафис.** Хикәя. № 6.

## ДРАМАТУРГИЯ

Мингалим Р. **Өченче бүлмәдә эт яши.** Драма. № 8.

## ПОЭЗИЯ

Акмалов Н. **Кый-гак-к.** Шигырьләр. № 6.

Арсланов Н. **Сак-соклар.** Поэма. № 5.

Арсланов Н. **Тукайга.** Шигырьләр. № 9.

Афзал Г. **Урманнарга керәм...** Шигырьләр. № 6.

Баянов Ә. **Алтын кашбау.** Шигъри трагедия. № 12.

Беляев Н. **Рәхмәт сиңа, язмыш!** Шигырьләр. № 9.

Булатова К. **Чал тарихның...** Шигырьләр. № 3.

Гадел Ә. **Сөю. Шигырьләр.** № 11.

Галиев Ш. **Төрле еллар дәфтәреннән.** Шигырьләр. № 10.

Гатауллин Р. **Тулпар атның тояк җиле.** Шигырьләр. № 2.

Гәрәй Р. **Ник яшерим.** Шигырьләр. № 2.

Дәүли Н. **Мина белән солдат очрашуы.** Шигырьләр. № 1.

Закиров Р. **Туган туфрак.** Шигырьләр. № 4.

Золфәт. **Чиксезлеккә багам.** Шигырьләр. № 1.

Измайлова Н. **Әйбәт сүз ишеткән көн.** Шигырьләр. № 8.

Латыйп К. **Мәхәббәт һәм нәфрәт.** Шигырьләр. № 5.

Мостафин К. **Җәлил.** Шигырьләр. № 8.

Мәхмүдов Ә. **Әни.** Шигырьләр. № 6.

Мәҗитов З. **Төрле еллардан.** Шигырьләр. № 9.

Рәкыйпов Р. **Сакта.** Шигырьләр. № 2.

Рәшитов Ә. **Кем җырлады?** Шигырьләр. № 11.

Садә Г. **Җиргә якты күбрәк төшсен.** Шигырьләр. № 10.

Сибгатуллин К. **Безнең моңнар.** Шигырьләр. № 5.

Фәйзуллин Р. **«Таулар» циклыннан.** Шигырьләр. № 7.

Харис Р. **Яңа шигырьләр. № 8.**

Шабаев М. **Ачыктан-ачык.** Публицистик поэма. № 9.

Шәрипов Р. **«Оштарма» көе.** Шигырьләр. № 12.

Юзеев И. **Сез кабызган утлар.** Поэма. № 7.

Юнысов Р. **Дәште съезд.** Шигырьләр. № 5.

Яруллин Ф. **Ленин кулын тоеп.** Шигырь. № 4.

Яруллин Ф. **Җыр башы.** Шигырьләр. № 5.

Әхмәтҗанов Рәшит. **Бишташ.** Поэма. № 4.

Җиһангирова Ш. **Давылларга каршы.** Шигырьләр. № 3.

## БАЛАЛАР ӨЧЕН ШИГЫРЬЛӘР

Корбанов Р. **Сабан туенда.** Шигырьләр. № 6.

Миңнуллин Р. **Кунакка килегез!** Шигырьләр. № 11.

Низамиев Р. **Кояш кайчан йоклый?** № 4.

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Арсланов Н. **А. С. Пушкиннан яңа тәрҗемәләр.** № 1.

Карабаев М. **Тулган ай.** Шигырьләр. № 11.

Кудаш С. **Робагыйлар.** № 11.

Насыйбуллин М. **Дуслык көче.** № 12.

Нәҗми Н. **Париж өстендә.** Шигырьләр. № 6.

Парпара А. **Ватан турында уй.** Шигырьләр. № 11.

Семендер Ю. **Мәгърур имән кебек.** П. Хузангайның 80 еллыгына. № 1.

Сийг А. **Чүплек.** Шигырь. № 11.

Тельпугов В. **Якшәмбегә каршы төндә.** Хикәя. № 11.

Шугаев В. **Соңга калган яңгыр.** Повесть. № 12.

## ОСТАХАНӘ

Ахунов Г. **Киләчәк — һәркемнең үз кулында.** № 5.

Имамов В. **Таныш тыкрык.** Хикәя. № 5.

Хәсәнов М. **Читтә калмаска.** № 5.

Хөснияр З. **Сыңар канат.** Хикәя. № 5.

Сабитов Г. **Хикәя авторына ачык хат.** № 7.

Җиһангирова Ш. **Мәхәббәт бизмәне.** Хикәя. № 7.

## ЮМОР-САТИРА

Лерон Л. **Пародияләр.** № 6.

Нури З. **Китап лотереясы.** Шигырьләр. № 5.

Саттаров М. **Эштән чыгарылган түрә бәете.** Шигырьләр. № 6.

Сафиуллин Ә. **Иялэнеп киткәч...** Хикәя. № 6.

Хөснуллин Х. **Өченче теләк.** Фельетон. № 8.

### АЕК БУЛ — ЗАМАНГА ЛАЕК БУЛ!

**Аракы эчү, исерү һәм исерек башлар турында халык мәкальләре.** № 6.

Нури З. **Шигырьләр.** № 6.

## ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

### КПССның XXVII СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

Зарипов М. **Сигез сыер асраганчы...** № 5.

Ибраһимова С. **Безгә ничек хезмәт күрсәтәләр?** № 1.

Морозов Н. **Тау сыртларын кисеп...** № 10.

Рәхимов Ж. **Уңыш тылсымчысы.** № 8.

Сафин З. **Көч җитәрлек.** № 7.

Хәсәнов А. **Йөк атына — солыны күбрәк!** № 7.

Хәсәнов М. **Урман кайтавазы.** № 5.

### ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Виноградов М. **Үсеш юлыннан** (Балык Бистәсе районы). № 10.

Вәлиуллин Ж. **Ямьле Ык буйларында** (Мөслим районы). № 3.

Гәрәев И. **Үсештә, үзгәрештә** (Зәй районы). № 7.

Демидов А. **Борынгы Буләр җирендә** (Алексеевск районы). № 1.

Ефремов А. **Тау ягы** (Кама Тамагы районы). № 6.

Мортазин А. **Таулар биек** (Биектау районы). № 8.

Мәүлетхуҗин И. **Тарихы бай, киләчәге якты** (Баулы районы). № 2.

Мөбарәкҗанов Р. **Чирмешән буйлары ямьле** (Чирмешән районы). № 4.

Офицеров М. **Иделнең текә ярында** (Тәтеш районы). № 9.

Хәйруллов А. **Зөя буе йолдызлары** (Апас районы). № 12.

Яковлев А. **Кулләрдән — Иделгә!** (Лаеш районы). № 11.

Әхмәтҗанов Н. **Илһам чыганагы** (Актаныш районы). № 5.

### АЭС — ӘДӘБИ ПОСТ

Бәдретдинов Х. **Төеннәрне чишкәндә.** № 12.

Шәрифуллина Э. **Кабатланмас шәхес өчен.** № 9.

Әһлиуллин М. **Көрәш кискенләшә.** № 5.

### БЕЗНЕҢ ӘХЛАК

Баһаветдинов Ф., Вәлиәхмәтов Х. **Кем гаепле?** № 8.

Латыйпов Ф. **Нәфес баткагында.** № 1.

Латыйпов Ф. **Алдану.** № 5.

Латыйпов Ф. **«Дошман», «Демон» һәм башкалар.** № 9.

Таҗетдинов Э. Г. **Закон сагында.** № 7.

Шәрәфетдинов Д. **Яңа гадәтләр, яңа йолалар.** № 4.

* * *

Гафиятов А. **Алисә — дөнья чемпионы...** № 10.

Гыйсметдинов Д. **Польшага — дуслык күпере.** № 10.

Еники Э. **Касыймга сәяхәт.** № 11.

Рәхимов Ж. **Алмагачның алмасы.** № 6.

Тимбикова К. **Нигә сагынам икән?** № 10.

Шакир С. **Утлы еллар эзеннән.** № 2.

Юныс Р. **Ничек, Гата, барып җитәбезме?** № 7.

### ЖУРНАЛДА МӘКАЛӘ ЧЫККАЧ...

**«Безгә ничек хезмәт күрсәтәләр».** № 4, № 12.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Вәлиев М. **Учагың сүрелмиме?** № 5.

Вәлиев М. **Шигъри бушлык.** № 8.

Галиуллин Т. **Тарих һәм шагыйрь.** № 9.

Ихсанова Л. **Табигатькә һәйкәл.** № 6.

Кукушкин Р. **Гомер китабының битләре.** № 1.

**Яшьләр бәхәсләшә.** № 11.

**Өметләр аклансын!** Яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәк өстәл янында. № 4.

### БИБЛИОГРАФИЯ

Бакиров М. **Заман күзлегеннән карап...** № 10.

Бәширов Ф. **Тарих үзе шаһит...** № 12.

Галимуллин Ф. **Танышу дәвам итә.** № 9.

Лерон Л. **Йөрәктә ниләр бар?** № 5.

Миңнегулов Х. **Әдәбият тарихын өйрәнү юлында.** № 6.

Миңнуллин Ф. **Яңа сүзлек.** № 6.

Мәһдиев М. **Китап һәм тарих.** № 7.

Сабирҗанов Г. **Мәдәниятыбыз тарихы сәхифәләре.** № 10.

Таһиров И. **Бишенче елны уяндык таң белән...** № 11.

Урманчеев Ф. **Кадерлерәк була бара.** № 4.

Юсупов М. **Тукай турында яңа сүз.** № 4.

### КОНКУРСКА КИЛГӘН РЕЦЕНЗИЯЛӘР

Ахунов Г. **Нәниләр поэзиясендә яңа сулыш.** № 8.

Бәдретдинов И. Яшәү җаваплылыгы. № 6.
Баширов Ф. Әхлакый эзләнүләр. № 6.
Габиди Ә. Хыял ат канатында. № 6.
Гыйльманов Г. Шагыйрь сүзе бер була. № 5.
Дунай Ф. Гайрәт, акыл, гыйбрәт. № 2.
Зөлкарнәев Ф. Бөрене тамыр уята. № 7.
Нуретдинов Р. Вакытлар чиксез, гомерләр кыска. № 6.
Шәрипов Р. Ачык йөз. № 7.
Иң яхшы рецензиягә конкурс йомгаклары. № 12.

### ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Дунай Ф. Сөюнең сынаулары бар. № 5.
Зыятдинова Ф. Әйтер сүзе бар. № 8.
Шәрипов Р. Әкият чынлыгы. № 2.

### РЕПЛИКА

Рәхимов Җ. Шөбһәләнерлек булмасын! № 1.

## ТЕЛ ГЫЙЛЕМЕ

Хисамова Ф. Хәзинәдәниләр бар? № 6.

## СӘНГАТЬ

Иткина Ж. Рахлин могҗизасы. № 5.
Миңлебаев К. Төсләр балкышы. № 6.
Мәҗитова Г. Туплар атса да, музалар тынмады. № 10.
Салитова Ф. Театр һәм музыка. № 6.
Әйди Т. Заманнарга куелган һәйкәл. № 5.

## КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Алиш А. Очрашу. Шигырь. № 5.
Кәримуллин Ә. Станиславский хаты. № 8.
Мостафин Р. Абдулла Алиш белән очрашу. № 5.
Рәхимкулова М. Тукайга мәхәббәт белән. № 4.
Тәрҗеманов Җ. Профессор Г. Шәрәф шигыре. № 4.
Хисамов Н. XIII—XIV гасырларда Идел буе төрки поэзиясе. № 4.
Шәрәф Г. Шүрәле белән очрашу. Шигырь. № 4.
Яхин Ф. Кояш чыкты, нур балкыды... № 10.
Әхмәтҗанов М. «Таһир белән Зөһрә» дастаны. № 4.
Җамалетдинов Л. «Ак бүре»нең илгә кайтуы. № 8.

### ӘДӘБИ МИРАС

Габдрахман Әпсәләмов хатлары. № 10.
Госманов М. Кандалый мирасын барлау юлында. № 7.
Кандалый Г. Шигырьләр. № 7.
Насыйбуллин З. Без җаваплы. Шигырьләр. № 2.
Фәйзуллин Р. Хәтер. № 2.

### ИСТӘЛЕКЛӘР

Вәҗиева Җ. Остазыбыз иде... № 10.
Кудашев Г. Хәсән Туфан — студент. № 2.

* * *

Оренбургта культурабыз истәлекләре. №№ 4 — 12.

## ЮБИЛЕЙЛАР

### Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Абушаев Х. Г. Ибраһимов укыган иске мәдрәсәдә. № 2.
Акбиев С. Г. Ибраһимов һәм Дагстан халыклары әдәбияты. № 3.
Баттал С. Олы көрәш юлында. № 3.
Бәширов Г. Йолдыздай балкып. № 3.
Вәлиев К. Бер сорауга — бер җавап. № 3.
Г. Ибраһимовның В. И. Ленин белән очрашуына бәйле документлар. № 3.
Гыймадиев Ү. Г. Ибраһимов — «Чулпан» редакторы. № 3.
Еники Ә. Бер сорауга — бер җавап. № 3.
Зарипов М. Васыять. № 3.
Зәкиев М. Бер сорауга — бер җавап. № 3.
Зөлфәт. Ялга тыкрыгында. Шигырь. № 3.
Исхаков Б. Г. Ибраһимов һәм казах әдәбияты. № 3.
Исәнбәт Н. Остазыбыз иде. № 3.
Кадерле ядкарьләр. № 3.
Күренекле әдип, галим һәм җәмәгать эшлеклесе. № 12.
Мәһдиев М. Татарларда рәсем сәнгате һәм Галимҗан Ибраһимов. № 3.
Мөхәммәдиев Р. Тагын бер кат «Татар шагыйрьләре турында». Г. Ибраһимов тәнкыйтендә Г. Тукай. № 3.
Садыйкова С. Бер сорауга — бер җавап. № 3.
Сафиуллина Ф. Халыкчан һәм сурәтле тел. № 3.

Турдыев Ш. Г. **Ибраһимов һәм үзбәк әдәбияты.** № 3.
Хамматов Ш. **Г. Ибраһимов һәм М. Җәлил.** № 3.
Хатипов Ф. **Психологизм остасы.** № 2.
Хәйретдинов Р. **Олы юл башында.** № 1.
Хәсәнов М. **Зур талант, титаник хезмәт.** № 3.
Әгъзамов Ф. **Матбугат теоретигы һәм тарихчысы.** № 3.
Әйди Т. **И, кадерле як!** № 3.
Әхмәдуллин А. **Сәхнәдә яңа геройларга юл салганда.** № 3.
Әхмәтҗанов М. **Галимҗан Ибраһимовның автографлы китабы.** № 3.

К. ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Ганиева В. **Бер сорауга — бер җавап.** № 9.
Гыйззәт Б. **Яңа сәнгать өчен көрәштә.** № 9.
Ишморат Р. **Дустым һәм остазымны сагынып.** № 9.
Минкина В. **Бер сорауга — бер җавап.** № 9.
Шәрәфиев Р. **Бер сорауга — бер җавап.** № 9.
Әхмәдуллин А. **Ул кабызган утлар һаман янар.** № 9.
Җәләлов Х. **Бер сорауга — бер җавап.** № 9.

Җ. ВӘЛИДИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Вәлиди Җ. **Яшь йөрәкләр. Шигырьләр тирәсендә. Татар шагыйрьләре.** № 10.
Мөхәммәдиев Р. **Фидакарьләр фидакарьлек көтә.** № 10.

БАКЫЙ УРМАНЧЕГА 90 ЯШЬ

Арслан Н. **Тылсымлы аксакал.** № 2.
Биктимеров Ш. **Интернациональ рухлы рәссам.** № 2.
Бәширов Г. **Бәхетле иҗат.** № 2.
Еники Ә. **Мәгънәле яшәү.** № 2.
Исәнбәт Н. **Зур шәхесләрнең берсе.** № 2.

* * *

Алишев С. **Күренекле тарихчы һәм әдип** *(Г. Гобәйдуллинның тууына 100 ел).* № 6.
Ахунов Г. **Аналар бәхете** *(Р. Ишморатовага 70 яшь).* № 7.
Галимуллин Ф. **Изге ният белән** *(М. Хәбибуллинга 60 яшь).* № 12.
Галиева Э. **Абруйлы тәнкыйтьче** *(Г. Нигъмәтинең тууына 90 ел).* № 7.
Ганиева Ф. **Йөз яшьлекләр буыныннан Мәхмүт Галәү.** № 9.
Гатауллин Р. **Тормыш бизәкләре** *(К. Латыйпка 60 яшь).* № 5.
Гаффар Э. **Йөрәк хатере** *(Җ. Мостафинга 60 яшь).* № 5.
Госманов М. **Игелекле мирас** *(С. Вахидиның тууына 100 ел).* № 5.
Ихсанова Л. **Олы юлдагы маяклар** *(Г. Гобәйнең тууына 80 ел).* № 8.
Миңнуллин Р. **Балачак шагыйре** *(Б. Рәхмәтнең тууына 90 ел).* № 7.
Нуруллин И. **Киләчәк яктысында** *(М. Әмирнең тууына 80 ел).* № 4.
Нуруллина Р. **Тугрылык** *(Г. Кашшафның тууына 80 ел).* № 6.
Сабиров С. **Давыллы еллар җырчысы** *(Сиринның тууына 90 ел).* № 2.
Сабирова-Хәйдәрова Л. **Яшәү мәгънәсе** *(М. Юныска 60 яшь).* № 5.
Хуҗиәхмәтова Ф. **Яшьлек дәвам итә...** *(К. Тимбиковага 50 яшь).* № 10.
Шәрифуллина Э., Миңнуллин Җ. **Бүген дә хәрәкәттә** *(Ф. Туйкинның тууына 100 ел).* № 6.
Әбубәкеров Г. **Мәгариф каһарманы** *(Ш. Рамазановның тууына 100 ел).* № 12.
Әйди Т. **Дәртле, дәрманлы әдип** *(М. Хәсәновка 60 яшь).* № 11.

* * *

**Укучы сүзе.** № 10.
**Китаплар дөньясында.** №№ 1, 2, 6, 9, 10, 11, 12.
Рамазанов Т. **Эшчеме, галимме?** № 10.
**Культура тормышы көндәлеге.** №№ 1—12.
**Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары.** *(Р. Юныс, Н. Хәсәнов).* № 6.

* * *

**Шушма буйларында.** Фотохикәя. № 2.

## ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Вәлиева-Сөләйманова Г. **Болгар бизәкләре.** № 1.
Коробцова Л. **Алкаларда — күңел яктысы.** № 2.
Коробцова Л. **Яка чылбыры.** № 6.
Коробцова Л. **Беләзегем-йөзегем.** № 7.
Коробцова Л. **Көмешчеләр иҗаты.** № 10.
Цой В. **Әдипнең портреты.** № 3.
Цой В. **Чулпы җыры.** № 9.
Цой В. **Шанлы тарих елъязмасы.** № 11.
Шаһиева Р. **«Сөембикә кувшины».** № 4.
Шаһиева Р. **Хәситә.** № 5.
Шаһиева Р. **Челтәрле таҗка.** № 8.
Шаһиева Р. **Революцион сходка.** № 12.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Татарстан китап нәшрияты түбәндәге китапларны бастырып чыгарды:

**Галимҗан Ибраһимов.** Әсәрләр. 8 том. Төрки һәм татар теле буенча хезмәтләр (1910 — 1930). 432 бит. Бәясе 2 с.

**Галимҗан Ибраһимов.** Яз башы. Хикәяләр. 32 бит. Бәясе 5 т.

**Әхсән Баянов.** Язмыштан узмыш. Повестьлар. 512 бит. Бәясе 2 с.

**Шамил Бикчурин.** Тирән катлам. Роман. 336 бит. Бәясе 1 с. 50 т.

**Ибраһим Гази.** Әсәрләр. I том. Повестьлар һәм хикәяләр. 520 бит. Бәясе 2 с. 10 т.

**Рәдиф Гатауллин.** Мәхәббәткә — мәрхәмәт. Шигырьләр, җырлар, поэмалар. «Шигырь китапханәсе» сериясе. 320 бит. Бәясе 1 с. 50 т.

**Гариф Гобәй.** Замана балалары. Повесть. 366 бит. Бәясе 80 т.

**Мөдәррис Әгъләмов.** Киләчәккә кайту. Шигырьләр, балладалар, поэмалар. 176 бит. Бәясе 95 т.

**Мансур Вәлиев.** Үзәгең өзелгәндә. Новеллалар, повесть. 176 бит. Бәясе 30 т.

**Тәүфикъ Әйди.** Тылсымлы көч. Атаклы кешеләр турында очерклар. 192 бит. Бәясе 65 т.

**Кәшшаф Әмиров.** Шөгер моңнары. Пьесалар. 190 бит. Бәясе 80 т.

**Илдар Әхсәнов.** Ак дөнья. Шигырьләр. 80 бит. Бәясе 15 т.

**Харрас Әюпов.** Таң суы. Шигырьләр. 120 бит. Бәясе 45 т.

**Разил Вәлиев.** Ядкарь. Шигырьләр һәм җырлар. 144 бит. Бәясе 55 т.

**Илсөяр Ганиева.** Шигырьләр һәм җырлар. 96 бит. Бәясе 15 т.

**Гөлшат Зәйнашева.** Сара Садыйкова. Очерк. 144 бит. Бәясе 50 т.

**Рәшит Ибраһимов.** Алтын йолдызлы лачын. Документаль повесть. 128 бит. Бәясе 20 т.

**Рәисә Ишморатова.** Яшьлегем — гөлбакчам. Повестьлар һәм хикәяләр. 384 бит. Бәясе 80 т.

**Газиз Кашапов.** Язмышыңа ышан. Роман. 247 бит. Бәясе 1 с.

**Нәҗип Мадъяров.** Чәчәкле тугай. Балалар өчен шигырьләр. 56 бит. Бәясе 15 т.

**Шамил Маннапов.** Апрель авазы. Шигырьләр һәм поэмалар. 128 бит. Бәясе 70 т.

**Рөстәм Мингалимов.** Шигырьләр һәм поэмалар. «Шигырь китапханәсе» сериясе. 368 бит. Бәясе 1 с. 70 т.

**Роберт Миңнуллин.** Җәйнең яшел аты. Балалар өчен шигырьләр. 64 бит. Бәясе 20 т.

Мәкальләр һәм әйтемнәр. «Татар халык иҗаты» сериясе. 592 бит. Бәясе 3 с. 50 т.

**Зәет Мәҗитов.** Чыклы сукмак. Шигырьләр һәм поэмалар. 144 бит. Бәясе 80 т.

**Әмир Мәхмүдов.** Мәңгелек моң. Шигырьләр. 88 бит. Бәясе 30 т.

**Флүн Мусин.** Тормыш үзәненнән. Атилла Расих иҗаты турында очерк. 104 бит. Бәясе 15 т.

**Зиннур Насыйбуллин.** Гамьнәр илендә. Шигырьләр. 128 бит. Бәясе 70 т.

**Мәгъсүм Насыйбуллин.** Син — тикшерүче бит. Хикәяләр, повесть. 272 бит. Бәясе 65 т.

**Рашат Низамиев.** Яралы керпе. Балалар өчен шигырьләр. Рәсемнәр белән. 32 бит. Бәясе 10 т.

**Кояш Тимбикова.** Кышкы талпыну. Повестьлар. 382 бит. Бәясе 1 с. 50 т.

Туган як җыры. Шигырьләр. 200 бит. Бәясе 1 с.

**Равил Фәйзуллин.** Чишмәләр иле. Шигырьләр һәм поэма. 136 бит. Бәясе 70 т.

**Рафаил Төхфәтуллин.** Кечке бакча. Хикәяләр һәм повестьлар. 224 бит. Бәясе 95 т.

**Ренат Харис.** Ант суы. Яңа шигырьләр һәм поэмалар. 128 бит. Бәясе 70 т.

**Рахмай Хисмәтуллин.** Дөньяга көлеп чык. Балалар өчен шигырьләр. 40 т. Бәясе 10 т.

**Нурмөхәммәт Хисамов.** Бәрәкәтле чишмәләр. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. 152 бит. Бәясе 25 т.

**Мизхәт Хәбибуллин.** Туган йорт. Шигырьләр. 62 бит. Бәясе 10 т.

**Мәхмүт Хәсәнов.** Язгы аҗаган. Роман. 608 бит. Бәясе 2 с. 30 т.

**Илдар Юзеев.** Тургай чәчәге. Хикәяләр, иҗат турында очерклар, тормыш һәм әдәбият турында уйланулар. 184 бит. Бәясе 80 т.

*Якындагы кибетләрдә табылмаса, соратып алдыру өчен адреслар: 420057, г. Казань, ул. Октябрьская, 18. Магазин «Книга — почтой». 420084, г. Казань, ул. Баумана, 19. Книжный магазин, отдел «Книга — почтой».*

# РЕВОЛЮЦИОН СХОДКА

Дистәләрчә еллар дәвамында Совет Татарстаны сынлы сәнгать осталарының берничә буыны мактаулы бурычны хәл итүдә — юлбашчыбыз В. И. Ленин образын сынландыруда актив эшләп киләләр. Әйтергә кирәк, республика рәссамнары тарафыннан әлеге җаваплы теманы, илебез тарихына караган мөһим сәхифәләрне чагылдыруда байтак кына тормышчан сюжет һәм образлар иҗат ителде, традицияләр хәзинәсе баетылды...

Татарстан ленинианасы, Ильичның яшьлегенә яисә татар халкының киләчәген хәл итүдәге тарихи роленә мөрәҗәгать итеп, Ленин һәм Татарстан арасындагы тарихи бәйләнешләрне сәнгать телендә калку итеп сурәтләде. Лениниананың шушы ике тармагы, үсә һәм кристаллаша барып, татар халкы тарихындагы сыйнфый көрәш катламнарына үтеп керә, СССР халыкларының туганнарча гаиләсендәге социаль һәм рухи үсеш маякларына йөз тота: Н. Фешинның «В. И. Ленин портреты» (1918), Л. Фәттаховның «Ленинның ТАССРны төзү турындагы Декретка кул куюы» (1950), В. Скобеевның «Г. Ибраһимов һәм М. Вахитов Ленин янында» (1977); И. Зариповның «В. И. Ленин» (1981) картиналары һ. б.

...Кайнап торган Казан университеты. Сходка. Ульяновның революцион юлга аяк басуы. Харис Якуповның «Казан студентлары. 1887 ел» дигән ифрат зур панносы белән очрашканда, без нә шул кайнар көннәр сулышын тоябыз. Әсәр авторның «Пролог» исемле мәгълүм картинасындагы теманың үсеше рәвешендәрәк кабул ителә. Ләкин монда рәссам тагын бер мәсьәләне хәл итә: панно атаклы сходка булып узган актлар залын бизәү өчен эшләнгән. Шушы бурычны үзәктә тотып, картина ерактан карау, ягъни пространствоның вакыт агышы белән өртелгән тулаем бөтенлеген күзаллау мөмкинлегенә корылган. Үзенең рухы белән ул монументаль, төсләр тәэссоратны көчәйтүгә хезмәт итә, фреска һәм бизәкләр дивар сәнгате кануннары нигезендә уелган.

Бу хезмәт — тарихи материалларны, архив кәгазьләрен, шул елларның фоторәсемнәрен өйрәнү, вакыйгада катнашучыларның кием үзенчәлекләреннән алып тантана һәм мәһабәтлек билгесе итеп куелган люстрага хәтле барлык детальләрне җентекләп үзләштерү нәтиҗәсе дә.

Композициянең алгы сызыгында — реакцион режим вәкилләрен, иске карашлы укытучы һәм инспекторларны ике яклап кысрыклаучы студентларның тыгыз, тере ташкыны. Ярсыган-әсәрләнгән йөзләр балкышы тамашачының игътибарын шушы агым тирәнлегенә, вакыйганың идея-кульминацион үзәгенә тартып ала. Капма-каршы көчләр кисешкән урталыкта массаларның көч һәм ихтыярын үзендә туплаган Володя Ульянов басып тора.

Картинаның киеренке сулышы, җанлы пантомима, ыгы-зыгылы атмосфера, вертикаль шәмнәр һәм урындыкларның кырыс ритмга берләшүе, ал, кызыл, алтынсу, яшькелт-зәңгәр төстәге җылы һәм ачык буяуларның шәмәхә-кара төстәге тоннар белән чиратлашуы, яшьлекнең куәтен гәүдәләндерүче тере, эмоциональ бизәкләр,— болар барысы да капма-каршы басып торган көчләрнең килешмәүчәнлеген ассызыклауга хезмәт итә. Төп фикерне гипербола рәвешендә әйтергә тырышу картинадагы психологик үткерлекне көчәйтүгә, каһарманнарның тормышчанлыгына зыян китерми, киресенчә, аның сәнгатьчә яңгырашын көчәйтә.

Х. Якуповның бу әсәре Татарстан сынлы сәнгатендә хаклы рәвештә күренекле урын алып тора.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның
фәнни хезмәткәре.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казан дәүләт университеты каршында Володя Ульянов һәйкәле.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотосы.

# КОНКУРС НӘТИҖӘЛӘРЕ

1986 ел башында журналыбыз битләрендә рецензияләргә ачык конкурс игълан ителгән иде. Конкурска күп кенә кызыклы рецензияләр алынды һәм аларның бер өлеше 1986-87 еллар дәвамында журнал битләрендә басылып та чыкты.

Конкурс шартлары буенча, алынган әсәрләргә объектив һәм тулы идея-эстетик анализ ясаган, тирән эчтәлекле һәм композицион яктан камил булган рецензияләр җиңүче дип табылды.

Аларның авторларына түбәндәге бүләкләр бирелә:

I бүләк (200 сум) — **Галимҗан Гыйльмановка** — «Шагыйрь сүзе бер була» исемле рецензиясе өчен (1987 ел, 5 сан)

II бүләк (150 сум) — **Әхмәт Сәхаповка** — «Кемнәр алар «һәм башкалар»?» исемле рецензиясе өчен (1986 ел, 8 сан)

II бүләк (150 сум) — **Фәез Зөлкарнәевка** — «Бөрене тамыр уята» исемле рецензиясе өчен (1987 ел, 7 сан)

III бүләк (100 сум) — **Фаяз Дунайга** — «Гайрәт, акыл, гыйбрәт» исемле рецензиясе өчен (1987 ел, 2 сан)

III бүләк (100 сум) — **Рәниф Шәриповка** — «Ачык йөз» исемле рецензиясе өчен (1987 ел, 7 сан).

ЖЮРИ

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)